# казан утлары

3

МАРТ · 1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**3**

МАРТ
1970

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Ә. РӘШИТОВ. Иптәш Ленинга хат. Шигырь . . 3
Л. ДМИТЕРКО. Ленин җилләрне яраткан. Шигырь . . . 4
Ю. МАЦЯВИЧЮС. Аның исеме. Шигырь . . 5
Н. САБА. Син яшисең шәрык йөрәгендә. Шигырь . . . 6
Д. СОКОЛОВ. Дус. Хикәя . . . . . . . . 7
С. ДАНГУЛОВ. Изге теләк . . . . . . . . 12

ПОВЕСТЬ, ПЬЕСА, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

Г. МӨХӘММӘТШИН. Йөрәктәге эзләр. Повесть . . . 22
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Эшең юк... Хөрлектән башлана... Дөньяда һәрбер нәрсә... Зур кеше... Яу-дауларны күргәннәр күп... Кадер... Хак сүз... Әти эшләгән җирләр бу... Йөгереп, уйнап... Бәлки син... Күктә — яшен. Этюд. Шигырьләр . 67
Р. ИШМОРАТОВА. Яшьлек канат җәйгәндә. Пьеса . . . 71
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Фал китабы. Поэма . . 101

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Бәхет үз кулыбызда . . . 113

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. ХАЛИТ. Киләчәккә карап . . . . . . . . 124

БЕЗ УТКӘН ЮЛЛАР

Т. ГАЛИУЛЛИН. Азатлык һәм гуманизм поэзиясе . . . 140

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

**В. ХАКОВ.** Әдәби тел хәзинәсенең кыйммәтле истәлеге . . . . . . . . . . . . . . . 151

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

**Й. ИСӘНБӘТ.** Җыр өйрәтте мине хер яшәргә . 158

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

**Г. ЗӘЙНАШЕВА.** Кәкүк. Очерк . . . . . . 161

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

**Ф. НАСЫЙРОВ.** Барысы да хәтердә . . . . 172

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

**З. КӘРИМОВА.** Нәриман Нәриманов белән очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . 177

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ХИСМӘТУЛЛИН.** Фатих Кәрими . . . . 180

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 182

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Ф. ХӨСНИ.** Кара кофе. Хикәя . . . . . . 183

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189


**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**


Редакциянен адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Баш редактор **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Кәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**



Производствога бирелде 5/I-1970 ел. Басарга кул куелды 13/II-1970 ел. ПФ 04018. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87446 экз. Заказ С-2. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1970 ел.




# ЛЕНИН—
# БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

**Әхмәт Рәшитов**

## Иптәш Ленинга хат

Сиңа ода язмыйм,
Иптәш Ленин,
Син алардан миллион кабат өстен...
Сәлам итеп тик юлларга телим
Күкрәгемнән ташкан рәхмәт хисен.

Бик аз күреп әткәм-әнкәм назын,
Мин,
Тугызда ятим калып,
Үстем,
Көтә-көтә илнең зәңгәр язын,
Хәсрәт дәрьясыннан сулар эчтем...
Дөнья әле һаман кырыс, каты,
Чор катлаулы,
байтак моңы-зары;
Җиде җир астыннан теш ыржайтып,
Сүгенә, әнә, атом бомбалары.

Тук башаклы алтын кырларымны
Солдат итекләре таптамакчы,
Минем коммунистик иманымны
Ят идеялар белән тапламакчы.
Иптәш Ленин!
Усал җилләр исә,
Көрәш авыр,
Юллар сикәлтәле,
Күңелләрне кайчак сагыш кисә,
Ә шулай да җирдә яшәү ямьле:
Як-ягымда туган тугайларым,
Баш очымда җитез спутниклар,
Хак эш өчен газиз башын салган
Әтием
Каберендә тыныч йоклар.

Туар таңнар җиңү вәгъдә итә,
Зур адымнан
Алга атлый илем.
Юлбашчы да безгә син,
Юлдаш та,
Син гел безнең сафта, иптәш Ленин.

Син гел иптәш безгә,
Син гел тере —
Сәламлисең җирнең һәрбер көнен;
Ил түрендә яңгырый бәхет җыры:
— Рәхмәт сиңа,
Рәхмәт, иптәш Ленин!

## Любомир Дмитерко.

Украин шагыйре

## Ленин җилләрне яраткан...

Җилләрне яраткан,
үрләргә менгән ул,
Ә аста шаулаган
киң Идел дулкыны.
Еракта, юнәлеп
җир шары артына,
Яшеннәр яшьнәгән...
Күзәткән ул шуны.

Каршыда һәр нәрсә
селкенә, кыймылдый,
Туктаусыз хәрәкәт:
болытлар күчена.
Эссе көн һавасын
салкынча иткәнгә
Соклана яшь күңел
җәйге җил көченә.

Ул күкләр күкрәвен
тыңлаган тын калып,
Ташкынлап акканда
караган суларга.
Россия язмышын,
туачак көннәрне,
Йолдызлы очышны
күргән ул шуларда.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

**Юзас Мацявичюс.**
Литва шагыйре

# Аның исеме

Уйланам мин, аның бөек исемен
Кушып булыр иде безнең чорга —
Заманның ул кан тибешен тойды,
Нигез салды шушы гасырга.
Таладылар безне оятсызларча,
Ә соңыннан,
төкерделәр күзгә!
Ул шуларга каршы яу күтәрде
Һәм кайтарды
хыялларны безгә.
Кайтты хыял — кеше горурлыгы,
Кайтты олы иҗат куанычы,
Ирек тойгылары кайтты җанга —
Биекләрдә безнең юллар очы.
Уятты ул безне ачышларга:
Безнең акылларда — йолдыз нуры.
Һәм агылды хәзер безнең өчен
Бу җиһанның серле микромиры.
Уйланам мин, безнең чорыбызга
Аның исемен кила бирәсе,
Ләкин куркам, икеләнеп куям —
Кимсенер күк аның хатирәсе.
Хыялларын, уен, фикерләрен,
Кешеләргә мәхәббәтен бары
«Минеке» дип әйткән бөек Ленин —
«Безнеке» дип әйткән калганнарын.
Усал көрәшләрнең гасыры дип
Атады ул безнең заманны.
Революция һәм иминлек өчен
Җавап бирә һәрбер кеше җаны.
Шуңа күрә без яшәгән бу чор,—
Катлаулы һәм фаҗигале заман,—
Безгә яңый атом үлеме белән,
Янар вулканнарга ул ошаган.
Ул вулканның уянмавы өчен
Без җаваплы җиһан алдында —
Имин яшәү өчен Ленин каршында без
Җаваплырак
мең кат
тагын да.

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәсе

**Нифон Саба.**

Ливан шагыйре

## Син яшисең шәрык йөрәгендә

Ленин!
Данлы эшең белән
дөнья бизәп,
кешелек бәхете булып
син яшисең.
Җир йөзендә
Ирек нуры чәчеп,
көчле күкрәү булып
син яшьнисең.
Кеше аңына
өмет рухы биреп,
шәрык йөрәгендә
син яшисең.
Дошман белән көрәшкәндә,
безгә
ышаныч һәм сүнмәс
дәрт өстисең.
Халыкларны дөрес юлдан әйдәп,
син чакырасың барырга
гел алга...
Бер максатка туплап кешеләрне,
Хакыйкатьне ярып саласың аңга.
Ленин!
Акылың һәм зиһенең —
заманыбыз горурлыгы бүген.
Дошман булып
дошманнарың хәтта
көчеңне танырга мәҗбүр синең.

ӘДХӘТ СИНЕГУЛОВ тәрҗемәсе

## Даниил Соколов

# ДУС

хикәя

Свердлов яшәгән бүлмәнең ишек төбенә килеп туктагач кына Владимир Ильич башын күтәрде. Колак салып беркавым тыңлап торгач, иптәп кенә ишек шакыды да әкрен генә атлап бүлмәгә керде. Шифаханәдә генә була торган кырыс тынлык, борынны ярып кергән әчкелтем дару исе, Яков Михайловичның элеккечә кәнәфидә түгел, урын өстендә ятуы, аның эчкә баткан күзләренең йомык булуы — болар бар да Владимир Ильичның борчуын тагы да көчәйтте, өметен какшатты, онытырга тырышып йөргән хәвефле уйларын яңадан кузгатып җибәрде.

Яков Михайловичның караваты янында тәбәнәк кенә өстәл тора, өстәлдә кичәгедән калган «Правда» газетасы, язылып бетмәгән мәкалә һәм кәгазьләр тутырылган папка ята иде. Карават башында озын кара шнурга бәйләнгән сөяк кысалы пенснэ асылынып тора. Хәле авыр булуга карамастан, Яков Михайлович бүген дә эле эшләмәкче булып караган, ахрысы.

Ленин авыруның сары коелган ябык йөзенә карау белән йөрәгенең сыкрап китүен тойды. Авырып яткан арада Яков Михайловичның йөзе танымаслык булып үзгәргән, аның пенснэсез, менә шулай күзләре йомык килеш күренгән йөзенә өр-яңадан ияләшергә кирәк иде.

Кинәт авыруның керфекләре дерелдәп куйды. Эчкә баткан яңакларына тир бәреп чыкты. Яков Михайлович башын борды һәм, күгәргән салынкы күз кабакларын көч-хәл белән күтәреп, Ильичка карады, сөенечтән йөзе яктырып киткәндәй булды. Якын дусын юатып аның нидер әйтәсе килде, әмма шундук хәле китте, елмаерга ниятләгән иреннәренә уңайсызлану, талчыгу галәмәтләре генә чыкты. Яков Михайлович чак кына күзләрен йомып, хәл җыеп алды, аннары тагын Ленинга сүзсез генә карап тора башлады; әйтәсе сүзләрен әйтә алмыйча, гаҗизләнеп, кара янган озын ябык бармакларын кыймылдатты. Владимир Ильич аның бите янына ук иелде. Авыруның күзләре кинәт кайнарланып ялтырый башлады, сулуы ешайды — хәле тагы да авырайды булса кирәк.

Ленин, урындыктан торып, профессор янына килде һәм аның кулларыннан тотып:

— Әйтегез әле, доктор, авыруга берничек тә ярдәм итеп булмыймыни? — дип сорады.

Профессор, ни дияргә дә белмичә, җилкәсен җыерып, кулларын җәеп җибәрде. Аның чәче алынган зур ак башы җилкәләре арасына

кереп бетте диярлек. Шул кыяфәтендә ул, эшләгән эшен тагын бер кат барлап чыккандай, күзен йомган килеш:

— Күрелмәгән бер генә чара да калмады, Владимир Ильич, бер генә чара да,— диде.

Владимир Ильич аяк очларына гына басып яңадан карават янына килде. Яков Михайловичның йөзе кәгазь төсле ак, башы, хәлсезләнеп, мендәрдән бер якка авышкан иде. Ленин авыруның маңгаеннан үпте, ябыгып беткән кайнар кулын учы белән каплап, бераз вакыт шулай, авыруның эчке халәтен тыңлагандай, тып-тын басып торды, аннан әкрен генә караватянынnan китеп барды. Авыру янында утыручыга басынкы тыныч тавыш белән:

— Кадерле иптәш, авыруның хәле турында миңа өзлексез хәбәр итеп торыгыз,— диде. Профессор белән баш кагып кына саубуллашты да ипләп кенә ишекне ачып чыгып китте.

Авыру турындагы борчулы уй аның күңеленнән китмәде, ләкин ул үзен-үзе җиңеп, эшенә тотынды. Килгән телеграммаларны тиз-тиз генә карап чыкты, аларны өстәлгә тезеп салып, төрен төргә аерды. Почтаны карап бетергәннән соң, өстәл тартмасыннан язулы кәгазь алып, укый башлады, берничә урынга карандаш белән нидер билгеләп куйды. Аның йөзе караңгыланып, кырысланып китте.

Кабинетка Фотиева килеп керде. Керде дә, еламаска тырышып, әкрен генә:

— Яков Михайлович вафат... Егерме минут моннан элек...— диде. Бу хәбәрне ишетү белән ул Владимир Ильичның йөзе агарынып китүен күрде, көч-хәл белән генә атлап бүлмәдән чыгып китте.

Владимир Ильич, бөтен гәүдәсендә әллә нинди бер авырлык тойган хәлдә, утырган кәнәфиендә өстәлгә таба борылды, нишләгәнен белештермичә, өстәлдә яткан буш папканың тасмаларын бәйләгән булды, аннары терсәкләре белән өстәлгә таянып, сул кулының учы белән йөзен каплады, бармак очлары белән чигә тамырларына басты. Шул хәлендә ул байтак вакыт хәрәкәтсез утырды; авыр уйларыннан аны алгы бүлмәдә кемнеңдер кычкырып сөйләшә башлавы гына айнытып җибәрде.

Владимир Ильич урыныннан торып, тәрәзә янына килеп басты. Урамда ябалак кар ява. Көн караңгыланганнан-караңгылана бара, шул сәбәпле чиркәү манаралары тәрәзә янында ук булып күренәләр. Яфрак хәтле бер кар бөртеге тәрәзә турысында әйләнеп-тулганып торды да, атылган шикелле югарыга очып, күздән югалды. Тоташ яуган кар пәрдәсенең югарыгы өлеше караңгылыкка чумды, җил иркенә эләгеп талпынышкан кар бөртекләре дә каралган сыман булып тоела башлады.

Владимир Ильич Кремль ишек алдына чыкты. Салкын, буранлы иде. ВЦИК бинасына бик зәү кәгазь ябыштырылган. Аңа тигезле-тигезсез зур кара хәрефләр белән Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе Яков Михайлович Свердловның үлүе турында язылган иде.

Большевиклар партиясенең VIII съездына килгән делегатлар кәгазь янында туктыйлар, озаклап-озаклап ВЦИКның хәбәрен укыйлар, аннары, суык җилдән качарга теләгәндәй, бөкрәя төшеп, битләрен яка эченә яшереп, китеп баралар.

Кремль эчендә мәйданнар караңгылыкка чумган. Фонарь элеңгән урыннарда гына җирдә түгәрәк ут яктысы төшкән, якын-тирәдәге биналарны бары тик шул урыннарда гына шәйләргә була. Җилдән тузынып яуган кар өскә оча, ут яктысында бөтерелә, лампочкалар янында кабынып-кабынып киткән шикелле ялтырый.

Ленин кулларын кесәсенә тыккан һәм, яка эченә кар бөртекләре эләкмәсен дип, якасын күтәргән көе, караңгыда бик озак хәрәкәтсез басып торды. Электр чыбыкларының сагышлы гүләве белән кушылып, җилнең улавы бермә-бер көчәя иде. Тәненә салкын йөгерүдән ул кал-

тыранып куйды. Иннәрне басып торган кайгылы авыр уйлары урнына күңелен тирән сагыш биләп алды. Аннары ул яңа яуган кар көртләрен ера-ера бүлмәсенә кайтты.

* * *

Беренче карашка кабинетта барсы да элеккечә, бернәрсә дә үзгәрмәгән сыман иде. Стена буендагы шыплап китап тутырылган шкафлар да шул ук, китап тулы әйләнгеч-этажеркалар да элеккечә кәнәфинең ике ягына куелган көе, өстәл өстендәге лампа да һәрвакыттагыча тоныклыкына яктырта һәм өстәл өстенә иелеп эшенә чумган Владимир Ильич та һәрвакыттагыча үзгәрешсез күренә кебек. Гадәтенчә, хәрәкәтләре дә төгәл, җитез; күз карашы да шул ук — тыныч, уйчан һәм сөзеп карый торган; ә менә аның күзләрендәге ягымлы тирән яктылык, күзләреннән бөркелеп торган җылы нур сүрелгәндәй булган. Шуңа күрәдер инде, кабинет эчендә хөкем сөргән тынлык тагы да тирәнәйгән, кырысрак булып калган кебек тоела; бу тынлыкта каләм кыштырдавы да, келт-келт итеп сәгать йөргәне дә аермачык ишетелеп тора.

Шушы кырыс тынлыкны бозып, кабинетка Лидия Александровна килеп керде. Керде дә, Яков Михайловичның искереп, шомарып беткән, сүтелгән почмаклары кулдан тегелгән портфелен дәшми-тынмый өстәл өстенә китереп куйды һәм бер сүз әйтми чыгып китте.

Владимир Ильич аркасын кәнәфигә терәп утырды, күзләрен йомды. Аның арыган йөзе хәзер генә йокыга талган кешенеке төсле тыныч, борчусыз булып калды.

Кабинетка Сталин белән Дзержинский керделәр.

Владимир Ильич алар белән сүзсез генә исәнләште, уң кулы белән ишарәләп, утырырга урын күрсәтте һәм тыңларга әзер икәнен белгертте.

Дзержинский папка эченнән листовкалар алып өстәлгә куйды. Ленин, аларны укырга керешкәнче, узган ел март башында яшерен үткәрелгән Бөтенсебер конференциясенең материалларын Сталинга алып бирде, шуннан соң гына листовкаларны кулына алды. Һәркайсын бик зур дикъкать белән укып чыккач, башын күтәреп, Дзержинскийдан:

— Шуның белән беттеме? — дип сорады.

— Бетмәде шул! Болар белән генә бетсә иде дә бит,— диде Дзержинский, басынкы әкрен тавыш белән.— Петроградтагы эсерлар завод эшчеләрен забастовка ясарга чакырып кына калмаганнар, алар су кудыргыч башня белән электр станциясен шартлатырга да әзерләнгән булганнар икән. Аларын вакытында туктатып калдык, ә менә листовкаларны таратып өлгергәннәр.

Ленин аркасын кәнәфигә терәп утырган хәлдә, күзләрен бер ноктага төбәгән килеш, Дзержинскийның сүзләрен дикъкать белән тыңлый. Дзержинский тавышын көчәйтми дә, әкренәйтми дә тыныч кына яңа хәбәрләрне сөйли:

— Колчакның һөҗүмгә күчүе, Уфаның акларга эләгүе сәбәпле, эсерлар Идел буе шәһәрләрендә генә түгел, Орелда, Брянскида да кузгала башладылар. Була-нитә калса, восстаниеләрне бастыру чаралары күрелде. Көньякта Махно Бердянск белән Дебальцево станциясен алган. Анысы да Кубань буендагы генералларның активлашуын чамалаган булса кирәк.

Дзержинский хәбәр иткәннәрнең барсын да Ленин кечерәк кенә бер кәгазь битенә язып куйды. Аннары, урыныннан торып, кабинетны сүзсез генә бер-ике мәртәбә әйләнеп килде. Сталин белән Дзержинский дә дәшмәделәр. Мәрхүм турында берсе берсүз әйтмәсәләр дә, һәркайсының уе тора-тора аңа әйләнеп кайта иде. Бу бүлмәдә хөкем сөргән тынлык,

алар арасыннан шулай вакытсыз китеп барган якын дусларына тирән хөрмәт билгесе иде.

Владимир Ильич өстәл янына килде, кәгазьләр арасыннан Реввоенсовет тәкъдимнәрен табып алды, Дзержинский белән Сталинга укырга бирде. Аларның укып чыгуларын көтеп торды да:

— Монысына ни диярсез? — диде.

Сталин ашыкмый гына урыныннан торды, карта янына барды, көнчыгыш фронты сызыгындагы нәни кызыл әләмнәргә бер сүз әйтми шактый вакыт карап торганнан соң, яңадан өстәл янына әйләнеп килде дә, һәр сүзенә басым ясап:

— Идел аръягына чигенү планы — черек план ул. Ул планны телгә алырга да ярамый. Монысы бер. Икенчедән, төп ударның юнәлешен төгәл билгеләргә кирәк, ягъни, без үзебезнең стратегия линиясен булдырырга тиешбез, ул линия дошман планыннан чыгып төзелгән булмаска тиеш,— диде.

Сталин сүзен тәмамлады. Дзержинский аның сүзләрен дөрес дип тапты һәм шунда ук бу план белән килеште.

Ленин кайгысын җиңәргә тырыша, ул гадәтенчә тыныч, сабыр күренә, бары йөзенең сулган, агарынган булуы гына аның дулкынлануын сиздерә иде.

— Моның белән килешми булмый. Көньякта контрреволюция ныгып алганчы без Колчакны җимерергә тиешбез, шушы хәлне моңарчы аңламаган кешеләр булуы минс гаҗәпкә кәлдыра. Колчакны Саратов янында түгел, Уфа янында тар-мар итәргә кирәк, моның өчен тиз арада яңа группа төзәргә, аның үзенең планын булдырырга һәм шул группаның җитәкчесе итеп,— Ленин, киңәш бирмәсләрме дигән төсле, бераз туктап торды да тиз генә фикерен тәмамлады,— бу группаның командиры вазифасын Фрунзега тапшырырга кирәк. Карар кабул ителгәннән соң, боларның барысы турында газета аркылы халыкка хәбәр итәргә кирәк; бүген эшләргә мөмкин эшне иртәгә калдыруның үкенечле буласын һәр эшче, һәр крестьян белеп торырга тиеш.

Сталин белән Дзержинский киткәч тә әле Владимир Ильич, уйларына бирелеп, байтак вакыт картага карап торды. Яков Михайловичны югалту кайгысы яңадан йөрәген уеп алды.

Яков Михайлович әле күзләре йомылган, ябыгып беткән, хәлсез күкрәкле, озын чандыр бармаклы булып, авыру кыяфәтендә, әле шат күңелле, ачык йөзле булып, гәүдәсенә караганда бик калын яңгыраган тавышлы булып, исән-сау хәлендә күз алдына килде. Аның хәтта ашыгып атлап йөрүе ишетелер төсле тоела башлады.

Уйлана-уйлана ул картадан Нарым өлкәсен, Турухан өлкәсен эзләп таба. Енисейдан Мәскәүгә кадәр коточкыч озын юл бит! Ә Себер нинди зур! Менә шулай. Россия дөньяны өр-яңадан кору хокукын үз улларының канын түгеп, хәсрәт чигеп яулап алды. Кем соң хәзер Свердловны алмаштырыр? Кем тыңлашер аның белән? Россиягә аның бик-бик кирәк чагы иде бит!

Владимир Ильич календарь битен ертып алмакчы булып кулын күтәрде, әмма иләмсез зур, кара 16 лы санын күрү белән кулын кире алды; бераз уйланып торганнан соң түшәмдәге утны сүндерде; Яков Михайловичның портфелен алып, өстәл лампасын кырыйгарак тартып китерде дә, бер аягын бөкләп кәнәфигә утырды һәм, бик нык бөкрәеп, портфельдәге кәгазьләрне карый башлады.

«Партиянең VIII нче съезды» дип язылган материаллар салынган папка эчендә Яков Михайловичның озын кара шнурлы пенснэсе дә ята иде. Ленин кәнәфигә сеныбрак утырды һәм таң атканчы урыныннан кузгалмады. Аның дәү маңгаендагы җыерчыклары тагы да тирәнәйде, тагы да күбәйде. Әмма кайгыдан авыраеп, каралып калган йөзендә бер генә мускулы да селкенмәде.

* * *

Я. М. Свердловны 18 нче март көнне жирләделәр.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының ашыгыч рәвештә чакырылган утырышында ясаган чыгыш, мәрхүмне күмгән чакта сөйләгән речь, өстәвенә съезд алдыннан булган бик мәшәкатьле, борчулы ике көн Владимир Ильичны тәмам арытты. Аның йөзеннән кан качты, ул ябыгып китте. Әмма съездны ачарга ул барысыннан да алдарак килеп житте.

Залның һавасы салкын, дымлы, утлар тонык яна иде.

Үзләре белән бергә салкын иртәнге, шау-гөр килеп ишектән делегатлар керә башлады, аларның төрле телләрдә сөйләшүе залга җан кертеп җибәрде, күңеллерәк булып китте. Соры шинельле Россия бүген илнең язмышын ачыкларга җыела иде. Делегатларның күбесе съезд беткәннән икенче көнендә үк фронтка, бер өлеше дошман кулына эләккән өлкәләргә китәчәк. Нык адымнар белән каты-каты басып йөрүче, җилдә янган, тәвәккәл һәм ачык йөзле кешеләр иде бу, аларның күбесенә көн саен диярлек үлем белән күзгә-күз очрашырга туры килә иде.

Владимир Ильич сәхнәнең түр почмагында торган кечкенә генә өстәл янында утыра. Өшер дәрәҗәгә житеп туңган бармакларын сулышы белән җылыта-җылыта, тау елгасының ерак гөрелтесе сыман булып ишетелгән халык шаулавына колак салып, ул съездны ачып җибәрү алдыннан әйтәчәк кереш сүзенең планын яза.

Залдагы рәтләр тыгызланып, шинельгә шинель елышып утырган делегатлар белән тула башлады. Ленин башын күтәреп залга карады һәм үзенә-үзе җавап биргәндәй:

«Партия сафында менә дигән кешеләр үсеп чыга. Свердлов кебек кешеләр большевиклар арасыннан гына чыга торгандыр. Аның ишеләр аз дисеңмени әле? Тормышны үзгәртеп кору бурычы йөкләнгән партия сафында гына шундый титаннар туа ала бит!» — дип уйлады.

Съезд ачуны Ленинга тапшырдылар. Тып-тын залда Владимир Ильичның аяк тавышы ишетелүгә, сәхнәдә нык гәүдәсе күренүгә, бөтен зал урындыкларын дөбердәтеп, өермәләнеп, солдат шинельләреннән торган соры стена булып, аягүрә басты һәм, шатлык-сөенечен яшермичә: «Яшәсен Ильич!» — дип остазын һәм юлбашчысын сәламләде.

Ленин барган җиреннән туктап калды. Зал бераз тынычлангач, трибуна янына килеп басты.

— Иптәшләр!

Аның тавышы ачылып бетмәгән, көч җыеп өлгермәгән иде әле. Тонык кына янган ут яктысында Ленин беренче рәттә утыручыларның йөзен күреп алды һәм, гадәтенчә, чыгыш ясаган чакларының беренче минутларындагыча, бу юлы да залдан үзенә таба агылган җылы дулкынны сизде.

Съездны ачканда, беренче сүзе итеп, Ленин Яков Михайлович Свердловны искә алды. Сөйләгән уңайга кулын трибунага куелган лампага таба сузды. Залдан караганда лампа югарыга таба күтәрелгәндәй күренә, әйтерсең лә, ул Ленин юлбашчылыгында баручы эшче-крестьяннарның юлын яктырту өчен шулай югары күтәрелгән иде.

Беренче рәттә Надежда Константиновна утыра. Ильичның сүзләрен яхшырак ишетү өчен, аны яхшырак күрү өчен ул әледән-әле башын күтәреп карый. Ильичны мондый кыяфәттә аның әле беркайчан да күргәне юк иде. Ленинның тәвәккәл тавышында, эчке нур белән балкыган йөзендә һәм кулын яктыга таба сузып, алга омтылган гәүдәсендә ниндидер җиңелмәс көч һәм бөеклек сизелеп тора [1].

**Ш. МАКСУДОВА** тәрҗемәсе

---

[1] Хикәя Даниил Соколовның «Чувство жизни» (Яшәү хисе) дигән китабыннан (1960, Харьков) алынды.

**Савва Дангулов**

# ИЗГЕ ТЕЛӘК[1]...

Ленинның бөтен фоторәсемнәре арасында монысы аеруча истә кала. Күзләре уйчан-кырыс, чак кына сагышлылар. Рәсемгә карагач, Ильич күп еллардан бирле белгән кешесе белән ихлас күңелдән озаклап сөйләшеп утырган яки музыка тыңлаган булса кирәк дигән тәэсир туа... Фоторәсем егерменче елның ноябренда төшерелгән. Нәкъ шул көннәрнең берендә ул Горький янында булып, Бетховенның «Аппассионата»сын тыңлый. «Искиткеч музыка...» дигән сүзләр шул көнне әйтелгәннәр. Бәлкем, фото Владимир Ильичның үзенә дә охшагандыр. Ул аны Хаммерга шуңа күрә бүләк итмәдеме микән? Артына инглизчә сүзләр язылган:

«Иптәш Арманд Хаммерга Вл. Ульяновтан (Лениннан).
10. XI. 1921».

Хәтеремдә, без Владимир Ильич кабинетыннан чыккач, Хаммер тәрәзә буена килде.

— Менә нәрсәсе кызыклы аның,— диде ул, фоторәсемне карый-карый, Мартенска мөрәҗәгать итеп,— монда: «Иптәш Хаммерга» дип язылган бит. «Иптәш капиталист Хаммерга» дигән шикеллерәк яңгырый бит бу, шулай түгелме.— Американы елмаеп куйды.— Премьер-министр әфәндене ничек аңларга икән? Әллә шаяртумы бу?

Ләкин Мартенс Хаммерның елмаюын күрмәмешкә салынды.

— Шаярту? Юк, ник алай булсын ди? Бәлкем, чынлаптыр. Якын күрү галәмәте булырга мөмкин.

— Әйе, әйе. Якын күрү галәмәте,— диде Хаммер, җанланып китеп, һәм Мартенска карады. Иртәгә башланачак зур сөйләшүләрдә Мартенс совет ягыннан вәкил буласы иде. Хаммер Мартенсны беләме соң?

Мартенс Америкада безнең тәүге илче иде, әмма ул гадәти илче түгел. Ул Ак йортта тантаналы тынлык шартларында президентка ышаныч грамоталары тапшырмады... Мартенсның киңәшчеләре һәм секретарьлары юк иде,— бөтен секретарьлар һәм атташелар даирәсе вазифаларын ул бер ялгызы башкарды. Ул дәүләт секретаре белән сәгатьләп әңгәмә дә алып бармады. Ул илче булып торган заманда илчелек машиналарының Ак йортка тантаналы агышы да, президент сараенда очрашу да, бөек социалистик дәүләт илчесен кабул иткәндә

---

[1] «Сукмак» исемле китаптан. Кыскартып бирелә.

президентның елмаюы да, хәтта президентның дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы сүзе дә һичкайчан гамәлгә ашмый торган хыял итеп карала иде.

Менә Америка газеталарының тәүге белдерүләре: «Нью-Йоркта Советлар Россиясе вәкиллеге эшли башлады, вәкиллек башында — ниндидер бер Людвиг Мартенс дигән кеше». Нәкъ шулай диелгән дә: «Ниндидер бер». Людвиг Карлович Мартенсның, гәрчә чыгышы буенча немец булса да, рус интеллигенты икәнен, Петербург «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы» буенча Ленинның күптәнге һәм турылыклы көрәштәше, Лондон съездында катнашкан кеше, механик, математик, уйлап табучы (кул пулеметын, формасы белән оригинал булган очу аппаратын ул уйлап тапкан), эшлекле коммунист икәнен ул чакта кем дә булса белдеме икән әле... Мартенс Советлар иленең Америкадагы вәкиле булып торган унсигез ай эчендә аны шундый атакага тоттылар ки, андый атаканы дипломатия тарихы, мөгаен, белми дә торгандыр. Бу атака совет илчелеге, ул чакта йөртелгәнчә, «Россия совет хөкүмәтенең АКШтагы бюросы» бинасына полиция һөҗүме белән бетте. Совет илчесен эзәрләүгә каршы протест белдерү өчен Медисон-сквер-гарденда егерме мең пролетарий җыелды. Дәүләт департаменты Мартенска Америкадан китәргә тәкъдим итте.

...Мәскәүгә кайтып төшкән көнне үк Мартенсны Ленин янына чакырып алдылар, дидәләр миңа. Кремльдә сүзнең нәрсә хакында барганлыгын әйтүе кыен, ләкин, һичшиксез, ул чакта Ленинны бик борчыган зур мәсьәләгә, ягъни концессияләр турындагы мәсьәләгә тукталмый калынмагандыр.

...Бу юлы коридорга чыга торган ишеккә барып җитмәстән, Ленин көтмәгәндә туктап калды һәм, күзләрен люстра утыннан саклау өчен кулын каш өстенә куеп, миңа карады.

— Ә, Дмитрий Дмитриевич, сезне очратуым әйбәт булды әле,— диде ул, кулын һаман каш өстендә тотып.— Миңа Мартенс шалтыратты. Ул «Люкс»та туктаган һәм Америка белән эшлекле элемтәләр турында хат проектын тәмамлап килә, ләкин монда бер проблема килеп туды...— Ул кулын каш өстеннән алды.— Мартенс хатка Америка газеталарында чыккан мәкаләләрне теркәргә теләгән иде, әмма аларны тәрҗемә итәргә аның өлгермәве мөмкин. Кыскасы, булышыгыз әле аңа! Бездә аның телефоны бар, бүлмә номеры да бар шикелле... Хәер, берниндн звонок та кирәкми! Кремльдән ике генә адымда ич ул — биш минуттан анда булырсыз.

...Мин егерме беренче елның көзенә хәтле Мартенсны кабат очратмадым. Ул чорда аның эше бик тыгыз булды. Менә берничә ай инде Мартенс Главметалл житәкчесе. Шундый югары илчелек постын әле генә калдырып киткән дипломат Мартенс беренче карашта аның үткәннәренә һичнинди мөнәсәбәте булмаган эшкә билгеләнгән. Әмма бу беренче карашта гына шулай күренә иде. Мартенс Америкада үзенчәлекле илче иде бит. Ул заманда яшь Советлар республикасы өчен әһәмиятле булган бөтен нәрсә аның өчен дә әһәмиятле иде: Россия өчен тракторлар, берочтан шул тракторларга механизмнар юнәтте, яшь совет дәүләте белән эш йөртергә теләгән купецлар һәм завод хуҗалары белән мөнәсәбәткә керде (утыз миллион долларлык контракт төзелде, кечкенә сумма түгел бу!), верфьларда, тегү фабрикаларында, элеваторларда, терлек сую урыннарында булды, һәммәсен күрергә һәм белергә теләде, кулы һәм күзе белән үренеп, бөтенесенә барып җитәргә тырышты. Бу эшнең нәтиҗәләре дә бик тиз күренде: Россиягә «фордзоннар», хирургия инструментлары, тегү машиналары һәм үз тормышының бүгенге көнен һәм бигрәк тә иртәге көнен планлаштырган чакта илебезгә бик кирәк дип саналган күп кенә башка нәрсәләр агылды... Мартенс, илчелектән китеп, Главметалл председателе булгач, аны Совет — Америка

мөнәсәбәтләре кызыксындырмый башлагандыр инде дигән уй Мартенсны белгән американлыларның башына да килмәде.

Мартенсны Мәскәүдә очратуы кыен, ул бүген — Курскида, иртәгә — Урал тавы артында була, ә Мәскәүгә кайтса, күбрәк вакытын — безнең тәүге карлыгачыбыз булган электроцентраль төзелә башлаганнан соң узган ике елны — Каширада уздыра, диләр иде миңа. Әйе, Кашира безнең тәүге карлыгачыбыз иде һәм, бәлкем, шуңа күрә дә ул Ленинның сөекле төзелеше булгандыр.

Ленин «вак-төякләр агымының» зур эшләр башкару өчен кирәкле үтә кыйммәтле вакытны алу ихтималын бик яхшы аңласа да, бу кагыйдәне ул Каширага карата кулланмады. Кашира өчен чуен коярга кирәкле коксны да, тышламаган тимер чыбыкны да, реостатларны да Ленин үзе юнәтә иде.

Минем алда барган сөйләшүдә дә сүз Кашира турында булды.

Ленин Троицк капкасы ягыннан килә иде. Аның шәһәрдә эшкә кагылышлы очрашуы булган һәм ул, машинасын җибәреп, җәяү кайтырга уйлаган, күрәсең. Ул көн иртәсе аяз һәм салкынча иде.

Ленин, бара торган җиреннән туктап, кояш төшкән болынга карап торды. Мондый кояш сентябрьдә генә була. Күренеш бик тә садә төсле иде: үлән дә кояш, ә Ленин ят бер нәрсә күргән шикелле, күз дә алмыйча гел шуларга карап торды.

— Минемчә, ул эшенә яки өенә кайтып бара,— дигән сүзләрне ишеттем мин янәшәмдә генә.— Шулаймы?

— Мин сезгә кичә кич белән шалтыраттым.— Ленин, туктап, Мартенска карап торды. Күзләре көләч, беркадәр кысыла төшкән, чырае, бүтән чакларда кичкә таба булганча, агарынмаган — димәк, ул бүген әйбәт йоклаган.— Америкада шундый... Хаммер дигән бер кеше бар.— Ленин Мартенска текәп карый, нәрсә әйтер икән дип көтә, дәшми.— Россиядән киткән кеше бугай?

Мартенс уйга кала.

— Хаммер? Нинди Хаммер булыр икән ул. Нью-Йоркта медикаментлар һәм химия препаратлары компаниясеме?

Ленинның йөзе яктырып китә. Кинәт Мартенсның Хаммерны бар дип тә белмәве ачыла калса, күңелсезрәк булыр иде, әлбәттә.

— Бик дөрес, Людвиг Карлович! Әмма Юлий Хаммер түгел, ә аның улы Арманд. Ул безнең больницалар өчен Семашкога хирургия инструментлары бүләк иткән, диләр! Ләкин мин ул хакта түгел.— Ленин яңадан уйга калды һәм китеп барды.— Бүтәне әһәмиятлерәк: безнең концессияләр турындагы тәкъдимебезгә Хаммерның җавабы бар, дөрес, аның җавабы бик үзенчәлекле: — Ленин елмаеп куйды.— Уралда чыга торган кыйммәтле асылташларга алмашка бер миллион пот икмәк бирмәкче...

Мартенс бармак очлары белән мыегын сыпыра — шатлыклы сабырсызлык билгесе бу.

— Тәүге концессионермы, Владимир Ильич?

— Тәүге...

Бер сәгатьтән соң мин Мартенсны Троицк капкасы төбендә очраттым — ул Ленин яныннан кайтып килә иде...

— Ленин Хаммер белән булган ситуациянең инде очына чыккан һәм аның үз планы бардыр, дип уйламыйсызмы сез? — дип сорадым мин.

Ленин белән аралашкан еллар эчендә мин аның бу сәләтен белдем: без әле проблеманы өйрәнәбез, шартларга яраклашырга һәм үз урыныбызны табарга тырышабыз гына, ә Ленин инде вакыйгаларның ничек барачагын һәм безгә үзебезне ничек тотарга кирәклеген аермачык белә иде.

— Әйе, бар, әлбәттә,— диде Мартенс, тиз генә ризалашып.— Сөйләшкәндә ул үзенең планын миннән яшермәде: «Хаммерны Уралдагы зур һәм житди эш белән кызыксындырырга кирәк»,— диде.

Мартенс кулын чигәсенә куйды.— Бәлкем, асбест...

— Асбест? — дидем мин гаҗәпсенеп. Дөресен әйткәндә, ул чакта минем асбест дигәннәрен белүем бик чамалы иде.

— Әйе, асбест шул, асбест — таш җепселле тау житене бит ул,— диде Мартенс.— Безнең Уралдагы ише асбест дөньяның бер жирендә дә юк. Табигать үзе эрләгән җеп — нык та, эластик та, ә иң мөһиме — утка чыдам. Мең ярым градуссыз эреми!

Мин аның сөйләгәнен тыңладым да уйлап куйдым: «Ул, мәйтәм, чын инженер. Әнә ничек матур итеп сөйли бит ул асбест турында — шигъри дә, төгәл дә».

— Ул договор безнең өчен файдалымы?

— Хәтта бүтән яклардан файдасы ул чаклы зур булмаса да,— диде Мартенс,— безнең өчен Хаммер белән договор төзү факты үзе мөһим. Владимир Ильич әйтте: «Американлыларның концессиягә барулары күрсәтү... политик яктан мөһим»,— диде.

...Ул Себердәге зур елгаларда гидростанцияләр, кырларда тракторлар һәм электр сабаннары, электр һәм пар көче белән эшләтелә торган заводлар күрде. Гәрчә Ленин концессияләр белән зур кыенлыклар килеп чыгуын яхшы аңласа да, аның өчен концессияләр дә хуҗалыкны аякка бастыруның нәтиҗәле чарасы иде. Сүз уңаенда шуны да әйтик: хәзер генә мин Арманд Хаммерның Россиягә килеп, өченче көн, Мартенс белән бергә, Уралга китеп барганын ишеттем.

Мартенс миңа Уралдан кайткан көнне шалтыратты: иртәгә көндез Ленин Кремльдә Арманд Хаммерны кабул итәчәк, һәм кичке алты сәгатьтән соң синең Халык Комиссариатыннан китмәвеңне үтенде. Дөрес, Хаммер Россиядән киткән кеше һәм русча белә, ләкин әңгәмә барышында текстларны тәрҗемә итәргә кирәк булуы ихтимал,— диде.

Мин, югарыга күтәрелеп, гадәттә килүчеләр Ленинның кабул итүен көтә торган секретарьлар бүлмәсе ишеген сагаеп кына ачтым. Тәрәзә буена кояш та, яңгыр да алмый торган кара-соры тупас йон френч кигән Мартенс баскан, ә бүлмәнең аргы башында, икенче бер тәрәзә янында тагын бер кеше тора. Костюмының иркен һәм шул ук вакытта килбәтсез булуыннан, аның ян кесәсеннән газета, ә күкрәк кесәсеннән кызыл карандаш чыгып торудан, мин аның американлы икәнен танып алдым. Мартенс күзе белән миңа үзе янындагы урындыкта урын күрсәтте һәм, мин килеп утыргач, миңа «Таймс» газетасын сузды, анда Арманд Хаммерның Уралга баруы турындагы хәбәр зәңгәр карандаш белән уратып алынган иде. Мин Хаммерны күзәттем: ул һаман тәрәзәгә карап тора. Арсенал стенасы буенда яткан туплар Хаммерда нинди ассоциация тудырганнардыр, анысын әйтүе кыен, әлбәттә, ләкин Хаммерның чырае караңгы иде.

— Нәрсә китерде икән аны Россиягә,— дидем мин, Мартенска күтәрелеп карап.— Нәтиҗәле эшчәнлеккә сусаумы, файда эзләүме, әллә яңа сукмакны сынап караумы: янәсе, нинди кешеләр икән ул кызыллар, алар белән эш майтарып буламы-юкмы?..

Мартенс мыек очларын сыпырып куйды:

— Мин дә шуны уйладым — монда да, тегендә, ягъни Уралның су баскан шахталарында йөргәндә дә уйладым.— Мартенс карашын әкрен генә Хаммерга күчерде — ул әле һаман, тәрәзә буена баскан килеш, тышта яшен уйнавын күзәтә иде.— Билгеле, гәрчә ул фантазиясез үк кеше булмаса да, аны исәп-хисап йөртә һәм, мин уйлыйм, ул, үз коллегаларының күбесеннән аермалы буларак, безгә ышана, безне ул үзен

уңайсыз хәлдә калдырмаслар, ягъни утыртмаслар, дип саный. Ул үз позициясен, әйтергә кирәк, теоретик яктан нигезләргә тырышты: аның безгә ышанычы безнең эш тәҗрибәбездән һәм түләргә сәләтле булуыбыздан бигрәк, безнең интеллигентлыгыбызга һәм әдәплелегебезгә нигезләнгән. Ул шулай әйтте дә: «Сез барыгыз да идея кешеләре, ә бу иң беркатлы һәм шуның белән бергә намуслы кешеләр категориясе — аларны алдыйлар, ә алар үзләре беркайчан да алдамый...»

Безне Ленин янына чакырдылар.

Курәм. Хаммер оялып кына елмаеп куйды, аннары, батыраеп киткәндәй, шатланып һәм кыяр-кыймас, ишекне ачты.

Ленин укый торган кәгазеннән кинәт кенә аерыла алмады, маңгаен учы белән әкрен генә сыпырды да чигәсенә җиткәч туктап калды — бу арыганлык галәмәте иде,— аннары, өстәлгә таянып, авырлык белән генә торып басты.

— Исәнмесез, исәнмесез, рәхим итегез.— Ул өстәл артыннан чыгып, кунак каршысына атлады.— Ничек барып кайттыгыз? Безнең Урал охшадымы соң?.. Минем анда булганым бармы, дисезме? Булдым, хәтта сез хәзер булган җирләрдән бик күп ерактарак та булдым. Әйе, Урал таулары артында, әйе, Минусинск янында... Себер, Себер...— Ул, күн кәнәфи күрсәтеп, утырырга тәкъдим итте — хәзер аның үткәннәрне хәтеренә төшерергә теләге юк иде.— Үтенәм сездән. Димәк, Алапаевск?

Ленин, әңгәмәдәшен сынарга теләп, карашын аңа текәде.

Хаммер күтәрелеп карады да Ленинның үзенә төбәлгән карашы белән очрашты.

— Ленин әфәнде,— диде ул, ихтирам белән,— мин үземнең кем белән сөйләшүемне бик яхшы аңлыйм һәм сезне артык борчырга һич тә җыенмыйм.— Хаммер ян кесәсеннән чамасыз зур форматлы куен дәфтәре чыгарып,— ул пиджак кесәсенә ничек сыйгандыр, алла белсен,— тиешле битен ачты да, учы белән ашыкмыйча гына сыпыргалады.— Мин үземнең лояль икәнемне совет ягы вәкилләренә исбат иттем инде...

— Без моңа югары бәя бирәбез,— диде Ленин якты чырай һәм шат күңел белән. Әңгәмәдәше белән эчкерсез контакт урнаштырырга теләгән чакларында гел шулай эшли иде ул.

— Минем фирмам һәм мин сезнең ышанычыгызга исәп тота алабызмы? —дип сорау өчен мин боларның бөтенесен хәтергә төшерергә кирәк дип таптым...

— Әйе, аныгы шулай,— диде Ленин, елмаеп. Әңгәмәдәше аның күңелен күтәрә башлады.

— Киләсе адымны атлап, концессиягә контракт төзегәнче,— вак кына хәрефләр белән язганнарына төшенү өчен, Хаммер дәфтәрен якынрак китерде,— шуны әйтим: мин үземә файдалы, кабатлап әйтәм, файдалы булган тәкъдирдә генә договор төзеячәкмен, мин бу хакта мистер Мартенска да әйттем.

— Мин бу мәсьәләдә алдатмыйм, Хаммер әфәнде,— диде Ленин, елмаеп,— сөйләшүдә җиңелчә генә ирония булырга тиеш дип уйлаган булса кирәк ул.— Бәлкем, без дустыбыз Мартенстан контрактның эчтәлеген бәян итүне үтенербез?

— Хуп, бик хуп.

Мартенс яктыгарак күчеп утырды. Ул әкрен генә сөйләде, сүзнең бик әһәмиятле нәрсә турында барганлыгын шуның белән ачык күрсәтте. Әйе, компания договорны гамәлгә ашыруның беренче елында сиксән мең пот асбест бирергә һәм концессиянең бишенче елына аны йөз алтмыш мең потка җиткерергә өстенә ала. Техник шартлар үзгәрүгә бинаән, предприятиенең эшләп чыгару программасы биш ел саен яңадан каралырга тиеш. Билгеле, концессиядә хезмәт турында совет законнары

гамәлдә була, шуның белән бергә, эшчеләрнең кимендә яртылашы Россия республикасы гражданнарыннан тупланырга тиеш. Концессионерлар Дәүләт банкысына илле мең доллар акча кертәләр — шул сума белән договорның үтәлеше тәэмин ителә. Чыгарылган асбестның уннан бер өлеше концессия өчен түләү сыйфатында Совет дәүләтенә кала. Совет ягы предприятиене сатып ала ала, әмма бу хакта концессионерлар алты ай алдан кисәтеп куелырга тиешләр. Сатып алу бәясе концессиянең узган елгы тулай продукция кыйммәте күләмендә булачак.

Мартенс укып бетерде дә:

— Владимир Ильич, сез еллык түләү суммасына игътибар иттегезме? — диде.

— Ун процент,— диде Ленин салкын гына, бу сүзләргә үзенең мөнәсәбәтен күрсәтергә теләмичә.

— Хаммер әфәндегә әйттем мин,— диде Мартенс,— бу монарчы әле бер кайчан да күрелмәгән түбән процент, дидем. Сүз унбиш процент турында барырга мөмкин.

Хаммер кашларын җыерды.

— Мин бит асбестны Каролина штатына Джорджия штатыннан түгел, бәлки җир читеннән кайтарачакмын,— диде Хаммер, күтәрелеп карамыйча гына.— Безнең компаниядә транспортка мондый зур чыгымнарның булганы юк иде әле.

— Компания унбиш процент бирсә дә, аның табышы бик зур булачак... Шулай бит, Хаммер әфәнде.— Теләгән биш процентны яулап алу өчен Мартенс тагын бер мөмкинлектән файдаланырга булды. Инженер—эш кешесе, шуңа күрә ул сүзне дәвам иттерү өчен әле нинди дә мөмкинлек калганын аңлый иде.

— Ләкин сез шуны да аңлагыз, Мартенс әфәнде, мин бу мәсьәләне бер ялгызым гына хәл итмим бит,— диде Хаммер.— Мин компаниянең вәкиле генә. Ә бу аның фикере...

Ленин кулын күтәреп куйды, әйтерсең лә, шуның белән әңгәмәдәшенә бәхәсне туктатуын аңлатырга теләде.

— Яхшы, без риза,— диде Ленин, Мартенска мөрәҗәгать итеп.— Ә безнең инглизчә текст бармы, Дмитрий Дмитриевич? — дип сорады ул, миңа карап.— Договорның төп статьяларын инглизчә уку урынлы булыр, бәлкем?..

Мин Мартенс кулыннан договор текстын алдым да статья артыннан статьяны тәрҗемә итәргә керештем.

Хаммер дәфтәренең тиешле битен эзләп тапты да имән бармагын шуның өстенә сузды. Текст укыла барган саен Хаммерның имән бармагы кәгазь бите буйлап түбән таба шуышты — Хаммер контрактның һәр санын дәфтәрендәге тиешле язмалар белән бик җентекләп чагыштырып барды.

Инде кабинет бусагасында Ленин белән саубуллашканда, Хаммер, адымнарын әкренәйтеп, тартыныбрак әйтеп куйды:

— Премьер-министр әфәнде, әлеге биш процент безнең мөнәсәбәтләргә киртә булмастыр дип ышанам?

— Һич тә киртә булмас, Хаммер әфәнде.— Ленин, күзләрен күңелле кыса төшеп, Хаммерга карады.— Эш дөньясының кануннары безгә дә мәгълүм! — Аның тагын да көчлерәк итеп әйтергә, мәсәлән, «капитализмның кануннары» дияргә дә нияте булгандыр булуын, әмма ул тыелып калды.— Сәүдәләшү барышында төрле сүзләр булырга мөмкин, әмма ул беткәч инде барлык сүзләрдән бер генә сүз кала: контракт...— Күзгә ташланган канәгатьләнү белән, ул Хаммерның кулын кысты.— Большевикларның контрактларны үти белүләрен күрерсез әле сез, Хаммер әфәнде.

— Мин сезгә ышанам, премьер-министр әфәнде,— диде Хаммер. Хәзер аның кәефе әйбәт иде.— Сүз уңаенда мин сездән шуны сорарга теләгән идем...— Ул тукталды да аптырабрак Ленинга карап куйды.— Әлеге эш... Безнең эш киләчәктә дә сезнең игътибарыгызга лаек булыр микән?

— Әйе, әлбәттә, Хаммер әфәнде.— Ленин елмаеп куйды.— Гафу итегез, сез шикләнәсезме әллә?

Хаммер, иреннәрен кысып, уйга калды.

— Юк, шикләнү түгел бу...— Ул тәрәзәгә карады.— Анда... Эш, әйтергә кирәк, дәүләт функциясе түгел, анда бизнесны бизнесмен ясый.

Ленин, кулларын җәеп, көлеп җибәрде:

— Әйе, әйе, бик дөрес әйтәсез: бизнесны бизнесмен ясый. — Ул көлүен дәвам иттерде.— Әмма монда, Советлар илендә, бизнесны дәүләт ясый!

— Рәхмәт сезгә, премьер-министр әфәнде, бу бик мөһим. Димәк, безнең өчен сез башкара торган эш ихтирам йөзеннән генә түгел икән?

— Һич тә ихтирам йөзеннән түгел, Хаммер әфәнде, бу минем вазифам!

— Рәхмәт сезгә, премьер-министр әфәнде!

— Рәхим итегез, Хаммер әфәнде.

Без кунакны озаттык та Ленин кабинетына кире кердек. Ленинның арганлыгы тәмам бетте. Капиталист белән бу очрашу (әйтерең бармы: тәүге концессионер!) аны дәртләндерде, җилкендереп җибәрде.

— Сәүдәнең башланып китүе ягыннан бу договорның әһәмияте зур булыр, әмма менә нәрсәсе мөһим...— диде Ленин.— Безнең йөкләмәләрнең факттагы үтәлешенә бик нык игътибар итәргә кирәк.— Ул «безнең» һәм «факттагы» дигән сүзләрне басым белән әйтте.— Өчләтә саклык һәм тикшерү чаралары күрергә кирәк. Сез мине аңлыйсызмы: өчләтә! Боерыкларга ышанып ятмаска! — Ул Мартенс янына килде.— Людвиг Карлович, шәхси җаваплы итеп каты куллы, төпле кеше билгеләргә һәм тикшерергә кирәк... Без концессионерларга илтифат күрсәтергә тиешбез! — Ул «илтифат күрсәтергә» сүзенә дә басым ясады.— Ә инде Хаммерның әлеге биш процентына килсәк... Юк, юк, мин сезне аңлыйм, Людвиг Карлович! Сезнең урында булсам, мин, бәлкем, тагын да катырак куяр идем. Безгә сәүдәләшә белергә кирәк! Ләкин бу очракта тәвәккәллек урынсыздыр, бәлкем. Шулай да, тәүге концессия, тәүге. Аннары... изге теләктә булу әһәмиятле...

Ленин өстәге утны яндырды да карта янына килеп басты. Ул Екатеринбургтан төньяк-көнчыгышта Алапаевскины эзләп тапты, аннан Владивостокка, аннары Архангельскига хәтле булган араны күз күреме белән үлчәп алды. Аннан соң Себергә күз төшерде — аның үткен һәм житез күзләре хәзер Алтай далаларына, салкын Байкал күле сулары аша еракларга текәлде. Аннары карашы бик аз гына вакытка Енисей буендагы киңлекләрдә, Березовое бусагасыннан чак кына түбәнрәк, Шушенское авылы тирәләрендә тукталып торды, соңыннан Уралга, әмма хәзер инде сырттан төньяк-көнчыгышка түгел, бәлки көньяк-көнчыгышка таба күчте...

— Безгә валдан биш процент бирәләр!.. Биш!..— Ул картадан борылды, чырае карангы иде.— Ишетәсезме: биш, ә без унны таләп иткән идек! Юк, монда Совет властеннан тиеннәр сәүдәләшеп алырга теләк кенә түгел, бәлки Совет властена дошманлык исе аңкый...

Ул ачулы иде.

...Ноябрьда инде Мартенс миңа, бодай төялгән беренче пароход Нью-Йорктан чыга, дип хәбәр итте. Билгеле, бер миллион пот икмәк безнең өчен бик аз. Әмма төп нәрсә башкада иде: безгә икмәк озатуы

белән Хаммер безнең арада эшне яхшы ният белән алып барырга теләвен аңлаткандай булды.

Хаммерның бу сыйфаты Ленинга охшады, һәм ул Америка концессионерлары белән договорның үтәлешен игътибар белән күзәтеп барды. Бөтен якларга — Халык Комиссарлары Советы, Хезмәт һәм Оборона Советы буенча урынбасарларына, Тышкы сәүдә халык комиссариатына, Главметаллга Лениннан хатлар китеп торды: «Америкалы Хаммер концессиясенә игътибар итүегезне үтенәм. Бу концессия буенча безнең йөкләмәләрнең бик нык һәм төгәл үтәлүен күзәтергә, гомумән бу эшне игътибар беләнрәк карап барырга кирәк булыр...» «Безгә 1 000 000 пот икмәк сату турындагы договорның әһәмияте гаять зур»...

Ленинның эшлекле фикерләр белән тулы кыска гына (өч-биш юллык!) язулары көч бирәләр, ашыктыралар, рухландыралар, борчып торалар иде.

...Эссе көннәрнең берсендә мин Кремльдә Мартенсны очраттым. Әле генә Халык Комиссарлары Советы утырышы беткән һәм ул үзенә, Яна мәйданга кайтырга ашыга иде.

— Дмитрий Дмитриевич,— дип дәште ул миңа,— Хаммер Мәскәүгә килгән, шушы көннәрдә аны Ленинның кабул итү ихтималы бар...— Әйтелгәне җитәр, мине калганын аңлады дип булса кирәк, ул туктап калды.

— Сүз шул чакта минем анда булырга тиешлегем турында бармыймы?..— дип сораштыра башлаган гына идем, ул мине шундук кырт кисте:

— Нәкъ шулай, Дмитрий Дмитриевич!

Май башында мине Ленин янына чакырып алдылар. Кичке эңгер-меңгер, яңгыр явып тора. Халык Комиссарлары Советының тәрәзәләре ачык һәм тышта малайларның җыелып торган яңгыр суында чабышып йөрүләре ишетелә.

Без килеп кергәндә Ленин тәрәзә төбенә таянып, аста барган тамашаны тәрәзәдән күзәтеп тора иде. Ул безне килеп керү белән күрмәде, безгә таба борылып караганда күзләре көләч иде — күрәсең, ул әле генә көлгән.

— Сез тагын безнең кунагыбыз,— диде Ленин, Хаммерның кулын кысып.— Димәк, бөтен кыенлыкларга да карамастан, безнең эшләр алга бара...

— Әйе, әйе, Ленин әфәнде, кыенлыкларга да карамастан,— диде Хаммер.— Бу кыш Россия өчен җиңел булмады.

— Без кичергән авырлыклардан соң инде безгә берни дә куркыныч булып күренми. Ләкин ачлык, ачлык...— Шул урында Ленин тынып калды һәм бүлмәгә балалар тавышы кабат үтеп керде. Алар, бу тавышлар бик тә куәтлеләр иде, аларда тормышка мәхәббәт, сүнмәс шатлык һәм, иң әһәмиятлесе, кешелек дөньясының мәңгелеге яңгырый иде.— Бодай өчен рәхмәт сезгә, ул безгә бик вакытлы килеп житте. Шулай бит, Людвиг Карлович? — диде Ленин, Мартенска карап.

— Нәкъ шулай, Владимир Ильич.

— Хуш, хәзер инде, бер-беребезне белә башлаганнан соң, эшләр куәтлерәк барырдыр,— диде Ленин, җанланып китеп һәм кунакка мөрәҗәгать итеп өстәп куйды: — Ни хөрмәт күрсәтә алам мин сезгә?

Хаммер кесән дәфтәрен чыгарды: бу дәфтәр без аңарда көз көне күргәненнән дә зуррак иде шикелле. Аның Ленинга әйтергә теләгән бөтен сүзе бу юлы да дәфтәренә язылган. Концессия гамәлгә кереп бара иде инде. Россиягә инженерлар килде. Бүген булмаса иртәгә җиһазлар төялгән пароходның килеп житүе көтелә иде. Бәлкем, ул киткәндә тәүге асбест партиясен алып китәр. Әгәр жирле властьлар концессиягә ка-

рата игътибарлы булсалар, Петроградта порт администрациясе һәм Внешторг вәкиле... Гомумән, Ленин моның Совет дәүләте өчен әһәмияте нихәтле зур икәнлеген Петроград властьларына төшендерә алмасмы икән?..

Ленин, урыныннан торып, өстәл артыннан чыкты.

— Петроград властьларына дидегезме сез? — Аның борчылганлыгы чыраеннан күренеп тора иде.— Яхшы, хәзер без Петроградны телефонга чакырырбыз.— Ул аппаратныйга керә торган ян ишеккә таба юнәлде.

— Эшләргә мөмкин булганның...— диде Хаммерга, аппаратныйдан торып. Ишек япмаган иде.

Ленинның аппарат ручкасын әйләндергәне ишетелеп тора.

— Петроградмы? Телефонда Ленин... Әйе, сүз Хаммер концессиясе хакында бара! Хаммер әфәнде яки аның компаньоны Мишель әфәнде... Дөрес әйтәмме мин? Мишель әфәндеме? — дип сорый Ленин, Хаммерга мөрәҗәгать итеп; Ленин Хаммерның аны тыңлап торуына ышанырга тели, ул ишекне тикмәгә генә ачык калдырмады.

— Дөрес, Ленин әфәнде, минем коллегам Мишель.

— Язып алыгыз: Мишель. Арманд Хаммер әфәнде хәзер минем янда, мин аңа әйтермен: безнең Петроградтагы властьлар... Үзегезнең кузәтүегезне үтенәм... Һәрьяклап ярдәм итәргә...

Ленин үз урынына килеп утырды.

— Мин боларның бөтенесен кабатлыйм.— Ул аппаратныйга таба башын селки.— Мин аларны хәзер сезгә тапшырачак хатта кабатлыйм.

Ул блокнотын тартып китерә дә, беравык уйланып алганнан соң, күзгә бәрелеп торган җитез йөгереклек белән блокнот битен тутырып та өлгерә, аннары укып чыга һәм шундук (бу артык еш булмый) хат текстына төзәтмәләр кертә — башта берне, аннары икене, өчне. Аннан соң ул хатны бик җентекләп күчереп яза да бөкләп конвертка сала, ләкин конвертны ябыштырмый, әйтерсең лә ул Хаммерны, кирәк тапса, хатны укырга чакыра. Ленин Хаммер белән бергә ишеккә таба атлый — мондый шәрәф кунакларның барысына да тими, әлбәттә. Юк, юк, Ленин аңа җәһәт кенә күз төшереп ала, шул чак Ленинның күзләрендә хәйләкәр, үткен, җанлы чаткылар күренеп китә.

— Әгәр сезнең большевиклар белән килешү төзүгә ышанычыгыз булмаса, сез тәвәккәллек итмәс идегез бит, шулаймы, Хаммер әфәнде? Юк, уенсыз: тәвәккәллек итмәгән булыр идегез бит?

Хаммер куен дәфтәрен кесәсенә тыгарга азаплана.

— Тәвәккәллек итмәс идем! — ди ул, көлеп.— Тәвәккәллек итмәс идем, премьер-министр әфәнде!

...Ике атна да узмады, Мартенс белән безне, тревога сигналы белән диярлек, Кремльгә чакырып китерделәр.

Кичке унбер сәгать инде, шулай булса да Ленин кабинеты тәрәзәләрендә ярым караңгы саргылт ут яктысы тирбәлә иде. Мин Владимир Ильичның гадәттәгечә китап укыган яки газеталар караган вакытына туры килермен дип уйлаган идем, әмма мин Ленинның талчыккан кыяфәт белән ишекле-түрле йөргәнен күреп шактый гаҗәпләндем.

— Менә рәхим итегез, Хаммердан хат! — диде ул, өстәл өстен күрсәтеп.— Сез минем Питер белән сөйләшкәнемне хәтерлисезме, минем анда язган хатымны хәтерлисезме? Ә бөтенесен киресенчә эшләгәннәр! Питерны телефонга чакырдым. Бик әйбәтләп тыңлап карыйм әле менә үзләрен.

Ул аппаратныйга таба атлады. Пиджак чабулары җилләнде. Ул йодрыкларын бер йомарлады, бер ачты — ярсудан яңаклары тимгелләнеп чыкты. Өстәл кырыена кагылып китеп, эскәтерне җыерды — яшел сукно кабарып калды. Ул борылып карамады.

Ленинның кинәт-кинәт каты итеп аппарат ручкасын әйләндергәне ишетелеп торды — бер мәртәбә әйләндерде, ике, өч мәртәбә.

— Бүген миңа Арманд Хаммерның хатын күрсәттеләр, әйе, америкалы Хаммер, мин сезгә шуның турында язган идем! — дип бик әкрен генә әйткән сүзләрен ишеттек без аның.— Әйе, америкалы, миллионер улы, безнең өчен үтә файдалы концессияне беренче булып алган кеше!— Ленин пауза ясады, ул сабырлык саклап, эшнең асылын тыныч кына бәян итәргә тырышты.— Хаммер болай дип яза: минем хатка, әйе, әйе, минем Питерга сезгә җибәргән хатыма карамастан, Хаммерның коллегасы Мишель Внешторгта эшләүче һәм Питерда аны кабул иткән Беггенның тупаслыгыннан һәм бюрократлыгыннан зарлана...— Ленин, ачуы килеп, беравыкка тынып калды.— Мин Беггенның үзен болай тотуын Үзәк Комитетта куячакмын! Нинди хикмәттер бу, шайтан белсен! Миннән махсус хат булуга карамастан, бөтенесен киресенчә эшләгәнсез! Сездән бу хәлне махсус тикшерүгезне сорыйм!

Ул шундый ук зур-зур адымнар белән бүлмәгә килеп керде дә, язу өстәле янында туктамыйча, кабинетның аргы башына үтте, аннары, җәһәт кенә өстәл янына килеп, яшел сукноны тартып куйды да кырыс күзләре белән безгә карады.

Ул кичне Мартенс белән без иртә аерылыштык — ул Главметаллга ашыкты (чөнки төнлә белән Курскига китәсе иде), ә мин Кремльдә калдым.

— Ленин: «Үз юлбасарларыбызны кудык, ә читләрне чакырабыз»,— дип әйтте диде Мартенс, мин аны Кече сарайдан Троицк капкасына озаткан чакта.—...Кыскасы, мин Владимир Ильичны болайрак аңладым: «Дөньяда бер генә паспорт бар, аннан безгә килүче һәркемнән без шул паспортны янында йөртүен үтенәбез: ул паспорт — изге теләк...»

К. ГЫЙМАДИ тәрҗемәсе.

Газиз Мөхәммәтшин

# ЙӨРӘКТӘГЕ ЭЗЛӘР

ПОВЕСТЬ

Таштагы эзләр жуела,
Йөрәктәге эзләр — юк.

I

Юеш һәм караңгы август иртәсе иде. Тайга уртасында йокымсырап яткан шәһәр вокзалына, үр менгән ат шикелле еш-еш сулап, поезд килеп туктады. Вагон ишекләре ачылды, проводниклар күренде, алар артыннан төрле-төрле чемоданнар, капчык, төенчекләр күтәргән пассажирлар төшә башлады.

Уртадагы йомшак вагоннан, иң соңгы кеше булып, егерме ике — егерме өч яшьләр тирәсендәге озын буйлы, җаенкерәк битле бер егет чыкты. Ул, тонык кына ялтырап яткан асфальтка баскач, кысыграк кара күзләре белән тирә-ягына каранып, кая барырга белмичә аптырап торды. Аннан вокзалга таба китте.

Вокзал ишеге өстендәге сәгать иртәнге бишне генә күрсәтә иде әле. Түбә калайларына ышкылып диярлек кара болытлар агыла. Ул болытлардан, перронның кытыршы асфальтын юып, өзлексез янгыр тузаны коела. Һава шул кадәр дымлы: аны учларыңа алып кыссаң, бармак араларыннан тамчылар тамар төсле. Фонарьларның тонык яктысы, салкын янгырдан качып, үзе эленгән тимер баганалар итәгенә елыша.

Әле генә егет чыккан состав янында да җәйге көннәрдәге шикелле ыгы-зыгы сизелми. Бары бер вагонның ишеге төбендә генә зонтик тоткан ике-өч хатын-кыз белән яшь егет күренә. Хатыннар аңа соңгы киңәшләрен бирәләр:

— Алдынны-артыңны карап йөр, улым, бата күрмә!

— Кораб зур ул, әни. Безнең авыл чаклы. Анда батырмыйлар.

— Адмиралыңның сүзен тыңла, берүк! Каршы килә күрмә! «Иванов» дип кычкыруына, шундук «что-о?» дип кычкыр. Бабаң әйтә торган иде...

Ишек өстендәге сәгатьнең зур теле уникене узып аска таба төшә башлады. Чабу итәкләрен каерып салкын җил исеп куйды. Янгыр тамчылары эреләнеп, авыраеп вагон өсләрендә биешә башладылар. Егет вокзалга ашыкты. Вокзал аны тир, юеш кием исе һәм вокзалларга гына хас гөрелте белән каршы алды.

Егет йомшак вагоннан котылуына шатланып куйды. Бүтән билет булмагач, әнә кайда тирбәлергә туры килде! Министр шикелле генә! Тик эче пошудан үлә язды. Каршы дивандагы полковник юл буе Бунинның сигезенче томын укыды. Көнгә өч сүз дә әйтмәде. Ә Свердловскида кучеп утырганга хәтле плацкартлы вагонда нинди рәхәт иде. Анда йөз төрле кеше белән йөз төрле сүз сөйләшәсең, йөз төрле яңалык ишетәсең.

Ул шулай уфтана-уфтана утырып урын эзли башлады. Төрле чемодан, капчыклар өстеннән атлый-атлый залны әйләнеп чыкты. Тик бер эскәмия дә буш түгел иде. Алардагы юлаучыларның кайберләре кырын төшеп йокымсырый, кайсылары күкрәкләрен шәлләре белән томалап бала имезә, кайсылары ашый-эчә, күршесе белән гәп алып бара иде. Күзләрен түшәмдәге пыяла люстрага текәп уйлана-уйлана, тәмәке тарткан — зиһене арткан дигәндәй, тәмәке поскытып утырган ирләр дә шактый. Ресторанның ябык ишеге төбендә егетләр төркеме оешкан. Төркем, дуамалланып кычкыра-кычкыра, чемодан өстендә домино суга. Алар янында утырган бер чегән хатыны, «житте, хлопцы, әкренрәк!» дип, әледән-әле тыеп тора.

Егет, стена буеннан җил җитмәсрәк урын табып, чемоданын куйды да шуның өстенә утырды.

Бу шәһәргә аның беренче тапкыр килүе. Көтеп торган кешесе, барып керер урыны юк. Учреждениеләрдә эш башланырга да иртә. Көтүдән башка чара күренми...

Егет плащ якасын күтәрде, эшләпәсен күзләренә төшереп куйды. Кулларын җиң эченә тыкты да күзләрен йомды.

Хәзер мине Чәчкә күрсен иде, дип уйлады ул, менә кызык булыр иде. Юк, кызганыч! Чыннан да бик кызганыч бәндә бит ул хәзер. Институт бетергәч әллә нинди якты, иркен дөньяга чыгам, дип хыялланып йөргән иде — менә, утыр хәзер бөкрәеп. Юк, ул бүген үк кайтып китәчәк, бүген үк! Бер минут тормаячак бу якларда. Ул романтик түгел, кемгә романтика кирәк,— тыңласын әнә карагайлар җырын. Ә аңа җыр түгел, Чәчкәсе кирәк!..

Ул шушындый ук шыксыз яңгырлы кичтә Казан вокзалында ялгызы басып калды. Әллә яшь иде, әллә яңгыр тамчылары иде аның күзләрендә.

Менә аерылыр минутлар да җитте. Егет, юеш плащ итәкләрен ачып, Чәчкәгә япты. Чәчкәне, бер кулы белән биленнән кочып, үзенә тартты. Кәләшенең тыгыз күкрәкләре аңа тиеп тора. Чәчкәнең уйчан, акыллы күзләре егеткә текәлгән. Егет, ул күзләрне ачык күрмәсә дә, аларның ярату һәм сагыш белән мөлдерәгәнен сизә. Үз чиратында, аның ак, чиста, түгәрәк йөзенә карый. Бу чибәр һәм мөлаем йөзне хәтерендә озаккарак калдырырга тырыша. Кайбер хатын-кызларның йөзе күз явын алырлык чибәр, ләкин ак мәрмәрдән юнып ясалган сын шикелле җансыз һәм салкын була. Чөнки алар кешеләргә иң кирәкле нәрсәдән — мөлаемлыктан мәхрүм. Аларга табигатьнең җансыз могҗизаларына карагандай күз сирпеп үтәсең. Ә Чәчкәнең әчкерсез мөлаемлыгы, тыйнак матурлыгы белән пар килеп, аны тагын да илаһирак итә. Егет күңелендә әнә шуның белән бер карауда ут кабызды инде ул.

Ә менә хәзер аерылу! Икесе дә күптән сизеп, белеп йөргән, тик аның шушы хәтле авыр буласын күңелләренә китермәгән рәхимсез аерылу.

Чәчкәнең күкрәк җылысы егеткә күчә, бөтен тәненә тарала, аз гына башын әйләндерә.

— Менә китәм дә, Чәчкә.

— Ялгыз башым ничек ямь табармын, ничек яшәрмен, Айзатым!?

— Кайгырма, Чәчкә. Мин барам да, әйтәм дә кайтам. Безне аерырга хаклары юк. Аңларлар.

— Әгәр аңламасалар?
— Аңламасалар да барыбер кайтам.
Аларның сөйлисе сүзләре күптән сөйләнгән, әйтергә теләгәннәре күптән әйтелгән иде инде. Бер-берсенә тагын да ныграк сыенып, поезд кузгалуын тын гына көтә башладылар. Бу аерылу минутларыннан да кыен, алардан да ямансу чаклар юктыр дөньяда. Айзатка да, Чәчкәгә дә күңелсез, бик күңелсез.
Менә дымсу һаваны яңгыратып радиодан нидер әйттеләр. Вагон буферлары чәкешеп, дөбердәшеп алды, һәм поезд әкрен генә алга шуып китте. Айзат Чәчкәне ашыга-ашыга үпте дә баскычка сикереп менде. Чәчкә, кулын болгый-болгый, вагон артыннан бер тын йөгереп барды. Поезд кызулагач туктады һәм:
— Ху-уш, Айза-ат! — дип кычкырды.
— Ху-уш, Чәчкә!.. Рәтле генә то-ор!
Айзат вагонга керде. Халык күп булса да, төн уртасы авышканлыктан, әллә ни тавыш, шау-шу юк иде. Күпләр йоклыйлар. Казанда утырганнары да, чыш-пыш килеп, урын-җир кайгыртып йөри.
Айзат тәрәзә янына килеп басты. Тәрәзә артында үпкәләргә сылanучан юеш һавалы, күзгә төртсәң күренмәслек шыксыз төн тантана итә. Ничә ел гөр килеп, суын эчеп, икмәген ашап яшәгән Казан төн кочагына сыена. Торбаларыннан ут-төтен бөркегән бинидһая заводфабрикаларын, асфальт урамнарын, баскычларын, күккә ашкан мәһабәт таш диварларын ияртеп, ашыга-ашыга артка чаба. Менә поезд тирән чокыр эченә килеп керде. Гүелдәп күпер астыннан үтте. Соңгы төртке утлар, калышмаска теләп, тәрәзә яныннан йөгереп бардылар да, тыннары кысылып, туктап калдылар.
Айзат авыр сулап куйды. Аңа кинәт хәзер бөтен дөньяда кап-кара төндер, шул төн кочагында ул япа-ялгызы калгандыр шикелле тоелды. Гүя Чәчкә дә, институт та, яшьлек хыяллары да кайдадыр, кайчандыр бик күптән төштә генә булган, ә хәзер алар икәү — төн дә ул.
Егет тагын көрсенде. Аннан үз урынына китте. Сакланып кына өске киштәгә менде. Көн буе йөреп бөтен тәне, атналар буе уйланып-моңланып башы арыса да, йокы аны тиз генә эретә алмады. Күзен йомса, күз алдында чәчкә кебек балкып Чәчкә елмаеп торды. Башына мең төрле уй килде. Туган авылы, ямьле Ык буйлары, әткәсе-әнкәсе, туганнары исенә төште. Ул быел үзенең егерме икенче язын үткәрде инде. Җиде яшендә кулына «Әлифба» алып, унбиш ел буе укыды. Менә хәзер ерак Себер урманнары арасына укытучы булып бара. Моңа кадәр ил гизгәне дә, чуен койганы да, шахтада күмер ватканы да — кыскасы, искитәрлек бер нәрсә эшләгәне дә юк. Ә аңа егерме ике яшь инде!..
Поезд, караңгы төнне ярып, ул күрмәгән, йөрмәгән ерак җирләргә чаба. Ул ерак җирләр Айзатка бик серле булып тоела. Егерме өченче яшен кайда, кемнәр белән каршылар? Бу билгесезлек аны бик дулкынландыра. Әзрәк шикләндерә дә: бер юл — ун хата, йөз юл — мең хата булмасмы? Ул аны билгеле итәргә — барып тиешле кешеләре белән сөйләшеп, сөйләшмәсәләр — сөйләшмичә генә кире китәргә күңеленнән кат-кат сүз бирә. Шулай буласына үзен ышандырырга тырыша.
Вагон тәгәрмәчләре шакы-шокы килеп чакрымнар саный. Киштә Айзатны җай гына тирбәтә. Йок-ла, йок-ла, ар-ган-сың, ди. Тик егетнең күзләренә йокы керми. Тәрәзәдән иртәнге сыек яктылык сирпелгәнче һаман ераклаша барган туган-үскән илен уйлый. Казан һаман ераклаша. Казан белән бергә моңлы Чәчкә ераклаша...

## 2

Айзат яктырганчы шулай уйланып утырды. Ниһаять, түшәмдәге утлар тоныкланды. Вокзал йокыдан уянды. Киоскалар, буфетлар ачыл-

ды, белешмә бюросы эшли башлады. Рестораннан җиренә житкереп пешерелгән кофе исе, чәч алу бүлмәсеннән затлы «Шипр» исе бөркелеп чыкты. Авыр ишекләрне бөтенләй япмас булдылар...

Айзат юынып һәм кырынып килде. Буфет янында аяк өсте генә капкалады да белешмә бюросыннан өлкә мәгариф бүлегенең кайда икәнен белеште. Хәзер шунда барып рәтләп сөйләшергә дә кичкә таба шушы вокзалдан ук Казанга кайтып китәргә, дигән ныклы теләк белән ишектән чыкты.

Урамда төнге утлар сүнгән, яңгыр туктаган иде. Күктә тавыш-тынсыз соры болытлар агыла.

Айзат, чыккан уңайга, кызыксынып шәһәргә карап торды. Шәһәрнең бу урыннары тигез җирдә булып, калган яртысы сөзәк тау итәгенә салынган иде. Вокзал алдыннан, кытай җилпәзәсе шикелле таралып, тигез урамнар сузылып киткән. Агач тротуарлар әле генә кырып юган идән шикелле ялтырап, парланып тора. Сары, күк һәм зәңгәр төсләргә буялган агач өйләр һаман йокыларыннан айнымаган шикелле.

Арырак киткәч — тау итәгендә һәм тау өстендә — агач өйләрне икешәр-өчәр катлы таш йортлар алыштырган. Алар арасыннан чиркәү манаралары башларын сузган. Шәһәрнең иң биек җирендә челтәрле телевизион манара һәм аның күршесендә янгын каланчасы калкып тора. Алардан унда, урман буенда, иске шәһәрдән әз генә кечерәк икенче шәһәр — монын үз «Черемушки»ын төзеп яталар. Анда күтәрү краннары, ә иске шәһәрдә төтәп торучы калай һәм кирпеч торбалар бик күп. Аннан соң агачлар күп. Шәһәрнең әллә ничә урынында яшел утраулар шикелле бакча-парклар күренә. Вокзал тирәсендәге урамнарның да чит-читләреннән куе аллеялар сузылган. Яшел, җыйнак шәһәр...

Троллейбус тукталышында зонт тоткан берничә хатын-кыз тора иде. Айзат алар артыннан троллейбуска кереп утырды һәм кызыксынып ят шәһәрне карап барды. Монда завод-фабрикалар, төрле артельләр, магазиннар бик күп. Яр кырыена ук салынган пластмасса заводын, «Металлист», чуен кою, такта яру заводларын, аяк киемнәре, мех эшкәртү фабрикаларын үткәч, троллейбус тәбәнәк ярлы киң елганың челтәрле агач күпереннән чыкты да таш шәһәргә күтәрелә башлады. Монда завод-фабрикалар әзәйде, аларны кино-театрлар, төрле оешмалар алыштырды. Чиркәүләр күбәйде. Урамнар иркенәеп, яктырып китте. Буш стадионны үткәч, шәһәрнең икенче ягына килеп чыктылар. Ул текә ярлы киң елгага терәлә икән. Ә өлкә мәгариф бүлеге урнашкан ике катлы борынгы таш йорт нәкъ яр читендә булып чыкты.

Айзат такта тротуар өстеннән шунда китте. Йорт, ярым подвалын да кертеп исәпләгәндә, өч катлы иде. Өлкә мәгариф бүлеге аның икенче катында икән. Өченче катны укытучыларның белемен күтәрү институты биләгән...

Айзат, күкрәгең киереп тирән сулады да, тар баскычтан икенче катка менеп китте. Юан чылбырына ярты потлы гер тагылган авыр ишекне көч-хәл белән ачып, бер ягына ак ишекләр тезелгән караңгылы-яктылы озын коридорга килеп керде. Коридорда ыгы-зыгы. Егетләр һәм кызлар төркем-төркем булып ишек төпләрендә торалар, чемодан өсslәрендә утыралар, тәрәзә төпләренә иелеп нидер язалар, әле шатланып, әле борчылып сөйләшәләр, көлешәләр. Болар да нәкъ аның шикелле, направление буенча илнең төрле почмакларыннан әле генә килеп төшкән яшь укытучылар иде.

Егет чемоданын куйды да иң кырыйдагы ишек янында торган чират янына китте. Арттагы кыздан:

— Әйтегез әле, зинһар, направление белән килгәннәрне шушы бүлмәдә кабул итәләрме? — дип сорады.

— Әйе. Сез дә хәзер генә килдегезме?

— Хәзер генә,— диде Айзат.— Татарстаннан, дөресрәге, аның башкаласы Казаннан. Беләсезме?

— О-о, беләм! — диде кыз һәм күпереп торган чәчен рәтләп алды.— Белә-әм. Университетында Ленин укыган. Тукай, Муса Җәлил, нефть, Нижнекамск. Шулай-мы?

Айзат елмайды:

— Дөрес. Каян беләсез?

— Белмәскә, без якташлар ич.

— Шулаймени-и? — диде Айзат, күңелле гаҗәпләнеп.— Сез кайдан соң?

— Ригадан.

Айзат көлеп җибәрде.

— Ә-ә-ә, шулай икән шул, якташлар икәнбез.

Кыз да аңа кушылып көлде.

Ишеккә житкәндә алар бер-берсен күптән белгән якын танышлардай сөйләшәләр иде инде.

Кабул итү бүлмәсе урындык сыярлык кына ара калдырып уплап өстәл тезелгән ике тәрәзәле кысан бүлмә булып чыкты.

Ябык йөзле, очлы борынлы, күз төпләре күгәреп торган яшь-яшь кыз Айзатның направлениесен, дипломын һәм башка документларын алды. «Берәр студенткадыр, эш бик тыгыз чакларда аларны чакыралар, керү имтиханнары вакытында гел шулар патшалык итә» дип уйлады Айзат.

— Сез филология факультетының татар бүлеген тәмамладыгызмы? — дип сорады кыз, күтәрелеп карамыйча.

— Анда язылган,— диде Айзат.

Кыз аның кинаясен игътибарсыз калдырды. Сул кулының карандаштай нечкә чәнчә бармагы белән кара кашларын сыпырып алды. Дипломны жентекләп карый-карый:

— Әйбә-әт,— дип куйды.

— Нәрсә әйбәт?

Кыз бу юлы зур соры күзләре белән күтәрелеп карады.

— Казан безгә һәрвакыт яхшы кадрлар җибәрә. Менә сезнең дә «с отличием». Бер булды. Икенчедән, татар теле һәм әдәбияты укытучылары бик кирәк.

— Ә сезнең өлкәдә татар мәктәпләре күпме соң?

— Ике йөзгә якын. Унысы — урта мәктәп.

Кыз, алдында яткан калын кенәгәгә, Айзатның документларына карый-карый, кирәкле белешмәләрне теркәп куйды. Аннан соң аларны егеткә сузып:

— Иртәгә мөдир янына керерсез. Кайсы районга китәчәгегезне ул әйтер,— диде.

Егет аптырап:

— Ник, мөдир бүген кабул итмимени? — диде.

— Ул юк,— диде кыз.— Елга арты районында яңа мәктәп ачачаклар... Сез, иптәш, кайдан? Кәгазьләрегезне бирегез әле?

Айзат, ак чырайлы кыз икенче кешенең документларына «чумганчы» әйтеп калырга ашыгып, алгарак иелде:

— Ә миңа нишләргә соң? Кая барырга?

Кыз, инде бүтән кешенең кәгазьләрен карый-карый:

— Ә сез хәзер аска — гомуми торакка төшегез. Анда сезгә урын бирерләр. Ял итегез, шәһәрне карагыз. Кичен елгачылар сараенда симфоник концерт. Теләсәгез барыгыз,— диде.

— Мин монда ял итәргә, концертларга йөрергә килмәдем бит, туташ.

— Беләм,— диде кыз, тыныч кына.— Тик сез беркая да китә алмаячаксыз. Ким дигәндә, тагын өч-дүрт көн. Автобуслар йөрми. Яңгырны күрәсезме?

— Күрәм.

— Менә, бик әйбәт. Ял итегез. Музейны карарга тәкъдим итәм. Анда мамонт скелеты бар.

— Ә-әй, сез мине аңламадыгыз ла,— диде Айзат һәм кулын селтәп ишеккә юнәлде.

Ишек алдына чыкты да таш плитә түшәлгән сукмак буйлап китте. Сукмакның як-ягында үскән алабута һәм әремнәрдән һавага әчкелтем ис таралган иде. Айзат күкрәген тутырып шуны иснәп торды. Аннан соң кырыйлары түгәрәкләнеп, урталары уч төбе шикелле чокыраеп беткән ике таш күтәрмәдән атлап төште. Сыңар лампочка белән яктыртылган ярым караңгы коридорга килеп керде. Коридор почмагында өстенә утын өелгән зур тәбәнәк мич калкып тора. Янында бытыр-бытыр килеп ялтыравык титан кайнап утыра иде. Быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлар ишетеп, Айзат икенче ишекне ачты һәм караватлар тезелгән дүрт почмаклы иркен бүлмәгә килеп керде. Бу бүлмә дә ярым подвал иде. Тәрәзәләрнең яртысы җир астында булганлыктан, монда да лампочкалар яна.

Ишек төбендәге караватта, кулларын баш астына куеп, тезен чәнчеп, ябык йөзле бер кеше ята иде. Айзат кергәч, ул күзләрен ачып карады, ләкин кымшанмады.

Айзат чемоданын идәнгә куйды да тартыныбрак сәлам бирде:

— Исәнмесез!

— Исәнмесез! — дип, калын тавыш белән җавап кайтарды теге кеше. Торып утырып, йон оекбаш кигән аяклары белән карават астыннан җылы туфлиләрен эзли башлады.

Айзатның бер сәер гадәте бар иде. Ул кешеләргә секунд кына текәлеп карап ала һәм аларның йөзен, төсен, килеш-килбәтен, кием-салымын һәм тагын бүтәннәр күзенә чалынмый торган бик күп вак-төяк билгеләрен хәтеренә сеңдерә, ягъни, үзе әйтмешли, баш миендә «кәртечкегә төшереп» калдыра иде. Аннары һич онытмый. Группадашлары аның бу гаҗәеп сәләтен психология үткәндә психологик, логика үткәндә логик законнарга туры китерергә азапланып карадылар да, планнары барып чыкмагач, Павлов түгел шул без — бу я шартлы, я шартсыз рефлекс булырга тиеш, дигән акыллы нәтиҗә чыгардылар.

Айзат хәзер дә карават читендә утырган кешене ялт кына «кәртечкегә төшереп» алды. Илле яшьләр тирәсендәге бу кеше бүрәнәнең юан башын күтәреп яшәгән, дөньяның ачысын-төчесен күп татыганга охшый иде. Озын куе чәчләренең яртысы агарган, алар, сарылары белән аралашып, күксел тимер кисәге шикелле ялтырап тора. Кашлары әле агарырга өлгермәгән. Туры борынының уң канатында бодай бөртеге сыман озынча каралҗым миңе күренә. Аксыл йөзе ябык. Бераз алга чыгып торган калынрак иреннәре аның ихтыяр көче, текә маңгае — акылы хакында сөйли. Сул кулының баш бармагы белән беләзеге арасында «Сибирь — моя Родина!» дигән вак хәрефле татуировка. Димәк, бу тәбәнәк буйлы чандыр кеше — Себернеке. Айзат менә хәзгле аларны алып гәүдәле, аюдай гайрәтле халык дип йөри иде. Мондыйлары да бар икән...

Себер кешесе урыныннан торды. Йомшак кына басып, тәрәзә янына килде.

— Коя-а,— диде, авыр сулап.— Туктарга исәбе юк. Күпме икмәк әрәм була. Басу тулы җыелмаган салам... Татарстанда да явамы?

Айзат көттереп һәм ашыгып җавап кайтарды:

— Ява... Ә сез минем аннан икәнемне кайдан беләсез?

Теге борылды да елмаеп аңа карады.

— Гафу итегез, дускай! — диде.— Аны сезнең төсегез-кыяфәтегез әйтеп тора. Кылдай каты, төн кебек кара чәчләр, кызларныкы шикелле дуга кашлар, карлыган кебек чем-кара күзләр сезнең милләт кешеләре-

нә хас бит. Ә без менә киресенчә — алладан җирән төсне сораганбыз. Сары белән ак буяуны яратканбыз. Аннан соң акцентыгыз да сизелә.

Икесе дә көлеп куйдылар.

Айзат ишек төбендәге артсыз урындыкка утырды.

— Монда башлыклар бармы соң? Мина берничә көн шушында яшәп торырсыз дип әйткәннәр иде.

— Бар. Беатриса түтәй. Йортлар идарәсенә киткән иде. Хәзер кайтыр.

Шул чакта коридорда доп-доп атлаган аяк тавышлары ишетелде, тумбочка өстендәге стаканнар зыңгылдап алды, ишек ачылды, һәм бүлмәгә баштанаяк кара киенгән юан хатын килеп керде. Айзат торды. Хатын шундук лып итеп аның урынына утырды. Кабарынкы күкрәкләрен тагын да калкыта төшеп, «у-уфф, у-уфф» дип сулый-сулый, газета белән тышланган зур калын кенәгәсен җилпәзә итеп бите янында селкеп торды. Аз-маз сулу алгач, Айзаттан:

— Исәнмесез, җаным! Урын кирәкме? Ничә көнгә? — дип сорады.

— Өч-дүрт көн торырсың, диделәр.

— Ярый, җаным,— диде Беатриса түтәй һәм, Айзатның паспортын алгач, ишек янындагы кырый караватны күрсәтте.

— Урнашыгыз, ял итегез, җаным. Тамагыгыз кипсә, титанда чәй кайнаган,— дип, кинәт сикереп торып, титанны карарга чыгып китте дә шуннан соң күзгә-башка чалынмады.

Теге кеше бүтән дәшмәде. Озын өстәлнең бер башында, чәйнекләрне, шахмат-шашкаларны шудырып, урын әзерләде. Портфеленнән кәгазьләр алып, язу-сызуга чумды.

Айзат ишегалдында юынып керде. Шәһәр карарга һәм бер уңайдан ашап та алырга ниятләп, урамга чыгып китте. Челтәрле чарлакларга, борынгы чуен капкаларга, сөяктән төрле шырдым-бырдымнар ясаучы артель тәрәзәләренә кызыксынып карый-карый такта тротуарлардан алга атлады. Урамның уртасыннан йөрерлек түгел иде.

Үзәккә якынлашкач, урамнар киңәйде, агачлар сирәгәйде. Асфальт башланды. Айзат «Республика проспекты»на килеп керде. Бу проспект бик чиста һәм матур иде. Кибетләр, кафелар, кинотеатрлар каршында, яңгыр тузанына игътибар итмичә, халык кайнаша иде.

Айзат кибетләргә кереп, ашказаны сырхау бәйләнчек ревизор шикелле тикшереп йөрде. Мондагы кибетләрдә дә җаның теләгән ризык бар иде. Төрледән-төрле, тәмледән-тәмле ашау-эчү әйберләре белән шүрлекләр сыгылып тора иде.

Балык кибетләрендә, камбала, хек ише нәрсәләр белән янәшә, затлы кызыл балыкларга күзе төшкәч, житез сатучыларның пыяла чаң эчендә йөзеп йөргән чөгә һәм сазаннарны җәтмә белән генә эләктереп алуларын күргәч, Айзат көнләшеп, монда яшәргә мөмкин, безнең кебек, хатынга дигән балык базарда, я кибеттә дип йөрүче юеш артлы адәмнәргә әрәме оҗмах, дип уйлап алды.

Республика проспекты тимер коймалы бакчага килеп чыкты. Бакча алдындагы тигез мәйданда таш һәйкәл тора иде. Айзат аның янына барып туктады. Һәйкәлне биш-алты метрлы багана итеп ясаганнар. Һәйкәл алдындагы кызыл мәрмәр тәлинкәдә мәңгелек ут янып тора. Баганага:

«Без, исән кешеләр,
Бөек Ватан сугышы корбаннары
истәлегенә
шушы һәйкәлне куйдык
һәм
шушы мәңгелек утны
кабыздык»,—

дип язылган.

Һәйкәл тирәсендә тынлык.

Һәйкәл итәгендә чәчәк бәйләмнәре ята.

Тып-тын...

Уйчан бакчаның сары яфраклары арасында вак яңгыр шыбырдый.

Мәрмәр тәлинкәдә лепер-лепер ут яна.

Каһәрле яуда егылганнар, крематорий мичләрендә көлгә әйләнгән адәмнәр истәлегенә ут яна.

Айзат һәйкәлгә карап уйга чумды. Аңа бу таш плитәләр астында йөзләрчә көрәшчеләр ятадыр һәм плитәләр аларның сөякләрен көзге яңгырлардан ышыклап, бу мәңге сүнмәс ут җылытып торадыр шикелле тоелды.

Плитәләр астындагы көрәшчеләр арасында үзенең дә ике газиз абыйсы ятадыр кебек тоелды.

Сугыштан кайтмый калган егерме өч авылдашының якты истәлеге булып та кабынган ич бу ут!

Ул гел шулай янып торыр: көнен дә, төнен дә, җәен дә, кышын да! Мәңге, мәңге, мәңге!..

Җир өстендә изгелек үзе генә түгел — аның артында явызлык та бар.

Бу ут исән кешеләргә әнә шул хакта сөйләп торыр: онытмагыз, дияр, онытылып китмәгез, дияр...

Айзатларның утыз сигез генә өйле авылларында электән үк ике нәсел дөнья көткән: Сәетбатталлар белән Әсхәдуллалар ыруы. Сәетбатталларның кардәш-ырулары урамның түбән очына — күл янынарак оешып утырганнар, ә Әсхәдуллаларның нәсел-нәсәбе югары очка — урам башына төпләнгән. Революциягә хәтле, гәрчә бәләкәй бер урам булып кына гомер итсәләр дә, талаш-кычкырышлар, олы-олы гаугалар чыгып торган. Каен урманы, чәчкә печәнле әрәмә болыны, балыклы күлләр, бодай котырып уңа торган кара туфраклы Бөгә басулары — тавышны әнә шулар һәм кара крестьянның гомер буе эчендә саклана торган комсызлыгы, мин-минлеге китереп чыгарган. Һәр ыру яхшы җирләрне үзенә күбрәк эләктерергә, калҗаның майлырагын кабарга тырышкан. Кайсы елларда эш шуңа барып җиткән ки, түбән очлар югары очтан кыз алмаганнар, кызларын кияүгә бирмәгәннәр. Әсхәдуллалар да, үз чиратларында, нәкъ шулай кыланганнар. Кыскасы, аларның тату чакларыннан этле-мәчеле торган вакытлары күбрәк булган.

Бәхеткә каршы, революция Бөгә басуларының межасын сөргән. Авыл урамына тынычлык кергән. «Сәетбатталныкылар», «Әсхәдулланыкылар» дигән сүзләр генә онытылмаган. Нәселдән-нәселгә, бабалардан аталарга, аталардан балаларга күчеп, хөрмәт белән саклана килгән...

Сугыш башлангач, Татарстанның әнә шул утыз сигез генә учаклы бәләкәй авылыннан кырык өч ир-егет, Ватан — барысыннан да газиз дип, җыенып яуга китә. Сәетбатталлар нәселеннән — егерме өч, Әсхәдуллалар нәселеннән — егерме. Әгәр дәһшәтле сугыш тагын да озаккарак тартылса, һәм чират авыр елларда авыр эш эшләп суырылган бала-чагаларга килеп җитсә — кем белә, бәлки, авылдагы ике нәселнең икесе дә сүнгән булыр иде. Ләкин, бәхеткә каршы, эш моңа ук барып җитмәде. Сугыш бетте. Җир, Гитлерның өй түбәсенә кызыл байраклар элеп, маршлар уйнап, җылый-җылый, көлә-көлә ду килеп алды да тынычланып үзенең гадәти хезмәтенә керешге.

Сәетбатталларның ыруыннан — унбер, Әсхәдулланыкылардан — тугыз кеше исән калып, туган-үскән илләренә әйләнеп кайттылар. Киткән чакта алар кырык өч иде. Ике нәселнең егерме өч баласы әле хәзер дә Мәскәү белән Берлин арасына сибелеп йоклый һәм мәңге йоклар...

Гик сугыш афәте моның белән генә бетмәгән икән әле. Егерме солдатның да яртысы җәрәхәтләнеп кайткан иде. Тән яралары аларны тиз эрегте, ачы үлем ширбәтен эчертеп, тиеш булганнан бик иртә зират

юлларына чыгарды, өч аршын ак кәфенгә төреп, ак каеннар төбендәге бер сажин урынга җирли торды.

Хәзер Чияледә сугышта булган кешеләр тәгәл унике.

Әмма аларның тамыры нык булып чыкты. Алар нәсел-нәсәпләренә сүнәргә ирек бирмәделәр. Сәетбатталлар ыруы да, Әсхәдуллаларныкы да әкренләп кенә тагын ишәя башлады.

Еллар үтә торды. Еллар үткән саен ир-егетләр арта торды.

Авыл уянды. Күкрәгеннән бер киерде дә, элекке тар урамына сыймыйча, алты почмаклы нарат өйләрен тезеп урманга таба менеп китте. Авылда инде йөзгә якын учак бар.

Сәетбатталлар белән Әсхәдуллалар ыруында, киң Ватанның төрле урыннарында иген игеп, калалар салып, белем эстәп йөргәннәрен дә кертеп санаганда, ике йөздән артык ир-егет бар...

Менә аларның берсе — Сәетбатталлар ыруыннан чыккан егет — Сәетбатталов Айзат шул ут янында басып тора.

Тыныч булыгыз, бу ут сүнмәс: без хәзер инде ике йөздән артык!..

Тузан шикелле вак яңгыр һаман сибәли иде. Урамда халык әзәйгән. Айзат та, әле анда, әле монда ут кабына башлаган якты тәрәзәләргә кызыгып карый-карый, тулай торакка кайтып китте.

Ул кайтып кергәндә зур бүлмә кешеләр белән тулган иде инде. Мондагыларның һәммәсе дә утыз-кырыктан узып, яшьлек шуклыгыннан аерылып өлгергәнгә күрәдер — шау-шу юк. Бернечә агай өстәлгә төрле-дән-төрле затлы нигъмәтләр таратып салган да, юмартныкы уртак дип, сөйләшә-киңәшә чәй эчә. Театрга-фәләнгә җыена бугай, көзге каршында берәү кырына. Аргы башта шахмат уйныйлар, белем эстәүчеләр, караватларына сузылып ятып, газета-журнал укый.

Айзат, бүлмәдәгеләргә сәлам биргәч, плащын салды да караваты янындагы урындыкка килеп утырды. Аның баш очында моннан биш былтыр модасы беткән «эшләпә» репродуктор өлкәнең соңгы хәбәрләрен сөйли. Урып-җыю, ит-сөт, ау, балык, урман һәм нефть, нефть, нефть, газ, газ, газ — дикторның телендә шул иде. Айзат шуны тыңлый-тыңлый аягын чишенде һәм мендәренә таянуга рәхәтләнеп күзләрен йомды. Бер генә чеметем хәл алыйм, дигән иде, арганлык үзенекен итте: оеп йокыга китүен сизми дә калды.

Ул уянганда бүлмә тынган иде инде. Тәрәзәләрдәге кичке саргылт яктылык сүнеп, дөм-караңгыга әйләнгән, баш очындагы «эшләпә» дә арып, сөйләүдән туктаган.

Аның уянганын күргәч, күршесе язуыннан туктады да соры күзләрен кыса төшеп елмайды:

— Хәерле төн! — диде.

Айзат торып утырды.

— Хәерле төн?

— Әйе.— Күршесе беләгендәге алтын сәгатенә карады.— Сәгать нәкъ төнге бер.

— Ә бездә ун гына әле. Урам тулы халык. Бабайлар белән малайлар гына йоклый.

Айзатның күршесе йон оекбаш кигән бер аягын икенчесенә чәнчеп куйды да балтырын ышкый башлады.

— Ревматизм... Язын, көзен үтерә... Көннәр яңгырга китсә, бөтенләй котыра, һич чыдар әмәл юк... Сездә шула-ай... Менә мин дә йоклама-дым әле. Әнә тегеләр дә. Август киңәшмәсенә докладлар әзерлибез.

— Гафу итегез, нинди киңәшмәгә?

— Укытучылар киңәшмәсенә. Ярый, сез дә гафу итегез, без әле һаман танышмадык бит. Мине Петр Петрович, диләр. Хәтта фамилиям дә Петров. Аю-Атар районының мәгариф бүлеге мөдире. Мине истә калдыру бик җиңел. Районда Петр III дип йөртәләр.

— Ә минем фамилия һич истә калдыра торган түгел,— диде Айзат, көлемсерәп.— Сәетбатталов. Исемем Айзат. Пединститут тәмамлагач, мене монда килдем. Дәресрәге, җибәрделәр. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Алар кул кысыштылар.

Петр Петрович, аксыл-сары чәчләрен сыйпаштыргалап, Айзатка бер тын карап торды. Айзат уңайсызланып башын иде.

— Кайсы районга билгеләделәр? Направление алдыгызмы әле? — дип сорады Петр Петрович.

— Юк әле, өлгермәдем,— диде Айзат.— Облоно мөдире мәктәп кабул итеп йөрде. Иртәгә инде. Ләкин мин районга китмәм, ахры.

— Ни өчен? — дип сорады Петр Петрович, гаҗәпләнеп.

Соңы кичә-кичә белерсең, кешене тора-тора белерсең, дип әйтәләр әйтүен дә, әмма Айзатка бу кеше көндез үк ошап калган иде. Аның түбәнсетмичә, үзенә тиң күреп, ягымлы гына сөйләшүеме, әллә акыллы соры күзләрен текәп караганда аларда ниндидер әчке моң чагылып китүеме — ул аны рәтләп аңламый әле.

Айзат аңа үзенең өйләнүе хакында сөйләргә теләде. Ләкин тыелып калды. Хәзер үк кирәкмәс. Беренче күргән кешегә ни өчен сер сандыгын ачарга, дип уйлады. Шуңа күрә көттереп кенә:

— Мин өйләнгән кеше. Хатын Казанда калды,— дип куйды.— Ни өчен безне аерырга тиешләр? Өйләнү — кеше гомерендә бер килә бит.

— О-о, әлбәттә, әлбәттә! — диде Петр Петрович, аның белән килешеп.— Мин сезне, Айзат дускай, әле өйләнмәгән егет дип уйлаган идем. Ялгышканмын икән.

— Беренче елны ук ул Казанда, мин Себердә яшәп булмый инде. Ара ерак, яна йөрәк, дигәндәй...

— Әлбәттә, ләкин ара ерак булса да, күңелләр якын булсын. Димәк, сезнең туй сәяхәтегез инде бу?

— Әйе. Бик күңелле туй сәяхәте! Кияү егете ялгызы гына. Кәләшеннән башка.

Петр Петрович, аягын алыштырып куеп, икенче балтырын ышкырга тотынды.

— Ә ник сезгә, Айзат дускай, ялгыз йөрергә? Үзегез әйткәнчә, ялгыз кияү егете булып?

— Нәрмичә нишлисең, Петр Петрович?

— Нишләргәме? Минемчә, туй сәяхәтен парлашып, сөекле кәләшегез белән бергә ясарга кирәк иде.

— Аңламыйм, Петр Петрович. Себергә минем үземне генә җибәрделәр бит.

— Ә аны кая җибәрделәр? Гафу итегез, исемен белмим.

— Чәчкә исемле ул. Чәчкә Казанда калды. Аны... Казанга билгеләделәр.

Шулай диде дә, киртәгә тәртә ялгавын сизеп, Айзат кызарды. Чөнки аларның икесен дә, яшь семьяны аермыйк дип, шушында билгеләгәннәр иде. Әмма Чәчкәнең әнисе, Себер дигән сүзне ишетүгә, һушы китеп егыла язды. Әти кешегә, бер бөртек кызыңны да калдыра алмасаң, галим дигән исемең корысын, диде.

Әти кеше галим исемен корытырга теләмәде, җиң сызганып эшкә кереште: телефоннар шалтыратты, кирәк кешеләрне күреп сөйләште, төрле оешмаларга йөрде. Чәчкәгә Казан мәктәпләренең берсендә урын табылды, кәгазьләрне үзгәрттеләр.

Билгеле, кияүне дә онытмадылар. Килен монда калып та ул китеп барса, шулай ук шәп түгел ич.

Айзат студентларның фәнни түгәрәгендә «башлы» егетләр рәтеннән чутланып килде. Аның Минзәлә белән Актаныш диалектына багышланган хезмәте шәһәр конференциясенә дә үтте, хәтта бүләкләнде дә.

Группа кызлары, син инде, малай, аспирантурада калырсың, зур галим булырсың, дача салырсың, машина алырсың, юанаерсың, Бауман урамында очрашсак, безнең ишеләрне күрмәгәнгә салынып кына үтеп китәрсең дип, аны кайчак шаярткалыйлар да иде.

Ләкин тел укытучысы моны хупламады.

— Сиңа башта дөнья күрергә, тормыш белән танышырга, тәҗрибә тупларга кирәк. Берәр мәктәптә эшләрсең, шул тирәнең диалектын, сөйләм үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнерсең. Шуннан соң инде аспирантурага биш куллап алырбыз,— диде.

Егет бу сүзләр белән килеште. Тик шулай да Казанда калу-калмау, сөекле кәләшеннән аерылу я аерылмау мәсьәләсе кабыргасы белән алдына килеп баскач, Айзат икеләнә башлады. Быел ук аспирантурада калсам, кемгә ни зыян дип уйлады, хәзер яшь галимнәр заманы, алар елдан-ел яшәрә бара, атом энергиясе, ракеталар уйлаучы физик һәм математикларны, химикларны әйткән дә юк — үзебезнең Казанда да яшь-яшь фән докторларыбыз, профессорларыбыз бар ич! Укый-укый тәҗрибә аласың аны. Командировкаларга чыгасың, экспедицияләрдә йөрисең.

Дача, машина дигәннәре дә кешегә кирәк нәрсә. Аларның гаебе кыегы юк. Үз машинаң белән выжт итеп кенә авылыңа кайтып төшкәч, о-о, фәлән абзыйның профессор малае кайткан, дигән сүзләрне ишетсәң дә зарары тимәс иде!.. Алсыннар гына аспирантурага!

Ләкин Айзатны алмадылар. Син инде эш урыныңа билгеләнгән, без берни дә эшләтә алмыйбыз, телисең икән үзең барып хәл кыл, әгәр азат итсәләр, карап карарбыз, диделәр. Аяк терәп сөйләшергә кәгазь-мәгазь дә бирмәделәр, хакыбыз юк, диделәр.

Шулай итеп, егеткә үз теләге белән үз йөрәгенә таянырга калды.

Айзат боларны Петр Петровичка бөртекләп торуны кирәксенмәде. «Аны... Казанга билгеләделәр» дип кенә әйтте.

— Гаҗәп! — диде Петр Петрович, аптырап.— Чыннан да, яңа гына оя кора башлаган семьяны аеру кем башына килде икән?

— Направление алганда без өйләнешмәгән идек әле,— диде Айзат, уңайсызланып.

— Ә-ә, алай икә-ән, ул вакытта икенче мәсьәлә,— диде Петр Петрович. Аннан соң Айзатка сөзеп карап торды да, балтырларын ышкудан туктап, җылы башмакларын кия-кия, ашыккан кебегрәк әйтеп куйды:

— Ә беләсезме нәрсә, Айзат дускай, сезне, мөгаен, безгә җибәргәннәрдер. Безнең Бөгелә-Тал мәктәбенә татар теле укытучысы кирәк. Элеккесе кияүгә китте. Менә шәп булыр иде.

Айзат аңа көлемсерәп җавап кайтарды:

— Шәп булмас төсле, Петр Петрович.

— Ә кәләшегез, гафу итегез, хатыныгыз, нинди бүлек бетерде? — дип сорады Петр Петрович, Айзат сүзенә колак салмаган шикелле.

— Хатыным...— Айзат, әле генә теленнән ычкынган сүзнең яңгырашына гаҗәпләнеп, тагын кабатлады: — Хатыным чит ил телләре факультетын тәмамлады. Немец бүлеген.— Һәм, тумыштан бер дә мактанчык кеше булмаса да, өстәп куйды: — С отличием... Минем шикелле...

Петр Петрович та моны сизде. Аның акыллы күзләрендә шаян чаткылар күренде.

— Бик яхшы! — диде ул, кайнарланып.— Бөгелә-Талда немец телен биолог укытып азаплана. Бичарадан ни чара. Класс та өйрәнә, үзе дә.

— Чәчкәгә Казанның үзендә эш тәкъдим иттеләр шул.

— Кызганыч, кызганыч! — диде Петр Петрович.— Сезнең шикелле белгечләргә мохтаҗлыгыбыз зур. Себер соңгы бишьеллыкта чын промышленность державасына әйләнеп бара. Себер йокысыннан уянды, күзләрен ачты. Безнең өлкәне алыйк: Новосибирск галимнәре әйтә, сезнең өлкәдә ике мең нефть һәм газ учагы бар, ди, сезнең өлкә нефть

буенча җир шарында беренче урынга чыгачак, ди. Нинди перспектива! Күпме төзелеш! Күпме халык агыла хәзер монда! Аларның балаларына белем бирергә кирәк. Мәктәпләр, педагоглар кирәк. Бу төзелеш проблемаларының авыр бер өлеше безнең — мәгариф хезмәткәрләренең җилкәсенә төшә.

— Ләкин Европада да төзелеш тукталмый. Анда да яңа мәктәпләр салына, ул мәктәпләргә дә укытучылар кирәк бит, Петр Петрович.

— Бик дөрес. Ләкин Көнчыгышка тегесе дә, монысы да артыграк кирәк. Бу — закон.

— Ни өчен?

— Чөнки үсәбез. Бик тиз, гаҗәеп дәрәҗәдә тиз үсәбез. Ә балалар үскән чакта күбрәк ашыйлар. Камил һәм көчле булып үсү өчен. Шулай түгелме?

— Шулай, Петр Петрович, ләкин ил дә бик киң, укытучылар дөнья тулы.

Петр Петрович егеткә сынаулы һәм шелтәле караш ташлады. Тумбочка өстендәге кәгазьләрен җыя башлады. Дәшмәде.

Айзат аның кинәт күңелсезләнүенә үзенең соңгы сүзләре сәбәпче икәнен төшенеп, уңайсызланды һәм оялды. Сүзләренең мәгънәсенә үзгәреш кертергә, аңлатып бирергә теләде.

— Петр Петрович... сез...

Петр Петрович кәгазьләрен папкага салып бәйләде, ул папканы күн сумкасына, сумкасын кечкенә юл чемоданына тыгып куйды. Тумбочкасыннан никельләнгән чәйнек һәм чәй савыты алды.

— Ятар алдыннан каты чәй эчәргә ярамый, диләр. Ә мин каты чәй эчмәсәм, киресенчә, йоклый алмыйм. Элгәре врачлар аны, һәр авыруга дару дип, эчәргә киңәш иткәннәр. «Илаһи үлән» дип атаганнар. Димәк, ярый, ә? — диде.

Ул, йомшак башмаклары белән тавышсыз гына басып, чәй пешерергә чыгып китте. Айзат, өстен чишенеп, урынын җәйде дә одеал астына чумды. Ак җәймәләр һәм мендәр тышлары өр-яңа, бик чиста, аларның әле түк сырлары беленеп тора. Сизелер-сизелмәс кенә тәмле пар һәм сабын исе килә. Айзат, аякларын җәймәгә төреп, рәхәтләнеп сузылып ятты. Петр Петрович керде. Айзатның борынын кытыклап, яңа пешкән һинд чәенең хуш исе бәрелде. Петр Петрович тумбочка өстенә күмәч, ак май, сыр, шикәр чыгарып куйды. Бик тантаналы, серле эш эшләгәндәй, житди кыяфәт белән чәй эчәргә кереште. Пөзенә дөньясында бөтен нәрсәләрдән канәгатьлек һәм бәхет билгеләре чыкты.

«Кайбер кешегә бәхетле булу өчен бик аз нәрсә дә җитә инде,— дип уйлады Айзат.— Бу минутта аның бәхете — кайнар чәй, ә минем бәхетем — хатыным. Бәләкәч хатыным Чәчкә! Ха! Хатыным!.. Кызык!.. Бераунең бәхетеннән таш эри, бераү бәхетеннән май туңа шул».

Ул ихтыярсыз елмаеп куйды...

Күрше бүлмәдә доң-доң сәгать сукты. Аргы башта кемдер ыхылдыйыхылдый әйләнеп ятты, кемдер йөткерде. Айзат шул якка карады һәм Казанда үзе яшәгән тулай торагы — сөекле «монастыре» кылт итеп аның исенә килеп төште. Шул монастырь, йөрәген кинәт кенә сулкылдатып, сагындырып куйды.

## 3

Айзат биш ел буе яшәгән сигезенче бүлмә икенче катка күтәрелгәч тә сулдан беренче иде. Менә хәзер төн уртасында уянып түр якка карагач, Айзат бу бүлмәне дә үзләренең сигезенче бүлмәләренә охшатты. Монда да шундый ук озын өстәл, карават араларында ак ситсы ябылган тумбочкалар. Хәтта Айзатның менә хәзер үзе моңаеп яткан караваты да, юри туры китергәндәй, нәкъ ишек янында — тупсадан атлап

кергәч тә уң як стена буенда. Караватны ишектән ышыклап торган шкафлар юк та... бүлмәдәш иптәшләр юк. Алар еракта. Алар да хәзер туган илнең төрле төшенә таралып, Айзат шикелле, йоклый алмыйча дусларын-иптәшләрен сагынып ята торганнардыр.

Айзат әйләнеп ятты. Уфылдады. Күзләрен тагын йомып, яңадан йокларга тырышып карады. Ләкин уйлар, хыял канатына утырып, тагын монастырьга, иптәшләре янына, сөекле Чәчкәсе янына кайтып китте. Чәчкә! Чын чәчкә шикелле гүзәл Чәчкәсе белән ныклап танышулары да һәм араларында саф мәхәббәт ялкыны дөрләп яна башлауга да бик күпләргә таныш, башыннан бик күпне кичергән шул борынгы монастырь (алланың рәхмәте төшкере нәрсә!) сәбәпче булды.

Аның нәкъ уртасында кечерәк пассаж кебек биек зал бар иде. Икенче каттан шул зал-пассаж аркылы канау күперен хәтерләткән күперкоридор эшләнгән. Ул залда танцалар барган чакта танцевать итә белмәгән егетләр өчен бик уңай булып, алар терсәкләре белән рәшәткәгә таянып, шул күпердә өерләре белән басып торалар, астагыларга, стена буендагы матур кызларга карыйлар һәм тирән сулый-сулый көрсенәләр иде...

Узган елның май ае иде. Агачлар яфрак ярган, чәчәкләр шыткан, сыерчыклар өздереп сайраган, киң җиһанга тереклек иңгән, күңелләр җилкенгән, киләчәк көннәр һәркемгә якты һәм өметле күренгән, егет-кызларның башлары әйләнгән, сәгадәтле сөю һәм татлы мәхәббәт хисләре уяткан язгы көннәр, институтның үзеннән дә, лекцияләреннән дә бик нык туелган язгы матур көннәр иде.

Шундый кичләрнең берсендә шәһәр өстенә әллә кай төштән генә кулъяулык хәтле мут болыт кисәге килеп чыкты да таш урамнарга, бакча-паркларга вак яңгыр сибәргә тотынды. Күңелләре бөтәйгән парлы мәхәббәтләрне дә, әлегә парын эзләп кенә йөрүче ярым-йорты мәхәббәтләрне дә өйләренә куып кертте.

Ләкин баллы бөреләр исеннән исергән һәм күкрәкләрендә ташларны тауларга орып ут чәчрәтерлек мәхәббәт көче ярсыган яшьлекне яңгыр белән генә, бар, куркытып кара!..

Курыкмадылар да, бар дип тә белмәделәр яңгырны студентлар. Аскы каттагы беренче бүлмәдән физика-математика факультетының бәләкәй аспирантын диссертация язып утырган җиреннән ай-ваена карамый җилтерәтеп алып чыктылар да, язы булгач, сазы да булырга тиеш дип, кулына баян тоттырдылар. Залда «Язгы вальс» яңгырады, залда күбәләктәй парлар бөтерелә башлады.

Күпер өстенә аның даими «хуҗалары» чыгып басты...

Айзат ул көнне китапханәдән кайтып барганда бер заводта конструктор булып эшләүче иптәшен очратты. Иптәше аны, «Казан» ресторанны астындагы буфетка алып кереп, коньяк белән сыйлады. Егетнең болай да күтәренке күңеле тагын да хушланып китте. Аяклары җиңеләйде, теле ачылды, йөрәгенә «арслан тотып менәрлек» кыюлык керде.

Шуңа күрәдер инде, бүтән көннәрдәге шикелле «объект өйрәнеп» күпер өстендә тормады, туп-туры залга чыкты һәм алтынчы бүлмә ишеге яныңдарак торган күк күлмәкле кызны биергә чакырды. Кыз бер кулының җыйнак учын аның киң һәм каты учына салды, икенче кулы белән көчле җилкәсенә таянды. Алар беренче «па»дан соң ук бөтерелеп биючеләр арасына кереп киттеләр.

Айзатның бик күп кызлар белән вальс әйләнгәне бар. Кайбер кызларның юка гына гәүдәләре, танцага керденме, ритмны югалтып, салмаклана да китә. Аларга, авыр көймәне боргандай, әле анда, әле монда көч белән юнәлеш биреп барырга туры килә. Ә бу кыз, егетнең бәхетенә каршы, оста да һәм җиңел дә бии иде. Аяклары вальс ритмына әз генә дә ялгышусыз йөри, тыңлаучан гәүдәсе Айзатның кул хәрәкәтен шунда ук сизеп ала иде.

Айзат болай шәп биючеләрдән санала. «Күпер егетләренең» бик күбесе аңа, их, синең шикелле танцевать итә белсәң иде, син дә без мокытлар сымак катык ашап үскән авыл малае инде югыйсә, кайдан, кайчан өйрәнгәнсеңдер дип, кызыгып һәм сокланып карыйлар. Бүлмәдә кеше юк чакларда, өйрәт әле, дип тинтерәтеп бетерәләр иде. Ә кызлар аның биюгә чакыруын куану һәм горурлану кебегрәк дулкынлы хис белән кабул итәләр, «дамский вальс» вакытларында Айзатның башка егетләр җилкәсенә ышыкланып торган чагы бөтенләй булмый диярлек иде...

Беренче вальста алар сөйләшмәделәр. Оста биюләренә эчләреннән генә куанып, рәхәтләнеп бөтерелделәр дә бөтерелделәр.

Вальс бетте. Айзат кызны үз урынына озатып куйды. Башын иде. Ләкин китмәде. Басып калды. Фокстрот башлангач, бүтәннәр килеп алмасын дип, тагын тизрәк аны чакырды. Шунда гына:

— Сез әйбәт бисез,— диде.

Кыз, күтәрелеп, коңгырт күзләре белән елмаеп карады да:

— Сез үзегез дә... Сезнең белән җиңел,— диде.

Егетнең дә, кызның да шушы комплиментлардан соң тартынулары кими төште.

— Ә мин сезне беләм,— диде егет, дөньяда юк әллә нинди сер белгән кыяфәт белән.

— Белсәгез әйтегез, мин кем соң? — диде кыз, үзе дә шаяруга шаяру белән җавап бирде.

— Сез иностранный факультетта укыйсыз. Ялгышмасам, немец теле шикелле. Белдемме?

— Ялгышмадыгыз. Монастырьда яши торгач, тәмам могҗиза иясенә әйләнгәнсез икән. Котларга ярыймы?

— Бик ярый. Рәхмәт сезгә, туташ!

— Бу туташыгыз үзе дә чегән хатыннарында укыды бит, фал ачу курсларын бетерде. Без хәтта сезнең исемегезне дә әйтә алабыз.

— О-о, рәхим итегез!

Кыз серле генә елмайды да, аның колагына иелеп:

— Сез — Айзат Сәетбатталов. Татар теле һәм әдәбияты бүлегеннән. Шулаймы, могҗиза иясе? — дип пышылдады.

— Шулай,— диде Айзат.— Сез миннән дә оста булып чыктыгыз. Бер — ноль сезнең файдага. Ә мин сезнең исемегезне бөтенләй хәтеремнән чыгарганмын.

— Хәтерегездә булмаган исем ничек чыксын ди инде, ә? Ярый, безнең тарафтан булсын изгелек, әйтсәм әйтим: исемем Чәчкә.

Егет елмайды һәм тирән сулап:

— Бу кыз я Кояштыр, я Чәчкәдер дип әйткән идем аны. Чөнки сездән җылы кояш нурларыдай илаһи бер нур бөркелә һәм сез нәк чәчкәсе шикелле гүзәл,— диде.

Кыз, егетнең әйтелми калган яшерен уйларын белергә теләгәндәй, аңа җитди итеп, сынап карады.

— Факультетыгызда башка егетләр дә шулай оста телләме?

— Оста телебез сездән гафу сорый!

Чәчкәнең түгәрәк йөзе кабат ачылып китте.

— Комплимент өчен гафу үтенмиләр. Без — мактауларны ярата торган халык,— диде...

Алар шулай көлешеп-уйнашып тагын берничә кат биеделәр. Соңгысыннан туктагач, Чәчкә сәгатенә карады да:

— Ярый, рәхмәт, Айзат! Мин кайтам,— диде.

— Нишләп... ашыгасыз?

— Җитәрлек булды инде,— диде Чәчкә.— Ленин районында укторабыз.

— Сез Казан кызымыни?

— Казан кызы. Авылны көз көне группа белән бәрәңге алырга баргач кына күрәм мин. Хушыгыз!

— Хушыгыз! Үзегез генәме әллә?

— Әйе.

— Курыкмыйсызмы?

— Нәрсәдән?

— Бүре-мазар чыкса,— диде Айзат, шаяртып.— Мин сезне бүреләрдән яклау өчен озата барам. Рөхсәтме?

— Шәһәрдә «бүре-мазар» булмый, авыл малае.— Аннан соң Чәчкә Айзатка нидер уйланып карап торды, күз очлары белән генә көлемсерәп:— Алайса, әзрәк көтегез, мин зонтымны гына алыйм,— диде.

Алар бик күп күзләрнең кызыксынучан, «күпер хуҗаларының» уфтану катнаш көнләшүчән карашларын җәлеп итеп, залдан чыгып киттеләр.

Вакыт шактый соң булса да, Идел өстеннән тулы ай карап торганга һәм шәһәрнең бөтен урамнарын, мәйданнарын нурландырып меңнәрчә лампочкалар янганга, төн әнә сапларлык якты. Күксел-зәңгәр һавага, йокларга ятмыйча һаман гөрләп торган зур шәһәр өстенә аксыл-җемелдек якты җәелгән. Егет белән кызны, ишектән чыгуга, май төненең яңгырдан соң тагын да җылынып киткән чиста һавасы үз кочагына алды. Алар, үләннәрнең шифалы исе таралган татлы һаваны ләззәтләнеп сулый-сулый, Кремль стеналары буйлап Казанка дамбасына төшеп киттеләр.

Кремль күперенә кергәч, икесе дә мондагы матурлыкка хәйран булып, ихтыярсыз туктадылар һәм рәшәткәгә таянып тын калдылар.

Аларның тирә-ягында ай нурлары белән ярыша-ярыша меңнәрчә утлар җемелди иде. Каршыда гына «Парус» рестораны үзенең гадәти төнге тормышы белән яшәп ята. Аның ачык тәрәзәләреннән кәеф-сафа корып утыручыларның шәүләләре күренә, барабан һәм труба тавышы ишетелә. Арырак — Киров дамбасы буйлап ике утлы эз сузылган. Дамба белән янәшә юлдан, бик күп вагоннар тагып гөрли-гөрли, куәтле тепловоз бара. Аның гөрелтесенә Идел өстендәге теплоходларның өзек-өзек тавышлары кушыла. Диңгез шикелле җәелеп яткан Казанка өстеннән искән талгын җил тәнгә рәхәтлек бирә. Шәһәр урамнарына, таш һәм тимер исенә кушылып, су һәм юеш үлән исе тарала.

Айзат кызлар белән ялгыз калган чакларында туктаусыз сөйләргә, көлдерергә, аларның күңелләрен күтәрергә, кыскасы, ут-егет булып күренергә ярата иде. Авызына су капкан егетләрне кыз-кыркын халкының яратмавын белгәнгә, минем дә даным таралмасын дип борчыла да иде. Ләкин ул бүген, менә хәзер, шундый сихри төндә, Чәчкәгә үз хыяллары белән хыяллану, рәхәт дулкынланып бер уйлану өчен тынлык кирәк икәнлеген сизде. Шуңа күрә алар дамбаны чыкканчы тын гына бардылар. Шәһәр урамына кергәч, сөйләшә башладылар. Шаяру, балачагалык юк иде. Бер карасаң, май төне яшь күңелләрне җилкетергә, уен-көлкегә тартырга тиеш иде. Ләкин, гаҗәпкә каршы, сүзләр, олы кешеләрнекедәй, салмак һәм акыллы булды: язгы имтиханнар, Иделдә балыкның бетүе, Германия дәүләтләре, Зөһрә йолдызы һәм шуның ише аралары бик-бик ерак темалар тирәсендә әйләнде.

Воровский урамына җитеп, чаттагы чәчәк кибетеннән уңга борылгач, биш катлы өйләрнең берсенә күрсәтеп:

— Менә безнең өй,— диде Чәчкә.

Ишек төбенә килеп туктагач, Айзат:

— Ничәнче кат? — дип сорады.

— Өченче.

— Әйбә-әт.

— Я, хуш, Айзат! Мин керим. Болай да соңга калдым. Танца өчен дә, озатып куюың өчен дә бик зур рәхмәт!

— Сау бул, Чәчкә! Тыныч йокы, тәмле төш!
— Сиңа да, Айзат!
Чәчкә кереп китте. Икенче кат тәрәзәсеннән кул изәде дә югалды. Айзат, кинәт кенә борылып китәргә кыймыйча, ишек төбендә тагын әзрәк торды...
Айзат трамвайга утырырга теләмәде. Чәчкә белән әле генә парлашып килгән юл буйлап, ялгызы уйлана-хыяллана, тагын җәяү китте. Монастырьга таң беленгән чакта арып-талып, ачыгып, ләкин күтәренке күңел белән кайтып җитте. Ишек, гадәттәгечә, күптән бикле иде. Айзат тәрәзә шакыды. Маһинур әби өстәлен титан янына — җылыгарак күчереп, шуның өстендә бөгәрләнеп йоклап ята иде. Башта бик озак уяна алмый аптырады. Уянгач, сукрана-сукрана тәрәзәгә килде. Айзатны танығач, стенадагы сәгатькә күрсәтә-күрсәтә йодрык янады, иреннәрен бик тиз кыймылдатып, өстәлгә кире менеп аркасын титанга терәп ятты.
Айзат көлде дә өй түрендәге бәләкәй бакчага керде. Башта коймага үрмәләп менде, аннан стена сырларына сакланып баса-баса, кулы белән икенче катның тәрәзә рамнарына тотына-тотына үз бүлмәләренең тәрәзәсенә килде.
Егетләр каты таң йокысы белән йоклап яталар иде. Кыймылдаучы булмады. Тик ул тәрәзә төбенә тураеп баскач кына, географ Тимачев сикереп торды. Ул, гадәтенчә, плавки гына киеп йоклаган иде. Шәпшәрә килеш, күзләрен чәшкә кадәр иттереп, һич нәрсә аңламыйча, таңның кызгылт шәүләләренә уралып тәрәзәдән килеп керүче әкәмәткә карап торды. Айзат, ят, ят, бу мин дип кул селкегәч, әллә ык диде, әллә мык диде — кеше аңламас телдә нәрсәдер әйтте дә дөп итеп урынына ауды һәм мыш-мыш йоклап та китте.
Монастырь уянып, шалт та шолт ишекләр ачыла-ябыла башлаганчы, Айзат үзенең шкаф артындагы тыныч урынында елмаеп, уйланып ятты. Уйлар бүген бик игелекле булды: ул йокы бәясеннән әллә никадәр кыйммәт торган ике ачыш ясады. Беренче ачыш «тормыш та, яшәү дә әйбәт, чукынган!» иде. Икенче ачыш аның үзен дә бик гаҗәпләндерде — ул бүгенге таңда Чәчкәгә үлеп гашыйк булуын аңлады...

### 4

Икенче көнне Айзат бүлмәдәгеләрнең барсыннан да соң уянды. Ул күзләрен ачканда Петр Петрович та, башкалар да торып беткән, кайберәүләр чыгып та киткән иде. Петр Петрович нәкъ кичәге урынында, нәкъ кичәгечә чәй эчеп утыра. Айзатка елмаеп карады да:
— Хәерле иртә! Яңа урында әйбәт йокладыңмы? — диде.
— Хәерле иртә! — диде Айзат.— Әйбәт йокладым. Ләкин төшләр күреп бетердем.
— Казанныммы?
— Казанны.
— Кәләшне дәме?
— Анысы да булды,— диде Айзат, сер бирмәгән кыяфәт белән һәм, урын-җирен әйбәтләп җыеп, юынып кергәннән соң, ашап та тормастан, мәгариф бүлегенә менеп китте.
Тар баскычтан икенче катка күтәрелеп, авыр ишекне тагын көч-хәл белән ачканда, коридор кичәге шикелле егетләр һәм кызлар белән кайнап тора иде инде.
Айзат, кабул итү бүлмәсенә үтешли, кичәге «якташ»ын күреп, ихтыярсыз туктады. Йомшак аксыл чәчле, аксыл йөзле Рига кызы тәрәзә төбенә иелеп нәрсәдер яза иде.
— Хәерле иртә, якташ! — диде Айзат.
Кыз язуыннан туктап башын борды.
— Ә-ә, бу сезмени? Исәнмесез!

— Башлыклар янында булырга өлгердегезме әле?
— Язу кесәдә. Бүген очам.
Егет тәрәзәдән елга аръягындагы очсыз-кырыйсыз тайганы, берәм-берәм кабарып торган күксел болытларны күздән кичерде.
— Көн аязырга итә, самолетлар очар. Кая билгеләделәр? — дип сорады.
— Якын түгел. Обь тамагына ниятләдем,— диде кыз, гади генә итеп.
Айзат аның йөзенә карап алды. Ләкин анда пошыну эзе юк иде. Егет моңа аптырады.
— Ният иткән — морадына җиткән, диләр дә... Борчылмыйсызмы?
— Нигә борчылырга?
— Соң... җәһәннәм тишегенә олактырганнар бит!
— «Олактырганнар»? — диде кыз, гаҗәпләнеп.— Мин үзем китәм ич.
— Сез ул җирне беләсезме соң? «Ямал» — ненецчә җир чите дигән сүз. Тугыз ай кыш. Анда болан асраучылар һәм балыкчылар белән аучылар гына яши.
Кыз аптырап күперенке чәчләрен сыйпады. Яртылаш язылган хатын тәрәзә төбенең икенче башына куйды.
— Хәзер анда нефтьчеләр дә күп ич. Билгеле, туган-үскән якта яшәве күңеллерәк булыр иде! Ләкин кушкан җиргә бармый калырга ярыймыни?!.
Айзат кочакласаң биле өзелергә торган бу кызның сүзенә үртәлә башлады. Дөресрәге, кыз кешенең дә әллә кая — җир читенә, икеләнмичә, рәхәтләнеп китәргә җыенып, җитмәсә, авыз ерып торуына, ә менә үзенең — көчле һәм нык рухлы ир-егетнең шушы коридордан ук тәртәсен кире борырга теләп йөрүенә үртәлде. Үзе танырга гына теләмәде, моның шулай икәнлегенә үзен ышандырырга гына теләмәде.
Айзат кызның кечкенә сусар якалы көзге пальтосына, башындагы озын колаклы куян башлыгына карап алды да:
— Анда суык, салкын. Гомумән кыргый як,— диде.
Кыз, маңгаена төшеп чуалган йомшак чәчләрен башлыгына рәтләп кертә-кертә:
— Беләм. Элек кыргый булган. Ә хәзер кулга ияләнгән инде. Без аны мәктәптә үттек, ничек әле, хәтерләмисезме? — диде.
— Нәрсәне?
— Лермонтовны.
— Лермонтовны?
— Әйе. Ә... Исегездә калмаганмыни? Ятлатканнар иде бит. Менә:

На Севере диком стоит одиноко
    На голой вершине сосна
И дремлет, качаясь, снегом сыпучим
    Одета, как ризой, она.

И снится ей все, что в пустыне далекой,
    В том крае, где солнца восход,
Одна и грустна на утесе горючем
    Прекрасная пальма растет.

Айзат та бу шигырьне ярата иде. Ә менә монда — тайга уртасындагы таш каланың таш йортында кура җиләге шикелле кыз авызыннан ишеткәч, шигырь үзенең моңа кадәр сизелмәгән яңа ягы белән яңгырап китте. Элек аңга җитсә, хәзер йөрәк түренә үтте һәм анда хисләр давылы уятты. Айзат, мең чакрымнарга китсә дә ак кардан бүтән нәрсәсе булмаган коточкыч салкын тундрада, биек салкын күктә җемелдәгән тоныкı төньяк балкышы астында, ялан җирдә ялгыз башы туңып-калтырап утыручы бәхетсез наратны күз алдына китереп, үзе дә кинәт калтыранып куйды. Көяз пальма өчен ул кадәр борчылмады, чөнки аның баш өстендә салкын төньяк балкышы уйнамый, нурлы кояш көлеп тора.

— Матур шигырь,— диде Айзат.— Сезне ялгыз нарат шикелле ялгыз моңайтмас өчен, мин дә бәлкем артыгыздан шул якларга барып чыгармын әле.

— Мин анда ялгыз түгел. Ил эчендә, үзең теләмәсәң, ялгыз яшәп булмый. Килсәгез, шәп булыр,— диде кыз.

Шул чакта секретариатта утыручы кичәге ябык йөзле, очлы борынлы кыз күренде. Ул, култык астына папкалар кыстырып, ашыгып кына коридорның икенче башына үткәндә, Айзатны күреп туктады.

— Сәетбатталов, сезне ИУУ директоры эзләтте. Кердегезме?

— Нинди ИУУ? — дип сорады Айзат, гаҗәпләнеп.

— Укытучыларның белемнәрен күтәрү институты директоры. Кермәсәгез, хәзер керегез, Сәетбатталов. Әйтәсе сүзләре бар бугай. Алар өченче катта.

Кыз энә үкчәләре белән тык-тык басып үтеп китте һәм бер ишеккә кереп күздән югалды.

«Сәетбатталов та Сәетбатталов. Тапкан. Авызыннан да төшерми», дип мыгырданды Айзат, әмма кызның үз фамилиясен онытмавына күнеле булып куйды.

— Килеп өлгермәдек — кирәгебез дә чыкты. Кереп карыйм әле, ник чакыра икән,— диде Айзат, «якташ»ына елмаеп.

— Керегез, кер. Берәр әһәмиятле эштер,— диде кыз.— Менә мин дә хатымны гына язам да...

Айзат өченче катка менеп китте. Тар баскычның яртысына җиткәч, икеләнеп туктады. Кара, сау булыгыз дип тә әйтмәдем, әллә кире төшим микән, дип уйлады. Тик, директор яныннан чыккач күрермен әле дип, уеннан кире кайтты. Ләкин Айзат ялгышты. Ул чыкканда тәрәзә төбенә иелеп ерак Ригадагы әти-әнисенә сәлам хаты язучы ак күбәләктәй ак кыз юк иде инде. Айзат, күрергә теләсә дә, аны бүтән очратмады, аларның гомер юллары бүтән туры килмәде...

Өченче катта астагы кебек ыгы-зыгы сизелми, тыныч һәм тын иде. Кабул итү бүлмәсенә килеп кергәч, кукле-яшелле чәчен кабак зурлыгы итеп баш түбәсенә өеп куйган бәләкәй буйлы секретарь хатын, машинкасыннан аерылып, сораулы күзләре белән аңа текәлде.

— Мин Сәетбатталов. Директорыгыз мине эзләткән икән,— диде Айзат. Секретарьның кымшанмыйча һаман карап торуын күргәч, ярдәме тияр бәлки дип, аңлатыбрак бирде:

— Яшь укытучы мин. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Казаннан җибәрделәр.

Шунда секретарь хәрәкәткә килде.

— Ә-ә. Нина Степановна кызыксынган иде шул, хәтерлим, хәтерлим, мин хәзер,— диде дә ялт итеп кырыйдагы ишеккә кереп китте. Айзат кара дермантин өстендәге «Укытучыларның белемен күтәрү институты директоры Н. С. Плохих» дигән язуны укып алды. «Плохих!.. Нинди милләт кешесе икән бу?» дип уйларга гына өлгерде, секретарь ханым елмая-елмая килеп тә чыкты. Куллары белән килешле ишарәләп:

— Рәхим итегез, иптәш, Нина Степановна сезне көтә,— диде.

Директор кабинеты зур түгел иде. Түрдә кечкенә өстәл. Өстәл артында тәрәзәгә аркасы белән Нина Степановна утырган. Ул, Айзат кереп исәнләшкәч, аңа каршысындагы креслодан урын күрсәтте дә, кабаклары шешенебрәк торган зәңгәр күзләрен әледән-әле нык итеп йома-йома, аның ник керүен исенә төшерергә теләгәндәй карап торды һәм кинәт кенә калын матур тавыш белән бераз сузыбрак:

— Сезне татар теле һәм әдәбияты белгече дигәннәр иде. Дөресме? — дип сорады.

— Дөрес әйткәннәр, Нина Степановна.

— Ә-ә, бик хуп, бик яхшы, иптәш. РСФСРның егерме сигез өлкәсендә һәм автономияле республикаларында татар мәктәпләре бар. Безнең

өлкәдә дә алар күп, бик күп. Шуңа күрә безгә дә татар кадрлары бик кирәк.

Әдәбиятның искиткеч бай мирасыннан файдалана алу безнең укытучыларның һәм укучыларның гаять зур бәхете түгелмени? Бу турыда Максим Горький нәрсә дигән? Максим Горький бу турыда бик хаклы рәвештә: «Безнең әдәбиятыбыз — безнең горурлыгыбыз...» — дигән. Сез менә...

Шул вакыт телефон шалтырап, Нина Степановнаның сүзен бүлдерде. Ул, трубканы колагына куеп, бер-ике минут чамасы тыңлап торды. Аннан үзенең калын матур тавышы белән җавап бирә башлады:

— Юк, юк, география укытучылары бер айга килергә тиеш. Уку шуннан да ким була алмый... Ни өченме? Менә ни өчен, иптәш, чөнки география фәненең тормыштан артта калырга хакы юк. Тормыш география фәнен искиткеч тизлек белән үзгәртеп тора. Менә шуның өчен дә алар унбиш көнгә түгел, ә төгәл бер айлык курска килергә тиеш. Шунда гына эшебезнең нәтиҗәсе булуы мөмкин. Нәрсәнеме?.. Әйе, үткәнне һәм бүгенгене! Үткәнне һәм бүгенгене!..

Трубканы сак кына куеп, сул кулы белән арган күзләрен сыйпап алды. Аннан соң яңадан Айзатка карап:

— Районо мөдирләре җәфалый,— диде.— Берсенең дә укытучыларын анда-монда җибәрәселәре килми. Ә без «анда-монда»мыни? Түгел. Без — өлкә укытучыларының белемен күтәрү институты.

Нина Степановна туктап хәл алды, тәрәзә төбендә торган графиннан агызып бер йотым су эчте. Күзләрен тиз-тиз йомгалап, стенадагы бер портретка ымлады.

— Моравиянең бәләкәй генә Нивниц шәһәрендә тегермәнче гаиләсендә туып-үскән менә бу сакаллы кешегә карагыз, иптәш. Сез кемне күрәсез? Сез чехның бөек педагогы һәм гуманисты Ян Амос Коменскийны күрәсез. Йөзләрчә ел үтте, ә аның педагогик хезмәтләренең кыйммәте һаман да бетмәде. Хәзер уку-укыту системасындагы безгә гади булып күренгән нәрсәләрне — класслап укытуны, дәресне, уку елын, каникулларны — иң беренче булып Ян Амос Коменский башлап җибәргән. Укытуның төп принциплары һәм башкалар, һәм башкалар, һәм башкалар да анык бит. Менә шул алтын мирас хәзинәсен өйрәнми торып хәзерге чорның яхшы укытучысы булып буламы?

Нина Степановна, күзләрен еш йома-йома, Айзатка карап тора башлады. Айзат мөдирнең үзен ни өчен чакыртканын аңламыйча аптырап, сорарга теле кычытып-кычытып китсә дә, үзеннән өлкән кешене сүзеннән бүләргә кыймый утыра бирде. Шуңа күрә аңа сорауның үз сүзләре белән генә җавап кайтарды:

— Булып булмый.

— Менә шул шул,— дип, аны күтәреп алды Нина Степановна,— дөрес, дөрес, дөрес... э-э-э... Гафу итүегезне үтенәм, иптәш... исем-фамилиягез хәтеремнән чыккан...

— Фамилиям — Сәетбатталов, исемем — Айзат. Безнең татар халкында әтисенең исемен кушып дәшү гадәте юк,— диде Айзат.

— Әйе, әйе, әйе, иптәш Сәетбатталов. Картларның хәтере иләктәге су кебек: ага да бетә. Менә шулай. Йөзләрчә еллар буе җыелып килгән педагогик хәзинәне җентекләп өйрәнми торып үз фәнеңнең төпле белгече булам димә... Ярый. Сезнең белән күреп сөйләшүемә мин бик шатмын... Менә шул. Хәзергә хушыгыз! Яңа эштә сезгә уңышлар телим! Сез яшь, энергияле. Көчегезне кызганмассыз дип ышанам. Хәер, мин үзем дә сезгә кулымнан килгән кадәр ярдәм итеп торырмын. Үзегез дә тартынмагыз, кирәк булсам, керегез. Менә шу-ул...

Нина Степановна өстәл тартмасыннан бер папка алды. Ниндидер кәгазьләргә кул куя башлады. Айзатны бөтенләй онытты.

Айзат чыгып китәргә дә, китмәскә дә белмичә, икеләнеп, мангаен ышкый-ышкый урынында тора бирде. Ни булды соң бу? Ник чакыртты икән соң ул мине? Менә кызык, тамаша! Аннан соң икеләнүен җиңеп, юк, тукта әле, шулай да нигә чакыртуын белеп китим, берәр сәбәбе бардыр дип, тамак кыргандай итте.

Нина Степановна башын күтәрде. Гаҗәпләнебрәк:

— Әле сез китмәгән идегезмени? — дип сорады.

— Юк әле... Нина Степановна, ни өчен чакыртуыгызны беләсем килгән иде. Гафу итегез, әлбәттә.

— Ни өчен чакыртуыгызны дисезме?

— Әйе.

— Я ходай, мин сезгә кергәч тә әйтмәдеммени аны?

— Әйтмәдегез шул, Нина Степановна.

— Ие, ие, ие. Кызганыч. Әйтәм бит, картлар хәтере — иләккә салган су, ага да бетә. Гафу итегез инде мине! Утырыгыз әле, иптәш Сәетбатталов. Менә нәрсә, безнең институтның татар теле һәм әдәбияты кабинетына мөдир кирәк.

Һич көтмәгәндә ясалган бу тәкъдим Айзатны бер мәлгә аптырашта калдырды. Ул, Нина Степановнага ни дип җавап бирергә дә белмичә, байтак кына сүзсез утырды. Нина Степановна акыллы зәңгәр күзләрен йома-йома аның җавабын көтте. Аны үз соравына тырышып җавап эзли дип белеп:

— Уйлагыз, уйла. Мондый чакта ансыз булмый,— дип «ярдәм» иткәләп тә алды.

— Нина Степановна,— диде Айзат,— шундый җирдә эшли алыр дип уйлавыгызга, ышаныч күрсәтүегезгә чын күңелемнән рәхмәт әйтәм. Ләкин мин, беренчедән, монда эшләмәм дип уйлыйм. Куркудан, я теләмәүдән түгел — бүтән объектив сәбәпләре бар. Икенчедән, калган тәкъдирдә дә андый җаваплы урында эшли алмас идем. Теорияне белсәм дә, тәҗрибәм бөтенләй юк әле.

— А-а, сез, иптәш Сәетбатталов, бу сүзләрегез белән миңа тагын да ныграк ошадыгыз, ышанычым арта гына төште,— диде Нина Степановна.— Ә сез кыенлыклардан курыкмагыз. Ялгышлардан курыкмагыз. Эшләмәгән адәм генә ялгышмый. Ә-ә, беләсезме, иптәш Сәетбатталов...

Айзат, кызып китсә, тагын туктамас дип, Нина Степановнаның сүзен бүлеп сорау бирде:

— Нина Степановна, мин ул кабинет мөдиренең вазифаларын бөтенләй белмим бит, күз алдыма да китерә алмыйм. Әле болай, туры килеп эшләгән тәкъдирдә дим.

Соңыннан бу саксызлыгы өчен әй үкенде Айзат. Телемнән җен тарттымыни, дип үзен-үзе әрләде. Чөнки шул урынсыз сорау авызыннан ычкынуга, Нина Степановна, сөйләргә җай чыгуына шатлана-шатлана, аңа кырык минут буена институттагы татар теле һәм әдәбияты кабинеты турында, кабинет мөдиренең эше һәм бурычы турында лекция сөйләде. Бернича мәртәбә телефон шалтырады. Нина Степановна миндә кеше бар, соңрак шалтыратыгыз дип кенә җавап бирә торды. Ике-өч мәртәбә ишектә чәчен баш түбәсенә кабак шикелле өеп куйган секретарь күренде. Нина Степановна аңа да, без бик мөһим мәсьәлә хәл итәбез, соңыннан, соңыннан дип, кул гына селтәде.

Айзат кырык минут эчендә Нина Степановна җитәкчелек итә торган институтның төзелү тарихын, андагы татар теле һәм әдәбияты кабинетының төзелү тарихын, эш формаларын, институттагы бүтән кабинетларның нәрсәләр эшләвен, институтның өлкә мәгариф эшендә тоткан әһәмиятле урынын, өлкәдәге биш-алты атказанган укытучының биографиясен, аларның укыту методларының үзенчәлекләрен, институтның Мәскәү, Ленинград, Казан кебек шәһәрләр белән нинди элемтә тотуын,

кабинет мөдирләреннән нинди̇рәк эш таләп ителүен белде. Ломоносов, Ушинский, Горький, Чернышевский, Шолохов, Белла Ахмадуллиналарның, Европа, Азия, Америка, Африка, Австралиянең унсигез атаклы галименең фән кешеләре турында язып калдырган яки күптән түгел генә әйткән акыллы сүзләрен ишетте, бу өлкәнең бик зур — Европаның берничә дәүләте кадәр территориясе булуын, кабинет мөдиренең фәкать кабинетта гына казынып ятмыйча, елына биш-алты тапкыр мәктәпләрнең хәлен белү һәм аларга практик ярдәм күрсәтү өчен командировкаларга чыгарга тиешлеген, самолет, вертолет, трактор, машиналарга, атларга, этләргә, боланнарга утырып, җәяүләп, саз чаңгылары киеп йөрергә, кышкы зәһәр салкыннарда, ачы бураннарда туңарга, җәйге эссе бөркүләрдә тирләргә-пешәргә, чебен-черкиләрдән искиткеч җәфалар чигәргә, атналап койган көзге яңгырларда шәбәрергә туры киләчәген хәтеренә салып куйды.

Айзат, Нина Степановнаның сөйләү дигәндә үлеп китүен һәм бер башлагач һич туктатыр чара юклыгын белгәнгә күрә, йомшак креслога чумыбрак утырып, аны бүлдерергә теләмичә тыныч кына тыңлады. Нина Степановна көзнең җәфа яңгырларын әйтеп, кипшенгән иреннәрен тел очы белән ялап куйгач һәм тәрәзә төбендәге графинга үрелгәч, үзенә дә авыз ачарга форсат чыгуын аңлап, Айзат әйтәсе сүзен әйтеп калырга ашыкты:

— Нина Степановна, минем бөтенләй икенче төрле...

Ләкин Нина Степановна су эчәргә өлгергән иде инде.

«Туктагыз, тукта, хәзер» дип кулын гына селкеде дә, күзләрен еш-еш йомгалап, телефон трубкасын алды. Үзенең матур тавышы белән:

— Христофор Тер-Казарович, исәнмесез! Бу мин әле. Плохих борчый сезне. Бер генә минутка кереп чыгарга мөмкинме? Әйе, әйе, бик мөһим эш. Ваканция мәсьәләсендә. Татарстаннан килгән яшь белгеч белән... Рәхмәт, без хәзер...— диде.

Нина Степановна, телефон трубкасын куеп, торып басты. Айзат шунда аның озын буена, нечкә биленә карап, баскетболчы булгандыр бу кыз чагында дип уйлап куйды. Нина Степановна кечкенә көзге алдында чәчләрен рәтләде дә эре-эре атлап ишеккә юнәлде. Ишекне ачканда гына башын борып Айзатка дәште:

— Әйдәгез, иптәш Сәетбатталов.

— Кая?

— Ишеттегез бит, облоно мөдире янына.

Алар чыгып киттеләр. Секретарь ниндидер кәгазьләр сузып, ялварулы тавыш белән:

— Нина Степановна, Нина Степановна! — дип кычкырып калды. Директор, чебен кугандай, кулын гына селтәде.

Өлкә мәгариф бүлеге мөдире Христофор Тер-Казарович Цисернын кабинеты, нәкъ Плохих кабинетының астында булып, зурлыгы һәм формасы белән дә аннан аерылмый иде, аңа бары тик катлы-катлы тәмәке исе сеңгән иде. Ул ис бүлмәдәге бар әйбердән: мөдирнең үзеннән, хәтта пластмасса кара савытыннан да килгән кебек тоелды.

Христофор Тер-Казарович үзе зур башлы, пенснэле, тар җилкәле, кыска буйлы кеше булып чыкты. Ул ике-өч бөртек озын чәчен,— чәче генә булсын, таравын төрлечә итеп була дигәндәй,— ялтыр башына маңгаеннан җилкә чокырына кадәр сузып тарап куйган. Нәзек бармаклары белән чәчен сыпырганда ак нейлон күлмәгенең кыйммәтле каптырмалары җемелдәп-җемелдәп китә иде.

Ул Айзатлар белән кул биреп исәнләште, өстәлнең ике ягындагы күн креслога урнашуларын сүзсез генә көтеп торды.

— Христофор Тер-Казарович, сез минем татар теле һәм әдәбияты кабинетына бер мөдир кирәк икәнен хәтерлисездер инде? Менә, Казаннан иптәш килде,— диде Нина Степановна һәм күзләрен еш-еш йомып

алды.— Иптәш Сәетбатталов быел гына татар бүлеген тәмамлап чыккан. Эшләргә теләге бар, атлыгып тора. Хәер, яшь вакытта барыбыз да шулай идек инде.

Мөдир көмеш кысалы пенснэсен алды да, аңа өреп, кулъяулыгы белән ашыкмыйча гына сөртә башлады. Уң кулының баш һәм имән бармаклары белән борын өстендәге ике кызыл эзгә массаж ясаган шикелле баскалап торды. Һәм ашыкмыйча, тәкәллефсез генә:

— Аңлашылды, Нина Степановна. Бу турыда безнең яшь коллега үзе ни уйлый? Аның фикерен ишетү бик мөһим,— диде.

Нина Степановна белән сөйләшкән чакларда, ул пенснэ астыннан гына сөзеп-сөзеп Айзатка карап утырган иде. Айзат, моны сизмәгәнгә салынып, карт төлке, үзенчә яшь кадрларны өйрәнә инде бу, ниндирәк кош икән, канатлары ныкмы, очар күренәме дип, каурыйларын сыный инде, дип уйлап куйган иде. Менә хәзер Христофор Тер-Казарович, аның башындагы уйларның тамчысына кадәр калдырмый белергә теләгән сыман, туп-туры Айзатка карап тора башлады. Айзат уңайсызланып:

— Мин, иптәшләр, бөтенләй бүтән уйлар белән килгән идем,— диде.

— Нинди «бүтән» уйлар булырга мөмкин тагын? — дип гаҗәпләнде Нина Степановна.

— Беләсезме... э-э... Мин кыш көне генә өйләнгән идем.

— Хатыныгызның профессиясе нинди? — дип, тиз генә сорады мөдир.

— Укытучы. Немец теле. Институтны бергә тәмамладык.

— Бик тә шәп,— дип, аның сүзен элеп алды Нина Степановна.— Ул да безнең өлкәгә билгеләндеме? Бергә килдегезме? Эш табарбыз аңа да, табарбыз. Чит ил телләре безнең шәһәргә кирәктер дип беләм. Шулаймы, кадерле Христофор Тер-Казарович? Яшь педагоглар, яңа яшь гаилә... Бу турыда...

— Гафу итегез, Нина Степановна,— диде мөдир.— Хатыныгыз чыннан да безнең өлкәгә билгеләндеме, иптәш Сәетбатталов? Кайда ул?

— Ул Казан мәктәбендә укытырга калды.

— Ә сез?

— Ә мине монда җибәрделәр.

— Без хат язарбыз. Семья хәленә карерләр. Хатыныгызны да монда җибәрерләр.

— Киресенчә, мин үзем Казанга, хатыным янына кайтып китәргә уйлыйм. Сезнең белән сөйләшеп, рөхсәт язуы алып китәргә дип кенә килдем.

— Ә без рөхсәт язуын бирергә теләмәсәк?

— Бирерсез. Мин кешеләргә ышанам.

Нина Степановна күзләрен бик озак йомып торып ачты да, гаҗәпләнгән дә, шелтәләгән дә тавыш белән:

— Иптәш Сәетбатталов!.. Иптә-әш!..— дип сузып куйды.

Христофор Тер-Казарович, озын өч бөртек чәчен йолкырга теләгәндәй, озын бармаклары белән башын капшап куйды. Нина Степановнага карап:

— Безгә быел татар теленнән дүрт белгеч кирәк иде. Өчесе инде билгеләнгән урыннарына чыгып китте. Иптәш Сәетбатталовны сезгә бирсәм, Петр Петровичка ни диярбез? Бер урын аныкы бит. Тагын пенсионер Гали Илдаровны чакырып торырбыз микән? Тагын бер елга гына диярбез микән?

— Христофор Тер-Казарович, институтның үтенече беренче чиратта хәл ителергә тиеш,— диде Нина Степановна.— Һәм ул фәкать уңай якка гына хәл ителергә тиеш.

— Аңлыйм, ләкин...

— Юк, юк, Христофор Тер-Казарович!..

— Нина Степановна!..

Айзат дулкынлана башлады.

— Туктагыз әле, иптәшләр! Ник минем үз фикеремне дә тыңлап карарга теләмисез?

Христофор Тер-Казарович ябык кулларын кушырып күкрәгенә куйды. Аның йөзе җитдиләнде, күзләре ялтырый башлады. Ул ныкы тавыш белән өзеп-өзеп:

— Иптәш Сәетбатталов, без сезнең фикерегезне ишеттек инде. Бу — эшлекле сөйләшү. Без мәктәпләр язмышы белән шаяра алмыйбыз. Без сезгә ике эш тәкъдим итәбез: я институт, я авыл мәктәбе. Уйлагыз һәм фикерегезне иртәгә кереп әйтегез. Чыгарга мөмкин. Хушыгыз! — диде.

Айзат, сүзнең кинәт болайга борылуына аптырап, саубуллашырга да онытып чыгып китте. Тышта суык җил исә һәм янгыр тамчыларын кыеклатып биткә сибә иде. Үләннәр дә яңгыр белән юыла-юыла аптырап беткәннәр, су эчеп туйганнар һәм хәзер, иелгән башларын күтәреп күктән кояш эзләргә теләгән шикелле, тын гына торалар иде. Ике яктан да сукмакка авышкан ул үләннәр Айзат үткәндә аның чалбар балакларын чылатып калдылар. Айзат койма янына килде, текә яр астында шадраланып айкалган болганчык дулкыннарга карады.

Ул басып торган яр бик текә булып, аннан соң елгага кадәр йөз—йөз илле метрлап ара бар иде. Яр астыннан адым саен диярлек чишмәләр чыгып бөтен елга буен кеше керә алмаслык сазлыкка әйләндергән. Ара-тирә, бәләкәй утраулар шикелле, алабута, песи койрыгы һәм газета битедәй киң әрекмәннәр котырып үскән урыннар калкып тора.

Су читендә, түгәрәк бүксәләрен соры дулкыннарга каршы куеп, пластмасс уенчыклар шикелле бер оя ак каз тирбәлә. Елга уртасыннан, кабыргасына чулт-чулт бәрелгән салкын дулкыннардан курыкмыйча, печән төягән моторлы көймә бара.

Икенче як ярда — суднолар ремонтлау заводы. Аннан дон-дон, чаң-чаң тимер тавышлары ишетелә, һаваны, аҗаган уйнаган шикелле, сварка утлары ятырыптып җибәрә. Тимер тавышлары моңлы, сварка утлары тоныкк. Заводның теге ягында тайга. Киткән саен җәелә һәм куелана барып, кошлар очып җитмәслек җирләргә сузылган. Җилкәсенә болытлар һәм яңгырлар басып тора. Тайгага да авыр, аңа да күңелсез, ул да кояшны сагынган сыман күренә.

— Һе, кызык әле бу, менә, тора торгач бер амин,— диде Айзат (бер карарга да килә алмый аптыраган чакларында аның шулай сөйләнеп куя торган гадәте бар иде) һәм, кысык кара күзләрен тагын да кыса төшеп, бер көрсенде дә, ни булса да булыр дип, ак плитәләр җәелгән сукмак буйлап тулай торакка төшеп китте.

Коридорда, түшәктәй аркасын быгыр-быгыр кайнаган титанга терәп, яңгыр тавышын исе китеп тыңлагандай тын гына уйланып, Беатриса түтәй утыра иде. Айзат килеп кергәч, уфылдап кымшангандай итте, урындыгы да аңа кушылып шыгырдап куйды.

— Явамы, җаныем?

— Ява,— диде Айзат, юеш чәчләрен тарый-тарый.— Эре яңгыр гиз туктаучан да — туктамый: күкнең төбе тишелгән. Ник кирәк инде шул кадәр... Кемгә файда...

— Файдасы юк инде, җаныем, анысы хак. Көзге яңгыр җирне генә күгәртә. Әмма безгә әллә ни зыяны тими. Корыда арка җылытып тик утырабыз. Эпекәйне харап итә менә, эпекәйне, җаныем. Тәннең азыгы — эпекәй. Ничә тәүлек ура алмыйлар. Шытып, черәп, суга агып, туфрак белән буталып әрәм-шәрәм булып бетә инде эпекәй, бетә инде эпекәй. И алла...

— Бетмәс, Беатриса түтәй, хафаланма.

— Ничек хафаланмыйсың! Коя бит. Әле кибеттә эпекәйләрнең кы-

рык төрлесе тулып ята. Шул хәтле ашәкеләндек: күмәчләр әле генә мичтән чыкмаса, җылысы кулга беленеп тормаса — талашабыз. Шуларның җәзасын күрсәтмәсен... Халык оныта. Ачлык азабын күрмәгән — икмәк кадерен белми шул.

Беатриса түтәй күкрәкләрен калкытып уфылдады да мич башыннан шытырдап кипкән әрдәнәләр алып титанга якты. Сагызлы әрдәнәләрне гөлт итеп ут элеп алды. Титан көпшәсеннән кайнар пар бөркелә башлады.

— Син ничек уйлыйсың, җаныем, бездә эпекәйнең ничә еллык запасы бар икән? Ходай күрсәтмәсен дип әйтәм, теге нәрсәләр — фашистлар тагын чукына башласа, аптырап калырлык түгел микән?

Айзат, титан янында юеш кулларын җылыта-җылыта, рәхәтләнеп көлеп куйды.

— Юкка борчыласың, Беатриса түтәй,— диде.— Бездә икмәк бар. Менә уйла: узган ел без СССРдагы һәр кешегә бишәр пот икмәк үстердек.

— Кеше саен бишәр пот?

— Бишәр пот.

— Миңа да биш пот туры киләме, җаныем?

— Сиңа да, Беатриса түтәй.

— Балаларга дамы?

— Советлар Союзында яшәүче бөтен-бөтен кешегә.

— Күп икә-ән... Ә минем биш балам ачтан үлде. Биш пот, диң! Исән яшәсә аңа да булыр иде,— диде Беатриса түтәй, шаккатып.— Шул хәтле эпекәйне чәчәргә, үстерергә, җыеп алырга кирәк бит, җаныем, ә?.. Җен гыйлеме, җен тырышлыгы бар диярсең бу адәмдә... Кая, тагын нәчәльствога менеп төшим әле. Колакларына ни тукыйсың! Кышлар җитә, җаныем, утын кирәк... Ә син кереп ял ит. Утын кирәк, утын... Кышлар җитә...

Беатриса түтәй, кесәсеннән бер төргәк ачкыч алып, ни өчендер селкеп, чыңлатып карады да уфылдый-уфылдый чыгып китте. Айзат та, «Тәмле тамак» кафесына барып кайтмакчы булып, аның артыннан чыкты...

## 5

Кафедан чыккач, ул урамнар буйлап китте. Ул тагын өзелеп Чәчкәне сагына башлады. Юк, сөекле хатыныннан аерым яши алмаячак Айзат. Сөйгәнең еракта булгач, көн яктысы күзгә күренәмени! Җиреннән аерылган җиде ел җылар, ярыннан аерылган гомер буе җылар. Айзатның гомер буе җылыйсы килми. Аннан аерылып җир читенә киту нигә хаҗәт! Казан мәктәбендәге укучылар да, Себернекеләр дә Совет балалары ич... Айзат үзен моңа кадәр романтика җилләре эзләүче шашкын геройга чутламады һәм хәзер дә чутламый. Ул ашкынып алга да ашкынмаучы, артка да калышмаучы урта кул яшь кеше. Яңа гына өйләнеп, чибәр хатынын чын күңеленнән сөюче, гомергә сөяргә ант иткән яшь ир. Хатыны белән парлап яшәргә теле икән — моңа закон каршы киләмени!

Айзат тулай торакка кич кенә кайтты.

Озакламый бүтәннәр дә җыела башлады. Петр Петрович та кайтты. Аның соры күзләрендә, уйчан йөзендә арганлык сизелеп тора иде. Петр Петрович өстен чишенде. Күзге алдында яртылаш агарган озын чәчләрен тарады, җылы башмакларын алып киде. Урындыкка утырып алмаш-тилмәш балтырларын уды. Айзаттан:

— Я, дускай, бүген ниләр уңдырдыгыз? — дип сорады.

— Эшнең рәте юк, Петр Петрович.

— Нишләп?

— Гел монда калдыру турында сөйлиләр.
— Үзегезнең хак булуыгызга ышанасыз икән — сугышырга кирәк. Мин дә бүген бик каты сугыштым. Цисер белән дә, потребсоюз белән дә, хәтта склад мөдире һәм йөк төяүчеләр белән дә. Өлкә комитетының беренче секретарена җиттем.
— Ә ни өчен сугыштыгыз, Петр Петрович?
— Шифер өчен... Үзебезнең МСО [1], юкка мин дә тук дип, тик утыра. Шушыннан юлларга туры килде. Юкса Кул-Сарай директоры, түбәмә су үтә дип, җанымны ашый.
— Ә сез ашаттыгызмы? — диде Айзат, ышанмыйчарак.
Петр Петрович аңа көлемсерәп карап торды. Сары кашларын уйнатып, калын тавышы белән көлеп җибәрде.
— Ашыйлар, дускай, эһ тә итмиләр. Куркып тормыйлар. Безнең ишеләргә аны юнәтеп, моны табып, теге теләген, бу теләген үтәп торырга тиешле кеше итеп карыйлар.
Петр Петрович, аяк балтырларын массажлый-массажлый, җитди итеп:
— Ә мин сезгә, дускай, һичнигә карамыйча, бу шәһәрдә калмаска, авыл мәктәбенә китәргә киңәш бирер идем,— диде.
— Мин әле дә монда калмыйм бит, Петр Петрович.
— Ниятегезне беләм, тик тормышта һәр төрле көтелмәгән борылышлар булырга мөмкин. Язмыш борылышлары... Ә шулай да дөресен генә әйтегез әле, дускай, сез ни өчен Казанга шул кадәр атлыгасыз? Сәбәбе — хатыныгыз гынамы?
Айзат карап-карап торды да, ул белгәннән зыян булмас, бәлки файдасы тияр әле дип, аңа үзенең аспирантурада укырга нияте барлыгын сөйләп бирде. Петр Петрович аны бүлдерми-нитми игътибар белән тыңлап торды. Аннан, җитди итеп:
— Сезгә нәкъ киресен эшләргә кирәк,— диде.— Монда ике-өч ел укытырга, Себер татарларының диалектын өйрәнергә кирәк. Ул бик үзенчәлекле, бай. Сезнең өчен менә дигән материал. Соңыннан Казанга яртылаш әзер диссертация белән кайтачаксыз. Андагылар монда җибәреп кулыгызга фән ачкычын да тоттырганнар. Сезнең фән юлыгыз нәкъ менә шушы җирләрдә башлана да инде. Татар галимнәре өчен бөтенләй кеше кулы тимәгән яңа тема бу. Хәер, университет укытучыларыннан монда йөрүчеләр булды. Мәсәлән, бер ханым. Ул үзе шушы яклардан диләр. Шушында туып-үскән. Себер татарлары диалекты турында ике китабын мин дә беләм. Ләкин болар диңгездән бер тамчы гына әле. Яңа галимнәрнең яңа эзләнүләрен, яңа хезмәтләрен көтә бу яклар. Яшьләрне көтә. Сез яшь түгелмени! Мин сезнең урында булсам, үз алдыма китәргәме, калыргамы, дигән сорауны куеп та тормас идем. Казандагы укытучыларыма рәхмәт укый-укый, бу тәкъдимгә тешем-тырнагым белән ябышыр идем. Себер татарларының сөйләмен, диалектын үземнең киләчәктәге фәнни эшләремә төп тема итеп алыр идем дә эш урыныма килеп җитү белән, бер көнемне дә югалтмыйча, сүз энҗеләрен эзли башлар идем...
Петр Петрович, Айзатка уйларга вакыт бирү өчен микән, җылы башмакларын киде дә, кулына ялтыр чәйнеген тотып, коридорга чыгып китте. Бераздан кереп:
— Я дускай, уйладыгызмы, ни әйтәсез? — дип сорады.
— Белмим шул,— диде Айзат.
— Алайса тормышның теориясе түгел — практикасы хакында сөйләшик. Ансы аның зарурыйрак та, кырысрак та. Сез институтта калсагыз, күп дигәндә йөз сум хезмәт хакы алачаксыз. Артык түгел.
— Ие.

[1] МСО — колхозара төзелеш оешмасы.

— Сез — яңа гына институт бетергән студент кеше. Эшли башлау белән кеше төслерәк киенергә кирәк. Дөресме?

— Соң... билгеле инде. Студент акчасына...

— Сез яшь кеше. Хәзерге заманда шәһәрдә яшь кешегә күңел ачарлык нәрсәләр күп. Атлаган саен. Ләкин аларның барсына да акча кирәк. Акчаң булмаса, шәһәрдә бер стакан су да эчә алмыйсын. Дөресме?

— Дөрес.

— Бабайлар «шәһәрне макта, авылда тор» дип юкка гына әйтмәгәннәр. Ярый. Инде килеп, торак мәсьәләсе. Сиңа кеше өстендә торырга туры киләчәк. Ай саен егерме-егерме биш сум...

— ...долой!

— Ашарга-эчәргә кирәк. Бәлки әле әти-әниеңә дә җае килгәндә ярдәм иткәләргә кирәктер. Унбиш ел укыткан улларыннан ярдәм өмет итәргә аларның хакы бар. Тугансыз, кардәш-ырусыз кеше булмый. Тормыш бит — тегесе-монысы чыга да тора. Берәвенә пальто кирәк. Абый, әзрәк булыша алмассыңмы, ди. Икенчесе укырга кергән — стипендия җитмирәк тора дип яза. Ә син сер бирмәскә тырышасың. Йөзең белән җиргә капланырга теләмисең... Хатыныгыз килеп, тиз генә эш таба алмый да йөрсә... Менә.

— Мин калган тәкъдирдә аңа эш вәгъдә итәләр.

— Кай очракларда биргән вәгъдәләр дә үтәлми кала.

— Аңлыйм, Петр Петрович.

— Сез мине, дускай, зинһар, дөрес аңлагыз. Мин шәһәрне дошман күрүче дә, акчага табынучы да түгел. Яраткан эшең, тату семьяң һәм чын дусларың булганда яшәве кайда да күңелле. Тормышның әлегә сез белмәгән якларын ачыклап куйыйм дидем. Җаныгыз теләгән җирдә эшләргә хакыгыз бар, сез үзегезгә кулай карар кабул итәргә хокуклы.

— Чыннан да, шәһәр күп расход таләп итә ул. Авыл җире түгел.

— Авылда әйбәт кенә, тыныч кына бер кешегә урнашсагыз, алар сезне аена егерме сумга ашатып-эчертеп, тәрбияләп тотачаклар. Авылда ашау-эчү мул. Акча кадерле. Минем әни, акча ике төрле була, ди. Авыл акчасы һәм шәһәр акчасы. Икесенең холыклары ике төрле икән. Авыл акчасы ялкаурак, аз йөри, күп йокларга ярата... Берәр төенчеккә, я сандык төбенә төшеп яттымы, еллар буе чыкмый. Ә шәһәр акчасы — киресенчә. Ул бик кыбырсык нәрсә. Бер урында һич кенә дә утырып тора алмый. Аңа гел йөрергә, бөтерелергә, һәр кемнең кесәсенә кызыксынып борын тыгарга булсын. Ул күпне белергә, күпне күрергә, күп урыннарда булырга тели. Төрле тәм-томнарга да, чүпрәк-чапракка да бик ихлас, сразы күзен тондыра икән.

Әни аның такмагын да ишетеп кайткан.

Йөзләп кереп тора,
Йөзләп чыгып тора акчасы —
Ачык ике капкасы.

Тапканнар бит, ә, дускай?

— Халыкның теленә генә керсен — тешләп өзә.

— Менә шулай, дускай. Ни әйтергә теләгәнемне аңлагансыздыр инде? — диде Петр Петрович.

— Аңладым шикелле,— диде Айзат.

— Иртәгә тагын үгет-нәсихәт башланса, Аю-Ятар районына китәм, диегез. Мин анда эч пошарга ирек бирмәм. Эш белән күмеп ташлармын. Үзеңә, сеңелкәшкә дә сәгатьләр җитәр. Аның белән булгач, икегез аерым йорт алып урнашырсыз. Бездәге табигать, бездәге киекҗәнлекләр! Яз көне мин сезгә кыр тавыгы уйнаган урыннарны күрсәтер идем.

Айзатның йөрәге сулкылдап куйды. Бездәге табигать, киек-җәнлекләр, ди. Калын тавышында нинди горурлык! Дөрес, һәр шөлди, минекеннән матуры юк дип, үзе яшәгән сазлыкны мактый. Петр Петровичка, шунда туып-үскәч, билгеле, үзенең салкын Себере кадерле. Адәм баласы — үз иленең лаләсе.

Айзатның да туган авылы табигатьнең иң гүзәл җиренә урнашкан иде. Инде күптән, әтисе дә бала чакта, кыр ягында урман-болын, балыклы күлләр җитмәүдән җәфа чигүче өч-дүрт өй башы йөрәкләренә таянып тәвәккәлләгәннәр дә, бала-чагаларын төяп, Ык буендагы киек-җәнлек тулы, ырып-ерып йөргесез кара урманга килеп урнашканнар. Колач җитмәс юан-юан имәннәрне төпләп җир әрчегәннәр. Землянкалар казып тора башлаганнар. Алар артыннан бүтәннәр килгән. Землянкалар саны арткан. Урман кисеп урам сузганнар, урман аударып ихата урыннары әзерләгәннәр.

Ул вакытларда авыл күкрәп торган урман кочагында булган. Тирәякта киек-җәнлекләр чабып йөргән, күз күреме җитмәс болыннарда бил тиңентен чәчәкле сусыл печән үскән, әрәмәләрдә җыеп бетергесез балан, карлыган һәм бөрлегән, түмгәкле сазларда күгәрчен башыдай мүк җиләге, тау итәкләрендә кызыл яулык япкан шикелле булып чия һәм җир җиләге пешкән, камышлы күлләрдә чутсыз-чамасыз симез балыклар йөзеп йөргән.

Тик урманнар әкренләп авыл тирәсеннән чигенгән, күлләр ләмләнеп саеккан.

Җәнлекләрнең исән калганнары урман ешкынлыкларына, саз буйларына качканнар.

Айзат башлангыч мәктәптә укыганда тау буйларындагы чиялекләр дә, Олы күл белән Бәләкәй күл арасындагы зиреклек тә, күрше авыл белән ике арада гөрләп утырган мәгърур имән урманы да юк иде инде. Аларны корытып, кисеп бетергәннәр иде.

Ләкин шулай булса да табигать тиз генә бирешергә, бөтенләй үләргә теләми иде әле. Кеше белән күкрәккә күкрәк килеп тартыша, көрәшә иде.

Авыл әле һаман матур иде.

Айзат җиде еллык мәктәптә укый башлаган елны мәтрүшкәле болыннарга, кыр үрдәкләре, торналар, аккошлар, акчарлак-тәкәрлекләр гомер иткән төнбоеклы күлләргә тагын һөҗүм булды. Ыкның оҗмах сәйраны кебек гүзәл бер борылмасында аның йөгерек чиста суына таш буа аркылы ятты. Чите яшел камышлы саф күлләр болганды, шул күлләрнең куанычы һәм мактанычы булган табан балыклар, кара балыклар, өсләреннән туфан афәте давылланып үткәндәй, болганчык сулар белән актарылып өскә күтәрелде. Ык тугайларында сыер сөтенә хуш ис һәм тәм бирә торган чәчәкле печән болыннары, айлы төннәрдә каузылар[1] шылтыравы, чыклы таңнарда яшь тай кешнәүләре яңгырап, ат саклаучы малайларның учак ялкыннары бик ерактан күренеп торган хәзинә болыннар, мал-туар утлап көрәйгән, илнең асыл егетләре каерылып печән чапкан, алар киткәндә түбәсе күккә тигән яшел кибәннәр белән бизәлеп кала торган җанга якын болыннар өстендә кара дулкыннар айкала башлады.

Карлыган куаклары, кызыл-кара бөрлегәннәр караңгы су төбендә калды.

Күл читләрен, Ык ярларын яшел бәрхет шикелле бизәгән, җил-җил җилфердәп, карасаң арган күзләреңә ял бирә торган яшел яфраклы куе таллыклар корыды.

Кошлар туган-үскән илләре өстеннән җылап бер әйләнделәр дә, бала чыгарырдай тыныч урыннар эзләп; еракларга очып киттеләр.

[1] Каузы — ат муенына тага торган дүрт почмаклы калай кыңгырау.

Язгы кичләрдә бака тавышлары янгырамас булды.
Елкы көтүләре комлы ярларга күтәрелде.
Табигатьнең оҗмах шикелле гөрләп торган бер төше үлде. Аңа җилләр һәм дулкыннар хуҗа булды.

### 6

Бүлмә, гадәтенчә, бүген дә төн уртасында утын сүндерде. Айзат, йоклап китүгә, бик матур төш күрә башлады: чебиләп беткән ялан аяклы иптәш малайлары белән каен урманында йөгерә-йөгерә җиләк җыеп йөри, имеш. Агачлар да алар белән уйнап-көлеп сөйләшәләр һәм пароход булып кычкыралар, имеш...
Икенче көнне ул Христофор Тер-Казарович янына, кеше җыелганчы дип, кабул итү башлангач ук керде. Христофор Тер-Казарович йокысы туймаган кеше кебек йончу күренә. Ике-өч бөртек озын чәчен дә ялтыр баш түбәсенә тарап куймаган, галстугы да кыйшаебрак тора иде.
Айзат килеп керүгә ул, кулы белән буш урындыкны күрсәтте дә, аның утыруын да көтмәстән:
— Я, хәл иттегезме? Институтта каласызмы, әллә мәктәпкә китәсезме? — дип сорады.
— Мин сезгә әйттем инде, Казанга семьям янына кайтам,— диде Айзат, башын аска иеп.
— Тә-әк,— диде Христофор Тер-Казарович, хрусталь запонкаларын ялык-йолык китереп озын бармаклары белән өстәлгә чирткәләп алды.
— Туган-үскән ягымда яшәргә әллә минем хакым юкмы? — диде Айзат.— Татарстан — минем туган як. Моңа каршы килергә кемнең хакы бар?!.
— Минем хакым бар,— диде мөдир.— Без дә чит мәмләкәт түгел, бу да безнең туган илебез. Сез институтка педучилищедан килдегезме әле?
— Әйе.
Христофор Тер-Казарович пластмасс стаканнан карандаш алып календарь битендә тиз генә исәп-хисап чыгарды да:
— Сезгә хөкүмәт ике мең сум стипендия генә түләгән. Бурычны түләү — үзе бурыч. Барыгыз, Ватаныгызга шул бурычыгызны түләгез. Я монда, я районга! Документларыгызны тутырыгыз. Бетте.
Айзат чыгып китте.
Петр Петрович, чемоданын өстәл өстенә куеп, әйберләрен тутыра иде. Җылы башмагын газетага төргән җиреннән туктап, Айзатка карап торды.
— Кәефеңне кырдылармы әллә, дускай? — дип сорады.
— Кырдылар,— диде Айзат һәм, аякларының хәле беткәндәй, лып итеп урындыкка утырды.
— Ни диләр?
— Җибәрмиләр. Я институтка, я авыл мәктәбенә. Икенең берсе.
— Рәтләп аңлаттыңмы соң?
— Рәтләп сөйләшми.
— Эшләгәндә төрле чак була,— диде Пе.р Петрович.— Үзең ниндирәк уйда?
— Минем уйны бик сорап торалар! Хәзер ук я монда, я тегендә оформиться итәргә, ди.
— Минем кичә әйткәннәрне онытмадыңмы? — дип сорады.
— Онытмадым.
— Бик шәп! Киттек Аю-Ятарга минем белән?
— Туктагыз әле, Петр Петрович... Гомерлек эш бит. Киңәт кенә...
— Син, дускай, минәсең дә Аю-Ятарга направление аласың. Бергә китәбез дә барабыз. Бәхетле адәм икәнсең әле: беренче адымыңны ук

башлык белән бергә атлыйсың. Әйдә, болай сөйләшик: син миңа ияреп китәсең, район белән танышасың, мәктәбеңне барып карыйсың, коллегаларыңны күрәсең. Яратсаң, яныма киләсең дә «мин — бүгеннән сибиряк» дисең, яратмасаң — җибәрәм. Я?

— Белмим шул, аптыраган, йөдәгән, артын мичкә терәгән, дигән бит, прәме баш каткан.

— Аптырама, шайтан аптырасын. Урал ар ягына килеп җиткәнсең икән, тайганы да күреп китәргә кирәк.

— Чыннан да монда ятып хикмәт чыкмас. Мин риза, Петр Петрович. Кайчан китәбез?

— Дөрес карар. Сәгать ярымнан. Автовокзалга.

Айзат йөгереп өскә менеп китте. Ярты сәгатьтән бар йомышларын йомышлап кире төште. Петр Петрович каядыр чыккан иде. Шунда бүтән вакытларда күзгә-башка бик чалынмый торган Беатриса түтәй уфылдый-уфылдый килеп керде. Айзат аңа акча түләде.

— Кая җибәрәләр? — диде Беатриса түтәй, аңа паспортын сузып.

— Аю-Ятар диме.

— Шәп район. Булганым бар. Атай чирләгәч аю маена барган идем. Аларның шүре комбинатлары Русиядәге һәммә туку фабрикаларын тәэмин итеп тора.

— Ә-ә.

— Юлларың уң булсын, җаныем. Тырышып эшлә. Түрәләрең белән эрепләшмә. Алар эрепләшкәнне күтәрми. Килгәндә үзебезгә кер. Хуш, җаныем!

Беатриса түтәй дөп-дөп атлап чыгып китте. Айзат тиз-тиз генә Чәчкәсенә хат язып алды.

Әллә эткәйләргә дә берничә сүз язаргамы, кайда йөрүемне дә белми хафаланалардыр, дип уйлады. Ләкин коридорда аяк тавышлары ишетелгәч, вакыт тапсам, районнан салырмын, дип кәгазь-карасын җыеп куйды.

Ашыгып Петр Петрович килеп керде.

— Мин бухгалтериядә идем,— диде.— Я, җыендыңмы?

— Мин хәзер.

— Яхшы. Кояш чыкты. Шәт, юлыбыз уңар.

— Көн ачыла.

— Тәвәккәлләдек!..

Алар автовокзалга киттеләр.

Вокзал гадәттән тыш тыгын иде. Озын эскәмияләр, касса яннары, хәтта ишек төбе дә халык белән, чемодан-төенчекләр белән тулган. Касса ишеге белән диспетчерның тәрәзәсе ябык. Автобуслар йөрми, билет сатмыйлар. Сатылса да, касса янына барып җитүләре авыр булыр иде.

Петр Петрович, ишек алдына чыккач, Айзатны калдырып каядыр барып килде.

— Белештем: автобус бүген дә, иртәгә дә юк.— Аннан бер офыкка, бер юлга карап куйды.— Көн җылы, җил дә шәбәеп бара. Берсекөнгә бәлки булыр.

— Ә хәзер нишләргә соң, Петр Петрович?

— Урман борынына чыгабыз. Иөргәнгә юл ачылыр. Автобуслар паркта йоклап ятса да, йөк машиналары эштә. Нефтьчеләр, геологлар машиналарга һәм юлларга тамчы да тынычлык бирми. Тегесе кирәк, монысы кирәк...

Ак таш җәелгән чокырлы-чакырлы биек дамба буйлап ике километр шае баргач, алар ерактан ук ике гигант дуга шикелле күренеп торган тимер күпергә җиттеләр һәм, аны чыгып, таш эскәмиягә утырдылар. Петр Петрович яртылаш агарган куе озын чәчләрен сыпырды, текә

маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирләрен сөртте. Аяк балтырларын алмаштилмәш ышкып торды.

Тимер күперне дөнгырдатып машиналар үтте, брезент чабуын җилфердәтеп ГАЗ-69 выжлап үтте, озын торбалар төягән куәтле ЗИЛләр үкерә-үкерә үтте.

Ләкин аларның берсе дә юл уңае булмады. Озак кына вакыт үткәргәч, Петр Петрович:

— Урман борынына ук бармый булмас,— диде.

Алар корырак урыннарны сайлый-сайлый, тая-тая тагын алга киттеләр. Шәһәр артта калды. Ярты сәгать баргач, көймә сырты шикелле кабарып торган шоссе уңга борылды һәм купшы яшь наратлар гаскәр кебек саф-саф тезелеп торган урманга килеп керде. Тәмле сагыз һәм ылыс исләре белән аралашкан дымсу саф һава сулышларны рәхәтләндереп җибәрде.

— Шушында көтик,— диде Петр Петрович.

Юл читенә чыгып икесе ике нарат төбенә утырдылар. Петр Петрович күлмәк изүен ычкындырып җибәрде. Аның ябык йөзе суырылып киткән, күзләренә арганлык билгеләре чыккан иде. Ул, чалбар балагын сызганып, балтырларын ышкый башлады.

Айзат, үзенә сиздермәскә тырышып, аңа карап утырды. «Һе, кызык әле бу, менә, тора торгач бер амин,— дип уйлады.— Кырык беренче көзендә Мәскәүне сакларга килеп өлгергән һәм немецларны туздырган Себер дивизиясендәге баһадир сибиряклар шушылай булдылар микәнни? Немецлар моның нәрсәсеннән курыктылар икән?!. Һм, батырлык кыяфәт белән түгел шул...»

Күк йөзе атна буе теңкә корткан елак болытлардан тәмам чистарган һәм кояш та, ни гомер күзгә-башка күренмичә болыт артында качып ятуы өчен акланырга теләгәндәй, шәп кенә кыздыра башлаган иде. Вак-вак күлдәвекләр ялтыраган юеш юлдан, басулар өстендә тирбәлгән рәшә сыман, дерелди-дерелди җылы пар күтәрелә иде...

Шулай кояшта арка җылытып рәхәт кенә утырганда, борылыштан гүли-гүли зур МАЗ килеп чыкты. Аның артыннан икенчесе күренде, өченчесе... тугызынчысы. Тугызының берсе дә утыртмас микәнни?

Петр Петрович машиналар каршысына чыккан иде инде. Бик тәвәккәл кыяфәттә кул күтәреп тора иде. Айзат та, сулы канауны сикереп, аның янына килеп басты.

Алдагы машина туктады. Шофер тәрәзәгә башын тыгып, төксе генә тавыш белән:

— Ни бар? — дип сорады.

— Сез, дускай, Аю-Ятар аша үтмисезме?

— Үтсәк соң?

— Безне дә утыртмассыз микән?

Шофер майга каткан кепкасын күтәреп башын кашыды.

— Юлның ничек икәнен күрәсезме?

Арттагы машиналар түземсезләнеп кычкыртырга тотындылар.

— Ничек тә кайтырга кирәк иде шул. Укытучыларның август киңәшмәләре җитте.

— Ну, ярый, утырыгыз. Ләкин кисәтеп куям: машина батканда кулларны кесәгә тыгып торыштан булмасын. Саз уртасында ташлап калдырырмын.

— Рәхмәт, дускай!

Әрҗәдәге кешеләр Айзат белән Петр Петровичны җәһәт кенә өскә тартып алды. Машинага нефтьчеләр өчен кирәкле кораллар салынган авыр такта ящиклар, өч җәпле бораулар һәм Айзат белмәгән төрле тимер-томырлар төялгән. Әрҗә түрендәрәк, шул ящиклар өстендә, берничә кеше утыра иде.

Машина, арт тәгәрмәчләре белән салулап, кузгалып китте. Аның артыннан тезелешеп бүтәннәре иярде. Айзат белән Петр Петрович, җайлырак ящиклар табып, бортка терәлеп утырдылар. Айзат машинадагыларны «кәртечкәгә» төшереп алды.

Түрдә өстенә соры плащ, башына шундый ук соры берет кигән, сапсары озын толымлы, очлырак иякле, кечкенә гәүдәле сылу кыз утыра. Аның янында кара чехоллы зур чемодан. Чемодан өстендә, машина чайкалган саен селкенеп, менә-менә төшеп китәм дип, чәчәкле зонт ята. Кыз бер кулы белән борт читенә тотынган, икенчесе белән калку күкрәкләре өстенә салган алтын толымнарын учлаган да артка карап бара.

Кыз янында, очлы тезле озын аякларын җайсыз бөкләп, башына козыреклы мех бүрек, өстенә бөрмә билле кыска пальто кигән, каратут йөзле егет утырган. Алтын кысалы күзлеге һәм кыска куе сакалы аны XIX йөз интеллигентларына охшата. Машина чокырга туры килгән вакытларда ул кызга елышып куя, аннары читкәрәк тартыла. Елмаеп нидер әйтә. Елмайган чакта эре ак тешләре ялтырап китә.

Алардан болайрак чип-чиста кырылган какча яңаклы, туры борынлы уйчан кеше утыра. Аның күз төпләре бераз күгәреп, озак йокламаган кешенеке кебек шешенебрәк тора. Ул, күршеләренә сиздермәскә тырышып, вакыт-вакыт көрсенә. Еш-еш төкереген йота. Шул чакларда аның чыпчык күкәе кадәр бугаз төене калтырап куя. Ак күлмәгенә искәрәк кара галстук таккан. Күп йөреп тәсе уңган эшләпәсенең бер чите, туры гына торырга теләмичә, уң колагы өстенә салынып төшкән. Яка читләре сары күн белән каеп тегелгән телогрейкасына төрле төймәләр тагылган. Аның кирза итекләре һәм туп кебек түгәрәк юл капчыгы гына яңа. Ул, текәлеп-текәлеп, арттагы машиналарга, пычрак юлга, өстенә сары таңкәләр шикелле сары каен яфраклары, нарат-чыршы энәләре сибелгән сулы канауга, агачларга карый.

Аңа каршы бишенче кеше утырган. Аның тулы йөзе туктаусыз елмаеп бара. Соры күзләреннән шаянлык сибелә. Ул һич кенә дә тик утыра алмый. Кыбырсый да кыбырсый. Кызыл буй сызыклы галстугы кыйшайган, бер якасы өскә, икенчесе аска карап тора. Очлы башлы шәп туфлиенә һәм чалбар балакларына балчык чәчрәп беткән. Пинжәгенең аскы төймәсе генә эләктерелгән. Шакмаклы кепкасы ящиклар арасына төшеп кысылган. Кепкасы янында ике мылтык чехолы ята. Ә ул үзе боргалана, елмая, сикереп киткән чакларда ухылдый, кычкырып куя. Җай килгән саен юлдашларына сүз кушарга, әңгәмә бәйләп җибәрергә тырыша. Ләкин алар үзләре дә машинага шәһәрдә генә утырып, ныклап танышырга да, сөйләшергә дә өлгермәгәннәр бугай әле. Шуңа күрә теле кычытып барган Аучыга (мылтыклы булгач Айзат аны аучы дип уйлады) яңа кешеләрнең пәйда булуы бик хуп килде. Ул аларга утыру белән әзрәк хәл җыярга, тын алырга ирек бирергә теләгәндәй текәлептекәлеп карап барды да, ахырында түзмәде, булды, җитәрлек ял иттеләр дип уйлады, күрәсең, тамагын кыргалап сорау бирде:

— Гафу итегез, сез кая кадәр барасыз? — диде.

— Аю-Ятарга,— диде Петр Петрович.

— Гафу итегез, барасызмы, кайтасызмы?

— Кайтабыз.

— Мин дә кайтам. Тик сездән арырак.

— Э-э.

Яңа кешеләрнең сөйләшергә атлыгып тормавы аны бераз уңайсыз хәлгә төшерде. Ул бүтән сорау бирергә яхшысынмыйча, тамагын кыргалады да юлга карап бара башлады.

Айзат тайга урманнарын моңарчы поезд тәрәзәсеннән генә күргән иде. Менә хәзер ул аңа бик якыннан карап бара. Ләкин тайганың Татарстан урманнарыннан аермасы юк. Шул ук каен, нарат һәм чыр-

шылар үскән гади урман. Тик каеннар гына иртә саргайган. Әле август ахыры гына, ә инде аларга монсу сары төс йөгергән. Күлле һәм сазлыклы урыннарда каен урманын зирек белән усак урманнары алыштыра. Әледән-әле төп-төз юл шикелле булып еракларга сузылган диләнкәләр, урманны ярып үткән тимер аяклы электр линияләре күзгә чалынып кала. Урман чигенгән урыннарда салам эскертләре белән чуарланган иген басулары, сабаклары көеп егылган бәрәңге басулары күренә. Еш кына эре һәм вак авыллар, алар арасындагы начар юллардан әкрен генә үрмәләгән машиналар, бик күп күл-елгалар, бик күп күперләр килеп чыга. «Нәкъ бездәге шикелле,— дип уйлады Айзат,— аермасы юк».

Машина бүрәнә күпердән дөбердәп чыкты да сирень куаклары, яшь чыршылар үскән төзек һәм яңа зират яныннан үтте.

## 7

Айзат белән Чәчкә бер көнне яшәү һәм үлем турында бик озак бәхәсләшкәннәр иде. Әле кайчан гына! Уйласаң, кичә генә кебек. Карасаң, инде озын җәй үткән, көз җиткән. Июнь ае иде. Студент халкының тыз-быз килеп, утка-суга төшеп, тамактан калып йөргән чаклары.

Айзат имтиханнарны дәреслекләргә ябышып ятмыйча, конспект ятламыйча, үзе уйлаганча сөйләргә күнексә дә, Чәчкә лекцияләрне генә түгел, шул лекцияләргә тәкъдим ителгән өстәмә әдәби материалларны да җентекләп өйрәнеп чыгучы, төгәллек яратучы кеше булганлыктан, быелгы имтиханнар вакытында Айзатка да гел китаплар күтәреп йөрергә, бик тырышып укыгандай күренергә туры килде.

Алар һәр көнне иртән Идел, Казанка буйларына, парк-бакчаларга китеп, кичкә кадәр «зубрить итеп» яталар иде.

Күңелле чаклар, бәхетле чаклар!

Кире кайтмас чаклар.

Бер көнне алар Максим Горький исемендәге культура һәм ял паркына барып чыктылар. Әле иртә булганлыктан, көлке бүлмәләре, аттракционнар эшләми иде. Шуңа да карамастан, дәү паркның күләгәле эскәмияләре, куак аслары, чирәм өсләре, Казанкага төшә торган чокыр-чакыр буйлары — һәммәсе ял итүче халык, бала-чага, имтиханга әзерләнүче шәрә аркалы студентлар, укучылар белән тулган. Кеше күзенә бәрелми торган ышык урыннарга ия чыгып беткән. Айзат белән Чәчкә, анда кагылып, монда сугылып, аптырап йөрделәр дә зират астындагы юан өянкеләр күләгәсенә килеп урнаштылар. Монда да алар теләгән тынычлык юк иде югын. Өстә зират, аста ашъяулык-ашъяулык бәрәңге җирләре. Алар аша кешеләр Казанкага су коенырга үтеп-сүтеп йөриләр, шәһәр ягыннан трамвай чыңлаулары, өстән аэродромга төшәргә барган самолет гөрләүләре, Арча тимер юлыннан поезд шыкылдаулары, Казанка ягыннан су коенучы һәм пляжда ятучы халыкның дулкын шаулавыдай өзлексез гөжләве ишетелеп тора иде.

Ләкин нишләмәк кирәк? Алар сәгать текелдәсә дә йоклый алмый азапланучы бәндәләр түгел ич. Өянке төбенә газеталар һәм, Чәчкәнең сумкасыннан алып, иске одеал җәйделәр дә, трусик белән купальниктан гына калып, китап «кимерергә» тотындылар.

Кояш күтәрелеп, өянке күләгәсе икенче урынга күчкәч, одеалларын өстерәп күләгә артыннан үзләре дә күчтеләр. Айзат газетадан икесенә дә эшләпә ясады. Чәчкә җаны-тәне белән немец теленә чумса да, Айзатның башына һич нәрсә кермәде. Тирә-яктагы шау-шу дикъкатен гел читкә тартып торды. Кыбырҗыды-кыбырҗыды да, ахырында түзмәде, китабын яфрак кыстырып ябып куйды.

— Уф, әйдә су коенып килик, Чәчкә,— диде.

— Әле килгәндә генә Кремль буенда коендык бит,— диде Чәчкә.

— Кыздыра, чыдар әмәл юк.

— Уникегә кадәр укыйк инде, Айзат. Мин бу бүлекне бетерим.

Айзат авыр сулап тагын сузылып ятты. Тау өстендә агарып күренгән кабер ташларына карап:

— Әнә кемнәрнең имтихан дип иза чигәселәре юк. Гүрләре дә салкынча, рәхәт,— диде.

Чәчкә китабы белән анын аркасына сукты:

— Тәүбә дин, юньсез, юраганың юш килсә!

— Мин юрамыйм ич, әйтәм генә.

— Андый нәрсәне әйтергә түгел, уйларга да ярамый.

— Кара әле, Чәчкә...

— Укы әйдә, укы!

— Баш авырта. Әзрәк ял итик. Кара әле зиратка гына. Йөз еллар буе күпме кеше күмелгән. Анда исемлеләреннән исемсезләре күп. Кеше туган, яшәгән, кайгырган, шатланган, менә безнең шикелле мәхәббәт хисләреннән исергән, өйләнгән, хезмәт иткән, яраткан эше булган, ул да без басып торган җирләрдә йөргән, ә бер бәхетсез көнне шыпырт кына дөньядан китеп барган. Анын кояшы баткан. Күпмедер вакыт үткән — без инде анын яшәү-яшәмәвен дә, исемен дә белмибез. Анын дуслары да, туганнары да, балалары да юк — гомумән аны белүче юк. Кызганыч бит, әйеме?

— Син бик хисләргә бирелүчән. Кызганыч, әлбәттә. Тик нишлисең,— табигать законы. Әҗәлгә чара юк.

— Дөрес түгел бу закон.

— Төзәт.

— Илле ел, алтмыш, җитмеш ел буе кеше укый, өйрәнә, тәҗрибә, акыл җыя. Шул тәҗрибәсе белән рәхәтләнеп хезмәт итәсе, гомер буе нинди каршылыкларны җиңә-җиңә, интегә-интегә туплаган ан-белемен тормышта кулланасы, файдасын күрә башлыйсы урында — үлә дә китә. Дөресме әллә шул закон? Кыргый закон бу, гуманизм кагыйдәләренә капма-каршы.

— Ә син, Айзат, болар турында уйлама. Әле безнең яшисе бар. Әгәр һәр кеше синең шикелле фикер йөртсә, тормыш үсүеннән, алга баруыннан туктар иде һәм, ахыр килеп, дөнья бетәр иде. Монысы инде, минемчә, шулай ук тормыш законы, тик психологик закон.

— Дөрес. Ләкин без дә шулай югалырбыз бит. Үләрбез дә тынарбыз. Мин дә, син дә. Ә минем сине бер кайчан да югалтасым килми. Чәчкә, гөл чәчкәсе шикелле балкып, мәңгегә минем каршымда торырга тиеш.

— Кайгырма, мин синнән аерылырга теләмим. Мин мәңгегә синең белән булачакмын.

— Рәхмәт! Кайчакта күңелгә әллә нинди ерундалар килә дә бозлы суга чумгандай чиркәнеп китәм. Без — ике исәр, әйеме?

— Ялгышмасам, исәрләр монда берәү генә шикелле. Бер кеше дә эзсез югалмый, исемнәре, эшләгән эшләре кала.

— Геройларның.

— Чын кешеләрнең.

— Без бәлки чын кешеләр дә булырбыз. Тик исемнәребез, белмим, гасырларга күчәр микән? Безнең һәйкәлләр янында пионерга кабул итүләр булыр микән?

— Бөтен кешегә дә һәйкәл куя башласалар, җир өстендә урын җитмәс.

— Моңа хәтле безнең шикелле гади укытучыларга ничә һәйкәл куйганнар? Я, әйт әле, ничә, беләсеңме?

— Без әле укытучы түгел.

— Булырбыз. Анысы кыен түгел. Ә менә авыл укытучысы килер буыннарга исемен калдырып китә алыр микән?!

— Яраткан эшем булса, ул миңа рухи ләззәт, туган илемә файда бирсә, коллегаларым мине хөрмәт итсә, тәнем сәламәт булса — мин тормыштан канәгать. Артыгы кирәкми.
— «Артыгы», синеңчә, нәрсә?
— Артыгымы? Данга, исемеңне мәңгеләштерергә омтылу.
— Эһем, эһем. Син мине дөрес аңламагансың икән, Чәчкә. Миңа дан кирәкми. Мин бер ерак авылдагы гади укытучыга караганда ВУЗ, я фәнни институттагы галимнәр илгә күбрәк файда китерә, дип әйтергә генә телим. Әллә мин хаклы түгелме?
— Кешесенә һәм эшенә карап. Профессорлар арасында да карьерист адәмнәр булырга мөмкин.
— Синең әтиең әллә карьеристмы?
— Түгел. Ул җаны-тәне белән фәнгә бирелгән, ул фән өчен генә яшәүче кеше. Тик хәзер сүз аның турында түгел. Синең турыда.
— Минем турыда? Менә тагы, мин әле кайчан профессор булдым?
— Булырга хыялланасың түгелме соң?
— Генерал булырга хыялланмаган солдат юк диләр. Биек тауның томаны да биек. Кабатлап әйтәм, мин үзем дә бер ерак авыл мәктәбендә балалар укытуга караганда, аспирантура бетереп институтларда эшли башласам, мәгариф системасына үземнән күбрәк өлеш кертер идем, мин моңа шатланыр гына идем. Бу — гаеп түгел. Сәетбатталовлар нәселеннән әле моңарчы галим чыкмаган.
— Эх син, мактанчык. Эрләмәгән-сукмаган, ди. Галим дә булып куйды.
— Ялган тыйнаклык күркәм гадәт түгел. Су түбәнгә омтыла, кеше югарыга.
— Әйдә, әйдә, укы, хөрмәтле галим, укымасаң, академик була алмассың. Надан академикларны яратмыйлар.
— Башыма чорт та керми. Коенып чыгыйк әле.
— Укы!
— Мәрхәмәт итегез! Бу колыгызның тәк тә дивана мие быгырдап кайный башлады.
— Әйдә алайса, түзмәс җан.
Алар, кырык якта кырык төрле халык кырылып торуына әһәмият бирмичә, кочаклаштылар да үбештеләр.
Яшьлек көче белән сөю хисе күңелсез уйларны суга барып җитмәс борын ук юып төшерде.
Дөнья түгәрәкләнде.
Күктәге кояш янына бәхет кояшы менеп басты.
Алар, кулларын тотышып, шәрә аякларын шул ике кояшның якты нурларында ялтырата-ялтырата, көлә-көлә иркә дулкыннар эченә йөгерделәр...

## 8

Бер урында машиналары баткач, аны төшеп эттеләр дә тагын үз урыннарына менеп утырдылар. Колонна әкренләп тагын чакрымнар җыя башлагач, күңелләнеп киттеләр. Бу тукталыш бер-беренә якынаерга, күптән кычытып килгән телләрне кашырга унайлы сәбәп булды. Сөйләшә башладылар.
Яшь егет алтын кысалы күзлеген рәтләп куе сакалын сыпырып алды, бүтәннәргә күз төшереп елмайды.
— Һә, торф чыгаручылар бригадасына әйләнгәнбез бит,— диде.
— Ә ни өчен торф чыгаручылар? — дип сорады кыз.
Егет, күршесенең үз сүзен игътибарсыз калдырмавына шатланып:
— Өсләрегезгә карагыз әле,— диде.
Башкалар да елмаерга мәҗбүр булдылар: бит-куллары, өс-башлары

саз пычрагына буялып беткән иде. Аучы шакмаклы кепкасы белән маңгаен сөртә-сөртә:

— Я, беттеме, инде хәзер беттеме? — дип төпченде һәм кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Хатын әйтер, ю-ук, парень, син минем ирем түгел, минем ирем калага җыелышка киткәндә болай пычракка батмаган иде, дип әйтер.

Аның юк кына нәрсәдән дә тәм табып рәхәтләнеп кеткелдәвеннән бүтәннәр дә көлде. Карагыз әле, җәмәгать, бергәләшеп шактый җир үтәсе бар, ә без исемнәребезне дә сорашмадык, танышырга кирәктер бәлки дип, һәм бу тәкъдимне барысы да бик хуп күреп, тиз арада танышып алдылар. Үзләре белән иңгә-иң терәлеп утырып баручыларның кем икәнлекләре ачыклангач, иркен сулап куйдылар, тартынуларын онытып, уйнап-көлеп, сөйләшеп барсаң юл үрчемле була дип, гади генә сөйләшә башладылар. Машина әрҗәсе җыйнакланып, җылынып киткәндәй булды.

Араларындагы бердәнбер кыз музыкант булып чыкты. Мәскәүне ташлап, геологлар базасына бара икән.

— О-о, Тамара, Тамара! — диде аның күршесендәге егет, тәэсирләнгән күренергә тырышып,— Тамара дисәләр, күз алдыма Кавказ килеп баса. Лермонтовның «Мцыри»ы. Сез ул поэманы беләсезме?

— Беләм.

— Яратасызмы?

— Яратам.

— А-а, ул гүзәл әсәрне яратмыйча мөмкин түгел. Аның һәр юлы арфа кыллары шикелле чыңлап тора. Хәтерлисезме:

Высокий дом, широкий двор
Седой Гудал себе построил...

Тамара шигырьне дәвам итте:

С утра на скат соседних гор
От стен его ложатся тени.
В скале нарублены ступени...
Княжна Тамара молодая
К Арагве ходит за водой.

— Браво! — диде егет.— Лермонтовка гашыйк тагын бер кешене очратуыма бик куанам.

— Нурбак туган, үзеңне гашыйк итмәсен,— диде Аучы һәм Тамарага карап көлеп куйды, җайлап утырды.

Ләкин егет югалып калмады.

— Әгәр шулай булса, мин үземне бәхетле адәмгә хисаплар идем. Кызганычка каршы, сондыр дип уйлыйм. Тамарабызның да Демоны булмый калмас.

Тамараның чынлап та «Демоны» бар икән. Ул ерак тайгадагы геологлар базасында повар булып эшли икән. Тамараны чакырып инде алты телеграмма суккан. Тамара тартынып тормады, ул телеграммаларны кесәсеннән алып күрсәтте. Хәзер аның нәкъ базага, кияве булачак кеше янына күчеп баруы икән.

Петр Петровичның йөзе ачылып китте.

— Молодцы,— диде ул.— Без нәкъ аның кебек кешеләргә мохтаж. Геологларыбыз да, нефтьчеләребез дә бар. Ә менә аларның тамакларын туйдыру хакында уйлаучылар сирәк.

Тамара аның белән килеште.

— Менә шул-шул. Сез дә аның сүзләрен әйтәсез.

— Ә сез бергә укыган идегезме әллә?

— Юк. Ул армияда укыган. Москвада бик зур ресторанда эшләде.

— Кинәт кенә кунәргә уйлаган — эшен ошатмадымы?

— Кешеләрен.
— Ничек?
— Ул бик кызу канлы. Башына уй кердеме — чыгар димә. Тоткан жиреннән сынлыра. Бер көнне кайтты да, расчет алдым, ди. Нигә, дим. Повар эше барыбер язучылар, композиторларныкы шикелле ижат эше, ди. Мин, ди, төн йокламый, бөтен жаным-тәнем белән тырышып әзерлим, тәмле булсын, дип янам-көям, ә шул ризыкларның кайберләрен эткәләренең акчаларын туздыручы жыен малай-шалай, тәмәке тартучы чәрелдек кыз-кыркын, алдына ни килгәнне карап та тормыйча, аракы артыннан ватып-жимереп чәйнәп йоткан чакта йөрәгемә кан сава, ди. Китәм, үзем шикелле, эшләрен чын ижат дип эшләүчеләр янына китәм, ичмасам, әзерләгән ашымны чын кешеләр ашасын, елмайсыннар, күңелләре күтәрелсен, тагын да тырышыбрак эшли башласыннар, ди, әйеме?
Аны ничек үеннан кайтарасын! Китте. Жир читенә китсә китте, әмма үзенекен итте. Хатында, монда бер әрәм тамак та юк, ашларымны бик яратып ашыйлар, үземне кулларында гына күтәреп йөртәләр, дип яза иде, әйеме? Болан итеннән яңа салат уйлап тапкан, шигырьләр яза башлаган, әйеме?..
— Язучы авылда туа, шәһәргә шуа, дигән булалар, киресенчә икән бит,— дип көлде Аучы.— Хикмәт чыкмый калмас моннан, чыкмый калмас.
Нурбакның күзләре очкынланды:
— Тамара, мин сезнең ул үз сүзле Демоныгыз турында кайчан булса да унай фельетон язачакмын.
— Хикәягезгә мине дә өстәп куярсыз,— диде Тамара, көлеп.— Без бит хәзер икебез бергә эшләячәкбез, әйеме. Бәлки минем дә кайчан булса да үз көем булыр әле.
— Булыр, булыр! — диде Нурбак.
Юл чыршы урманына килеп керде. Корыды. Машиналар тизлекләрен арттырып, чыршы күркәләрен таптый-таптый, шәп кенә бара башладылар. Тәгәрмәчләргә бәйләнгән чылбырлар, ат юыртып килгән шикелле, каты жиргә шак-шок бәрелде, салынып торган яшел ботаклар кабина түбәсенә чаж-чож сыдырылды. Андый урыннарда Нурбак:
— Башыгызны саклагыз! Игътибар — иелдек, игътибар — иелдек! — дип иптәшләрен кисәтә торды. Тураеп басты да кинәт:
— Тиен, тиен! — дип кычкырды.
Кешеләр ашыгып ул күрсәткән якка карадылар.
— Кайда? Кайда? Миңа да күрсәтегез әле? Кайсы агачта? Мин күрмим,— дип шаулаштылар.
— Әнә теге сәнәк шикелле наратка карагыз! Һәй, үтеп киттек инде. Хәер, безне куркуга качты бугай ул,— диде Нурбак, хәйләкәр елмаеп. Аннан соң Аучының мылтык чехолларына ымлап елмайды:
— Автомобиль тартмасында ни шалтырап баруын белә хайван: сул күзенә пуля әләктерәсе килми.
— Ә нигә сул күзенә?
— Соң безнең Себер аучылары турында тиеннең тиресен бозмас өчен аның күзенә генә төзиләр дип язалар ич. География дәреслегендә. Үзем күрдем.
— Юк сүз,— диде Аучы.— Сөйлиләр тузга язмаганны. Тидерерсең күзенә генә. Теге... өч чакрымнан черкинең сул күзенә ук тидергән оста Мәргән шикелләмеме? Әмма әкият шул ул, парень.
— Ә сез үзегез болай... ничә тиен аттыгыз? Аюлар да бардыр инде? Аңысын без сорамасак та соңга таба үзегез сөйләрсез.
Аучы, дөресен әйтергәме-юкмы дигәндәй, егеткә карап торды да шәп туфлиенең очлы башы белән аяк очында яткан чехоллы мылтыкларына тибеп куйды. Аннары көлеп жибәрде.
— Үз гомеремдә сукыр аю да атканым юк минем.

— Менә сиңа кирәк булса — аучы! — дип көлештеләр юлчылар.
Петр Петрович калын тавыш белән көлүчеләргә кушылды һәм, сары кашларын уйната-уйната:
— Дускай, Себер аучыларының абруен төшермә инде, монда яңа кешеләр дә бар,— диде.
— Ә-әй, булмаганны булды дип ялганлар хәлем юк,— диде Аучы, кул селтәп,— әйтсәм әйтим инде: моннан берничә ел элек кенә мылтыктан ата башладым әле мин.
— Китчәле!..
— Ышанмыйсызмы? Менә! — Аучы йөзенә җитдилек чыгарып, рәттән өч мәртәбә чукынып алды.— Курка идем.
Нурбак сызгырып куйды.
Мотор гөжелдәвен бердәм көлү тавышы күмеп китте. Шофер, тизлекне әкренәйтеп, кабина ишегеннән башын сузды.
— Нәрсә бар?
— Юк, болай гына. Үзебездән үзебез көләбез.
— Кызык анда сезнең. Руль тотасы юк. Мин дә рәхәтләнеп әрҗәдә генә барыр идем.
Шофер төкерде дә шартлатып ишеген япты һәм газ бирде.
— Сез, минем белүемчә, район аучылар җәмгыятенең җитәкчесе бит? — дип сорады Петр Петрович.— Өлкә газетасына да яздылар түгелме? Хәтерем ялгышмаса, тәнкыйть тә, фельетон да түгел иде бугай?
Аучы тагын кеткелдәп көлде.
— Фельетон ди сезгә! Мактадылар. Оешма эше шәп минем.
— Ничек алай килеп чыкты соң!
— Нәрсә?
— Председатель булуыгыз дим?
— Ә-ә. Дөньяда очраклы хәлләр еш була бит.
— Очраклы дисезме?
— Әйе. Бу эш сезне кызыксындыра, ахры?
— Иренмәсәгез сөйләгез!
Башкалар да:
— Әйе, әйе. Кыен булмаса, сөйләсәгез иде. Юл озын,— диештеләр.
Аучы җайлабрак утырды. Тулы йөзенә тагын елмаю җәелде.
— Менә болай булды... туктагыз, башта үзем көлеп куйыйм әле... Мин үзем тумыштан мондагы түгел. Дала ягыннан ун-унбиш ел элек күчтем. Бер сүз белән әйткәндә, чын сибирякка әйләнеп беттем дияр идем — аучы түгел. Мылтык тотып чыпчык та атып караган юк. Яши башлагач дуслар, иптәшләр табылды. Икесе белән бик нык дуслашып киттек. Кунакка йөрешәбез. Дусларымның берсе колга кебек озын, икенчесе төп шикелле тәбәнәк. Аларны эштә дә Тарапунька белән Штепсель дип йөртәләр. Мин дә озын иптәш белән кыска иптәш дип сөйлим, яме...
Шулай бер чакны моннан ун еллар элек, эчеп утырганда, тегеләр миңа бәйләнергә тотынды. Әйдә, диләр, без сине ауга өйрәтәбез, диләр. Тайгада яшәп үз гомереңдә сыңар аю да үтермәгәч, сине моннан соң ничек арабызга кертик, ничек оялмый дус итеп йөрик, диләр. Ай-һай, үтерерсең аюны! Тайгада торучы һәр адәм аю үтерә башласа, кая китә! Тайгадагы аю диңгездәге балык түгел лә! Чутлы, чиге-чамасы бар... Ну инде миңа нишләргә? Ничек котылырга бу бәладән? Иртәгә үк кышлауга китәбез, диләр. Әйдә дә әйдә! Ризамы да ризамы?.. Риза, мин әйтәм, тегеләрдән тизрәк котылу өчен. Сүзне икенчегә бормакчы булам. Хатын да күз кыса, кухня ягына үткән саен я боттан, я аркадан чеметеп китә. Ну, риза, мин әйтәм, өйрәтсәгез-өйрәтерсез, чукынсын, дим.
Мин аларны кызган баштан гына шапырыналар дип уйлаган идем. Баксаң, чынлап план корганнар икән. Икенче көнне мылтыклар, арка

капчыклары асып килеп кермәсеннәрме! Шаккаттым. Хатын миннән дә бигрәк аптырады. Җибәрмим, әллә нишләр, аю-җанвар чыгар, бүре тотып ашар, атылып үләр, мылтык тоткан кешеме, алла сакласын, үзенең җүләр башын үзе харап итәр, ди.

Шунда минем ачу кузгалды. Ни әйтсәң дә, мин — ир, ул — хатын. Тукта, хатын, дим хатынга, кем ир монда, минме, әллә синме? Беренче — алла, икенче — патша, өченче — ир, белдеңме? Әзерлә җылы кием, әзерлә азык-төлек — и баста.

Хатын минем гадәтне белә. «Баста» дигән сүз артыннан ни кубасын да белә. Малы-что, ул мине характеры йомшак дип күршеләргә әйтә дә...

Ну, без әзерләндек. Озын белән Кыска, мин — өчәүләшеп кышлауга киттек. Мылтыклар астык. Тегеләр миңа да куш көбәк алып килгәннәр.

Безне башта Озынның кассиры упбиш чакрым ат белән илтеп куйды. Кыяк болын янында төшеп, чаңгылар белән тагын уникe километр эчкә кереп киттек. Шунда урманның матурлыгын күрсәгез иде! Ул кар, мин сезгә әйтим, Үзбәкстан мамыгыдай күпереп тора, шикәр кебек ап-ак. Юл-юл булып, читләре зәңгәрләнеп торган агач күләгәләре сузылган. Кар өсләре җәнлек эзләре белән челтәрләнгән. Нарат башларында, өй түбәсендәге шикелле, бүрек-бүрек кар яткан. Тирә-якта кошлар чыр да чыр. Әле алдан, әле арттан тук та тук тукран тавышы яңгырый. Миләш агачында, туңган миләш чүпләп, кызылтүшләр, сары песнәкләр тирбәлеп утыра. Көн җылы, рәхәт. Бияләйләрне билгә кыстырып ялан кул бардык.

Өчебезнен дә күңел күтәренке. Кар өстен сырлаган җәнлек эзләренә карап куанабыз.

— Ну туныйбыз киекне! — дип көлә Озын иптәшем.

— Әлбәттә! — дип аның сүзен җөпли Кыскасы.

— Бүре ук димибез: бүре ул бер күзе белән генә йоклый, ләкин син дә куянсыз, көртлексез кайтмассың,— диләр икесе берьюлы.

— Авызыгызга бал да май,— дим.

Артыбыздан, без салган чаңгы юлыннан, һау да һау өрә-өрә Озынның Трумэн исемле дәү эте килә.

Оҗмах инде, оҗмах!..

Дөресен әйтим, мин шунда хәтта аю белән дә хыялланып алдым.

Ау йортына барып җиттек. Куе урман уртасындагы зур күл кырыенда икән. Күл читләре ауган усак-каен белән тулган. Ул көнне безгә ауны уйларга да вакыт тимәде. Бәләкәй өй карбазы шикелле салкын иде. Билләһи менә, әзрәк утыргач, җылыну өчен тышка йөгереп чыктык.

Җиһазларне сызганып торакны тәртипкә китерә башладык. Ишек төбендәге карны көрәп кердек. Бик һәйбәт чыршы ботагы белән идәнне себереп чыгардык. Сәке өстендәге мүкне кабарттык, ачуым килмәгәе, атнага җитәрлек коры утын җыеп куйдык.

Шул мәшәкатьләрдән соң рәхәтләнеп мичкә ут төртеп җибәрдек. Мич дулый-дулый дөрләп киткәч, аның алдына тезелешеп утырдык, тартмасаң сүнә дип, тәмәке кабыздык. Мичтә сагызлы ботаклар коты-ра-котыра яна. Шарт та шорт кузлар атылып китә. И рәхәт, и шәп тә инде утка карап, тәмәке тартып, уйланып утыруы!..

Нурбак, очлы тезләрен кочаклап утырган җиреннән башын күтәреп сөйләүчегә карады да, эре тешләрен күрсәтеп елмайды.

— Без сезнең ничек аучылар җәмгыяте башлыгы булып китүегез белән кызыксынган идек,— дип, кыска куе сакалын сыйпап тора башлады.

Аучы кулмәк изүен әләктерергә тырышып карады да кул селтәде. Ни өчендер торып басты. Кесәләрен актарды. Утырды. Шаянлык һәм күңел көрлеге сибелеп торган соры күзләре белән Нурбакка төбәп карады.

— Ашыккан ашка пешкән,— диде.— Монысы әле хикәянең кереш өлеше генә иде. «А»сы гына, «б»сы аның артыннан булыр.

— Һа-а,— диде Тамара, көлемсерәп һәм Нурбак белән күзгә-күз карашып алды. Бит алмалары алланып китте.

— Юл озын. Әле сөйләр сүз дә калмас. Аптырап утыра башларбыз,— диде Аучы. Өзелгән хикәятен ялгап җибәрде:

— Без беренче көнне ау дигән операның прелюдиясен генә уйнаганбыз икән әле. Мин икенче көнне урманга чыгып ике-өч мәртәбә шартлатып атып керербез дә шуннан соң тәртәне кирегә борырбыз дип уйлаган идем. Юк икән, Себер авы дигән нәрсә, иптәшкәй, полный опера икән, балет, фантазия, кантата — тагын әллә нәрсәләр икән.

Ашап-эчкәч, ялкаулыкны ташларга вакыт, шаярдык — җитте, диделәр дә болар, җиң сызганып эшкә тотындылар.

— Син карап, өйрәнеп тор,— диделәр миңа.— Без сине чын аучы итәргә сүз бирдекме — бирдек. Хәзер без менә куян тотарга әзерләнәбез.

Капчыклары, әйтәм аны, бик авыр иде — тыкмаган әйбер калмаган икән. Иң әүвәл җеп йомгагы итеп чорналган нечкә генә йомшак тимер чыбык алдылар. Аны берәр метр итеп кисеп, иллеләп тозак ясадылар.

Шул арада Озын дус куе итеп чәй кайнатты һәм шул хуш исле II сорт индийский чәйгә учлап тоз тондырды.

— Харап иттең,— дип кычкырдым мин.

Сөйләп бирсәләр — исләрем китте.

II сорт һинд чәе, беләсезме, кемгә икән? Куянга! Кыш көне куян тозга тилмерә икән. Тозлы чәйне кар өстенә сибеп чыгалар. Куян үтеп барган җиреннән кызгылт-сары карны күрә дә гаҗәпләнеп туктый. Ни хикмәт бу, ди куян, үз күзләренә үзе ышанмый — бер ача, бер йома. Урманда тугыз кыш үткәреп (куяннар тугыз ел яшиләр) мондый әкәмәт карны күргәнем дә, ишеткәнем дә юк, ди. Бүтән чакта үз койрыгыннан үзе куркып йөрсә дә, монда батырая. Тукта, якынрак барып карыйм әле, ди. Ялап караса — тоз! Күктән көткән нәрсәсен җирдән бирде. Комсызланып яларга керешә. Туйганчы ялый. Бу шатлыклы хәбәрне иптәшләреннән дә яшерми. Куяннар саран түгел. Иптәшләре дә тоз яларга килә моның. Бу урынга иялэнеп китәләр. Ә аучылар, болар ияләнеп җиткәч кенә, капкын куялар. Мылтыкларын төзәп посып утыралар. Капкыннар шылт та шылт, мылтыклар шарт та шорт!.. Куян-җаныйның башын камчы белән камыш түгел, тозлы чәй харап итә икә-ән...

— Ярый, кылый белән эш тәмам,— диделәр тегеләр.— Давай, төлке хәйләкәр белән бүре юлбасарга тотыныйк.

Кыска дус иләмсез олы капчыгыннан баш хәтлерәк брезент төргәк алды. Чиште. Күзем дүрт булды: канлы сарык эчәгеләре белән үпкәбавыр, карта-корта!

— Әһә, беләм,— мин әйтәм,— боларны инде бүре ялыймы?

— Яламый шул, исни генә,— диләр.

Озын дус капчыгыннан пыяла банка тартып чыгарды. Ачып җибәрде, мин сиңа әйтим, күңелем болганып укшый башладым. Ник дисәң, банкадан коточкыч сасы ис чыгып бөтен өйне басты. Сулап булмый, тын кысыла.

— Яп! — димен.— Үтерәсең! Бозылган ит бу! — дим.

— Дөрес,— ди.— Бу — алдавыч. Шушы искә алданып, канга туймас бүре агаң белән төлке апаең килә дә — шап капкынга. Моны без алдан ук махсус әзерлибез. Ә аны әзерләү майлы ботка ашау шикелле җайлы түгел. Беләсеңме моның составында нәрсәләр бар? — дип сорый миннән.

— Белмим,— дим.

Аңлатты.

Банкаларына башта бер кило тапалган ит салганнар. Шуңа стакан тутырып бурсык мае кушып болгатканнар да җылы урынга куеп, ике

ай буе сасытканнар. Шәп алдавыч, ә? Ну үзе дә ничә чакрымнан җәнлек-җанварларның борынына бәрәдер!

Ә мин ике җуләрне сүгепме сүгәм. Ау дип бурсык мае һәм әллә нәрсәләр белән җенләнеп йөргәнче, мич башыгызда арка җылытып ятсагыз ни булган, мин әйтәм...

Капкын-тозакларны, мылтыкларны, алдавычларны алып, чаңгыларны тактык та тайгага киттек. Мин дә, чын аучылар шикелле, капрон җептән үрелгән җәтмә астым, билгә «Бурский» патронтаж бәйләдек. Ләкин ул бик уңайсыз булып чыкты. Үзе киң, үзе авыр — егермедән артык патрон. Чаңгым әйбәт. Кыска, киң. Табанына болан аягының тиресе беркетелгән. Каты йоны артка яткан. Тау менгәндә кире төшеп китмисең. Бик җайлы.

Тирә-якка сокланып карый-карый тезелешеп бер эздән барабыз. Кышкы иртә чыннан да сокланырлык. Бик якты. Искиткеч матур. Әйтергә кирәк, куркыныч матур. Аның иксез-чиксез икәнен белеп торасың. Шуңа күрә башка «чыгып котылып булса ярый бу җәһәннәмнән» дигән шомлы уй да килә. Күңел кытыклана. Зур сарайларның мәһабәт колонналарын хәтерләткән юан, төз кәүсәле нарат, кара һәм ак чыршылар, карагайлар чатыр башларын һавага сузып тора. Аларга, яшь балалар аналарына сыенган төсле, шәмдәй каеннар, яшел усаклар, көрән зирекләр сыенган. Чыршы-наратларның киң ботакларында ястык-ястык калын кар ята.

Күктә кояш, җирдә сызык-сызык, челтәр-челтәр күләгәләр. Һава коры, салкын, чиста.

Әкрен генә барасың. Агачлар уйга чумган. Агачлар арасында тавыш-тын юк. Җәнлекләр дә юк. Алар барысы да аяусыз кыштан куркып качып беткән шикелле тоела. Ләкин беләсең: бар алар. Көртлеге дә, кыр тавыгы да, тиене дә, куяннары да. Тагын әллә кемнәре. Туган җирләрен ташлап бер кая да, бер кайчан да китмәүчеләр.

Тайга — дөньяда иң зур урман. Ләкин мин аны әле тагын дөньяда иң матур урман да дияр идем. Иң серле, иң куркыныч, шул ук вакытта иң бай, иң юмарт урман дияр идем...

— Сез сөйләгәннәр барысы да дөрес,— диде Петр Петрович.— Тайга дөньяда иң зур, иң юмарт урман. Җәнлек-җанварлар да җитәрлек. Безнең кеш мехыннан тегелгән туннарны тегеләрдә утызар мең доллар түләп алалар. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Икенче ягы шунда, тайганың юмартлыгыннан, җиңел генә әйткәндә, кирәгеннән артык иркен файдаланабыз кебек тоелмыймы сезгә?

— Сез, мәсәлән, нәрсәне күздә тотасыз? — дип сорады Аучы.

— Мәсәлән, агач кисүне. Киселгән һәр өч агачның берсе тиешле җиренә барып җитә алмый. Тайгада калып чери, юлда югала, сал агызганда төпкә бата, таркала, диңгезгә агып китә.

Машинадагылар, кызык сүзнең җитдиләнеп китүен күреп, игътибарларын арттырдылар. Аучының йөзе уйчанланды.

— Әйе, миңа да тайганың юмартлыгыннан артык иркен файдаланабыз кебек тоела. Сез дөрес әйтәсез. Минем дә моңа йөрәгем яна. Без, район масштабындагы кешеләр, моңа чаралар да күргән булабыз. Ләкин бездән башкалар да бар бит...

Нурбак күзлек пыялаларын сөртә-сөртә:

— Сез киләчәкне бигрәк кара буяулар белән сурәтлисез. Эшләр алай ук начар дип әйтмәс идем. Безнең, бер агач киссәң — икене утырт дигән, акыллы девизыбыз бар. Шуның буенча эшлибез дә. Ел саен меңнәрчә гектар яшь урманнар утыртыла.

Моңа кадәр сөйләүче-бәхәсләшүчеләрнең әле берсен, әле икенчесен тыңлап кына утырган Тамара, киләчәкнең Петр Петрович сурәтләгәнчә үк куркыныч булмаганына шатлангандай, Нурбакның сүзен җөпләп куйды:

— Әйе, әйе. Минем газетадан укыганым бар: безнең илебездә е. саен бик күп яшь урманнар утыртыла ди, моңа Совет хөкүмәте зур-зу сумма акча тота икән.

— Ләкин ул карандаш юанлыгы чыбыклар кайчан үсеп җитә сон Ике йөз елдан. Ә без хәзер әнә дүрт йөз ел үскән кедрлар кисәбез Урманга ни дип кычкырсаң, ул да шулай дип җавап бирә. Тагын шу нысын да истән чыгармаска кирәк, урманы үсмәгән агач кисмәгән дигәндәй, ул бәләкәй агачларның ничәсе үсеп дәү агач була? Уннан берсе. Димәк, шуңа яраклаштырып, отчет саннарына да ун мәртәб киметеп карарга кирәк,— диде Петр Петрович.

— Ие. Киек-җәнлекләр, кошлар да күзгә күренеп азая,— дип, Аучь Петр Петровичның сүзен дәвам итте.— Мылтыклар саны елдан-ел арта су кошлары кими. Сез әйткән килер буынга чыпчыкларны йөзәрг өйрәтергә калмагае. Судагы балыкларның хәле дә шундый. Сакламый быз. Бер җәзасын күрербез күрүен. Ә беләсезме, мин элекке Урал казакларының карарында әзме-күпме дөреслек ишетәм: алар, балыкны тынычсызлый дип, Урал елгасына пароход керттермәгәннәр, имеш. Безнең җиребез һәм суыбыз күп. Безнең җирдә җәмгыять үсеше һәм кеше яшәве өчен бөтен нәрсә бар. Без бай, ифрат бай! Таба белү бер һөнәр булса, тота белү ун һөнәр диләр. Ә безгә, җиңел табылган дип, кайчакта бик күп нәрсәне җилгә җибәрмәскә иде!

— Дөрес фикер,— диде Петр Петрович, тамагын кырып.

— Кадерле Петр Петрович, мин тагын, үземчә, болай уйлыйм: әгәр, мин әйтәм, без бер генә ел бер тиенне дә әрәм итмәсәк, һәм әйтерг кирәк, сволочь адәмнәрдән урлатмасак — безнең ил бер ел эчендә ун-лап елга алга китәр иде. Сизәсезме, ун елга! Менә шуны уйлап торам. Ачуым килә. Кемдер өендә ярыкка төшкән бакыр акчасын да идән тактасын куптарып ала бит...

Петр Петрович көрсенеп куйды.

— Кешеләрнең аңы акрынрак үзгәрә шул. Андыйларга мораль түгел — карар кирәк. Шуның белән — бетте китте. Эзе дә калмасын,— диде Нурбак.

Петр Петрович көлемсерәп куйды.

— Без гуманистлар. Кешенең кешелек сыйфатларын хөрмәт итәбе. Без кешеләрне яратабыз һәм аның ялгышын бөтенебез бер булы бетерергә тырышабыз.

Нурбак:

— Мин сезне аңламыйм,— дип, гадәттәгедән кычкырыбрак аңа каршы төште.— Гуманизмны мин дә беләм. Гуманист булуым белән горурланам да. Ләкин мәсьәләнең бу ягына игътибар итегез: әйтик, бер хулиган йөз намуслы кешегә тынычлык бирми, йөз чын совет кеше-сенең тормышын агулап тора, ди. Монда ничек? Җәмгыятькә каршы бер шакшы җан белән маташып яту гуманизм буламы, әллә йөз чын гражданның иминлеген яклап бер кабахәтне акылга утыртумы?

— Болар барысы да дөрес. Әмма без фашистлар түгелбез. Җәза-лау — тәрбиянең уңышлы чарасыннан хисапланмый. Тарихта моңа мисаллар тулып ята. Мәсәлән, элек шәһәр мәйданына җыелган бөтен халык алдында каракның кулын чаба торган булганнар. Моның макса-ты, билгеле, каракларны куркыту. Тик, нәтиҗәдә, киресенчә килеп чыга. Әле генә җәзаланып торган каракның иптәшләре нәкъ шул чакта, бар халык авызын ачып, бөтен дөньясын онытып җәзаны тамаша кылып торган вакытта, аларның кесәләрен бик әйбәтләп чистарта торган бул-ганнар. Аңлашыламы?

— Әйе. Ләкин моны да йөз процент дөрес димәс идем.

— Мин аны әйтмәдем дә. «Алтын урталык» диләрме әле? Әнә шуны табарга кирәк. Һәр эш, бигрәк тә башта тотынганда, каршы аргумент-

ларны да, уңайларын да бизмәнгә салып, җитди игътибар белән үлчәүне таләп итә.

Нурбак һаман да аның белән килешеп җитмәде. Сүзен бирергә теләмәде.

— Мин шулай да каты куллы булу ягында.

— Көч политикасы безгә ят нәрсә,— диде Петр Петрович.— Без шәхескә ихтирам итәбез. Безнең көчебез ышандыруда.

— Ә революция вакытындагы кызыл террорлар? — дип, Нурбак тиз генә аңа каршы төште.— Сез боларны да көч куллану түгел дип ышандырырга тырышасызмы?

— Ул чакта шулай кирәк иде. Чөнки «я без, я алар». Бер сыйныфның яшәве өчен икенче сыйныф үләргә тиеш иде. Либеральлек үлем белән бәрабәр. Капитализм үлде, советлар җиңде. Кызыл террор үзен аклады. Хәзер «кирәк идеме, кирәк түгелме» дигән сорау һәм бәхәскә, минемчә, нигез юк.

Ә хәзерге сез әйткән «кеше калдыклары» безнең җәмгыятебезгә нинди куркыныч тудыра? Анадан балалар бөтенесе дә бер төсле булып туалар: саф һәм изге күңелле. Бала үсә. Аннан юлбасар чыгамы, әйбәт кешеме — монысы турыдан-туры өлкәннәр намусында. Шуның өчен аны бишектә үк өйрәтергә кирәк. Баланы караватта аркылы ятканда тыңлата алмасаң, буй яткач тыңлатырмын димә. Бер моментта бу бәләкәй кешене әз генә күздән ычкындырсаң, аның бозылуы, ялгыш адым ясавы мөмкин. Тумыштан җинаятьче булып тумыйлар, һәм аңлы рәвештә ясалган җинаятьләргә караганда ялгышулар күбрәк. Менә шуңа күрә дә мин гуманистлыкны яклыйм, ялгышкан кешеләрне тәрбия һәм аңлату юлы белән зур тормышка кайтаруны яклыйм.

Тамара аңа рәхмәтле караш ташлады.

— Билгеле, кешеләрне кызганырга, авыр чакларында якларга кирәк,— диде.— Алар анына капитализм да йогынты ясый. Бөтен әшәкелек һәм ярамаган эш — һәммәсе дә капитализм мирасы, капитализм калдыгы ич. Димәк, бу очракта капитализмны да гаепләргә кирәк.

Петр Петрович Тамараның очлырак иякле алсу йөзенә һәм сары береткасы астыннан чыгып, җилкәсенә төшеп торган сап-сары озын толымнарына карап тагын көлемсерәде.

— Юк, Тамара дускай, мин синең сүзләрең белән тулысынча килешә алмыйм. Мәсәлән, менә сездә нинди капитализм калдыгы булсын! Сезгә капиталист әфәнделәр нинди мирас калдырды? Сезнең тере капиталистны күргәнегез дә юк. Аларның инде моннан илле ел элек тамырлары корыды. Сез туганчы, чама белән, утыз еллап элек. Революциядән соң бу тезис дөрес иде әле. Ул чорларда капиталистик җәмгыятьтә яшәгән һәм аның ачысын-төчесен татыган кешеләр анында капитализмның йогышлы авырулары калмый булмый иде. Ә хәзер... Хәзерге гарип җаннар, минемчә, безнең үзебезнең «калдык». Алар өчен җавапны да, әллә кайчан беткән капиталистка сылтамыйча, без үзебез бирергә тиеш...

Шул вакытта Тамара шатланып кычкырып җибәрде.

— Болан!.. Күрегез әле, болан!..

Барысы да ул күрсәткән якка карадылар. Күе төнбоеклар һәм яшел камышлар белән капланган күл читендә, яшь усак куакларына ышыкланып, сәнәк шикелле мөгезен горур гына күтәреп, бик зур пошый тора иде. Ул, машиналарга кызыксынып караса да, курку-өркү әсәре күрсәтмәде. Бары борынын кыймылдатып һаваны иснәде, тамак астындагы сакалын селкетеп куйды. Юл ягына карасу арты белән борылды да тынычланып сусыл саз үләне ашый башлады. Шулай булса да, әледән-әле башын күтәреп усаклыкка карый торды.

— Болан түгел бу, Тамара, пошый. Анасы. Баласы да шушы тирәдә булырга тиеш,— диде Нурбак.

— Пошыйның да шактый зуры,— диде Аучы, аңа өстәп.— Озынлыгы өч метр, авырлыгы ярты тонна булыр.

— А-а! — диде Тамара сокланып һәм кычкырып җибәрде.— Әнә баласы, күрәсезме, әнә баласы, усак арасыннан чыгып килә!.. Икәү, икәү! Тагын берсе күренде!.. Икәү!.. Әнә әнкәләре янына килделәр. Күрдегез ме?.. И сабыйкайлар!.. Нинди матур!.. Искиткеч!..

Дөрестән дә, тал чыбыгы кебек кенә нечкә усаклар дереддәп китте. Ике пошый бозавы, озын аяклары белән мәзәк кенә атлап, әниләрен якынлаштылар һәм, син бездән качырып кына нинди тәмле әйбер ашап ятасың, әни, дигән шикелле, аның алдында чемченә башладылар.

Менә урман эчен яңгыратып әллә кайдан, ерактан ыңгырашуга охшаган үкерү ишетелде. Аңа күл аръягыннан шундый ук ярсулы үкерү белән җавап бирделәр.

Каен башында киек-җанварларның гайбәтен сатып утырган ике саескан, шыгырт-шыгырт килеп, бу тавыш хуҗаларын үз телләрендә сүгә-сүгә юл аркылы очып киттеләр.

— Ата пошыйлар бер-берсен дуэльгә чакыра,— диде Аучы.— Август, сентябрь аларның котырган чоры.

Менә урман өстендә, бөтен тирә-якны каты шау-шуга күмеп, тимер торбалар бәйләме таккан зур вертолет күренде. Ул астан гына оча, ә торбалар бәйләме әле алай, әле болай борылып чайкалып бара иде.

Пошый кинәт дереддәп башын күтәрде. Көчле аякларын түмгәкләр өстеннән селтәп яшь каен урманына кереп китте. Җеп белән тагылган шикелле, аның артыннан бер адым да калмыйча, балалары да чапты. Каен ботаклары сары яфракларын җиргә коя-коя тирбәлешеп алдылар да тындылар.

— Вертолеттан өркәләр әле,— диде Аучы, көлемсерәп.— Машинага исләре китми, әмма вертолетларга күнегеп җитә алмыйлар...

Машиналар ике күл арасындагы озын дамбага килеп керделәр. Астагы торбадан кечерәк күлнең суы икенче күлгә бөтерелә-бөтерелә агып тора иде. Күлнең аргы башы тигез болын. Анда күп кенә печән кибәннәре күренә. Кибән башларында, сумала кисәге шикелле, кара каргалар йокымсырап утыра. Урман итәгендә сыер көтүе утлап йөри. Аның өстендә, гармонь күрүге шикелле бер сузылып, бер җыелып, болыттай сыерчык көтүләре чайкала. Агачлар өстеннән ниндидер кирпеч торбаның очы күренеп тора. Аның ак төтене ак флаг шикелле урман өстенә сузыла. Ерак-еракларга киткәч, болытларга кушыла да эреп күздән югала.

Сары ком һәм вак таш түшәлгән дамба күл беткәч түбәнәйде. Чокырлы-чакырлы кара юлга әйләнде. Күп урыннарда эреле-ваклы күләвекләр җыелып тора иде. Машина батып яткан урыннар очрый башлады. Юл тарайды. Аның ике ягыннан да каты камыш һәм очлары корыган таллар үскән сазлык җәелеп китте. Һавада торрыйк-торрыйк торкылдашып барган торна кәрваннары күренә башлады.

Ни өчендер юл кырыена утыртылган чакрым баганалары да бетте. Айзатның күңеленә шом төште. Ул, күз күреме җитмәс сулы сазга һәм тәгәрмәчләр ерып бетергән күңелсез юлга карап, тизрәк чыксак иде моннан, дип пошынып куйды.

Бүтәннәрнең дә уйлары шул чамадарак иде бугай. Һәрхәлдә, сөйләшүдән туктадылар. Алмаш-тилмәш юлның ике ягына карап тик кенә бардылар.

Машиналар колоннасы, сазлыкка килеп кергәч, һәр метр җирне тикшереп, капшап барган шикелле, сакланып үрмәли башлады. Шунлыктан ул биш-алты чакрым араны сәгатьтән артык үтте.

Һич көтмәгәндә камыш урманы һәм таллыклар бетеп, кондыраклы тигез болынга чыккач, юлаучыларның йөзе ачылып китте. Дөнья иркенәйде.

Ә юл һаман яхшырмады. Чөнки бу ялан, күрер күзгә бик матур булып, ымсындырып үзенә тартып торса да, торфлы дерелдек болын иде. Анда атлар да, мөгаен, җәйнең коры чакларында гына керә торгандыр.

Ярты чакрым тирәсе җир үткәч машина туктады. Юлчылар урыннарыннан торып, алга күз салдылар. Өсте үлән һәм камыш белән капланып бетә язган ике-өч сажин киңлегендәге бәләкәй елгачык юлны аркылы кискән иде. Ул боргалана-боргалана илле метрлар сузылган да кырт туктаган. Әллә җир астына төшеп киткән — аңларлык түгел. Шул серле җирдән ун-унбиш метр киткәч, арткы тәгәрмәчләре белән кара сыек сазлыкка чумып, ике машина батып ята. Аның берсе кечерәк автобус — кинопередвижка, икенчесе — аны сөйрәп чыгарам дип, үзе дә кереп батканы — кыска такталар төягән көчле йөк машинасы.

Шоферлар шул машиналарны чыгара калды, юлчылар, аяк буыннары язылсын дип, җәяүләп алга атладылар.

Айзат белән Петр Петрович әкрен генә атласалар да, хәтсез җир киттеләр. Башка юлчылар бөтенләй күренмәс булды. Баткан машиналарын чыгарып азапланучы шоферлар да артта калды.

Күпереп торган калын сфагнум[1] мендәрләре белән капланган торф сазлыгы тагын да киңәеп китте. Саз өсте монсу һәм серле, куркыныч серле булып тора. Аның өстендә зәгыйфь усаклардан һәм озын ак мамык чуклы бүреге астында уйланып утырган мамык башлардан бүтән адәм рәтле үсемлек заты күренми иде.

Нечкә усаклар түшәлгән бер-ике баткак урынны үткәч, күңелсез сазлык яшь каен урманы белән алышынды. Каен — һәр кайда яктылык сөюче һәм шул яктылык артыннан кояшка омтылучы үзе дә якты агач. Каен урманы башка урманнарга караганда яктырак та була. Кеше күңеленә дә яктылык бирә торган урман.

Яфраклары алтын тәңкәләр шикелле саргаеп коела башлаган шул каен урманын үткәч, озын иңкүлеккә килеп чыктылар, һәм Айзат, алдында ачылып киткән күренешкә гаҗәпләнеп, ихтыярсыз туктап калды. Петр Петрович башта Айзатка, аннан ул текәлгән җиргә күз салды. Аңа комачауламас өчен, ахры, бер читкәрәк китте.

Алар бара торган юлның ике ягында да, шомлы бер тынлык эчендә, әле моңарчы күрелмәгән тайга иңрәп утыра иде.

Зилзиләле янгыннардан соң кара күмергә калган урманның куркыныч тынлыгы иде бу.

Мүкле сазлык читеннән башланган янгын иңкүлектәге нарат урманының аскы өлешен ялмап үткән. Җилгә монда урын тар булган, күрәсең. Ул иркенәеп дулый алмаган. Ялкынны коры нарат ылыслары өстеннән генә куып алып киткән. Шуңа күрә ут афәте өскә — агач башларына урләргә өлгерә алмый калган. Шулай булса да елның-елына җиргә калын ястык шикелле түшәлә барган коры ылыс, вак чыбык-чабык белән генә канәгатьләнеп калырга теләмәгән, нечкәрәк нарат, чыршы кәүсәләрен һәм аларның астагы ботакларын яртылаш күмергә калдырып харап итеп киткән.

Җирдә эскәк белән алырлык та яшел үлән заты юк.

Җирдә калын көл һәм күмер ята — коры көл чүле.

Кара көл өстендә ташкүмер шикелле кара баганалар.

Караңгы.

Үле тынлык.

Айзат кара кашларын әле җыерып, әле дугаландырып, бу шомлы күренешкә карап торды. Аның мондый янгыннарны гомерендә дә күргәне юк иде. Ул бәләкәй чакта Чияледән егерме-утыз чакрымдагы Көләгеш сазы, дөресрәге, андагы гасырлар буена җыелган коры торф

[1] Сфагнум — мүкнең бер төре.

берничә тапкыр янды. Авыллар өстендә атналар буе соры төтен тирбәлеп торды. Ул көндез кояшны күренмәс итте. Кич һәм төнлә, бигрәк тә җил тынган чакларда, төшеп җиргә ятты. Моңа атлар һәм башка малтуарлар сөенсә дә, кешеләр ютәлли-ютәлли сазны сүктеләр.

Маяк тапмый адашып, Кама өстендә чаң кагып утырган пароходларны күреп кайтучылар булды. Ләкин Айзат, төтенен күрсә дә үзен күрмәгәнлектән, ул янгынның нинди бәла-казалар китерүен белми иде. Ә менә хәзер ул шундый янгынның нәтиҗәсен күрде, һәм бу аны үзенең зурлыгы белән аптыраштa калдырды...

Петр Петрович ипләп кенә аның җилкәсенә кулын салды.

— Күргәнең юк идеме?

— Юк иде. Күпме урман харап булган. Бу агачлар ничә авыл салырга җитәр иде! Безнең якта булса бигрәк тә!..

— Әйе. Тик, дускай, урманнар биредә дә артык түгел. Чамасыз дип сөйлибез сөйләвен, әмма табигатьтә бер нәрсә дә чамасыз булмый.

— Гаепле кешене таптылармы соң, Петр Петрович? — диде Айзат, кайнарланып.

— Монда янгын сүндергәндә ике десятник һәлак булды,— диде Петр Петрович, егетнең сүзен ишетмәгән шикелле.— Утны агач эшкәртү комбинатына биш-алты километр калгач кына туктата алдылар... Юкса... Ике егетнең гомере сүнде...

— Петр Петрович, кем чыгарган соң утны? Таптылармы? Нишләттеләр?

— Утыралар. Бишәү. Шул учак, игътибарсызлык аркасында. Алар утырыр да чыгар. Монда да берничә елдан янгын булганлыгы бөтенләй сизелмәс. Җире ашланды. Яктылык күп. Бу көлне икенче елда ук ерып йөргесез куе үлән, чәчәк каплап китәр. Тагын бераздан кура җиләкләре, карлыган, яшел агачлар шаулап күтәрелер.

Моннан үткән кешеләр бу урыннарда синең шикелле куркынып һәм шомланып карап тормас. Тайга төсле тайга, дияр дә җилдереп үтәр дә китәр. Монда ике егетнең корбан булуын белмәс тә...

Петр Петровичның акыллы соры күзләрендә моңа кадәр сизелмәгән сагыш күренде. Бераз алга чыгып торган калын иреннәре дерелдәп китте.

— Петр Петрович!

— Ничего, ничего! — диде Петр Петрович, маңгаен сыпырып.— Кешеләр белсен өчен генә эшлибезмени без! Кешеләр белсен өчен генә ут-ялкын эченә кереп башларын салалармыни безнең балалар!..

— Петр Петрович! Соравым урынсыз булса, зинһар, кичерегез, янгын сүндергәндә һәлак булган ике батыр десятник егетне әйтүем... Әллә сезнең үз...

— Әйе, үз балаларым! Үз укучыларым! Миндә укып чыккан егетләр! Владимир белән Сергей!

Петр Петровичның тәбәнәк буе тагын да кыскарып, чандыраеп калгандай тоелды. Ул, кара урманга күзләрен тутырып карап торды да, авыр сулый-сулый алга китте.

Айзат та, бүтән сүз дәшергә кыймыйча, әкрен генә аның артыннан атлады...

*Дәвамы бар.*

## Равил Фәйзуллин

●

Эшең юк, язган чакта мин
үксимме, әллә көләм.
Ничек язганымны бары
бер үзем генә беләм!

Япа-ялгыз мин. Ялгыз чагым —
иң бөек хөрриятем.
Вөжданым белән сөйләшәм,
шул минем шигърherятем.

●

Хөрлектән башлана кеше.
Рухың кол икән — ләхет.
Арын көн дә коллыгыңнан!
Ирегең арту — бәхет.

Ирешкәч шушыңа акылым
ничек дөньядан бизием?

Юк! Җиһаннан, табигатьтән
җанга хөр иш эзлимен!

Әйдә, сүзем, кылган эшем
урләтсен хәрлегемне!
Шәхесемдә барын ачыйм да,
раслыем ирлегемне!

●

Дөньяда һәрбер нәрсә
үз исемен алса,
Хаклыкка һәркемнең ачкычы
булыр иде ласа!

●

Зур кеше шул — кем үзенә
һәм вакытына үзе алла.
Бәхетле шул — кем ирекне
һәр нәрсәдә тоя ала.

●

*Н. Исәнбәткә*

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.
Вакыт-яу — иң-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны!

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман, иелеп, җиңүченең
шанлы исемен алып кала.

•

Кадер, бәя, чын хак,
кайчак
иясеннән, һай, ерак!
Бирәүгә таҗ буласы сүз
бер туң җанда —олтырак...

Дулкынын мәңге югалткан
ялгыз акчарлак сымак,
килә ул кадер. Тик бик соң...
Куныры кайтмас ерак!

•

Хак сүз, тарих, гыйбрәтләр
өстә ятмый. Алсаң гына
чумып, мәрҗән эзләүчедәй.
Йөрәк таза, тын киң булып
исән-имин калсаң гына...

Карама күзгә,— тонгандыр,
яңагым, бәлки, сулгандыр,
карама беләкләремә!
Кара учка: бу — тапканым!
Кара тотып, тешләп, чиртеп...
Тик төпчеңмә —каян алган?
Ничек алган? Кайчан алган?
Иң мөһиме — түгел ялган!

Без эзлибез — шунда бәхет —
туры карап хәвефебезгә.
Шуңа, ахры, шатлыгы да,
газабы да бөтен бездә.

Әй, сез — өстә йөзүчеләр!
Шактый оста йөзүчеләр!
Дулкын-күбек сөзүчеләр!
Сез кояшның күзендәме?..

Көнләшмибез. Көл, уп, кояш,
сыйпа дулкын йөзендәген!
Үпкәләрдән биегрәк без!
Кирәк — ерак йөзәрлек без,
кирәк — тирән чума алырлык!
Төптә тәнне иркәләүче
сулар да дулкын булырлык!

Кояшкамы тел тидерү! Юк!
Сөйсен дулкын йөзендәген!
Тирән төшсәң, «кеше» дигән
кояш кыйбат үзеңдәге!

●

Эти эшләгән җирләр бу.
Эти казганган өйләр.
Кешеләр әйтә: уллары да
яхшы ат казанган диләр.

Бер эти үзе беләдер
ни ат казанганнарын...
Эндәшми тамырлы куллар,
сөйләми чаллары аның.

Бары бер үзе беләдер,
күпме мал, даны барын.
Тормыш атын ничә җигеп,
ничә кат туарганын...

Эти эшләгән җирләр бу.
Эти казганган өйләр.
...Яшь бара безнең дә. Инде
күрелде җирләр-илләр.
Эти гел ир, ә без әле
һаман да сабый ирләр.
Һаман әле эти бара
давылның уртасыннан.
Без һаман тормыш-корабның
тыныч каютасында.
...Урам. Әнә эти. Бара.
Сизәме: карап торам.
Бара. Мәшәкать дөньясында
билгесез кораб сыман.

●

*Фантазия*

Йөгереп-уйнап
ага Болак.
Камышлары — рәшәдә!
Казан өсте — ап-ачык күк,
Иделкәй янәшәдә!

Йөгереп-уйнап
ага Болак.
Чуерташлар — төбендә.
Тымык түгел, йомык түгел,
Болак гел саф күңелдә.

Тanda тор да,
ят та тыңла,—
җир астында чишмәләр!
Алар бит эндәшәләр!
«Идел-ана янәшәдә!
Безгә мәңге яшәргә!»

Йөгереп-уйнап
ага Болак.

## Бәлки син...

Бәлки син минем җырланмас
иң гүзәл бер җырымдыр?
Бәлки син минем кичелмәс
иң данлы бер юлымдыр?

Бәлки син минем беркайчан
кул җитмәс аккошымдыр?
Бәлки син үзем ишетмәс
иң көчле алкышымдыр...

●

Күктә — яшен!
Дәһшәт, шом!
Ярда — син —
алиһә сын.

Тузанга да
күрмәүме бу —
алла, күкрәве!

Син — зур зат, дип,
тирбәнә әнә
алма күкрәге!

Күктә — яшен,
ярда — син.
Кем сынамак
без — табигать
баласын?

Күкрәү. Тетрәү.
Ярлар ишелә!
...Илаһи тын гына
сылу чишенә.

## Этюд.

*Идиллия*

Кешеләр менгән айга,
Ә без менә җайга
бу борынгы җирдә,
тамырланган илдә,
үзебез корган өйдә
тәрәз юабыз.

Шундый бездә йола:
язлар житү белән —
халык өйләр юа.
Йөзләрдә көләчлек,
табигатьтә яшьлек!
Әле кояш яна,
әле ләйсән ява!
Кызлар су ташыйлар
йөгерә-чаба.
Кыска итәкләргә
шук тамчылар тама...
Кем чыгарган йола?
Язлар житте исә —
халык өйләр юа.
Юа бар жирен дә,—
калдырмый җеген дә!

Кешеләр айга менгән.
Ә без җирдә менә
тәрәз юабыз
синең белән бергә.
Тыштан мин су сибәм,
эчтән син юасың.
Мин көлемсерим,
ә син елмаясың.

Гөрләвекләрмени
өлгеләр, рамнарда!
Күрәмсең, чистара!
Чистара! Тагын да
сафлана шикелле
икебезнең ара...

Житсен киче генә,
йолдызлар балкышып,
тезелгәч күгенә,
нәни улыбызны
уртабызга алып,
карарбыз тәрәздән
бу айга таң калып.

Рәисә Ишморатова

# ЯШЬЛЕК КАНАТ ҖӘЙГӘНДӘ

ПЬЕСА 6 КҮРЕНЕШТӘ

КАТНАШАЛАР:

Р а з и я — хирург, 38—40 яшьләрдә.
Ш а м и л — улы, 16 яшьтә.
Р и ш а т — укучы, 16 яшьтә.
И р е к — эшче, 17 яшьтә.
Л ә й с ә н — укучы, 16 яшьтә.
Ә к ъ л и м ә — укучы, 16 яшьтә.
Б а р ы й — инженер-төзүче, 40 яшьтә.
Х ә м з ә — 67—68 яшьләрдә.
С о л т а н и я — укытучы, 24 яшьтә.
И с м ә г ы й л — мәктәп директоры, 55—56 яшьләрдә.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әкрен генә пәрдә ачыла. Яшен яшьнәп яңгыр узган. Салават күпере. Биек йортлар, яшел агачлар. Л ә й с ә н белән Ш а м и л керә. Л ә й с ә н мәктәп формасыннан. Кулларында сумка. Алар зур йортның подъездында туктыйлар.

Л ә й с ә н. Килеп тә життек, яңгыр да туктады.

Ш а м и л. Туктап бетмәде.

Л ә й с ә н. Салават күпере... Зәңгәр, яшел, сары, кызыл төсләр. *(Тирән сулый.)* Яратам!..

Ш а м и л. Иртәгә урманга барабызмы?

Л ә й с ә н. Кыш көне барган идек, исемә төшермә. Нинди каты буран чыкты.

Ш а м и л. Минем ул чак адашасым килгән иде дә...

Л ә й с ә н. Үзең теләп адашыргамы?!

Ш а м и л. Яратам буранны. Күзләрне томалый торганын. Барасың, барасың, сулыш алып булмый, аяклар атламый. Адашасың, сине эзлиләр, эзлиләр, тапмыйлар... Үзең юл табып кайтасың.

Л ә й с ә н. Минемчә, яңгырдан соңгы матурлыктан шәбе дөньяда юктыр. Туфлиләрем белән керимме шул суга. *(Шаяра.)*

Ш а м и л. Шулай... шулай... басып тор — хәзер рәсемгә төшерәм. *(Керәп китмәкче була.)*

Л ә й с ә н. Әй... каен суы эчәргә баргач та төшергән булдың. Үзең ясап бирмәдең.

Ш а м и л. Ул чак фотоаппаратның рәте юк иде, хәзер яна.

Зонтик тоткан Х ә м з ә карт керә.

Х ә м з ә. Һей, улым кайтып килә икән. Әйдә, әйдә, кер. Кара нинди зур балык, хәзер кыздырабыз, һәйбәтләп!

Ш а м и л. Рәхмәт, Хәмзә бабай.

Х ә м з ә. Ничек анда эшләр, этиеңнең кайтыр хәбәре юкмы?..

Ш а м и л. Юк.

Х ә м з ә. Тормагыз баскыч төбе сагалап, сезне күреп хулиган малайлар җыйнала. *(Шамилнең башыннан сыйпап.)* Бичаракаем!.. *(Кереп китә.)*

Л ә й с ә н. Син?.. Бичара?! *(Көлә.)*

Ш а м и л. Әй! Аны тыңласаң... Хәзер. *(Кереп китә.)*

Л ә й с ә н. Нинди матур. Алсуы миңа, юк, яшеле, икесе дә... Сарысы кирәкми. Шамил кайсысын сайлар икән?..

Ш а м и л *(фотоаппарат алып чыга)*. Я әле, баягы кыяфәттә тор.

Л ә й с ә н. Салават күпере фонында төшер, яме!

Ш а м и л. Сулгарак бас. Шулай. Елмай. Нәкъ үзең бул... Күбрәк елмай. Менә, менә... Төшерәм!.. Бер, ике, өч... Булды! Тукта, тагын бер. Башыңны күтәрә төш. Булды!..

Л ә й с ә н. Давай, инде үзеңне төшерим.

Ш а м и л. Мә!..

Л ә й с ә н *(фотоаппаратын карап)*. Әйбәт!..

Ш а м и л. Бүләк.

Л ә й с ә н. Сулгарак, сулгарак... Нәкъ үзең бул! Шаярма инде, җыерма кашыңны... Менә шулай. Төшерәм. Булды. Тагын бер. Булды. Мә. Рәсемнәрне иртәгә эшләп бирмәсәң...,

Ш а м и л. Эшлим.

Л ә й с ә н. Тик кара!..

Ш а м и л. Кая карыйм?..

Л ә й с ә н. Ул рәсемнәрне башка кызлар күрмәсен...

Ш а м и л. Ни өчен?

Л ә й с ә н. Кит!.. Күзләреңне алай серле итеп карама.

Йөгереп чыгып китә.

Ш а м и л *(тәэсирләнеп аның артыннан карап кала)*. Ләйсән, Лэйсән. Лэйсән яңгыр... йомшак, җылы... *(Уйлана.)* Тфү!.. Лэйсән алдында: бичара, имеш. Хулиган малайлар, имеш... Өйгә кереп әлләниләр сөйләве генә җитмәгән, урамга чыгып кычкыра башлады... *(Кереп китмәкче.)*

И р е к *(керә)*. Һей, дускай!..

Ш а м и л. О, Ирек!.. Кая ашыгасың? *(Күрешәләр.)*

И р е к. Эшкә, второйга.

Ш а м и л. Кайда эшлисең?..

И р е к. Спартакта.

Ш а м и л. Укыйсыңмы?..

И р е к. Ташладым. Эшләп укуы авыр, брат. *(Тарта.)* Мә.

Ш а м и л. Тартмыйм...

И р е к. Егет башың беләң?

Ш а м и л. Син дә тартмый идең...

И р е к. Дөнья бу, өйрәтә... Ә син бәләкәй малайлар сыман таш җыясыңмы?..

Ш а м и л. Җыям.

И р е к. Ташла... Лучше этиең янына Якутиягә сыпыр... Анда вак-төяк ташлар түгел, алмаз җыярсың... Бриллиант!..

Ш а м и л. Китәрмен әле бер.

И р е к. Әйдә, малай, махнем, ә? Аннан кешеләр баеп кайта...

Ш а м и л. Баер өчен?.. Мин күрер өчен, җирләрендә яткан асыл ташларын кулыма тотып карар өчен китәр идем ул якларга.

И р е к. Әллә тау-тау алмаз, алтын җиреннән безгә чыпчык башы кадәр генә бриллиант алып кайтырга ярамасмы?

Ш а м и л. Чыпчык башы кадәр бриллиантның ничә мең сум торганын беләсеңме син?..

И р е к. Торса, әллә сатып аламмы?.. Махнем, әйдә... Чынлап! Син бит геолог булам, дисең... Геология эшендә практикаң булыр... Әнә Исмәгыйл абый тарихны нинди шәп укыта... Потому что ул дөньяны күп күргән.

Ш а м и л. Озакламый әти отпускага кайта, сөйләшербез...

И р е к. Эх, малай, бүген үк ычкыныр идем дә...

Ш а м и л. Бүген үк?..

И р е к. Ярый инде, киттем, хуш... *(Кызу гына чыгып китә.)*

Ш а м и л *(аның артыннан)*. Ирек, нигә бер дә безгә килмисең?

И р е к *(арттан)*. Вакыт юк...

Ш а м и л. Кызык. Укыганда да каядыр китәргә дип сөйләнеп йөри иде. *(Ирек ташлаган тәмәке төпчеген аягы белән этәрә дә кереп китә.)*

Сәхнә алышына. Зәвык белән җиһазланган зал. Ш а м и л ишекне ачкыч белән ачып керә. Кулында газета, хат...

Ш а м и л *(сумкасын өстәлгә куеп, кухня ишеген ачып карый)*. Ух, тәмле аш исе. Әби килеп киткән. Хәзер ашыйбыз. Нәкъ син кушканча, әбкәй, тәмләп... *(Хатны карап.)* Хат?.. Әтидән...

Р и ш а т керә.

Р и ш а т. Мөмкинме?..

Ш а м и л. Кер, кер...

Р и ш а т. Кай арада чыгып киттең?..

Ш а м и л. Кирәк идеммени?..

Р и ш а т. Малайлар футболга фотоаппаратың алып килсен, диделәр.

Ш а м и л. Рәсем төшереп йөрергә минем вакытым булмаячак...

Р и ш а т. Үземнең дә, малай, куллар-аяклар калтырап тора... Сиксәненчеләр безне төп башына утыртабыз, диләр икән...

Ш а м и л. Но!.. Финалга чыксак, җиңү безнеке инде...

Р и ш а т. Мондый җаваплы ярышта катнашканыбыз юк иде әле... Әгәр җиңсәкме, ул чак Мәскәүгә дә...

Ш а м и л. Хыялланма... Кайтып ял ит, бар!.. Әйт, фотоаппаратны алып барам... Менә абзаңның байлыгы нинди? *(Фотоаппарат күрсәтә.)*

Р и ш а т. Но!.. Каян эләктердең?..

Ш а м и л. Барый абый бүләк итте, туган көнемдә.

Р и ш а т. Барый абый да, Барый абый дисең, кем соң ул?

Ш а м и л. Әниемнең дә, әтиемнең дә якын дусты.

Р и ш а т. Аңладым. Әниеңнең личный дусты...

Ш а м и л. Ничек личный?

Р и ш а т. Ну якын, үз иткән дус. Синең белән минем шикелле.

Ш а м и л. Әйт әле, Ришат, дуслыктан да кадерлерәк нәрсә бар?

Р и ш а т. Бер нәрсә бар, малай.

Ш а м и л. Малай да малай. Менә паспорт алдым. Егет хәзер, гражданин.

Р и ш а т. Тәбрик итәм. Миннән дүрт айга кече икәнсең, иптәш гражданин. Дуслыктан да кадерлерәк нәрсә бар икән шул бу дөньяда.

Ш а м и л. Әйт, әйт...

Р и ш а т. Ярату!..

Ш а м и л. Белмим...

Р и ш а т. Белмәмешкә салынма... Дәресләр беткәч тә китапларыңны

кыстырасың да атыла-бәрелә класстан чыгып сыпырасың. Аның белән кайтыр өчен. Сиңа мәхәббәт җене кагылган.

Ш а м и л. Кем турында син?

Р и ш а т. Боргаланма. Тик шушы яшьтән гыйшык-мыйшык белән чуала башлау...

Ш а м и л. Нинди гыйшык... Әй, минем бу бөтенләй башка. Күңелгә шундый рәхәт. Мәңгегә шулай булуын теләр идем. Кайчакларда эч поша башлый, үзеңне үзең кая куярга белмисең, ул искә төшә дә рәхәт булып китә... Ниндидер көч җитмәслек эшләр эшлисе килә.

Р и ш а т. Шәп!.. Бүген футболда Ләйсәнчекне исенә төшерә-төшерә, күз алдыңа аның зифа гәүдәсен китереп, сиксәненчеләрнең кирәгеп бир әле, малай... Тузаннарын туздыр әле, яме...

Ш а м и л. Хәзер Әкълимә килергә тиеш.

Р и ш а т. Нигә килә ул монда. Солтания апа класста гына дәресен карашырга диде түгелме?..

Ш а м и л. Өйдә тынычрак.

Р и ш а т. Аңлашыла... Әйдә, өстерә, өстерә...

Ш а м и л. Солтания апа сиңа кушкан иде дә...

Р и ш а т. Беренчедән, җиңги, ягъни абыйның хатыны, өйгә малайлар, кызлар китерергә кушмый. Икенчедән, буялган тырнаклары белән Әкълимә күземне чукып дип куркам.

Ш а м и л. Усал түгел лә ул, ялкаурак кына бераз.

Р и ш а т. Классында утырып кала ул чегән кызы.

Ш а м и л. Калмый, калдырмабыз.

Р и ш а т. Киттем. Син укыт, тәрбиялә. Кара, ул чегән кызы үзе сиңа сабак укытмасын!..

Ш а м и л. Кая ашыгасың, әйдә ашап алабыз...

Р и ш а т. Кешеләрдә ашап йөрергә ярамый, җиңги кушмый.

Ш а м и л. Гафу... Онытканмын...

Ә к ъ л и м ә керә. Ул зур кара күзле, кара чәчле, мәһабәт сынлы. Кыз, кай ягы беләндер, чегән кызына охшаган.

Ә к ъ л и м ә. Ха!.. Отличниклар гына икән ич монда. Салют!..

Ш а м и л. Салют!!!

Р и ш а т. Мин киттем!.. Уңыш телим. *(Китә.)*

Ш а м и л. Сал жакетынны!.. Уз.

Ә к ъ л и м ә. Жакетымны салырга?.. Пожалуйста... Ә син, матурым, ярдәм ит.

Ш а м и л. Әйттемме сиңа, матурым дип дәшмә.

Ә к ъ л и м ә. Синең бүген кәефең начар, иптәш профессор...

Ш а м и л. Нигә кыланасың?..

Ә к ъ л и м ә. Кыланмыйм...

Ш а м и л. Кичә физиканы ничек яхшы өйрәндек, беләм дидең, бишкә җавап бирәм дип мактандың. Такта янында суга төшкән тавык.

Ә к ъ л и м ә. Солтания апаның күзләренә карадым исә, белгәннәрем башымнан чыга да бетә... Яратмыйм мин Солтания апаны.

Ш а м и л. Солтания апа өчен кирәкми синең яратуларың... Ал дәфтәреңне...

Ә к ъ л и м ә сумкасыннан дәфтәр һәм китап алып өстәлгә куя.

Ш а м и л. Чиш шул ике мәсьәләне.

Ә к ъ л и м ә *(бераз язган була да)*. Кара әле, Шамил, башта үзең генә дәресеңне әзерлә, яме, мәсьәләңне чыгар, дәфтәреңә яз. Аннан мин күчерермен, син аңлатырсың, яме, матурым, әй лә Шамил дигәнем.

Ш а м и л. Тагын нәрсә, әйтеп бетер...

Ә к ъ л и м ә. Әйтер сүзем дә юк, мәсьәлә дә чишеп утырасым килми...

Ш а м и л. Нигә вакыт әрәм итеп килдең!..

Ә к ъ л и м ә. Әй, Шамил матурым, йөрәгемдә ут, шул басылмасмы дип киләм янына. Киңәш бир, ничек тынычланырга миңа, ә? Кайларга китеп... Ә син мәсьәлә дисең. Әй, математикаңа төкерәм... Физикасына да...

Ш а м и л. Син тилерә башлаган...

Ә к ъ л и м ә. Унбиш яшьтән тиле мин... Физикасын да, математикасын да отличнога беләм.

Ш а м и л. Мактанырга оста син...

Ә к ъ л и м ә *(пианинога күзе төшеп)*. Ә менә җырларга, биергә, пожалуйста... *(Аккорд ала, авыз эченнән «Ромашкалар» көен җырлый.)* Әй... *(Шамилнең читтә урнаштырылган ташлар коллекциясен күреп.)* Минем дә малай кеше, егет кеше буласым килә. Йөрер идем ташларга гашыйк булып, җыяр идем тау-тау мәрмәр ташлар. Мин оешып бетмәгән бер җан шул. Чәчәккә, күбәләккә, музыкага гашыйк... Эчем тулы кайгы-хәсрәт...

Ш а м и л. Егетләр яратуларын да, кайгыларын да урамга чыгып актармыйлар... Тыныч кына...

Ә к ъ л и м ә. Тыныч кына шул, кызларның йөрәкләре янып беткәндә, аларныкы җылына гына башлый... Эгоистлар...

Ш а м и л. Мәхәббәт турында сөйләшергә вакыт юк, Әкълимә, утыр...

Ә к ъ л и м ә. Ташлачы, зинһар... Миңа җанымны кая куярга урын кирәк. Бармы шундый урын, Шамил? Я? Ник дәшмисең? Табып бир...

Ш а м и л. Юк андый урын... Кешеләрнең җаны беркайчан да тыныч булырга тиеш түгел, минемчә. Шул. Тагын нәрсәләрдер чишәргә белемем җитми.

Ә к ъ л и м ә. Укып, белем алып кына четрекле мәсьәләләрне чишеп булса икән. Кешеләр институт бетерә, югарыга омтыла, ә үзләре...

Ш а м и л. Кайбер кешеләр диген, кешеләр димә...

Ә к ъ л и м ә. Әй. Аңлыйсыңмыни син... *(Пластинкаларга күзе төшә.)* Бию көе? Чардаш, Шейк? Я әле уйнат!

Ш а м и л. Утыр, бернинди музыка да кирәкми...

Ә к ъ л и м ә. Бик теләсәң ун-унбиш минутта эшләп бирәм мәсьәләләреңне, Шамил матурым...

Ш а м и л. Аңламыйм мин сине, Әкълимә.

Ә к ъ л и м ә. Фи... мине бер кеше дә аңламый. Әти дә, әни дә... Үземне үзем дә аңламыйм... *(Радиоланы боргалый. Музыка. Әкълимә Шамил каршына килеп баса, бии башлый.)*

Спорт киеменнән Л ә й с ә н керә.

Л ә й с ә н *(үз-үзен тотарга тырыша)*. Хәерле көн!

Ә к ъ л и м ә. Хәерле көн, Ләйсән.

Л ә й с ә н. Дәрес әзерлисезме?..

Ш а м и л. Әйе...

Л ә й с ә н. Дәрес карамыйча җырлап, биеп утырганыгызны Солтания апа белсә...

Ш а м и л. Белсә?..

Ә к ъ л и м ә. Син, акыллы кыз булсаң, Ләйсән, кайда нәрсә күргәнеңне мәктәпкә ташып йөрмә. Гайбәтче кызларны яратмыйлар мәктәптә. Отличница булсалар да.

Л ә й с ә н. Ялганчы булу яхшырак алайса?.. *(Пауза.)* Бәлки әле футбол ярышына да бармыйсыңдыр, Шамил...

Ә к ъ л и м ә. О, анда барабыз, име, Шамил матурым.

Ш а м и л. Ләйсән, уз, утыр, без ярты сәгать кенә...

Л ә й с ә н. Дәвам итегез, дәрес өйрәнүегезне, дим. *(Чыгып китә дә шунда ук ишекне ачып.)* Бүгенге ярышта иң җаваплы кеше син, Шамил, шуны онытма! *(Китә.)*

Э к ъ л и м э. Ха, көнләште. *(Пауза.)* Сизәм, кәефен китте. Борчылма. Бүгенгә китәм, ә иртәгә... ярсуымны басарга тырышырмын да килермен. Күңелеңне төшермә, иптәш профессор, начар укучы булмам.

Ш а м и л. Алгебра белән физикадан иң кимендә дүртлегә укымасаңмы?..

Э к ъ л и м э *(жакетын кия; кесәсеннән таш алып.)* Мә, ташлар профессоры, коллекцияңә куй.

Ш а м и л. Рәхмәт.

Э к ъ л и м э. Сау бул... Футболда уңыш телим, җиңү!.. *(Чыга, шунда ук ишекне ача да.)* Салют! Шамил матурым!..

Ш а м и л. Салют! *(Пауза.)* Менә аңла бу кызларны. Аңла! Малай түгел, егет инде син, паспорт алган егет кисәге. *(Көзге алдына басып.)* Егет!.. Ләйсән ачуланды... Күзләре зур булып ачылдылар... Шундый матур күзләр... Аңарга үпкәләсә дә килешә, иреннәре елмаерга гына тора. Ашап алыйм да китәргә кирәк. Бүгенге футболда... Иң зур җаваплылык синдә диде бит Ләйсән...

Х ә м з ә керә.

Х ә м з ә. Ярый торгандыр, шәт.

Ш а м и л. Керегез...

Х ә м з ә. Мә әле, улым, кыздырып аша әле шуны. *(Балык бирә.)*

Ш а м и л. Рәхмәт. Минем балык кыздырырга вакыт юк.

Х ә м з ә. Алайса, әбиең килгәч кыздырыр.

Ш а м и л. Әби бүген килеп киткән инде.

Х ә м з ә. Аңа да ике йорт арасында йөрү бик авыр. Аякларым сызлый, ди.

Ш а м и л. Йөрмә, әбкәй, дип әллә ничә әйттем мин аңа, әни дә...

Х ә м з ә. Ул үзенчә сөйли. Шушында килеп Шамилне вакытында ашатсам, үзем көне буе ашамый йөрсәм дә риза, ди.

Ш а м и л. Мин бала түгел. Үзем дә әзерләп ашый алам.

Х ә м з ә. Әбиләр өчен син иллегә җитсәң дә бала. Әтиеңнән хәбәр бармы соң, улым?

Ш а м и л. Әнә хат килгән.

Х ә м з ә. Нәрсә яза?

Ш а м и л. Укымадым.

Х ә м з ә. Ничек түзеп торасың, ачып укы.

Ш а м и л. Әнигә адресланган хатларны укымыйм мин. *(Спорт киемнәрен кия.)*

Х ә м з ә. Кая барасың?..

Ш а м и л. Футболга. Ике мәктәп ярыша.

Х ә м з ә. Ярый, ярый, хәерле юл. Җиңеп кайтыгыз. Ой, харап та яратам шул футболны. Кичә ничек уйнадылар, телевизордан карадык. Теге нилэр белән... Англияләр уйнады. Төнге бергә кадәр. Үзебезнекеләрне кызганып ашказаным авыртып бетте. Шундый китереп тибәләр, хәерсезләр! Һей, урында утырып торып булмый. Кабыргаң-фәләнеңә тибеп сине дә имгәтмәсеннәр, улым. *(Телефон шалтырый.)*

Ш а м и л *(трубканы ала).* Исәнмесез, Барый абый... Әни кайтмады әле... Хәлләрем яхшы... Әйе, хушыгыз... *(Трубканы куя.)*

Х ә м з ә. Теге кеше шалтыратамыни?

Ш а м и л. Кайсы кеше?

Х ә м з ә. Теге ни, Барый дисең бит. Бик еш килә дә үзе.

Ш а м и л. Килсә соң...

Х ә м з ә. Әтиең өйдә чакларда бер дә күренми иде... Кая эшли ди үзе?

Ш а м и л. Белмим.

Х ә м з ә. Белмисең шул, бичара шул син, мәхлук син...

Ш а м и л *(каты).* Нәрсә? Мәхлук?..

Хәмзә. Дулама, улым, дулама... дошман түгел мин сиңа. Менә мондый чагыңнан кулымда күтәреп йөрттем сине. Әтиең дә, киткән чакта, Хәмзә бабай, улыма күз-колак булыгыз, дигән иде.

Шамил. Әйтмәгез миңа бичара дип, житмәсә кешеләр алдында.

Хәмзә. Кешеләр дигәнең шул теге сары чәчле кызмы инде? Баскыч төбе сагалаган кызларны әйтер идем, улым. Андыйлардан ерраграк тор син... Әй, аңламыйсың шул әле син, Шамил улым, балалыгыңнан чыгып бетә алмыйсың...

Шамил. Паспорт алган кеше бала буламыни?..

Хәмзә. Миңа Гәрәй кызганыч...

Шамил. Инде әти бичарамы?..

Хәмзә. Гомерем буе намуслы кеше булдым, гадел... Яратмыйм әшәкеләрне... Паспорт алган егет булсаң, әтиеңнең йөзенә кызыллык китертмә, куып чыгар ул Барый дигән ләгыйнне.

Шамил. Ләгыйн түгел. Инженер ул — төзүче. Бөтенсоюзда беренче урында торырлык больница төзергә килгән ул безгә... Яхшы кеше ул.

Хәмзә. Аның яхшылыгыннан безнең йөрәкләр ат башы кадәр булып күперде.

Шамил. Кемнең ул, сезнең?..

Хәмзә. Тирә-күршеләрнең. Әнә Шәймәрдән нәрсә сөйли... Синең өчен мин оялам. Сөйләш әниең белән әйбәт кенә... Китереп йөртмәсен ул инженерны.

Шамил. Нәрсә, нәрсә?..

Хәмзә. Миңа сөйләве дә бик авыр, улым... Эчем поша... Яратмыйм кыек-мыек эшләрне...

Шамил *(өстәлдә яткан балыкны алып)*. Мәгез!.. Алыгыз!.. Әгәр тагын...

Хәмзә. Чү, чү! *(Ишеккә кила.)* Менә... ит яхшылык, көт явызлык, һей, миңа дисәгез... *(Чыгып китә.)*

Шамил *(кулындагы китабын атып бәрә)*. Аптыратты... кешеләр пенсиягә чыккач псих була башлый, дип сөйлиләр иде. Әллә дөрес тә инде. Керә дә әллә ниләр сөйләп чыга... *(Бүлмәсенә кереп китә.)*

Пауза. Разия, аның сумкасын күтәреп Барый керәләр.

Разия *(сумкасын алып)*. Рәхмәт. Синең машина шәп булды әле. Троллейбуста кайта-кайта кырык минут вакытым уза иде. Утыр, Барый. Әле безнең бер ун минут вакытыбыз бар бит.

Барый. Көтәм... *(Утыра.)*

Разия. Хатлар?..

Барый. Гәрәйдәнме?

Разия. Анардан... Мин үзен көтә идем... *(Укый, йөзе караңгылана.)* Һей!..

Барый. Нәрсә?..

Разия. Ышандырган булды. Июньдә кайтам, бергә ялга китәрбез, дигән булды.

Барый. Нәрсә яза?..

Разия. Экспедициядә бер егетләре өйләнгән дә Гәрәй аңа үзенең отпуска вакытын биргән.

Барый. Тегеләр туй сәяхәтенә киткәннәрме?..

Разия. Әйе.

Барый. Гажәпләнерлек урын юк. Гәрәй ич ул. Баштан кешеләргә, аннан гына үзенә.

Шамил чыгарга барган жиреннән туктап кала.

Разия. Бүген үк шундый хат язам, өйгә кайтып та йөрмә, дим... Бу кадәр таш йөрәкле булмаса соң. Минем бөтен планнарымны бозды.

Барый. Тынычлан, Разия...

Р а з и я. Тынычландырма, Барый... Ул һәрвакыт шулай... Аңарга әллә без бар, әллә юк... Ачуымны китерсә, китәрмен дә барырмын... ялгызын калдырып...

Б а р ы й *(көлеп)*. Җиде кат җир астыннан хәзинә таба белгән Гәрәй сине генә бик тиз табар... Әйдә, киттекме?..

Р а з и я. Хәзер...

Ш а м и л югала.

Б а р ы й. Мин чыга торам...

Р а з и я. Ярар... *(Барый чыгып китә.)* Беләм инде, ике ай дигәне аның ярты ел була... *(Нервланып, сумкасындагы әйберләрен бушата. Кухня белән ике арада йөри.)* Шамил!.. Ничә мәртәбәләр әйткәнем бар, аш өстәленә портфелеңне куйма, дип. Тыңламыйсың гына бит. *(Бүлмә ишегенә килеп.)* Нигә вакытсыз яттың?.. Әнә, әтиеңнән хат килгән, укы!.. Мин киттем, берәр сәгатьтән кайтырмын.

Ш а м и л *(чыга)*. Әни...

Р а з и я. Нәрсә?..

Ш а м и л. Минем синең белән сөйләшәсем бар иде...

Р а з и я. Сөйләш соң...

Ш а м и л. Ә син утыр, тыңла...

Р а з и я. Утырып торырга вакытым юк, ашыгам. Төзелеш участогына барып киләсем бар... Барый абыең көтә... Кайткач сөйләшербез.

Ш а м и л *(әнисенә карап тора да)*. Һәрвакыт шундый син... Ашыгасың, вакытың юк... *(Чыга.)*

Р а з и я. Шамил, Шамил!.. Нәрсә булган бу балага! Мәктәптә берәр хәл бармы?.. Мөгаен, икеле алгандыр... *(Шамилнең сумкасын актара.)*

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәктәп. Кызыл почмак. Төрле лозунглар. Стенада отличникларның рәсемнәре. Призлар. Бераз паузадан соң Л ә й с ә н керә. «Яшен»гә кәгазь элә. Анда карикатура.

Л ә й с ә н. Укысын да, күрсен дә, Шамил, Шамилчик... Оялмый да, ичмасам. Шундый җаваплы көнне. Миңа ачуланыр инде... Син редактор, синең эшең, дияр. Юк, шаярма! Без редколлегия белән, Солтания апа ризалыгы белән...

Чыгарга бара. Ишектә Ш а м и л белән очраша. Ш а м и л нык дулкынланган. Л ә й с ә н Ш а м и л н е бәреп чыкмакчы. Ш а м и л аның кулыннан тотып ала.

Ш а м и л. Тукта, Ләйсән.

Л ә й с ә н. Җибәр!..

Ш а м и л. Әйт, нинди гайбәт сөйләдең Ришатка?

Л ә й с ә н. Җибәр, дим, Ришатның үз күзе юкмы әллә.

Ш а м и л. Нәрсә күргән ул. Ни хакы бар аның... Белер-белмәс җыелыш җыйнарга да яла ягарга...

Л ә й с ә н. Бик бар. Иң җаваплы ярышны өздең. Футболга килмәдең. Син уйнаганда беркайчан да җинелмиләр иде безнең малайлар. Бар да шулай, ди. Шамил булса болай хур булмас идек, диләр. Әкълиманең шейк биюе синең өчен кыйммәтрәк булган шул.

Ш а м и л. Мин сине мондый дип белми идем, Ләйсән.

Л ә й с ә н. Мин дә сине шундый дип белми идем.

Ш а м и л. Нинди дип?..

Л ә й с ә н. Мин нинди?..

Ш а м и л. Син көнче, син чебенне фил итүче, фантазер.

Л ә й с ә н. Ә син... син әнә нинди, кур, ничек бисез?..

Ш а м и л *(«Яшен» янына килә. Андагы рәсемнәрне күреп).* Кем эше бу?.. *(Ачу белән Ләйсәнгә килә.)* Кем язды, дим?

Л ә й с ә н. Редакция эше сер.

Ш а м и л. Эх, син... Менә син нинди икән...

Л ә й с ә н. Ә син, син... Ничә мәртәбәләр бергә киногa бардык, урманга.

Ш а м и л. Берни дә күрми дә, белми дә торып... *(Кинәт газетаны ертып ала.)*

Л ә й с ә н. Шамил!.. Нишлисең син? Шәп!.. Егетлек күрсәттең...

Солтания, Ришат керәләр.

С о л т а н и я. Тавышыгыз бөтен коридорга яңгырый... Нишлисез?

Р и ш а т *(газета ертыкларын ала).* Ни хакың бар синең?..

Ш а м и л. Яла ягарга синең хакың булган кук...

С о л т а н и я. Җикеренмә, Рамазанов. Әкълимәгә дәрес әзерләргә булышу өчен беркеттем сине. Өеңдә һәмит уйнарга түгел. *(Газетага күрсәтеп.)* Кем эшли мондый эшне, кем? Юк, бу кыланышларың болай гына калмас. Ата-аналар комитеты тикшерер сине, педсовет.

Ш а м и л. Тикшерсеннәр... Тикшерегез...

Р и ш а т. Әйттем сиңа, ул чегән кызы белән сак бул, дидем.

Ш а м и л. Яхшы чакта туктат акыл сатуыңны...

Р и ш а т. Туры сүзгә җавап юкмы, Шамил дус. Җыелыштан күл селтәп чыгып киттең дә бит, бюрога чакырсак нәрсә диярсең икән...

Әкълимә керә. Ул Солтаниягә нәрсәдер әйтмәкче.

Ә к ъ л и м ә. Солтания апа... *(Солтания читкә борыла. Ришатка.)* Нигә күзегез белән ашардай булып карыйсыз?.. Әллә Әкълимә хурланып да җылап мәктәптән чыгып китәр дисезме?.. *(Газета ертыкларын ала.)* Нәрсә бу?..

С о л т а н и я. Әйдәгез, директор кабинетына. Анда сөйләшербез.

Ә к ъ л и м ә *(укый).* Безнең мәктәп футбол командасын хурлыкка төшерүчеләр, күрегез ничек матур биниләр... *(Ришатка.)* Син ясадыңмы бу рәсемне?

Р и ш а т. Синең ише курчакны ясап вакыт әрәм итәмме соң.

Ә к ъ л и м ә *(Ләйсәнгә).* Синме, Ләйсән?..

Р и ш а т. Кагылма!..

С о л т а н и я. Әйдәгез... *(Ишеккә юнәлә. Ришат белән Ләйсән дә аның артыннан баралар.)* Рамазанов, Сәетова!.. Кемгә әйтәләр?

Ш а м и л. Директор алдына барырлык гаебем юк минем.

Ә к ъ л и м ә. Әнә Ләйсән барсын. Ул язарга да, сөйләргә дә бик оста.

Р и ш а т. Нәрсәгә ялынасыз аларга... Әйдәгез, Солтания апа...

Чыгалар. Пауза.

Ә к ъ л и м ә. Шамил... Хәзер үк Исмәгыйл абыйга барысын да сөйлим. Мин гаепле, мин начар кыз. *(Пөгереп ишеккә килә.)*

Ш а м и л. Барма!.. Мин гаепле... Җавабын үзем бирермен... Мин кичә шундый хәлгә калдым... Уйланып йөрдем-йөрдем дә... Шундый хәл, кешегә дә сөйләп аңлатып булмый... Пөгереп килдем, соң иде инде... Безнекеләрне күреп...

Ә к ъ л и м ә. Шатлыгым шундый зур иде. Константин Михайлович аркамнан сөйде, коридорда, молодец, Әкълимә, ди, алгебрадан контрольныйны дүрткә язгансың, ди.

Ш а м и л. Бүген язган контрольныймы? Тикшергән дә... Ух... шәп... *(Әкълимәне кулыннан тотып әйләндереп ала. Әкълимә аңа тотынып биеп китә.)*

Әкълимә. Там, там, тамчы, там! Тамуынны яратам... Торам-та, та...

Исмәгыйл, Солтания, Ләйсән, Ришат керәләр.

Исмәгыйл (*кулларын җәеп*). О!.. Шәп!.. Анда дәресләр бара, монда танца, җыр, бию... Я, я, нигә туктадың, Әкълимә, һәйбәт биисең, күрәм.

Шамил. Гафу итегез, Исмәгыйл абый. Без, мин... болай гына.

Исмәгыйл. Күрәм, күрәм...

Ришат. Бер бии башлагач туктатып та булмыймы, Шамил дус.

Солтания. Каршында директор басып тора. Аңлат җинаятеңнең сәбәпләрен.

Шамил. Җинаять?.. Нинди? Сез... Эх, сез... Үзегез әле укытучы... (*Чыгып китә.*)

Исмәгыйл. Тукта, Шамил...

Әкълимә (*Солтаниягә*). Төрмәгә ябарга гына калды инде җинаятьче булгач, конечно!.. (*Чыгып китә.*)

Исмәгыйл. Нинди кәмит булды бу...

Солтания. Күрдегез бит.

Исмәгыйл. Кызганычка каршы, бернәрсә дә күрмәдем дә, аңламадым да.

Солтания. Әнә ул призлар Шамил катнашында яулап алынды. Ә бүген безнең мәктәп хурлыкка калды. Җитмәсә әле газетаны ерта.

Исмәгыйл (*газетаны ала, дикъкатьләп карый. Ришатка.*) Кемнәр болар?.. Шәп бииләр.

Ришат. Шамил белән Әкълимә... Әнә бераз охшаганнар да.

Исмәгыйл. Шәп, шәп... Димәк, безнең мәктәптә һәйбәт кенә художниклар да бар.

Солтания. Белми идегезмени, Ришат инде андый эшкә...

Исмәгыйл. Әлегә кадәр белми идем шул. Хәзер белдем. (*Ришатка.*) Бар, Ришат, Шамилне кабинетка чакыр.

Ришат. Хәзер, Исмәгыйл абый.

Исмәгыйл (*Солтаниягә*). Әйдәгез әле...

Чыгалар. Ләйсән газета ертыкларын җыйнап озак карап тора. Куллары белән күзен каплый, үкси...

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Разиялар квартирасында зал. Пәрдә ачылганда беркем дә юк. Разия кайта. Ул борчулы, кулында конверт.

Разия (*конвертны ача*). Мәктәптән. Больницага да шалтыраткаННар. Нишләде ул Шамил?.. Кичә дә соң гына кайтты. Ашамады, эчмәде, төренде дә ятты. Бер сүз дәшми (*кухняны карап чыга*). Ашамаган да. Мәктәпкә барырмын дигән идем, вакытында больницадан кайта алмадым.

Барый керә.

Барый. Исәнме, Разия. Уф-ф... (*Арып диванга утыра.*)

Разия. Нигә уфылдыйсың?

Барый. Иртәнге җидедә чыгып киткән идем, көчкә иллала котылдым. Минем Шамил дус өйдәме?

Разия. Кирәк идемени?

Барый (*пакет күрсәтә*). Менә бу аңа.

Разия. Нәрсә ул?

Барый. Сер...

Р а з и я. Әнә бүлмәсенә кертеп куй...

Б а р ы й. Сәгать дүрт, әйдә киттекме?..

Р а з и я. Син инде гафу ит, Барый. Мин бара алмыйм. Үзен генә бар.

Б а р ы й. Үзем генә?! Башлап үзен шалтыраттың. Киев профессорын каршы алырга мине дә алып бар, аның белән таныштыр дидең. Хәзер инде бармыйм, имеш.

Р а з и я. Кырык эшем кырылып ята, Барый. Аннан...

Б а р ы й. Аңла, Разия, сиңа аның белән танышу бик кирәк. Гаҗәп кеше ул Карабатинка.

Р а з и я. Батинка түгел. Бутинко. Кара түгел. Коро.

Б а р ы й. Шул, шул Коробутинко. Искиткеч машиналар, төрле нечкә механизмнар, асыл мехлар, тагын шундый ук асыл җиһазлар эшләнгәнен белә идем Казанда, ә менә бөтендөнья өчен әһәмияте булган медицина инструментлары эшләнгәнен белми идем. Андрей Михайлович шулар өчен Казанга килә м дигәч, күзләрем шар булды. Сиңа ул әле бик күп медицина яңалыклары сөйләр.

Р а з и я. Аның белән очрашу минем өчен зур бәхет. Мин аның медицина өлкәсендәге ачышларын, хирургиядәге олы хезмәтләрен яхшы беләм.

Б а р ы й. Нинди эшең бар, әйт, үзем эшлим.

Р а з и я. Эш түгел... Шамил борчый. Мәктәпкә чакырып хат та җибәргәннәр. Бара алмадым. Үч иткәндәй, бүген бик авыр операция булды. Белмим, коткарып булырмы?..

Б а р ы й. Менә, менә... бик шәп тә... Коробутинконы алып бар консультация ал аңардан. Атаклы хирург Казанга килә, ә син...

Р а з и я. Үзем дә шулай уйлаган идем дә соң...

Б а р ы й. Шамил өчен борчылма, үсеп җиткән егет ич ул.

Р а з и я. Игътибарның иң кирәк чагы. Кичә дә нәрсәдер әйтмәкче иде, минем вакытым юк, дигән сүзгә үпкәләп чыгып китте.

Б а р ы й. Профессорны каршы алып гостиницага илтеп куйыйк та аннан мәктәпкә барырбыз.

Р а з и я. Ярый, алайса, киттек. Тукта *(номер җыя)*. Алло! Люция, синме? Я, ничек хәле? Хатынына әйт, бер кашык та су бирмәсен, температурасын күзәт. Әйе... Бик ашыгыч кирәк булсам, шылтыратыгыз. Мин озакламый өйдә булам. *(Трубканы куя.)*

Б а р ы й. Самолет килергә ярты сәгать вакыт кала.

Р а з и я. Хәзер, хәзер... *(Иренен буйый.)* Киев профессоры Казан хатыннарын килбәтсез димәсен әле. Әйдә *(чыгарга баралар)*. Барый, тукта. Нәрсә бу? *(Пиджагының җиңен күрсәтә.)*

Б а р ы й. О, о!.. Әкәмәт!.. Кая шулкадәр буялдым икән?..

Р а з и я. Буялган җиңле жакет киеп профессор каршы алырга барасың, ә? Сал тизрәк.

Б а р ы й. Салырга?.. Пиджаксыз барыйммы... Кара, күлмәкнең дә рәте юк.

Р а з и я. Сал, сал, тизрәк. Мә, Гәрәйнең костюмын ки.

Б а р ы й. Тиз генә чистартып булмасмы соң?.. Я тиз генә безнең өйгә барыйк.

Р а з и я. Ленин районына барырга?.. Сәгатьне кара... Мә, ки.

Б а р ы й. Рәхмәт, Разия ханым, яхшы түгел...

Р а з и я *(кычкырып көлә)*. Нәрсәдән, кемнән яхшы түгел... Бик тиз оныткансың, дустым.

Б а р ы й. Нәрсәне?..

Р а з и я. Гәрәйнең кара костюмын киеп, кызлар күзләргә йөргән чакларыңны дим... Ә Гәрәй синең модный туфлиләреңне киеп туздырды.

Б а р ы й. Туздыра алмады. Мин аны синең белән танцага барган

чакларда гына бирә идем аңа. *(Пауза.)* Эх, Разия, матур иде ул чаклар... Картаябыз. Әнә синең дә чәчләреңдә ак бәсләр.

Р а з и я. Ә дуслыгыбыз һаман дәвам итә. Әнә үз костюмыңны урындык башына элеп куй...

Б а р ы й *(костюмны кия)*. Киттекме?..

Р а з и я. Киттек. *(Кызу гына чыгалар.)*

Пауза. Ш а м и л керә. Ул дулкынланган. Туп-туры тәрәзәгә килә.

Ш а м и л. Әтинең костюмы...

Ишектә Х ә м з ә. Ул ярты гәүдәсе белән бүлмәгә керә язган.

Х ә м з ә. Шамил, Шамил улым, күрдеңме?

Ш а м и л. Нәрсәне?..

Х ә м з ә. Минем сүзгә ышанмыйсың. Әнә һәр көн шулай, иртә дә, кич тә... Я машина белән, я подручком...

Ш а м и л. Тагын нәрсә?..

Х ә м з ә. Бик тәкәббер сөйләшмә, улым, бу серьезный эш. Мин сиңа малай-шалай түгел, ак сакаллы бабаң.

Ш а м и л. Ишекне ябыгыз.

Х ә м з ә. Ишекне ябармын анысы, тик син бераз уйла... Ир бул!..

Ш а м и л *(ишеккә килә, Хәмзә югала. Шамил ишекне ябып ачкыч белән бикли. Урындыктагы пиджакка карап тора да урындыгы белән тибеп җибәрә.)* Нишләргә?.. *(Телефон шалтырый. Шамил трубканы алырга тели, ләкин алмый.)* Мәктәптән шалтыраталар. Шалтыра, шалтыра... Бармыйм... Укыйсым да килми, өйдә дә торасым килми... Нигә кайтмый бу әти... Ичмасам, Ләйсән дә килми... Әйтәм әнигә... тик ничек әйтергә, нәрсә дип... Телем бармый... Туйдым, барысыннан да туйдым... *(Ишектә звонок. Чыгаргамы дип икеләнеп тора да, ача. Ирекне күреп шатлана.)* Ирек!.. Әйдә уз, уз... *(Аны кочаклап ук ала.)*

И р е к. Нәрсә бик кызуланып киттең... Шаккаттыңмы, нигә килдең дисеңме?..

Ш а м и л. Кызуланмадым да, шак та катмадым... Килүеңә просто шат... Уз, утыр, менә монда.

И р е к. Утырып тормам... Эштән кайтып килә м дә... *(Уза, утыра.)* Өегездә берәү дә юк, ахры...

Ш а м и л. Юк, юк...

И р е к. Бүген акча алдык, получка көне, эштә бераз тоткарландым. Югыйсә, башка көннәрне иртәрәк кайтам мин...

Ш а м и л. Ашыйсыңмы?.. Әйдә, мин дә ашамаган, бераз капкалап алыйк әле...

И р е к. Рәхмәт...

Ш а м и л. Хәзер, хәзер. Монда гына алып керәм... *(Кухняга чыгып ашарга алып керә.)* Менә колбаса, өчпочмак... Аша...

И р е к *(кесәсеннән вино чыгара)*. Ашы булгач, суы да булсын... Стакан бир әле, эчик әле шул хирсаны, күрешү хөрмәтенә.

Ш а м и л. Мин эчмим. Син дә эчмә.

И р е к. Агитлама, малай. Получка алган көнне без барыбыз да эчәбез... Ничектер традиция димме... Я мастерны сыйлаган буласың, я старшийны шунда... кыланасың инде, кеше кыланганны. Мәктәпне ташлаганга бер елмы... Шуннан нибары бер күрештекме, ике микән. Укыганда ничего гына дуслар идек. Конечно, син яхшы укый идең, ә мин җиденчедә ике ел утырган малай, сөйрәлә идем үземә күрә.

Ш а м и л. Тарихны отличнога укый идең.

И р е к. Һо! Тарих шул кызыклы фән. Укытучысы да во! Исмәгыйл абый. Әгәр укыган булсам, тарих факультетына кергән булыр идем.

Ш а м и л. Укырсың әле...

Ирек. Булмас... Минем тормыш шундыйрак, ә менә син бик знаменитый геолог буласың инде. Әтиең кебек.

Шамил. Хыяллар зур да, ничек булыр. И-их, малай, кайчакта шундый кызыклы уйлар килә башка. Җирнең астын-өскә китереп актарып, әлегә кадәр беркем дә тапмаган яңа байлыклар табасы иде.

Ирек. Табарсың да. Баш йомры синең. Беләк нык, күз үткен. Көтәрдекме?

Шамил. Эчмим.

Ирек. Кызлар эчә торганы бу... Ярар, эчмә. Эчкән кешеләрне мин дә яратмыйм. Бигрәк тә кызлар, хатыннар эчсә... *(Пауза.)* Исерек әтинең бәласе менә шунда утыра *(җилкәсен күрсәтә)*. Авыр йөк булып. Туйдым, әллә кайчан башымны еракларга олактырырга йөрим дә, әни кызганыч. Минем аркада әнигә дә әлегә.

Шамил. Кыйныймы әллә?

Ирек. Ничек кенә әле. Баштан мина бәйләнә, мине яклаган өчен әнигә әлегә. *(Стаканын алып.)* Хурлыкка калып яшәр өчен тудырганнар мине дөньяга... Эчик әле...

Шамил. Аңламыйм. Әтиеңне эчкән өчен ачуланып утырасың, ә үзең эчик тә эчик...

Ирек. Юк, юк та эчәсе килә башлады... Үземне үзем тыярга тырышам. Эчәргә ярамый... Шуның өчен, брат, әнине ташлап китәргә булдым.

Шамил. Китәргә? Кая?..

Ирек. Бер-ике малай уйлашып йөрибез әле... Якутиягә, я башка якка.

Шамил. Якутиягә?..

Ирек. Яраса әгәр, бир әле, малай, миңа әтиең адресын. Дөнья хәлен белеп булмый, бәлки күрешербез дә... Гәрәй абый мине таный.

Шамил. Таный, таный, ул сине ярата иде... Кайчан китәсең?.. Кемнәр белән?..

Ирек. Ике дус.

Шамил. Бергә эшлисезме?..

Ирек. Нәрсәгә ул кадәр төпченәсең?..

Шамил. Әгәр дус дип йөргән малайларың син бәлагә очраганда ярдәм итәсе урынга сыртларын гына күрсәтсәләр?

Ирек. Сырт күрсәтсәләрме?.. Менә!.. Ул чак мин дә нәрсә күрсәтергә белермен.

Шамил. Алыгыз мине дә үзегез белән, ә?

Ирек. Сине?!

Шамил. Әйе.

Ирек. Ә укуың?..

Шамил. Анысын үзем хәл итәм... Кайчан китәсез?.. Бүгенме, иртәгәме?..

Ирек. Юлга акчаң бармы?..

Шамил. Табам. Менә боларны сатарга кирәк *(проигрыватель һәм фотоаппарат бирә)*. Күпмегә булса да сат... Магнитофонга дип җыйган акчам да бар.

Ирек. Ярар, Коляга әйтермен, ул сиңа сатып бирер.

Шамил. Аппаратны бирмим... хуҗасына тапшырам. Я әйт, конкретно, кайчан китәбез?..

Ирек. Кил иртәгә безнең бакчага, шунда сөйләшербез.

Шамил. Ничек барырга, өйрәт.

Ирек. Әйдә, урамда сөйләшербез, өегез бик эссе.

Шамил. Әйдә, озатам.

*Чыгалар. Озак пауза. Шамил Әкълимә белән керә.*

Әкълимә. Каян килеп чыккан ул синең яныңа?..

Ш а м и л. Эштән кайтып килә. Уз!..

Э к ъ л и м ә. Үзең генәме?..

Ш а м и л. Әйе, утыр. Иртәгә физика.

Э к ъ л и м ә. Булса соң. Син бүген дәрескә килмәдең. Физикадан нәрсә уттек, белмисең. Нигә килмәдең?..

Ш а м и л. Үземнең Ришат ясаган карикатурама караргамы, я булмаса шуларның бөтенләй юк гаепләрне минем өскә ыргытканнарын ишетеп торыргамы?..

Э к ъ л и м ә. Дөресен сөйлә дә бир. Шундый хәл булды, футболга килеп булмады, диген. Уенда бит запасной вратарь Әнвәр бар. Синең килмәскә сәбәбең булган.

Ш а м и л. Сәбәбен шул менә кешеләргә сөйләп булмый. Үзем уйларга да куркам ул сәбәп турында. Аңламыйсың син, Әкълимә... Үзем дә аңламыйм.

Э к ъ л и м ә. Мин аңлаттым инде.

Ш а м и л. Кемгә? Нәрсәне?..

Э к ъ л и м ә. Исмәгыйл абыйга кердем дә сөйләдем дә бирдем.

Ш а м и л. Нәрсә сөйләдең?..

Э к ъ л и м ә. Барын да... Ничек синдә музыка уйнаттым, ничек биеп киттем. Ләйсән кергәнне, сөйләгәннәрне, барын да...

Ш а м и л. Бер карасаң акыллы гына син, Әкълимә, ә бер карасаң?..

Э к ъ л и м ә. Бер карасаң акылсыз кебекме?..

Ш а м и л. Мин бит ул сәбәпне. Әй... калсын! Кемнең ни эше бар минем өйдә ни эшләвемдә. Синең биюең дә, Ләйсән килүе дә... Бар да ерунда... Утыр... Дәрес карыйбыз.

Э к ъ л и м ә. Син үзең утыр... Физиканы да, математиканы да бүген шундый игътибар белән тыңладым. Солтания апаның күзләре дүрт булды. Бүген мин үзем синең укытучың... Ал дәфтәреңне, ач физиканы. 27 нче бит, 16 параграф...

Шамил Э к ъ л и м ә г ә карап тора.

Э к ъ л и м ә. Утыр, утыр...

Ш а м и л *(Әкълимәчә кыланып)*. Укымыйм да, өйрәнмим дә, йөрәгемдә ут... Җанымны кая куярга урын табып бир... Төкерәм математикасына, физикасына да...

Э к ъ л и м ә *(кычкырып көлә)*. Шаярма, Шамил.

Ш а м и л. Ә шаярамы... Ничә көннәр инде син минем белән әнә шулай шаярасың... Дәрес карамыйча, җаныңны куярга урын таптырасың.

Э к ъ л и м ә. Яратам мин сине, Шамил.

Ш а м и л. Яратасың?!

Э к ъ л и м ә. Әй, күзләреңне шундый зур итеп ачып карамасана. Яратам дигәч тә, әллә... просто энем итеп, яхшы малай итеп кенә яратам.

Ш а м и л. Энем, малай?..

Э к ъ л и м ә. Ачуланма, яме, ни әйтсәң дә син әле минем өчен малай гына.

Ш а м и л. Әйтер идем инде әлдермеш бәетен. Калып торсын.

Э к ъ л и м ә. Әйе, калып торсын бер мәлгә. Минем аркада син бәлагә очрадың, әйт, күнелсезлекләрдән сине ничек котылдырырга?

Ш а м и л. Бернинди бәла дә юк, Әкълимә. Әгәр очрасам, үзем ерып чыгармын. Кемнәрнеңдер тикшерми-нитми торып яла ягулары, ышанмый маташулары, просто этлек!..

Э к ъ л и м ә. Эх, Шамил җаным, матурым, әгәр кешеләр бар нәрсәне уйлап кына, акыл бизмәненә салып кына эшли торган булсалар, мин шундый хәлгә дә калмаган булыр идем. *(Пауза.)* Аңламыйсың шул, берегез дә аңламыйсыз... Иң якын кешем — укытучым Солтания

апа да аңламады... Мин кая барып бәрелергә белми йөрдем, жылый-жылый күзләрем күрмәс булыр дип куркам, ә укытучым минем — сиңа ни булды дип сорашмады да... Икеле билгеләре куйды да куйды *(күзендә яшь)*.

Шамил. Әкълимә, мин сиңа ярдәм итәрмен...

Әкълимә. Әй, аңламыйсың ла, икеледәмени эш... Пустяк ул. Мин сине якын күрәм, Шамил *(җылый)*. Тик үземнең хәсрәтемне генә сөйли алмыйм. *(Шамилнең иңсәсенә башын куя, үкси.)*

Шамил *(юатып башыннан сыйпый)*. Сөйлә, Әкълимә, сер итеп сөйлә.

Сөйләшүләр барганда ишек шакыйлар. Аны әкрен генә ачып Ләйсән белән Солтания керә. Ләйсән шуны күргәч, чыгып китәргә тели, аны Солтания туктата.

Солтания. Мөмкинме?..

Шамил *(уңайсызланып)*. Солтания апа? Ләйсән? Узыгыз!..

Ләйсән *(зәһәр)*. Тәбрик итәбез, браво, Әкълимә!..

Әкълимә. Браво шул, браво!..

Ләйсән. Тырнакларыңны юкка гына тырпайтып йөрисең икән, ябышкансың, дим, ычкына торган түгел.

Шамил. Ычкынырга, бәлки, теләге дә юктыр әләгүченең.

Ләйсән. Әйтмәсәң дә күренеп тора.

Шамил. Кирәген дә, кирәксезен дә күрә-күрә күзең сукырайма-сын, иптәш староста.

Солтания. Әниең кайда, Шамил?.,

Шамил. Белмим.

Солтания. Кайчан кайта?.,

Шамил. Кызыксынмадым.

Солтания. Нәрсә генә кызыксындыра соң сине бу көннәрдә, Шамил?

Шамил. Сезнең ишекне шакымый килеп керүегез кызыксындыра.

Ләйсән. Ун минут шакып тордык.

Солтания. Ләйсән, акланып торуның кирәге юк, Утырыгыз әле. Сөйләшик. *(Әкълимәгә карап тора.)*

Әкълимә. Хәзер китәм, Солтания апа.

Шамил. Китмә, Әкълимә.

Ләйсән. Әгәр сүзебез сер булса, Әкълимәгә тыңларга ярамаса?..

Шамил. Синең серләрең әнә стена газетасында... Бар тагын да яз, бүген үк... Кочаклашып торалар иде, диген... Тагын шуны да өстә: мин Әкълимәне яратам.

Әкълимә. Шамил!..

Шамил. Әйе, бары тик Әкълимәне генә! Әнә языгыз, гаепләп языгыз...

Ләйсән. Ялганчы син. *(Пөгереп чыгып китә.)*

Солтания. Тынычлан, Шамил. Беркем дә сине гаепләргә дә, газетага язарга да жыенмый. Аңлашыйк, сөйләшик.

Шамил. Сез миңа ышанмыйсыз. Сезнеңчә, мин — ялганчы...

Солтания. Нигә укырга килмисең?..

Шамил. Моннан соң мәктәпкә аяк та басмаячакмын.

Солтания. Барырсың...

Шамил. Бармыйм!.. Сөйләшеп тору да кирәкми.

Солтания. Үз сүзем сүз. Ә сез китегез, дисеңме?..

Шамил. Теләсә ничек аңлагыз.

Солтания. Мин сине бу кадәр тар холыклы, кирe малайсыңдыр дип уйламый идем.

Шамил. Тар холыклы кешеләргә яраклашырга теләмәвем бу ми-нем, Солтания апа.

Солтания. Телең шундый әче, зәһәр.

Ш а м и л. Сездән өйрәндем, сез укыткан класста.

С о л т а н и я. Бу сүзләрең өчен, бу сүзләрең өчен бөтен класс алдында, директор алдында җавап бирерсең... Моннан соң мин укыткан дәрескә, бәлки, кермәссең дә... *(Чыгып китә.)*

Ә к ъ л и м ә. Ха, ха, ха... хур иттең! Молодец!.. Син аңардан минем үчемне алдың.

Ш а м и л. Нинди үч?.. Ни сөйлисең син...

Ә к ъ л и м ә. Укытучы ул укучыларның дусты, киңәшчесе булырга тиеш. Ә ул һаман ачулана, һаман кисәтә, куркыта.

Ш а м и л. Юк, Әкълимә... Үч алу түгел бу. Дөресен әйткәндә, бу минем тотнаксызлыгым, акылсызлыгымнан булды. Солтания апа мәктәптә генә әллә нинди...

Ә к ъ л и м ә. Нинди икәне күренеп тора. Яратмый ул безне.

Ш а м и л. Аның кечкенә генә улы бар. Марат исемле. Мәктәптән кайтышлый, һәр көн ул аны яслedән ала, юлда һаман нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә кайталар.

Ә к ъ л и м ә. Каян беләсең?..

Ш а м и л. Бик еш очратам мин аларны. *(Тәрәзәдән карап.)* Әни кайтты, Барый абый да...

Ә к ъ л и м ә. Ой, мине монда күрмәсеннәр.

Ш а м и л. Күрсеннәр, нәрсә син...

Ә к ъ л и м ә. Ой, юк, юк... Китим... Алар белән очрашмас өчен, дүртенче этажга менеп торам.

Ш а м и л. Әкълимә, син гафу ит... Мин ачудан гына, Ләйсән алдында гына теге сүзләрне әйттем. Чын түгел алар...

Ә к ъ л и м ә. Нәрсә чын, нәрсә ялган икәнен син үзең дә аңламыйсың, Шамил матурым. *(Кызу гына чыгып китә. Шамил үз бүлмәсенә керә.)*

Б а р ы й белән Р а з и я кайталар.

Р а з и я. Дәү рәхмәт сиңа, Барый. Син мине чыннан да искиткеч кеше белән таныштырдың. Сөйләгән медицина яңалыклары аеруча кызыклы.

Б а р ы й. Киләчәктә кешеләрнең нинди булачаклары турындагы фикере кызык түгелмени?

Р а з и я. Минемчә, ул медицина докторы гына түгел, ә киң карашлы галим, профессор.

Б а р ы й. Менә, менә әкәмәт. Философ.

Р а з и я. Хәзер үзебезнең профессор белән сөйләшәм дә...

Б а р ы й. Ул иртәгә көндез син операция ясаган авыруны барып карарга вәгъдә бирде. Мин, шуңа кадәр эшләремне тәмамларга тырышып, аны больницага илтеп куярмын.

Р а з и я. Зур рәхмәт.

Б а р ы й. Хәзер үземнең майлы җиңле пиджагымны киим дә...

Р а з и я. Минем тап ала торган сыекчам бар, тиз генә чистартыйк, әйдә.

Б а р ы й. Юк, юк... Өйдә карчык хәзер рәткә кертә аны.

Р а з и я. Син Гөләндәмгә миннән сәлам тапшырасыңмы соң?..

Б а р ы й. Бүген кичкә үзе синең янга киләм дигән иде әле. *(Пиджагын алыштыра.)*

Ш а м и л *(чыга, бераз боларны карап тора да фотоаппаратны биреп)*. Мәгез... Алыгыз...

Б а р ы й. Нигә?.. Биргән бүләкне кире ала торган гадәтем юк.

Ш а м и л. Алмасагыз, ятыр шунда. *(Фотоаппаратны каты итеп өстәлгә бәрә.)*

Б а р ы й.
Р а з и я. } Шамил!..

Шамил үз бүлмәсенә кереп китә.

Разия. Шамил дим, чык әле.

Барый. Кирәкми, Разия... Тынычлансын... Нәрсә булды бу?.. Хәзер үзем аның белән сөйләшәм. Әллә ул...

Разия. Юк, юк... Син кит, Барый... Үзем... Ул бу көннәрдә әллә нишләде. Сөйләшми... Тагын мәктәпкә керә алмадык.

Барый. Да... Кайтышлый керербез дигән идек, онытканбыз бит. Әллә мин хәзер кереп чыгыйммы, юл өсте бит. Аннан сиңа шалтыратырмын.

Разия. Хәзер инде соң. Иртәгә иртүк үзем барам.

Барый. Киттем... Тынычлан, Разия.

Разия. Сау бул, рәхмәт!..

Барый чыгып китә. Телефон шалтырый. Разия телефонга килә. Шул чак өстәлдәге вино-закускаларны күрә. Нишләргә белми.

Разия. Ой!.. Бу нәрсә?.. Нәрсә бу?.. Шамил, чык дим... *(Шамил чыга.)* Кем белән эчеп утырдың?..

Шамил. Дусларым белән.

Разия. Дуслар... Әниең юкта өйгә килеп аракы эчеп утыручылар дуслармы икән?..

Шамил. Сиңа дусларың килә, мин юкта да, әти юкта да, нәрсә эчеп утырасыңдыр, мин тикшермим.

Разия. Нәрсә сөйлисең син, Шамил?

Шамил. Туйдым... Укуны ташладым. Ә сиңа нәрсә... Машинада йөрергә, Барый белән сөйләшергә вакыт табасың, ә минем белән сөйләшергә вакытың юк. Ишек алдына чыгып булмый. Синең турыңда гайбәт. Нигә үзең турында пычрак сүзләр сөйләтәсең?..

Разия. Син, син... минем турымда гайбәт тыңлап йөрисең...

Шамил. Килеп йөрмәсен ул джентельменың.

Разия. Ой!.. *(Үзе дә сизмәстән, уңны-суллы Шамилнең яңагына суга. Разия дә, Шамил дә көтелмәгән бу хәлдән тетрәнеп калалар. Шамил, әнисенә текәлеп карап тора да, йөгереп чыгып китә.)*

Разия *(аңына килә)*. Нишләдем?.. Шамил, тукта!.. *(Ишеккә килә, телефон шалтырый.)* Тыңлыйм. Температурасы кырык. Нишләттегез?.. Тизрәк машина. Яныннан бер минутка да китмәгез. *(Трубканы куя, йөгереп ишеккә килә.)* Шамил!.. Кая китте соң әле ул?.. *(Чыгып китә.)*

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәр читендә Иреклар бакчасы. Кечкенә генә өй. Тышта, уң якта, чәчәккә күмелгән сирень куагы һәм шомырт агачы төбендә эскәмия. Ике җирдә төрле әйберләр тулы ике юл капчыгы. Шамил ялгызы. Ул җиргә йөзтүбән яткан да тынып калган.

Шамил *(паузадан соң кинәт торып утыра да)*. Бармыйм!.. Әти янына да бармыйм. Бөтенләй икенче якка китәм. Паспортым бар. Теләгән җирдә яши алам. Эшләрмен дә, укырмын да. Бала түгел лә!.. Хурлык!.. *(Пауза.)* Нәрсә дидем соң әле мин аңа. Яңакка суга. Беркайчан да авыр сүз әйткәнем юк иде. Нәрсә дидем, үтер, хәтерләмим...

Әйберләр күтәреп Ирек керә.

Ирек. Кара әле, менә бу чалбарны алыйм микән?

Шамил. Ал, ал...

Ирек. Бу бик иске шул. Тишеге дә бар икән...

Шамил *(карап)*. Чүпрәк бу, мәхит. Мә, ыргыт!..

Ирек. Бу консерваны синең рюкзакка салыйк. Минекенең, к черту, рәте юк, бүселеп чыгарга тора.

Шамил. Бир... *(Пауза.)* Ирек, кил әле, утыр әле менә монда. Киңәшик, сөйләшик әле тагын бер кат.

Ирек. Күп сөйлисең, колагым тонды.

Шамил. Минем әби әйтә, жиде кат үлчә, бер кат кис, ди.

Ирек. Егет сүзе бер була, күп сүз — юк сүз, дигән әбиләрне дә онытма.

Шамил. Бәлки әле синең әтиеңне тәрбия дә итеп буладыр.

Ирек. Әтине аны тәрбия итмәгән кеше калмады. Фабрикта да, управдомда да һаман тәрбиялиләр. Төкерә ул. Төзәләм, артык эчмәм, сугышмам дип сүз бирә дә, получка алдымы, тагын, таля-ля...

Шамил. Әгәр, малай, үзең тәрбия итеп карасаң?

Ирек. Үзем?.. *(Нервлана.)* Әгәр беләсең килсә, жиде яшемнән итәгенә тагылып йөрим. Жылый-жылый. Ә ул, бар кайт диң, акрына миңа, бәргәләп жибәрә. Хәзер мин житкән егет, аны сагалап йөри алмыйм. Ул өйдә тавыш чыгарганда әнине яклап төннәр буенча йоклалмыйм. Хурлыгыма чыдый алмыйча шәһәрне, әнине ташлап качам. Әллә мин заводта эшли алмыйммы. Эшлим. Озакламый разряд бирәләр. Уч тутырып акча алам. Менә дигән иптәшләрем, дусларым бар. Ә өйдә мәхшәр, жәһәннәм.

Шамил. Авыр хәл, дускай!

Ирек. Менә мин синең дускайларыңны бераз тәрбия итеп алыр идем алуын.

Шамил. Кемнәрне?

Ирек. Ришат белән Ләйсәнне. Дус булып йөргәннәр дә үзенне хур иткәннәр.

Шамил. Гәзиткә язуларына төкерәм. Ләйсәнне якын күрә идем. Ниндидер үзем дә аңламаган матур хисләрем бар иде. Бер көн күрмәсәм сагына идем. Ә ул барсына да... Күрсәм, өзгәләп ташлар идем.

Ирек. Кем белә инде, бәлки кочаклап үбәрсең... Синең акылың шундыйрак.

Шамил. Акылым белән уйлап, гафу итәргә дә, ачуланмаска да тырышам, булмый гына. *(Пауза.)* Ике тәүлек эчендә иң якын кешеләремне югалттым.

Ирек. Кайгырма, брат, кызлар буа буарлык.

Шамил. Әйт әле, Ирек, ни... ничек дип әйтим.

Ирек. Бутамый гына әйт. Кызлар мәсьәләсендә мин знаток. Үземнең дә романым бар. Озатырга төшәр, күрерсең.

Шамил. Ачуың чыккан чакта начар сүз әйтеп әниеңне хурлаганың бармы?..

Ирек. Әнине хурлаганым?.. *(Шамилгә карап тора.)* Аңламадым.

Шамил. Но... Рәнжеткәнең бармы әниеңне?..

Ирек. Әни ул гомере буена рәнжеп яши, жылап яши. Кемнәргәдер ләгънәт укый. Мин аның кайгысын, күңелсез тормышын күрә торып... аны рәнжетә аламмы. Юк, беркайчан да...

Шамил. Беләм. Әни мине гафу итмәс инде.

Ирек. Әниләр гафу итмәгән гаеп юк анысы. Син миңа әнием турында берни дә сөйләмәдең.

Шамил. Сорашма, сөйләп булмый.

Ирек. Алайса, бар, гафу үтен.

Шамил. Гафу үтенергә?.. Жиңел генә... *(Күкрәгенә суга.)* Менә монда таш ята, тимер...

Якында гына жыр ишетелә.

Кем жырлый?..

Ирек. Чегән кызы.

Шамил. Кем, кем?..

Ирек. Шул инде, Әкълимә Сәетова.

Ш а м и л. Әкълимә? Нишләп йөри ул монда? Әйдә, барыйк янына.

И р е к. Әнә түбәсен шифер белән япкан өйне күрәсеңме, ул Әкълимә дачасы.

Ш а м и л. Әкълимә дачасы?

И р е к. Просто... Әтиләре дачаны салды салуын, ә үзләре курортта да заграницада, дачаның рәхәтен Әкълимә күрә.

Ш а м и л. Нигә кичә әйтмәдең?..

И р е к. Әйтмәдеммени?.. Алайса, әйтергә генә уйлаганмын. Әллә тиле ул кызый. Көне-төне гитара чиертеп, җырлап йөри. Ромашкалар, ромашкалар, имеш... Көтәм дә яратам. Туйдырды, колакка мамык тыгарга гына калды.

Ш а м и л. Аңлавы читен аны.

И р е к. Аңлыйсы юк. Әтисе зур кеше. Инженер. Заводта цех начальнигы. Әкълимә бердәнбер кыз. Дингез тубыктан аңа, бии дә җырлый. Теләсә шәһәрдә өч бүлмәле квартирада яши, теләмәсә дачада. Тәкерә ул дөньясына.

Ш а м и л. Дөньяга төкереп буламы?.. Әйдә, янына барыйк.

И р е к. Әнә үзе килә, тсс...

Артта җыр.

Тау битендә үскән ак чәчәкләр,
Сез бит минем якын дусларым,
Көләч йөзегездән ямьләр алам,
Алам бәхет, шатлык нурларын.
Ромашкалар, серле ромашкалар...
Яшьлегемнең гүзәл чәчәге...

Ә к ъ л и м ә керә. Өстендә җиңел кофта, соры чалбар, башында салам эшләпә. Кулында гитара.

Ә к ъ л и м ә *(малайларны күреп)*. Шамил!.. Син монда?.. Мәктәптә ду килеп сине эзлиләр. Нигә укырга бармыйсың, ә?.. Нәрсә бу?.. *(Рюкзакны күтәреп карый.)* У-у... авырлыгы да ярыйсы гына... Димәк, ниндидер планнар корасыз?

И р е к. Без плансыз гына яши торган токым.

Ә к ъ л и м ә. Әһә, димәк, каядыр сыпырасыз?.. Әйтегез, кая?

Ш а м и л. Ерак юлга, моннан күренми.

И р е к. Шамил... *(Йодрык күрсәтә.)*

Ш а м и л. Әкълимә үз кеше.

И р е к. Хатын-кызларга ышану — язгы бозга таяну белән бер, ди минем әти.

Ә к ъ л и м ә. Ярым феодал ул синең әтиең.

И р е к. Шулай да дөрес сөйли.

Ә к ъ л и м ә. Әйт инде, Шамил...

Ш а м и л. Якутиягә китәбез.

Ә к ъ л и м ә. Котырган. Уку елы тәмамланырга бер ай вакыт калгачмы?

Ш а м и л. Барыбер.

Ә к ъ л и м ә. Авыру әниеңне калдырып син дә... Җибәрмим!.. Каравылчы Нигъмәт бабайга кычкырам... *(Чыгарга бара.)*

Ш а м и л. Әкълимә, шулмы сер саклавың?..

И р е к. Ха, гитара чиертеп килде дә безнең эшне сүтә дә башлады. Сүтми тор, яме. Әнә лучше гитараңны уйна да аерылу көен җырла. Ромашкалар, ромашкалар... *(Кинәт исенә төшеп.)* Шамил, кил әле... *(Шамилне читкә алып.)* Онытттык бит.

Ш а м и л. Нәрсәне?..

И р е к. Акчаны. Проигрывательне саткан акчаны Колядан алырга кирәк иде бит.

Ш а м и л. Бар, алып кил.

И р е к. Йөгердем. Кара, бу чегән кызы планны бозмасын. *(Чыга.)*

Ә к ъ л и м ә *(паузадан соң)*. Сине күргәч шундый шатланган идем, инде җылыйм...

Ш а м и л. Җырла, Әкълимә.

Ә к ъ л и м ә *(Шамилгә карап тора)*.

Сез беләсез бөтен гашыйкларның
Йөрәкләре ничек тибүен,
Егет белән кызның мәхәббәтен,
Берсен-берсе зарыгып көтүен.
Ромашкалар, серле ромашкалар...
Яшьлегемнең гүзәл чәчәге. *(Уйланып утыра.)*

Ш а м и л. Җырла, Әкълимә, җырла...

Ә к ъ л и м ә.

Сез бизисез барыр юлларымны
Көннәремнең якты иртәсен,
Тибрәләсез кебек хәбәр итеп
Саф мәхәббәт миңа киләсен.
Ромашкалар, серле ромашкалар...
Яшьлегемнең гүзәл чәчәге...

*(Ярсып.)* Ромашкалар!.. Кешеләр чәчәкләрне ярата, алардан шифа ала, ә үзләре...

Ш а м и л. Сүзең саен кешеләрне гаеплисең, ни хакың бар?..

Ә к ъ л и м ә. Бар, гаеплим, гомерем буенча гаепләрмен дә. Я, әйт, ни өчен безне гәзиткә яздылар?.. Аларның безгә ышанмаска хаклары бар идемени?..

Ш а м и л. Кемнәр язды соң аны. Үзләре турында гына уйлаучы нибары өч кеше.

Ә к ъ л и м ә. Нигә соң кешеләр бер-берсе турында шулай начар уйлыйлар? Бер-берсен пычратырга гына торалар?.. Нигә?..

Ш а м и л. Барысы да түгел.

Ә к ъ л и м ә. Беләм. Андый әшәке кешеләр бәлки күп тә түгелдер? Ә шулай да... Ой!..

Ш а м и л. Әкълимә!..

Ә к ъ л и м ә. Ә бер кеше... Әнә шул чәчәкләргә сокланды. Бәйләмбәйләм җыйнап миңа бүләк итте. Йолдызларга карап шигырь укыды. Бала чагыннан ук йолдызларга, айга оча алырлык булып үсмәгәненә үкенде. Киләчәктә үзенең зур кеше буласын әйтте. Әнә урман. Без аның белән анда көннәр буе йөрдек. Бик яратам, синнән башка миңа тормыш юк, дия иде. Мин дә аны ярата идем, бик ярата идем... Ышандым аңар. Ә ул... *(Үксеп җылый.)* Мин сиңа берәүгә дә сөйләмәгән серемне сөйлим. Көлмә миннән, Шамил, яме.

Ш а м и л. Сөйлә, сөйлә, Әкълимә.

Ә к ъ л и м ә. Шуннан бер көнне... Матур кояшлы көн иде бу. Мин җырлый-җырлый чәчәкләр җыям. Ул да минем белән. Күңелле безгә. Рәхәт. Кинәт ул беләгемнән тотып алды. Карыйм, күзләре аның әллә нишләгән, бөтенләй мин танымый торган кеше кебек ул. Шашынган! Әй, Шамил матурым, белмим ничек ычкынып киткәнмен дә, ничек котылып калганмын аңардан. Хәтерләмим. Аңыма килгәндә инде җиргә ятып үксеп җылый идем... Әйе... менә шушы тырнакларым, тешләрем белән саклап калдым мин үз намусымны. *(Пауза.)* Ул хәзер институтны тәмамлаган да икенче шәһәргә эшкә киткән. Киткәндә минем белән саубуллашырга да килмәде. Ә мин юләр кыз аны һаман көтәм. Зур белемле, акыллы, матурлыкны, табигатьне ярата торган кеше алай тупас булырга тиеш түгел... Ул вакытлы гына шулай саташкандыр, кешелеген җуйгандыр. Гаебен аңлар, килеп гафу үтенер дип көттем. Ул килмәде.

Шамил. Син шуның өчен кешеләрне гаеплисеңме?.. Явыз ул...

Әкълимә. Аңа минем рухи дөньям, кешелегем, киләчәгем кирәк булмаган. Юк, алар турында уйлап та карамаган ул. Ә башкалар соң? Миңа иң-иң якын кешеләр ничек? Мин начар укыйм, икеле билгеләре алам... Моның өчен мәктәп әти-әнине, ә әти-әни мәктәпне гаепли. Тик берсе дә: сиңа ни булды, Әкълимә, дип сорамый. Минем эчке дөньям белән кызыксынмый. Әти дә, әни дә һәрвакыт эштә. Эш, эш, эш... Ә кызлары ничек яши, көннәрен ничек уздыра...

Шамил. Әйдә, Әкълимә, безнең белән китәбез, Якутиягә. Минем әти янына. Анда да мәктәпләр бар. Укырбыз, институт тәмамларбыз.

Әкълимә. Юк, үз акылың булмаса, үз акылың белән яшәмәсәң, Якутиядә яшәдең ни дә, Казанда яшәдең ни, барыбер кеше түгел, түмгәк син.

Шамил. Ярар, булсын ди түмгәк.

Әкълимә. Сиңа түгел, күбрәк үземә әйтәм моны. Мин дә түмгәк, чурбан, чурбаниха. Уналты яшьлек кыз. Үз акылым бар. Уңны-сулны гына булса да аерырлык белемем бар. Киләчәк турында хыялларым бар. Үз язмышымны үз кулыма алырлык көчем бар. Ә үзем җылак кыз хәзер. Бичара кыз! Үкенәм!.. Нигә әле мин ул нахалның яңагына чалтыратмадым, битенә төкермәдем. Аның мыскыл итәргә теләвенә түзеп җылап кына калдым?.. Минем бит аның йөрәген тетрәтергә дә көчем җитә иде. Ха, ха, ха... Тиле кыз, мин бит әле үләргә дә җыенган идем.

Шамил. Үләргә?..

Әкълимә. Әнием никадәр кайгы-хәсрәт кичергән булыр иде. Янәсе, бер юлы барыннан да котылам. Эгоистка.

Шамил. Менә син нинди икәнсең?..

Әкълимә. Күрәм, үзең дә шундый. Син дә әнә качарга йөрисең, үзеңә җинеллек эзлисең. Әниең турында уйлап караганың бармы? Юк!.. Ә мәктәп? Дусларың?.. Я, нигә телсез калдың?.. *(Пауза.)* Кешеләрне гаепләүгә караганда начарлыктан арынуны бәлки үзебезне пакьландырудан башларга кирәктер?.. Шамил, ә?..

Шамил. Бәлки...

Әкълимә. Иң әлек сиңа беркая да китмәскә кирәк.

Шамил. Китмәскә?.. Юк!.

Әкълимә. Монда килеп чыккан бәлаләрнең барын да монда тикшереп, монда очына чыгар урында, син әнә китеп барасың. Үз башыңны алып качкач шул җитә, башкалар турында уйламыйсың да.

Шамил. Аңла әле, Әкълимә...

Әкълимә. Минем бик авыр минутларымда син миңа ярдәмгә килгәч, җаным бераз тынычланган кебек булган иде. Кешеләр барсы да әшәке түгел, кешеләргә ышанычны югалтырга ярамый, дип уйлаган идем. Карасаң, синең дә шул сүзең бер, эшләгәнең барыбер башка икән. Ярый, кит. Кит әйдә... Алып кач башыңны!.. *(Чыгып китә.)*

Шамил. Әкълимә! Тукта!.. *(Чыгып китә.)*

Пауза. Ришат белән Ләйсән керә.

Ләйсән. Монда берәү дә юк. Шулмы соң бакчалары?

Ришат. Әйттем бит, минем бер мәртәбә килгәнем бар монда. *(Тәрәзәдән карый.)* Әһе!.. Булды... Шамил монда.

Ләйсән. Монда?.. Мә, Исмәгыйл абыйның язуын үзең генә бир. Мин китәм.

Ришат. Беренчедән, Шамил үзе түгел, пиджагы гына эленеп тора. Икенчедән, Исмәгыйл абый нәрсә диде: Шамилне тапмыйча, күземә күренмәгез, диде ме? Өченчедән, үзең дә: Шамилне күреп сөйләшәсем, аңлашасым килә, дидең.

Л э й с ә н. Дисәм... Ул әллә ни уйлар, ялына дияр... Артымнан тагылып йөри, дияр.
Р и ш а т. Анысы дөрес тә.
Л э й с ә н. Син дә шулай уйлыйсың?..
Р и ш а т. Уйламый да шулай икәнен беләм. Шушы яшеннән мәхәббәт белән мавыгу ул инде...
Л э й с ә н. Әллә телеңдә мәхәббәттән башка сүз дә юкмы?..
Р и ш а т. Шуны бел, уналты яшьтә мәхәббәт теле була.
Л э й с ә н. Җиңгәң әйтәме?..
Р и ш а т. Кем әйтсә дә...
Л э й с ә н. Әйт җиңгәңә. Иң саф, иң матур мәхәббәт бары тик яшь йөрәкләрдә генә була диген... Ромеоның Джульеттасына ничә яшь?..
Р и ш а т. Джульеттага?..
Л э й с ә н. Ундүрт... Зөһрә үз Таһирын ничә яшьтән яраткан?..
Р и ш а т. О, ул Таһир белән Зөһрә бит.
Л э й с ә н. 12—13 яшьтәнме. Галиябану Хәлилен унөчтәнме?.. Фердинандның Луизасына нибары уналты яшьме?..
Р и ш а т. Аңладым... *(Пауза.)* Лэйсән, Лэйсәнчик, минем кайчак Таһир, я Фердинанд буласым килә дә...
Л э й с ә н. Кагылма!.. Сиңа тагын...
Р и ш а т. Нигә? Шамилдән кай җирем ким...
Л э й с ә н. Уф!.. Шашам.
Р и ш а т. Көнчелек шашындыра сине.
Л э й с ә н. Мин көнләшмим.
Р и ш а т. Көнләшмәсәң, Шамилне газетага язар идеңме?..
Л э й с ә н. Мәкаләне син дә укыдың, газетага чыгарыйк дидең. Үзең рәсемнәрен ясадың.
Р и ш а т. Дисәм, Солтания апа белән сиңа ышанып әйттем. Аннан, нигә син минем сүзгә карыйсың. Үз фикерең кая?.. Ә... мин бәлки сине Шамилдән көнләгәнем өчен...
Л э й с ә н. Шәп!.. Синең характерың ачылганнан-ачыла бара. Озак еллар буенча сыный алмый йөргән кешеләрне кайвакытта бер көн эчендә дә сынап була, дигән сүз дөрес икән шул.
Р и ш а т. Лэйсән, Лэйсәнчик... Мин, мин бит...
Л э й с ә н. Ал кулыңны...

И р е к керә.

И р е к. У-у, иске дуслар, бывший сабакташлар... Нинди җилләр китереп адаштырды...
Р и ш а т. Җил адаштырмады, үзебез адашып йөрибез. Кая Шамил?
И р е к. Шамил?.. Каян белим...
Л э й с ә н. Ялганлама, Ирек. Икенче көн инде ул сезнең бакчада качып ята.
И р е к. Телеграмма килдеме?..
Р и ш а т. Йөрисең кеше котыртып.
И р е к. Круглый дурак син, Ришат, татарча әйтсәк, түм-түгәрәк тиле. Әнә ул Шамилне котыртучы, аның башына житүче, сары чәч, зәңгәр күз, нечкә бил.
Р и ш а т. Телеңә салынма, Шамил кайда?..
И р е к. Шулай да әйтегез, кем сезне монда җибәрде?..
Р и ш а т. Әниең... Исмәгыйл абый белән элек Шамилләргә, аннан сезгә, өегезгә бардык.
И р е к. Исмәгыйл абый белән? Өйдә тагын кемнәр бар иде?
Л э й с ә н. Әйт, Шамил кая?..
И р е к. Яшь кенә кызларга, бигрәк тә класс старостасына, малайлар аулап йөрү килешми, урманда дим.

Л э й с э н. Эшәке малай син, Ирек.

И р е к. Син бик әйбәт кыз, бик чибәр, нәкъ су анасы. Шуны бел. Шамил ул сиңа тәтеми, чүп син аның өчен. Әкълимәсе бар аның. Менә, во кыз. Шамил аны үзе белән алып китә. Ә синең шикелле дегет чиләгенең кирәге юк аңа.

Л э й с э н *(бер сүз дә дәшми Ирек янына килә дә аны яңаклый)*. Монысы менә дегет өчен, монысы чиләге, монысы капкачы... *(Йөгереп чыгып китә.)*

И р е к. О!.. Менә сез нинди. Әй, син, егет кисәге, җансыз гәүдә, карачкы! Күрәләтә мине кызлардан кыйнатып торасың. *(Өстенә кизәнеп килә.)*

Р и ш а т. Әй, кем бар анда... *(Йөгереп чыгарга бара. Шамил белән Әкълимә керәләр.)*

Ш а м и л. Ришат?.. Ни эшлисең монда?..

Р и ш а т. Сине эзләп йөрим.

И р е к. Әйдә, табаныңны ялтырат, синең шикелле будущий бюрократларга урын юк монда.

Р и ш а т. Син ул будущий шпана. Көпә-көндез кызларга бәйләнәсең. Үрдәк борын. *(Шамилгә.)* Син дә шуның белән алтын эзләргә китәргә йөрисең. Ул әнә Лэйсәнне куып җибәрде.

Ш а м и л. Куып?.. Ни хакың бар синең?..

И р е к. Яратмыйм, егетләр артыннан сөйрәлеп йөргән кыз-кыркынны. Ультра современный.

Р и ш а т. Күрсәтим әле мин сиңа ультраңны... Ультрфиолет утлар чыксын әле күз алларыңнан... *(Ирекка кизәнә.)*

И р е к. Ну, ну... саграк, минем йодрык шундый салмак, бер төшсә...

Ш а м и л. Туктагыз, югыйсә мин... Лэйсән кая?..

Р и ш а т. Менә бу якка йөгерде.

Ә к ъ л и м ә. Бар, куып җит син аны, Шамил...

Ш а м и л дәшми, Л э й с э н киткән якка карап тора.

Ә к ъ л и м ә. Шамил дим, бар инде.

Ш а м и л икеләнеп тора да чыгарга бара.

Р и ш а т. Шамил, тукта... Мә!..

Ш а м и л. Нәрсә ул?..

Р и ш а т. Исмәгыйл абый бирде. *(Конверт бирә.)*

Ш а м и л. Исмәгыйл абый?.. *(Конвертны ача, укый.)* Әле кайда ул Исмәгыйл абый?

Р и ш а т. Мәктәптә сине көтә. Язгандыр ич.

Ш а м и л. Язган. *(Уйланып йөри.)* Язган.

Р и ш а т. Нәрсә язган?..

Ш а м и л. Сиңа нигә кирәк?..

Р и ш а т. Миңа ачуланма, Шамил. Синең белән мәктәп арасындагы бәйләнештә мин нейтраль позициядә. Исмәгыйл абый миңа хөрмәтле директор, Солтания апа яраткан укытучым, ә син якын дус.

Ш а м и л. Дус!.. Башта син дуслыкның нәрсә икәнен аңла, аннары дустым диярсең. *(Чыгарга бара.)*

И р е к. Тукта, Шамил... Менә билетың, акчаларың.

Ш а м и л. Бир. *(Уйланып тора да кире бирә.)* Мә, үзеңдә торсын. *(Чыга.)*

Ә к ъ л и м ә, Ш а м и л артыннан чыгаргамы, юкмы дип уйланып тора да, эскәмиягә барып утыра. Р и ш а т Ш а м и л артыннан чыга.

П ә р д ә

Исмәгыйль Сафаров кабинеты. Өстәл-урындыклар. Стенада Владимир Ильич Ленин, Антон Семенович Макаренко рәсемнәре.

Исмәгыйль *(уйланып йөри)*. Уннарча укытучылар белән бер лектә тугыз ел тәрбияләгән укучым хуш та дими торып мәктәптән кача Шәһәрдән үк. Кем бит әле — Шамил Рамазанов. *(Пауза.)* Ә сәбәбе? *(Газета ертыкларын карый.)* Шушында гынамы?.. Юк, әлбәтт Ә без — мәктәп нәрсә беләбез?..

Ришат керә.

Ришат. Мөмкинме, Исмәгыйль абый.
Исмәгыйль. Кер, кер, күптән көтәм. Я, ничек, таптыгызмы?..
Ришат. Таптык та...
Исмәгыйль. Һәм качты дамы?..
Ришат *(кулын селтәп)*. Качса, үзе аңламаган кешене аны.
Исмәгыйль *(сынап карый)*. Әйе, Шамил үз сүзлерәк малай, хол кы да кызурак.
Ришат. Кылана шунда. Төрле шантрапа белән бәйләнгән.
Исмәгыйль. Кемнәр ул шантрапа дигәнең?..
Ришат. Ни, теге, Ирек, Әкълимә... Гитарасын аскан да...
Исмәгыйль. Минем язуны бирдеңме?..
Ришат. Бирдем, Исмәгыйль абый. Язуны укыды да, бармыйм, мәк тәпкә әйләнеп карыйсым да юк, дип Ирекләр бакчасыннан чыгып у китте.
Исмәгыйль. Кая китте?..
Ришат. Белмим.
Исмәгыйль. Нигә артыннан бармадың?..
Ришат. Бала түгел лә ул.
Исмәгыйль. Әйт әле, Ришат, Шамил белән ничә ел берг укыйсың?
Ришат. Ну, бишенчедән инде.
Исмәгыйль. Болай үзегез якын дуслар да идегез бугай?..
Ришат. Бик үк якын булмаганбыз икән. Әнә бит сөйләшми дә...
Исмәгыйль. Бәлки, үзеңнең юньләп сөйләшәсең килмәгәндер?..
Ришат. Мин?.. Мин нәрсә...
Исмәгыйль. Синме? Стена газетасындагы мәкалә өчен Ләйсән белән бер үк дәрәҗәдәге җаваплы икәнеңне беләсеңме син?..
Ришат. Әйе.
Исмәгыйль. Бигрәк тә карикатурасы өчен җаваплы икәнеңне дә беләсеңдер... *(Кыза бара.)* Шамилнең футбол ярышына бармавының төп сәбәбен белдегезме?.. Ачыкладыгызмы?..
Ришат. Ачыкладыгызмы дип, мин... без...
Исмәгыйль. Сез?.. Биш ел бер партада утырып укыган иптәшең бәлагә очрый... Нишләргә белми өзгәләнә. Ике көн мәктәпкә килми. Каядыр качып китәргә җыена. Хурлыгыннан, классташларының шундый таш күңелле булуларыннан качадыр ул, бәлки. Ә син... сез... Сезгә ул берни тормый. Бармы Шамил, юкмы Шамил, барыбер. Шулмы иптәшлек. Шулмы дуслык. Оят...

Ришат башын иеп әкрен генә чыгарга бара.

Тукта әле, Ришат. *(Өстәлдә яткан альбомны күрсәтә.)* Менә мин фотоальбом карап утырдым... Син яхшы гына фотога төшерәсең, үзең дә әйбәт кенә рәсемнәр ясыйсың... Тик үз рәсемнәреңдә ничектер һаман кара яклар гына ясалган... Безнең мәктәптә бик күп яхшы эшләр эшләнә, классташларың һаман начарлыклар гына эшләп йөрмиләр бит.

Шул яхшы якларны да ясасаң шәбрәк булыр иде... Менә кара, бу да карикатура, монысы да... Менә Сәлимәне биш минутка дәрескә соңга калганы өчен нинди итеп ясап куйгансың...

Ришат чыга.

Менә бу номер. Дус кайгысы, башкалар кайгысы нуль ага. Ике тиен бер акча. *(Телефон шалтырый.)* Тыңлыйм. Исәнмесез, Шәмси Галимович... Рәхмәт, яхшы. *(Солтания керә.)* Әйе. Нинди тема?.. Балалар тәрбиясе һәм алдынгы үрнәк тәҗрибәләре?.. Шәмси Галимович, сез мине, зинһар, дөрес аңлагыз... миңа ул докладны ясавы бик авыр. Безнең мәктәпне хәзер инде үрнәк дип әйтеп булмый. Үрнәк мәктәпләр әнә безнең күршеләр. Содокладны, бәлки, директор Сергей Яковлевичка тапшырырсыз. Юк, аның өчен түгел... Мин сезнең янга бүген барырга да җыйналган идем, барам... шунда хәл итәрбез... Хушыгыз!.. *(Трубканы куя.)* РОНО мөдире шалтырата. Алдынгы тәҗрибә турында содоклад, ди. Элек отличного укыган малайлар хәзер икеле ала, мәктәптән кача, шәһәрдән үк. Ә мин анда барып алдынгы тәҗрибә турында лаф орырга тиеш. Юк, гомерем буена ялган сөйләмәгәнне хәзер генә сөйли алмам... Сездә ни хәлләр, Солтания...

С о л т а н и я. Юк, килмәде.

И с мә г ы й л. Хәзер генә Разия ханым шалтыратты. Икенче тәүлек больницадан чыга алмыйм, ди. Операция ясаган бер авыруның хәле бик начар икән. Шамил өчен борчыла. Сез аларга бармадыгыз инде?..

С о л т а н и я. Класс җитәкчелегеннән азат итегез мине, Исмәгыйл абый.

И с м ә г ы й л. Куркасыз!.. Уйлашырбыз, педсоветта сөйләшербез дә...

С о л т а н и я. Укыту өчен дә, класс җитәкчесе эшен алып бару өчен дә бөтен көчемне куям, тик...

И с м ә г ы й л. Сөйләгез, сөйләгез...

С о л т а н и я. Һәрвакыт, һәр җирдә балаларның опекуны булу, аларның ата-аналары янына барып йөрү, үзеңне кимсетүләрен ишетү, юк. Булдыра алмыйм...

И с м ә г ы й л. Әйе, сез үз фәнегезне яхшы беләсез, ә менә чыннан да балаларга тәрбия бирү, аларның эчке дөньялары, киләчәк язмышлары белән кызыксыну — юк ул сездә... Минем аңлавымча, сез, сез... *(Пауза.)* Профессиягезне сайлаганда ук ялгышкансыз диясем килә.

С о л т а н и я. Мәктәптә укыганда мин беркайчан да укытучы булырмын дип уйламый идем. Инженер-конструктор буласым килә иде минем. Ә үзем КАИга имтихан бирә алмадым. Пединститутка кердем. Берәр ел укырмын да күчәрмен, дигән идем. Күчмәдем дә...

Телефон шылтырый.

И с м ә г ы й л. Тыңлыйм. О, Шамил дус, сәлам!..

С о л т а н и я *(урыныннан сикереп тора).* Шамил?..

И с м ә г ы й л *(аңа утырырга ишарә ясый).* Синең адашыңмы?.. Хәзергә кайда икәне билгесез. Ярдәм?.. Рәхмәт, хәзергә кирәкми. Әйе, ишетәм. Шалтыратырмын. Хуш, дустым. *(Трубканы куя.)* Бу минем иске дус, кырык ничәдер ел элек мине пионерга алып кергән иде, Шамил Сидаев. Мәктәбебезнең дусты. Адашы турында сораша. Шундый тынгысыз кеше инде. Бөтен нәрсә кызыксындыра аны, һәрвакыт, һәркемгә ярдәм итәргә әзер. Хәзер инде пенсиядә, ак чәчле бабай. Ә йөрәгендә һаман ялкын дөрли... *(Солтания янына килеп утыра.)* Менә шулай, Солтания акыллым. Укытучы, педагог булу, әлбәттә, авыр эш. Кайчакта ата-аналардан, һич урынсызга, хәтер калырлык авыр сүзләр ишетергә туры килә. Балалар үзләре дә бик әче телле була беләләр. Йөрәгең өзелә, миең кайный. Түзәсең, чөнки син — тәрбияче.

Ишек шакыйлар.

Керегез!..

Пөхтә итеп киенгән Х ә м з ә керә.

Х ә м з ә. Ялгышмасам, сез мәктәп директоры Исмәгыйл Кәбирови буласыз? Исәнмесез?..

И с м ә г ы й л *(кул биреп исәнләшә)*. Исәнмесез.

Х ә м з ә. Без Хәмзә Баязитович булабыз, Байкиев.

И с м ә г ы й л. Таныш фамилия.

С о л т а н и я. Мин чыгыйм, Исмәгыйл абый, кирәк булсам, физика кабинетында.

И с м ә г ы й л. Яхшы.

С о л т а н и я китә.

Х ә м з ә. Күптән килергә җыендым сезгә, Исмәгыйл туган. Әллә көч җитми, әллә вакыт...

И с м ә г ы й л. Тыңлыйм сезне...

Х ә м з ә. Пенсиядә булсак та, без, старая гвардия, тыңгысыз җан дигәндәй... Әйләнә-тирәдәге гаделсезлекләр, тәртипсезлекләр борчый.

И с м ә г ы й л. Әйе, үзе гадел кеше гаделсезлекләрне күтәрә алмый.

Х ә м з ә. Сезнең мәктәптә Шамил Рамазанов дигән малай укый.

И с м ә г ы й л. Әйе, әйе...

Х ә м з ә. Миңа аның хакында сөйләве дә бик авыр инде дә...

И с м ә г ы й л. Тыңлыйм.

Х ә м з ә. Яхшы гына укый иде ул бичара малай.

И с м ә г ы й л. Ни өчен бичара?..

Х ә м з ә. Бичара булмый... сез аның хәзерге сәгатьтә кайда икәнен беләсезме?..

И с м ә г ы й л. Хәзерге сәгатьтә?..

Х ә м з ә. Качкан ул малай, шәһәрдән үк качкан. Өеннән, анасыннан, әбисеннән качкан.

И с м ә г ы й л. Качкан?.. Сөйләгез, сөйләгез...

Х ә м з ә. Сөйләве дә авыр, әйтми дә булмый... Шамилнең әнисе Разия ханым, ни инде, үзегез беләсез, шәһәребезнең күренекле докторы, хирургы...

И с м ә г ы й л. Беләм, Разия ханым бик хөрмәтле кеше.

Х ә м з ә. Кайвакытта миңа шундый хөрмәтле кешеләр дә юлдан язып куйгалыйлар дим... Хода белсен, әллә дан ярамый шунда...

И с м ә г ы й л. Нәрсә, нәрсә?..

Х ә м з ә. Соңгы вакытларда Разия ханым бик кәлтрифүтләнеп китте әле. Артык узынып, дигәнем.

И с м ә г ы й л. Эшем күп ди, байтак кына җәмәгать эшләре дә алып бара булса кирәк... Хәзер җәй, врачлар отпускага китәләр, өч врач урынына берәү генә калып эшли...

Х ә м з ә. Яшь кеше, бер ни дә булмас анысы, эшләр... Мәсьәлә анда түгел. Бер мыеклыга күзе төшкән аның.

И с м ә г ы й л. Сез нәрсәдер бутыйсыз, Байкиев иптәш.

Х ә м з ә. Бутар өчен түгел, ярдәм итәр өчен, бер гаиләне җимерелүдән коткарып калу өчен килдем.

И с м ә г ы й л. Сөйләп бетерегез.

Х ә м з ә. Шул. Разия ханымның ире озак срокулы командировкада, ә ул монда әге дә җеге. Шамил бичара беспризорник булып йөри. Җитмәсә барын да күрә, белә...

И с м ә г ы й л. Нәрсә күрә, нәрсә белә?..

Х ә м з ә. Нәрсә икәне ачык инде. Башта абайламаган, ахрысы. Хәзер миңа аңлаган да... Әмма ләкин, бичаракай, теге явызны куып чыгарыр урынга үзе өйдән чыгып киткән.

Разия. Исмәгыйл ага! *(Хәмзәне күрә, чигенә.)* Сез?..

Хәмзә. Саумы, Разия ханым? Ярый, Исмәгыйл туган, китим, йомышым шул гына иде. Үзегез карарсыз, ачыкларсыз...

Разия. Нәрсәне ачыкларга?.. Ничек итеп әнине үлем хәленә китерүегезнеме?.. Әллә Шамилнең ни өчен өйдән чыгып китү сәбәпләрен ачыкларгамы?..

Хәмзә. Анысын инде ачык әйтә алмыйм, Разия ханым, бигайбә.

Разия. Әйтерсез, әйтергә туры килер.

Хәмзә. Әллә тагын үз гаебегезне миңа аудармакчысызмы?

Разия. Нинди тар күңелле, тар карашлы кеше сез, Хәмзә бабай.

Исмәгыйл. Тынычланыгыз, Разия ханым. Утырыгыз. Сез бик аргансыз да, борчылгансыз да.

Разия. Беләм, Хәмзә бабай сезгә әллә ниләр сөйләгәндер... Гәрәйнең дә, минем дә яшьлек дустыбыз, бергә укыган, күп вакыт бер телем икмәкне бүлеп ашаган кеше, ике ай элек монда эшкә килде. Шул кеше эштән соң мине машинасына утыртып берничә мәртәбә өйгә китереп куйды, шуңа кайберәүләрнең, бигрәк тә менә Хәмзә бабайның, сөреме коелган. Янәсе, мин чит ирләр белән тегендә, монда йөрим.

Исмәгыйл. Йөрсә ни булган?..

Хәмзә. Разия ханым ир хатыны, бала анасы... Кешеләр әллә ни уйлар, Гәрәй ишетсә дә...

Исмәгыйл. Сез, абзый кеше, теге дөньядан кайткан Фәтхулла хәзрәт түгелсездер бит?..

Хәмзә. Сез инде, Исмәгыйл туган, мине әллә нинди Фәтхулла хәзрәтләргә, иске дөньяның кара күләгәләренә тиңләмәгез. Мин совет аппаратында кырык ел хезмәт иттем. Заслуженный пенсионер.

Разия. Безнең йортта кырык квартира, шуларда ничәмә ничә пенсионер тора, нигә аларның берсе дә болай урынсызга кешеләрнең тынычлыгын бозып йөрми.

Хәмзә. Бигайбә, мин сезнең эшәкелек эшләп йөргәнегезне күргәнем юк. Тирә-күршеләр, әнә Шәймәрдәннәр сөйли.

Разия. Ялган... Шәймәрдәннең көне буенча тәрәзәдән карап, кемгә кем кергәнне тикшерергә вакыты юк!.. Оят!.. Ул елдан артык якын күршеләр булып яшибез, Шамилне сезгә карата илтифатлы булырга, сезне хөрмәт итәргә өйрәттек, ә сез... Нигә шулай нахакка пычратасыз мине?..

Хәмзә *(куркып)*. Мин... мин бары тик сезгә яхшылык теләп, Разия ханым. Чит ирләр килеп йөргәнне ирегез ишетсә, дим...

Разия. Алайса әби өйдә юкта сезнең янга килеп керүче апай турында ни дисез инде.

Хәмзә. Апай!.. Нинди апай ул тагын!..

Разия. Әнә гастрономда эшләүче — Гайшә апай, әби чыгып китүгә, сезнең янга килә дә керә, диләр бит.

Хәмзә. Әстәгъфирулла, оят түгелме сезгә... врач башыгыз белән шундый сүз... Бохтан бу!.. Ул бичара хатын, ара-тирә йомышка дип керә. Сез шуны...

Разия. Мин түгел, әнә күршеләр шулай ди. Әби чыгып киттеме, бабай янына яшь ханым керә, диләр.

Хәмзә. Һей, явыз, усал тел... Кеше өстенә яла сөйли... Тикшермичитмичә торып.

Разия. Сез үзегез дә бит тикшереп тормыйсыз...

Хәмзә. Мин бит, ни бит...

Разия. Шулай шул, Хәмзә бабай, үзегезгә кагылгач, ошамый...

Хәмзә. Әй, Разия күрше, күрәләтә торып әллә ниләр сөйлисең. Җитмәсә директор алдында... Болай булгач... *(Кулын селтәп ишекк*

*килә.)* Алла сакласын, карчыгым белән сугыштырырсыз, картайган көнемдә... *(Чыгып китә.)*

Исмәгыйль. Без сезне, Разия ханым, өченче көн көтәбез... Нигә өегездәге хәлләрне ачык итеп сөйләп бирмәскә!..

Разия. Ничектер шулай килеп чыкты инде. Шамилнең моңа кадәр тәртип бозып йөргәне булмагач, болай булуы башыма да килмәде. Шул картның гайбәтенә ышанган бит ул...

Исмәгыйль. Бәлки үзегез дә гаепледер?

Разия. Кызык кына, миңа эштә ирләр белән бергә эшләргә, командировкаларга бергә китәргә ярый, ә өемә иптәш булып, дус булып ир кешегә килергә ярамый. Бала-чагага бар адымыңны, һәр эшләгән эшеңне аңлатып тору...

Исмәгыйль. Сезнең дә, шулай ук безнең дә Шамилгә бала-чага итеп карарга хакыбыз юк. *(Пауза.)* Шамилгә уналты яшь. Яшьлекнең канат җәйгән чагы. Җиткән егет ул хәзер, бу яшьтәгеләр бары да үзләре теләгәнчә яшәү өчен хокук даулый, мөстәкыйльлек.

Разия. Җитмәсә, кызулыгым белән, үзенә сугып та алдым.

Исмәгыйль. Суктыгыз!..

Разия. Гомеремдә беренче мәртәбә.

Исмәгыйль. Сез, бала тәрбияләү нечкәлекләрен онытып җибәргәнсез, хөрмәтле Разия ханым...

Ләйсән керә.

Ләйсән. Исмәгыйль абый... Шамил... Шамил вокзалга төшеп китте.

Разия.<br>Исмәгыйль. } Вокзалга!..

Ләйсән. Әйе.

Исмәгыйль. Әле ул монда килеп чыгар дип ышанып көтә идем. Болай булгач... *(Уйланып тора да кызуланып чыгып китә...)*

Пәрдә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Вокзал алды. Перронга чыга торган зур гына капка артында үскән агачлар аша вагоннар күренеп тора. Эскәмияләр. Перрон ягыннан ашыгып Шамил чыга.

Шамил. Өченче вагон дигән иде. Юк анда. Әллә килеп җитмәдеме?.. *(Карана. Кызу-кызу Ирек керә.)*

Ирек. Киттек, ярты сәгать вакыт калды.

Шамил. Куй әле капчыгыңны, сөйләшик әле.

Ирек. Юлда, вагонда рәхәтләнеп ләчтит сатарбыз. *(Чыгарга бара.)*

Шамил. Китмибез?! Мин дә китмим, син дә беркая...

Ирек. Юк инде. Китмәсәң, син китмә. Миндә эшең булмасын.

Шамил. Авыру әниеңне кемгә калдырдың?

Ирек. Әни мине үзе җибәрде. Я әтиең бөтенләй биртеп ташлар, ди.

Шамил. Бир капчыгыңны. *(Тартышалар.)* Әниең синең биргелүеңнән курка. Үгез кадәр егетнең...

Ирек. Шулмы синең дуслыгың, вокзалга кадәр дә җитмәде.

Шамил. Безнең дуслык әниләргә кайгы-хәсрәт китерергә тиеш түгел.

Ирек. Акыл сатма. Ике көндә йөз төрле уй. Китәм, китмим... Синең үз башың, үз акылың юк... Әйдә, теләгәнеңчә эшлә, хурласыннар әнә.

Шамил. Китү үз өстеңә юк гаепне алу булыр иде, Ирек дус.

Ирек. Мин гаебем булганга китмим лә. Авыр миңа, беләсеңме, минем башка чарам юк.
Шамил. Бәлки, киткән җиреңдә җиңел дә булыр.
Ирек. Әллә үз үземне туйдыра алмаммы?..
Шамил. Туйдырырсың анысы... Бер үзең өчен генә яшәү бик җиңел ул... Ә әниең?.. Әтиең?.. Аларга син киткәч тагын да авыррак булачак.
Ирек. Мин, синең белән китәм дип, иптәшләрдән аерылдым. Ә син шул Әкълимә коткысына бирелгән.
Шамил. Әкълимә коткысына түгел. Үз акылым белән.
Ирек. Әкълимә җибәрмәде, дөресен сөйлә.
Шамил. Беләсеңме, шундый бер акыллы сүз бар: әгәр берәү бер генә кешене бәхетле итсә дә, дөньяда яшәве бик җиңел булыр иде, ди. Начармы әллә?.. Әкълимәгә мин ярдәм итсәм, ул да миңа ярдәм итте. Кайтам да хәзер әнидән дә гафу үтенәм... Ул да бәхетле була. Начармы, ә?
Ирек. Бар... *(Кулын селтәп.)* Кругом бәхетле булыгыз, ә мин... Сәу бул... *(Чыгып китә.)*
Шамил. Ирек, Ирек, тукта!.. *(Чыгарга бара.)*

Л ә й с ә н керә.

Ләйсән. Шамил!..
Шамил. Ләйсән!..
Ләйсән. Китәсең?..
Шамил. Китсәм?..
Ләйсән. Гафу ит мине, Шамил... Мин, мин... *(елый.)*
Шамил. Җылама...
Ләйсән. Шамил!.. *(Каты кычкырып.)* Беркая да җибәрмим. Җибәрмим!.. *(Муеныннан кочаклап ала.)*
Шамил. Ләйсән!.. *(Үзе дә Ләйсәнне кочаклый.)* Җибәр әле, Ләйсән...

Репродукторда: «Хөрмәтле пассажир иптәшләр! Мәскәү — Караганда поезды китәргә 5 минут вакыт калды...» дигән тавыш.
Ш а м и л йөгереп чыгып китә.

Ләйсән *(аның артыннан ташлана.)* Шамил...

Ә к ъ л и м ә керә.

Әкълимә. Ләйсән!.. Кая Ирек, Шамил?..
Ләйсән. Киттеләр.
Әкълимә. Ужас, ужас! Коточкыч! Бакчага Ирекнең әтисе килде. Ужас! Җирне тырнап елый. Ул китсә, йөрәгем шартлаячак, ди. Миңа ялына: зинһар, кызый, Ирекне алып кайт, ди. Бану апа да елый.
Ләйсән. Әйдәле. *(Чыгып китәләр.)*

Пауза. Аркасына капчык аскан И р е к керә. Ул уйланып басып тора. Ә к ъ л и м ә, Л ә й с ә н керәләр.

Әкълимә. Ирек! Матурым, җаным!..
Ирек. Мин — матур, вот ерунда!..
Әкълимә. Матур шул! *(Кочаклап үбә.)*
Ирек. Әкълимә, әдәплерәк кылан. Әнә анда минем Розочкам басып тора.

Ш а м и л керә. Паровоз тавышы. И р е к капчыгын Ш а м и л г а бирә.

Ирек. Мә әле, Шамил дус, капчыкны тотып тор әле. Берне көйрәтим дә... *(Тарта.)* Китмәдем, ә поезд әнә минем юклыкны сизмәде дә,

китте дә барды. Бар ни дә Ирек, юк ни аңа... Тик менә әни... Әни өчен дә, эти өчен дә кирәк кеше мин.

Әкълимә. Бик кирәк, Ирек матурым, бик кирәк.

Ирек. Ярар, бик матурлама. Әйдәгез, киттек, безнең кайтуны отмечать итәбез.

Ришат керә. Ул Шамилгә нәрсәдер әйтмәкче. Шамил аңа карап тора да җилкәсенә кулын сала — барысының да йөзләрендә шатлык...

Әкълимә (*җырлый*).

Ромашкалар, серле ромашкалар...

Исмәгыйл белән Разия керәләр.

Исмәгыйл. Әнә үзләре дә.

Разия. Улым!.. (*Шамилне кочаклый.*)

Шамил. Әни... Тынычлан, әни...

Исмәгыйл. Кая поездыгыз, ничәдә китә?..

Шамил. Поезд китте, Исмәгыйл абый.

Исмәгыйл. Ә без озатып калырга дип ашыктык.

Шамил. Без китмәскә булдык, Исмәгыйл абый.

Исмәгыйл. Кешеләр күңелсез хәлләргә очраган саен туган җирләреннән, ата-аналарыннан качып китә башласалар, китәргә урын да калмас иде.

Ирек. Анысы урыннар күп күбен...

Исмәгыйл. Күп анысы, күп, безнең ил бик киң... Тик шунысы — үзеңнән, вөҗданыңнан качарга урын юк.

Шамил. Без...

Исмәгыйл. Ал капчыгыңны, Шамил, син дә, Ирек. Юл капчыкларыгызны истәлек өчен җыеп куегыз. Киләчәктә әле ерак юлларга чыгасыгыз бар. Олы бәхет эзләп. Үзегезнең дә, туган илебезнең дә матур киләчәге өчен... Шул вакыт кирәк булыр алар сезгә.

Ләйсән. Ой, яңгыр, кояшлы яңгыр!

Исмәгыйл. Бәрәкәт яңгыры.

Ләйсән. Күрегез, салават күпере, яшел, сары, кызыл төсләр...

Разия. Бәхет күпере ди безнең әни аны.

Салават күпере тагын да ачыграк күренә. Ерактан шатлыклы моң ишетелә. Әкрен генә пәрдә төшә.

## Саҗидә Сөләйманова

# Фал китабы

ПОЭМА

Тормыш! Бармы шундый фал [1] китабы —
Туар көннең серен белергә?
Киләчәкне кеше
хәерлегә
Юрап яши гомер-гомергә.

Кайгыларын кеше җиргә сала,
Сөенечен сибә күкләргә.
Туфрак кара, күкләр якты-зәңгәр,
Ак бәхетне кайдан көтәргә?

Зәңгәр шәлен иңнәренә салып
Һаваларда йөзгән хыяллар
Кәнтәр-кәнтәр кара җиргә төшсә
Челпәрәмә килеп уала.

Җидегән йолдыз! Җиде юлның берсе
Кайсы якта? Күкләр болытлы...
Була торгандыр ул һәр кешенең
Тормышында шундый минуты.

— Күктән көткән сиңа җирдән килер,
Барыр юлың якты күренә,—
Шулай диде нәнәм китап ачып,
Ул төшенгән яшәү серенә.

Ни югалтса кеше җиргә карый.
Күктә — кошлар... Җирдә — кешеләр,—
Эзләгәнне табышып, шушы җирдә
Бергә яшәү белән көчлеләр.

Ә көчлеләр үз иңенә ала
Берәр кайгы төшсә бу башка...

Укытучым — яңа председатель,
Мин мәктәптә — аңа алмашка.

---

[1] Фал (гарәпчәдән) — якты киләчәк.

Уйлыйсыздыр: Һай тиз җидегән йолдыз
Җиде юлның берсен балкытты?!

...Сугыштан соң кара көйгән кырлар,
Ә син шунда нәни бал корты.

Сулган, сынган күңел гөлләренең
Нәфисләрен тап син, алларын.
Ачы кышта үзләренә өләш
Саф гәрәбә кебек балларын.

Кулда китап: Туган ил тарихы.
Көрәш юлы... Юллар текәләр.
Бит ачам да янә юлга чыгам,
Алда тагын юллар көтәләр.

Юлдагылар — көрәштәшләр көтә,
Егылганнар алмаш чакыра.
Елдан-елга, ярдан-ярга илтә
Бәхет юлы — һаман яктырак.

I

Ап-ак таштан күккә ашкан бина.
Күтәрелә бетон баскычлар.
Салмак кына атлый өлкән ирләр,
Оча-куна менә яшь кызлар.

Баскычлары биек, ашык — шык-шык,
Ачыла да ишек, ябыла.
Кайсылары атлый җайлап — лып-лып,
Һаман үргә төркем агыла.

Киң ишекләр ачык — чык-чык, чек-чек,
Үргә, үргә, үргә — баскычлар.
Ишек тора йотып — тып-тып... Тып-тын.
Монда узар безнең яз, кышлар.

Таш диварның якты залын күрдек,
Төшеп меник хәзер түбәнгә:
Җырда җырланмаган кызлар исеме
Уелып калган бетон идәндә.

Кызлар бригадиры — Кәримова,
Катя Ивановна, Гөлйөзем...
Исемнәрен кушып, кызлар салган
Бу бинаның бетон нигезен.

Киң ишекләр ачык — шык-шык, чек-чек
Үргә, үргә, үргә — адымнар.
Ишек тора йотып — тып-тып... тып-тын.
Бер кыз калды капка янында.

Чуен ишек алда — өнсез, җансыз
Кыя кебек тора караеп.
Мөнирәкәй, синме? Кәримова?
Бу бит синең данлы сараең.

Истә эле аны салган җәен,—
Качкан иде сезнең йокылар,
Өлгертергә диеп фән сараен
Башланганчы кичке укулар.

Мактап сезнең кызлар бригадасын
Шаулап торган иде гәзитләр.
Синең рәсем миңа шуннан таныш.
Кыш үткән дә, тагын яз үткән.

Йортны үзең салган. Кылүләрең —
Бай кардәшкә гүя кунакка.
Күпләр, күпләр шулай, синең сыман,
Кичегә эле кичке сабакка...

Кыялмыйсың... Баскычлары биек,
Ишекләре авыр дисеңме?
Үзең салган баскыч басмалары
Күтәрмәсләрмени соң сине?

Күзләреңнән күрәм, китәр өчен
Килмәгәнсең безнең урамга.
Йөргән юлың кайдан ураган соң,
Язмышыңа ниләр уралган?

2

Унҗиде яшь иде Мөниргә,
Тиз өйрәнде бетон эшенә.
(Без бер елда эшкә башлаганбыз.
Ниләр сыймый ун ел эченә!)

«Сугыш бетте» дигән шатлык үтте.
Кайда бакма — анда хәрабә.
Өйләр иелеп төште — «өй хуҗасы
үлде» дигән өнсез хәбәрдән.

Авыру ана шуннан торалмады.
Ана урынына калды Мөнирә.
Бер утларга, бер суларга салсаң,
Шартлап сынар иде тимер дә...

Ә Мөнирә түзде. Төштәгедәй,
Зәңгәр күктә көмеш йолдызлар.
Күз кысмыйлар хәзер, сүз кушмыйлар.
Эшкә йөргән юлда — ком, тузан...

Коңгырт күзләр кырыс, сүзләр коры,
Йөзләр соры, кулда бетон, таш.
Салкын өйдә сеңелләре кәтә.
Иң беренче хәсрәт — утын, аш.

Котсыз өйгә кичтән җан индерү.
Иртән төзелеш... Чыдам кыз бала.
Төзелеш белән авыл юлын таптап
Ун ел узган — кызган-кызганма.

Ун ел азмы, әллә күпме дисән —
Үсеп чыкты якты яшь кала!
Мөниранең яшьлеге ул шулай
Карап тора ап-ак ташлардан.

Якты өйләр... Кайсы бәхетлесе
Гөл үстерер, бала тирбәтер!
Яшь урамга кызлар нигез салды,
Мөнирәбез монда бригадир.

Яңа клуб. Бие, жырла әйдә,
Тарт гармунын, оеп утырма!
Бу шатлыкка кызлар нигез салды
Үз моңнарын кушып бетонга.

Зәй буена төшә яшь урамнар.
Шаулап тора туйлар яз-көзен.
Кызгылт таннар... Тимер-бетон чаннар.
Сафка басты завод: «Газ-бензин».

Бүләк, грамоталар... Бетон чаннар —
Мәрмәр сандык, кызлар, бирнәгә.
Газ-ефәктән ап-ак күлмәк киеп,
Нейлон туннар салып иңнәргә,

Бер үтәсе әле пар атларда!..
Онтылыпмы шундый уйларда,
Мөнирәбез кичен килеп чыкты
Үзе мәктәп салган урамга.

Кем өчен соң мәгърур фән сарае,
Син дә керәлмәгәч, ташчы кыз?
Үз кулларың ижат иткән бина,
Үзегезнең нигез ташыгыз.

Кыялмыйсың... Баскычлары биек,
Ишекләре авыр күренә.
Ә мин сиңа китап ачып бирәм,
Төшендерер яшәү серенә:

Ата-бабаң инде нигезен салган
Бәхет алда, юллар ашыгыч.
Яшерелгән ачкыч урынын беләм,
Ә ишеген үзегез ачыгыз!

...Жан сызлатып сызылып киткән бер юл
Алып килде мәктәп янына.
Баш күтәрми таш күтәргән икән,
Таштан дисез мәллә жаны да?

Мөниранең менә шушы елы
Торыр әле бәлки ун елга.
Индә йөргән бөтен авыр йөкне
Селтәп ташлар сыман бу елда.

Сенелләре быел тәмамлады
Берсе унны, берсе сигезне.
Таш астыннан чишмә ургып чыкты
Көткән төсле бары бу көзне.

Жем-жем итеп җидегән йолдыз янды
Мөниранең шушы күзендә.
Юк, сөю дә түгел — сөенеч килде
Зәңгәр күзле ташчы төсендә.

Рәшит. Яшь. Өйрәнчек. Әллә ничек
Көч ташыган сыман һәр таштан.
Төшләр татлы, таннар якты була
Балкып торган зәңгәр караштан.

Ташлар — ташка. Күңел күккә аша.
Көн дә эшкә йөргән урамда
Адашырга хәтта мөмкин икән.
Төз урамны йөз кат урарга!..

Изге тынлык. Җилләр иссә генә
Юкә яфраклары коела.
Урау-урау урамнарның очы
Чыга икән елга буена.

«Ал яулыгым кояш баюы да,
Зәңгәр шәлем көмеш каюлы.
Җидегән йолдыз җирнең әйләнәсен
Бер әйләнсә, сузәр ай юлы...»

Җырлар, җырлар!.. Әллә күңелен сөйли,
Әллә күңелендәге хыялын.
Су буенда бәбкә үлән дисән,
Су буйлары — камыш кыягы.

...Әллә каян килеп чыкты Рәшит
Чәнечкеле яшел яшьлектән.
Мөниранең чыршы тирәсендә
Әйлән-бәйлән уйнар яше үткән.

Әрем кугән кыр юлларын үтеп,
Басты егет кызның каршына.
Әзер юлдан йөрмәс ярсу яшьлек! —
Синең кулдан килә барсы да.

Алтын тәңкә тамган көзге юллар,
Әкияттәге сыман ай юлы...
— Нигә сиңа егерме яшь түгел?!.

Әкият бетте. Тылсым көче үтте,—
Мөнирабез кинәт айнады.
— Мөнирә, сез шәп кыз. Тик хыялсыз,
Канатлары сынган кош сыман.
Ә мин көч җыям да, аннан — Вузга.
Бу якларда бары кыш чыгам.

Вузга... Әйе, егерме яшь узган...
Сезнең өчен бу хәл сәерме?
Язлар узган. Җил-янгырга түзгән
Күзнең күз булуы хәерле.

Еллар салган юлны бик тарсынып
Ярсып чаба язын колыннар.

Җәй, кыш үтә. Үзенең йөген салып,
Дөнья барыбер үзенекен итә,
Бер төшерә үзенең юлына.

Я, хуш, егет! Кызны үз ишләре
Көтәләрдер анда зарыгып.
Тәрәзәне күпме сыласаң да,
Җилләр таба керер ярыгын.

Яшьлегеңә ияртеп, азга гына
Алып керсәң әкият иленә,
Каеннарның һәрбер ботагына
Ыргак сыман сорау эленгән:

— Нигә сиңа егерме яшь түгел?!
— Нигә сиңа түгел егерме?
Җәза өчен каен ботагына
Элгәннәрме әллә күңелне?!.

Күзләреңне, колагыңны каплап,
Әкиятләрен ташлап, кач, йөгер! —
Кайтавазлар булып яңгырый урман:
— Нигә сиңа егерме яшь түгел!?
— Нигә сиңа түгел егерме?
Һичбер кемгә бирмәс иде Мөнирә
Чиреген дә үткән гомеренең.
Ул кадерле яше, яшене белән!
Аяз булалырмы дәвамы?
Син шул күтәрешеп киләлмәден
Авырлыгын безнең заманның.

Я, хуш егет! Рәхмәт! Хәтерләттең
Яшьлекнең дә әле яшәвен.
Селтәп ташлады да Мөнирәбез
Күзләренә килгән яшьләрен,

Тулай торак ишеген ачып керде...
Эленми дә калган келәсе.
Бригадирның күз карашы кырыс:
Техникумга, кызлар, керәсез!

Без кемнәрдән ким соң, Катерина?
Үрнәк булыйк әле яшьләргә!
Канат кирәк, канат! Эшебезнең
Бөеклеген күреп яшәргә.

* * *

Ташлар — ташка. Уйлар эшкә аша.
Куллар оста. Кыска — кичләре.
Күз кабагы — бәбкә кош канаты,
Тибрәнәләр китап битләре.

Укытучы! Менә синең алда
Төрле күзләр, төре язмышлар.
Күпме җиңү, күпме уңышлар да,
Язмышларда азмы ялгышлар.

Китапларын ташлап, корал алган,
Яшьли утка кергән — кем өчен?
Һәркем өчен! Таянып ил көченә,
Уттан исән чыккан җиңүче.

Бетончы да ташчы, бораулаучы
Тормыш йөген байтак күтәргән.
Алар иңенә төшкән авыр йөкләр
Синең йөрәк аша үтәләр.

3

Бригадада яши ике полюс:
Кырыс Катя, чибәр Гөлйөзем.
Берсе кешеләргә сөзеп карый,
Икенчесе куймый күзгесен.

Катя... Буташтырып язны-кышны,
Яшьне, ташны салып бер рәткә,
Тормыш дигән кырыс мәктәп аны
Көн итәргә үзе өйрәткән.

Рәшәткәләр арасыннан гына
Караган ул берчак дөньяга.
Уналты яшь. Романтика, юллар...
Дусларыннан Катя уңмаган.

Юл-тасманың чуалмаган очын
Сугыш өзеп киткән еракта...
Мөнирәбез бүген Катя белән
Куна калды тулай торакта.

Катяның бит кабат уянуы
Шушы Мөнирәдән башланган.
Прораб кушкан: «Яңа бригаданы,
Комсомолка, төзе яшьләрдән».

Бригадада яшьләр. Комсомолдан
Тик Катяның яше чыкса да,
Эштә аннан каты эшләүче юк —
Ул көн саен чыныга, остара.

Укытучы! Менә синең алда
Төрле кузләр, төрле язмышлар.
Синнән җавап көтә күп сораулар,
Төзәтүне көтә ялгышлар.

Кыраулардан йолып, олауларда
Тартып килгән йөкләр бер икән.
Норт-нигезгә салган ташлар белән
Язмышлар да безнен береккән.

Таркаламы нигез, нык торамы —
Синең намусыңда, тарихчы.
Җил-давыллар купса, таралмаслык
Яңа сафлар юлга алып чык.

4

Ташның гомере озын. Үткәннәрнең
Чын шаһите булып таш калган.
Кеше гомере кыска. Шуңа да ул
Үз белгәнен салган ташларга.

...Күп җирләрнең ашын, ташын алган,
Бу дөньяда хәзер ят сыман —
Күккә ашкан мәрмәр колонналар,
Чиксез уйга талган таш сыннар.

Үрә баскан патша һәйкәлләре,
Хатирәгә — патша сарае.
Кем салган дип түгел, кем алган дип,
Таш карашлар калган сагаеп.

Патшаларны ташка әйләндереп,
Күпме башлар чыкты ут аша.
Таштан-ташка —
тарих
еллар аша
Безнең юлга килеп тоташа.

Сөрән сала: «Кешеләр, уяу булыйк!» —
Канлы имза төрмә ташында.
Бу дөньяга яшәү нуры сибә
«Җиңү» сүзе рейхстаг башында.

Көрәш, җиңү!.. Җиңүчеләр кулы
Сузды юллар, ярды каналлар.
Көл-күмердән калкып, төп нигездән
Күтәрелде яңа калалар.

Безнең дуслык ташта берегеп калсын.
Ташлар сөйли белә. Таш чыдам.
Үз эшенең бөеклеген күреп,
Таң аттыра безнең ташчылар.

Ташлар-ташка. Уйлар эшкә аша,
Якты өйләр күккә үрелә.
Кешеләргә очар канат кирәк
Җирнең матурлыгын күрергә.

Кыяларга басып, төштә, өндә
Талпынырга кызлар өйрәнә.
Кыялары — ап-ак биек йортлар,
Төзелеш түмгәкләре — түбәндә.

Бер билгесез, ике билгесезләр,—
Укы, өйрән, эзлә, бел үзең!
Ә бер төнне җанлы сорау булып
Килеп керде төнлә Гөлйөзем.

Яшь баласын күкрәгенә кыскан.
«Куна килдем, Катя, кума» — ди.
Күзге төндә килгән кунагына
Чын күңелдән Катя куанды.

Бригадада алар ике полюс,—
Берсе шайтан, берсе фәрештә,
«Анаң итәгеннән ник төштең?» — дип
Әрләп торды Катя һәр эштә.

Гөлйөзем... И, бигрәк нурсыз йөзең,
Кара төндә нишләп бер үзең?
Сорашмады кызлар. Аңладылар.
Эндәшмәде берни Гөлйөзем.

Гөлйөземнең кызын алды Катя,
Үпте, сөйде... Тегесе уянды.
Башка берни кирәкмәгән кебек
Кызлар бала белән юанды.

Елмаю да көлү. Сөенечкә
Килгәнмени төнлә Гөлйөзем.
Бала елмайганга куанса да,
Уйлый ана, уйлый төрлесен.

Гөлйөзем... Ул бик тә көләч иде.
Кызыктырды ирек, сәфәрләр.
Институтлар, җем-җем утлар белән
Чакырып торды ерак шәһәрләр.

Көмеш медаль. Зирәк, өлгер,— керер,—
Ачык иде уку йортлары.
Яңа девиз: эшләп уку!
Яңа
Төзелешнең кичке утлары.

Чокыр казу, цех себерү... Эшнең
Зыян итми белү төрлесен.
Сиздермәде яшьтәш кызларына,
Шаян хатлар язды Гөлйөзем.

Аңа, имеш, сварщик егет гашыйк,—
Кулы эшли, күзе ут чәчә.
Язмышыңнан узмыш юктыр ахры,
Гармунчы да үзе җитмәсә.

Кыз ирекне бик тә ярата иде,—
Исеме Ирек иде егетнең.
Ирек кызның күңелен әсир итте,
Кыз Ирекне үзенә ир итте.

Кыз ирекне бик ярата иде,
Куелды соң чикләр кай ара?
Берең күбрәк ирек алыйм дисә,
Икенчеңнең ирке тарая.

Янып сөю ахры — әрнеп көю,
Үзең теләп алдың, их, йөрәк!
Сөю үзе, ахры, иркең җую,
Ә сөюсез ирек ник кирәк?

Әллә нишләп шулай чибәр кызлар
Я бәхетле, я бик бәхетсез.

Күпләр баш игәндә — королева,
Хаким булыйм дисә — тәхетсез.

Я, кем — язгы җилдәй таратала
Кеше күңелендәге болытны!
Була торгандыр ул һәр кешенең
Тормышында шундый минуты.

Бригадага алып, Гөлйөземгә
Багышлады Катя бер күзен.
«Үз иркенә хуҗа булыйм дисәң,
Кулың һөнәр белсен, Гөлйөзем.

Таулар ташы — җиргә йөзек кашы,
Бизик әйдә, кызлар, җир йөзен!»
Юк, сорау да түгел, сынау булып
Килеп керде төнлә Гөлйөзем.

Таулар ташы — җиргә йөзек кашы.
Я, бригадир, җирне бизәвең —
Нindидер бер «феодал» кыз баланы
Төнлә йөртсен дипме күзләрен?

...Ак куллары белән уратып та,
Таң чыклары белән чылатып,
Күпме тезде кызлар тау ташларын!
Ә Катяның менә ялгыз башы,
Бер бүлмәгә җитми чираты.

...Хокук, бурыч, хаклык — кайда чиге?
Кайчан һөҗүмгә күч, кайда түз? —
Киңәш кора кызлар. Тормыш дигән
Сынау белән алар йөзгә-йөз.

Укытучы! Кызлар синнән көтә,
Сүзең бармы өзеп әйтерлек?
Ирекне бит үзебез яулап алдык,
Байракларда безнең — гаделлек.

Утлар кичеп, байрак алдан барган,—
Көрәш — җиңү яки һәлакәт.
Тарих битләрендә уелып калган
Кайнар йөрәк, тирән җәрәхәт.

Янар йөрәкләрнең чаткылары
Йолдыз булып күккә атылган.
Ә кешеләр гел яктыга барган
Канлы, таңлы байрак артыннан.

Шул байракка шәүлә төшерсенме
Бу дөньяның ыбыр-чыбыры?
Я, кем өзә — канда, җанда калган,
Кайчакта чын, ә күп чакта ялган,
Үз-үзебезгә салган чылбырны!

Ә чылбырны коючы да чүкеч,
Ватучы да — соңгы орышта.
Чылбыр очы, елан койрыгыдай,
Чикләр аръягына шуышкан...

5

Ташлар — ташка. Өйләр күккә аша.
Төзик әле, бизик җир йөзен!
Осталары кемнәр дип сорасаң —
Мөнирә дә Катя, Гөлйөзем.

Ташлар — ташка. Ташкын сулар таша,
Алып китәр инде язларны.
Ә Рәшитне менә чакырып алды
Вузлы, имтиханлы Казаны.

Йортлар биек. Мөнирәбез боек,
Әллә сагына, әллә үкенә.
Кара керфекләрең сирпелдереп,
Бер карачы, кара бу көнгә!

Бер тыңлачы шушы якты язда
Сөенешеп кошлар сайравын!
Зәңгәр бөркәнчеген күтәргән дә,
Хәйран калган Урсал таулары.

Буш далада таштан үсеп чыккан
Әкият иле шушы буламы?
Як-ягына яшел каю чиккән
Ефәк тасма кебек урамы.

Кем уйлаган, көн дә йөргән юлда,
Эшкә йөргән юлда парлашып,
Әкиятләргә китеп була икән,
Була икән хәтта адашып.

Ташлар — ташка. Күз күремен ачкан,
Үзең салган гранит кыядан —
Бик якын да сыман болытларга
Уралып очкан якты хыялга.

Бик якын да сыман, һай, ерак та...
Ун ел гомер — яхшы, яманмы,
Таш күтәргән шул ук куллар белән
Һаман алга эткән заманны.

Өйгәнең таш, күргәнең зур кыя,—
Күтәрелгән аңа башкалар.
Ташка басып, яңа дөнья ачтың,
Ә башкалар күптән ачканнар.

Ачканнар да, сиңа дәшкәннәр дә.
Кулга кулын берсе сузмаган.
Сузгандыр да... Зәңгәр күзләреңдә
Бәхет йолдызлары йөзмәгән.

Ә сүзләре кайнар чишмә булып
Эретәлмәгән ташын күңелнең.

Я, кем кыялардан — хыялларга
Таш яуса да гел янәшә бара?! —
Иң яктысы алда гомернең.

* * *

Күрдегезме җирдә ак калалар —
Буш далада әкият дөньясы.
Йөрдегезме якты урамнарда? —
Минем яшьлекнең анда мең язы.

Кышлары да шунда, көзләре дә,
Күреп була гади күз белән.
Кешеләрнең җан көзгесе булып,
Таштан ташка — йортлар тезелгән.

Осталары кемнәр? Танышлар бар,—
Гади генә кызлар, ташчылар.
Кайгысы да кирәк-кирәкмәстән
Басып үткән алар башыннан.

Җиңелгән дә, җиңгән чак та булган,
Буран күмә, кеше юл саба.
Йолдыз булып күпләр атылмый да,
Йолдызларга карап юл таба.

Яңа сафлар юлга алып чыксаң,
Җаннарында очкын уйнатып.
Укытучы! Якты киләчәккә
Барып җитәр эшең шул вакыт.

Кайберәүләр бәхет юлын сыза
Йолдыз итеп үзенең гомерен.
Икенчеләр аңа нур өстиләр
Кояш итеп олы күңелен.

Өченчеләр карлыгачлар булып
Алдан оча. Юллар ашыгыч.
Яшерелгән ачкыч урынын беләм,
Ә ишеген үзегез ачыгыз.

Күз күремен томан томаласа,
Я, кем кабына, күңелен нур итеп?!
Була торгандыр ул һәр кешенең
Тормышында шундый минуты.

Минут — чаткы! Барыр юлда балкый.
Шуңа, ахры, җирдә кешеләр
Килер көнне, туар иртәләрне
Гел яктыга юрап яшиләр.

Мирхәт Хөснимәрдәнов

# БӘХЕТ ҮЗ КУЛЫБЫЗДА

## Җырчы кыз



«Тынычлык» урамындагы уныпчы йортның кече капкасы төбендә ике генә кешелек итеп ясалган тәбәнәк эскәмия тора. Бүген анда ялгыз бер ир кеше утыра. Бу тирәләрдә еш очрый ул. Көндез килсә, кич җиткәнен көтеп, башын түбән иеп утыра, үткән-сүткәнгә күтәрелеп карамый. Бүген исә күзгә караңгы төн аның уйчан йөзен үткен күзләрдән яшерә, әйтерсең лә ул тыныч кына кемнедер көтә. Кечкенә капка нишләптер озак ачылмый, үзе бәйләгән оренбург шәлен бөркәнеп капкадан чыгасы хатынның башлап нинди сүз әйтәсен дә белә ул: «Тагын килдеңме?»

Тагын килдеңме? Бу сүзләр бәгыренә үткен пычак белән кисеп үтә. Кайвакыт утыра-утыра да, берәү дә чыкмагач, юка тактадан гына эшләнгән кечкенә капканың шалтыравыклы тимер келәсен иләп кенә басып, ишек алдына керә, өйалды баскычыннан күтәрелә. Ләкин өй ишеген ачып, бусагадан узарга, тавышын күтәреп сәлам бирергә аның йөрәге җитми. Өйдә олы кеше, карчык кеше бар, аның һәрвакыт битәрләп карый торган күзләре белән очрашасы килми аның.

Тукта, ниһаять, капка ачыла. Сәүбәкер аны күзе белән күреп түгел, күңеле белән үк танып ала. Аяк тавышыннан, бәйләп чыккан мамык шәленең исеннән үк тоя ул аны. Бу ике җан биредә ничә тапкыр инде икәүдән-икәү генә сөйләшеп утырдылар. Кайвакыт озаграк торылса, шыпырт кына капка ачыла, аннан бер кул сузыла, һәм хатын кереп китәргә мәҗбүр була. Бу аларның кызлары — Илсөяр. Тик капка төбенә килгән бу кешенең үз әтисе булуына кызның һич тә ышанасы килми. Шулай буламы инде әтиләр! Әнисе нигәдер бу турыда бер нәрсә дә сөйләми.

Бер киселгән икмәк кире ябышмаган кебек, ир белән хатын да бер-берсен кабат якын итә алмадылар. Сәүбәкер ничә тапкыр инде гафу үтенде. Ничә тапкыр инде аны шушы бусагадан, шушы кечкенә капкадан, «сау бул» дигән бер-ике йомшак сүзне дә күпсенеп, салкын гына озатып калдылар. Иртән ана кеше, эндәшми-тынмый гына, баскан эзләре дә калмасын дигәндәй, ишек алдын, капка төпләрен себереп чыга, өйалды идәннәрен юып куя.

...Зәмия белән Сәүбәкер дүрт кенә ел бергә торып калдылар.



Араларына иренең әнисе — кайнана таракан булып төште. Малае аның сүзеннән чыга алмады. Әмма Зәмия ташлап киткән ире артыннан елап баруны түбәнсенү дип санады, хурланды. Кулымнан эш килгәндә, тәнем сәламәт булганда бер баламны ничек тә үстерермен әле, дип күңелен катырды да, җиң сызганып тормышын яңадан корырга, җимерелә башлаган семьясын үзе теләгәнчә һәм булдыра алганча рәтләргә тотынды. Иренең соңгы сүзе шул иде: миннән башка барыбер рәхәт күрмәссең, бәхетсез итәм мин сине...

Кешегә кое казыма, үзең төшәрсең, дип әйтәсе килгән иде Зәмиянең, тыелып кына калды.

Бәхетсезлек... Кемгә кайсы яктан килерен бәрә икән ул үзенең күренмәс усал тукмагы белән? Белсәң икән, сизенсәң икән! Язмышыңны яңа эздән салырга чара күрер идең. Шундый хәлдә калырмын, дип уена да китермәгән иде Зәмия.

...Ун елдан артык инде Зәмия тормышын ялгыз алып бара.

Кызы Илсөяр быел сигезенче классны тәмамлый.

Ничек үлчәргә соң ул бәхетне? Аерылышканда иренең йөрәккә кадап әйткән сүзләреннән калган күңел җәрәхәте инде төзәлгән, урыны гына калган. Иренең аерылганда әйткән сүзләре искә төшкәндә дә элекке кебек көйдереп алмый. Язмышы Зәмиягә һәр яңа сынау ташлаган саен, ул аны бөгелмичә күтәрә бирде, кер күңеле белән үткәрде. Татар хатыннарының кайгыдан бөгелми, шатлыктан кеше алдында артык кузгалмый торган, сыгылмый һәм сынмый торган үтә дә нык, үтә дә тормышчан, алтындай кыйммәтле сыйфатлары бар.

Зәмия дә әнә шундыйларның берсе.

Кирәк бит шундый чакта! Шулай бер көе генә яшәгәндә, «бәхетсез син» дигән сүзләрне ул тагын ишетте, тагын бик нык хәтерен калдырдылар аның. Кем авызыннан ишетте бит әле! Иң якын күреп, хәсрәт-кайгысын уртаклашып йөргән кешедән — Нәсимә Садриевна авызыннан.

Ишетте һәм бик озак рәнҗеп йөрде ул аңа. Очраклы гына әйтеп ташланган сүз шулай кеше күңелен китеп төшерер, дип кем уйлаган! Биздергән дә тел, сөйдергән дә тел, диләр шул. Йөрәген көйдерде бу сүзләр Зәмиянең. Ничек булды соң әле бу?

Иртән заводка эшкә барган чакны ярата Зәмия. Кешеләр бер-береннән хәл-әхвәл сорашып ипле генә сөйләшә-сөйләшә заводка таба атлыйлар. Барып җитәрәк сафлар куера, төге яктан да, бу яктан да килгән тасмалар бергә кушылып, көчле агым хасыйл итәләр. Алар арасында үзеңә нык терәк тоясың. Каршыга очраган кешеләр сиңа юл сабалар, бер читтәнрәк атлыйлар, эшкә килүчеләргә комачауламаска тырышалар.

Әнә шул эшче сыйныфның агым булып иртән эшкә баруын, ташкын булып кич эштән кайтуын ярата Зәмия. Алар белән бергә калышмый атлап баруына горурлана ул. Аларның атлавында көч тә, ышаныч та, матурлык та аңкып тора.

Заводка һәр көн шундый күтәренке хисләр белән йөри торган Зәмия ул көнне борчулы иде. Автобуска утырып тормады, Савинка поселогыннан болын аша бара торган сукмак буйлап атлады. Таныш болын юлы аны һәр көн шәһәрнең зур урамына — Короленкога алып чыга. Заводка инде ерак түгел. Уңда завод клубы. Ул аның югары каттагы тәрәзәләренә күтәрелеп карый. Берсендә дә ут күренми. Иртән кем булсын инде, дип үзеннән-үзе көлеп тә ала Зәмия. Кичен ул тәрәзәләрнең һәр кайсында ут балкый. Кичә дә, өченчекөн дә ул эштән кайтышлый бу тәрәзәләргә карамый үтте. Күтәрелеп караса, йөрәге түзмәс кебек иде аның. Керергәме, юкмы дип икеләнде шулай да Зәмия. Юк, бүтән аяк та атламам, дип бер тапкыр әйттеңме, үз сүзеңдә тор инде син. Ә кермичә ничек түзәсең? Ничә ел инде үзешчәннәрнең актив җырчысы булып ул заводта дан казанды. Бәлки, бүген сменадан соң кереп карап кына чыгар-

гадыр. Синнән башка иптәшләрең нишлиләр икән? Ул адымнарын әкренәйтте. Аяклар клубка таба атладылар. Кая, кая син, Зәмия? Клубта иртән кем дә юк. Сине станогың көтә, смена көтә. Соңга калырга ярамый.

Завод ишегеннән пропуск күрсәтеп үткәнен дә, цехка килеп эшкә башлавын да, төшке аш җиткәнен дә сизмәде ул. Бөтенесе ничектер үзеннән-үзе механик рәвештә башкарылды. Смена да бетте. Юынып, киенеп өйгә кайтырга чыктылар. Ләкин Зәмия поселокка кайта торган иптәшләреннән тагын аерылып калды. Клубны узып китә алмады ул. Кирәргәме? Иркен залларына үтеп, күкрәк тутырып бер җырлыйсы килә. Җыр аның өчен үзе бер тормыш иде. Кайгырса да җырлый, шатланса да җырлый. Эштә дә җыр суза, ял иткәндә бигрәк тә инде, аны һәр вакыт үзешчәннәр арасында күрәсең. Үткән ел «Красный ключ» ял йортында концертта катнашып мактау кәгазе алып кайтты.

Бүген үзен тыеп тора алмады Зәмия, ашыгып клубның икенче катына күтәрелде. Җыелу залы буш иде әле. Иң түргә, караңгырак почмактагы бер урындыкка киемнәрен дә салмыйча барып утырды. Беркем дә комачауламады аңа. Ул үзе дә кешеләрнең игътибарын җәлеп итмәскә тырыша иде. Хәер, клубка керүчеләр сирәк әле. Бирегә соңыннанрак, кино башланыр алдыннан кеше күп керә. Гел үзең генә, ялгыз гына каласың килгән минутлар була бит. Уйга чумасың, кемнедер, нәрсәнедер искә төшерәсең, кылган эшләреңә бәя бирәсең. Үз-үзең белән сөйләшеп шулай тик утырасың. Бигрәк тә менә-менә сиңа кырык яшь тула дип торганда... Ярты гомер инде үтелгәндер. Яхшы үтелгәнме ул, яманмы — уйлап карарга кирәк.

...Әтнә якларындагы Чембулат авылында алар дүрт бала үстеләр. Зәмия — төпчеге. Өчесе исән. Абыйсы һәм апасы — укытучылар. Ә ул бала вакытыннан ук артистка булам, җырчы булам, дип хыялланды. Мәктәптә укыган чакларыннан сәхнәдә җырлады. Аның җыры, тавышының моңлылыгы авыл кешеләрен таңга калдыра иде. Булдырыр, булдырыр, Мөхәммәтнекеләр алар, булдыклылар, дия торган иде кешеләр.

Ләкин тормыш син уйлаганча гына бармый икән шул. Сугыш елларының җәфасы, аннан соң күргән кыенлыклар Зәмияне, тугызынчы класста укуын ташлатып, урман хуҗалыгына нарат сагызы җыярга эшкә алып килде. Производствога бер әләккәч, шуннан Казанга килеп, Вахитов исемендәге заводка эшкә керде. Дүрт ел буе шунда эшчеләр арасында яшәде. Тырышлыгы бар иде Зәмиянең, кайнап торган яшьлек дәрте бар иде. Кич димәде, иртә димәде, ардым дип зарланмады, эштән соң һаман клубка йөрде, яңадан-яңа җырлар өйрәнде. Тамашачылар аның җырлавын алкышларга күмә иделәр. Сәүбәкер белән дә шушында таныштылар, шушында семья корып җибәрделәр һәм шушында ук аерылыштылар да... Шул көнне үк Зәмия заводтан җибәрүләрен сорап гариза язды. Йөрәгенә җәрәхәт салган кеше белән бер сукмактан йөрисе, аның күзенә күренәсе килмәде аның. Заводта тотмадылар, җибәрделәр. Зәмия Ленин районындагы предприятиеләрнең берсенә өйрәнчек булып барып керде. «Җүнсезнең колы булганчы, җүнленең толы бул. Күңелең эш сөйсә, кулың һөнәр белсә, югалмассың, балам» — диде әнисе дә. Егерме еллык хезмәт стажының уннан артыгын үзенә чорнаган заводтагы гомер йомгагы әнә шулай башланды.

Бер елдан соң ул аерылган иренең кайдадыр эчкән килеш хулиганлык кылып биш елга төрмәгә утырганын ишетте. Шул вакыт Сәүбәкергә карата эремәслек булып каткан күңеленең бер игелекле почмагы ачылып китте. Кызганды, бик кызганды ул Сәүбәкерне. «Әллә соң ул миннән аерылу хәсрәтеннән эчкечегә сабыштымы икән»,— дип, үз-үзен бераз шелтәләп тә алгалады. Срогын тутырып кайткач, ярдәмчесез калган һәм каршысына тезләнгән ир кешене гафу итәр өчен, үзенә яңадан кабул итәр өчен ихтыяр көче тапкан хатынның нинди хисләр кичергәнен белсәң икән дә, сөйләп бирә алсаң икән.

Кичерде ул аны. Акылга утыргандыр, бүтән эчмәс, мыскыл итмәс, дип уйлады. Ике яктан да ана-карчыклар үтенүе буенча яңадан бергә тора башладылар. Ике көн әйбәт кенә торганнар иде, өченче көнне Сәүбәкер бөтенләй ташлап чыгып китте.

— Бәхетле бул, рәхәт яшә,— диде Зәмия киткән минутында,— миңа гына бүтән өйләнеп киләсе булма, тормышыма бүтән зыян китерергә ирек бирмәм.

...Заводта ярдәмче эшче булып бераз эшләгәннән соң аны цех начальнигы Николай Владимирович Быков чакырып алды.

— Миңлекәева, син тырыш күренәсең. Станокка күчәсең килмиме?

Ничек инде килмәсен, ди! Күптәнге хыялы инде. Тиздән Зәмияне маркеровкага күчерделәр. Шунда ике елга якын вакыт үткәне сизелми дә калды. Бригада системасы белән эшләделәр. Зәмия кайвакыт онытылып китеп шундый рекордлар биреп ташлый, аңа иптәшләре кисәтү ясый башлыйлар. «Син алай бик алга чапма инде, без җитешә алмыйбыз», ди торганнар иде. «Үзен күрсәтергә тели», дип кырын караучылар да булмады түгел. Дөрестән дә, аның үзен күрсәтәсе, нәрсәгә сәләтле булуын бүтәннәргә аңлатып бирәсе килә иде. «Сигезенче цехка күч,— диделәр аңа,— анда бригада белән түгел, ялгызың аерым заказлар үтисең».

Күчте, тагын өйрәнчек булып йөрде. Өлкән эшче Клавдия Васильевна Журавлева кулы астында җиде генә көн өйрәнде дә Зәмия үзлегеннән эшләргә тотынды.

— Станогыңны ярат, мастерыңны тыңла,— дия иде аңа Клавдия Васильевна,— сине яратырлар.

Хак булып чыкты. Рекордларны берсе артыннан берсен куя башлады Зәмия, цехтагылар шаккаттылар. Коллективтагы ике йөзләгән кеше арасында технологияне бер дә бозмыйча эшли торган эшче булганга, Зәмиянең рәсемен цехның мактау тактасына эләргә карар иттеләр. Үткән елның Октябрь бәйрәменә аның зур рәсемен завод аллеясына куйдылар. «1965 нче елдан Коммунистик хезмәт ударнигы!» Хезмәте барның хөрмәте бар. Ел саен диярлек Зәмия түләүсез путевка белән ял итеп кайта. Цехлар буйлап йөрсә дә, клубка барса да аның белән исәнләшеп үтәләр. Җыелышларда Зәмия эшләгән детальләр турында «бер вакытта да ОТКдан кире кайтканы юк» дип зурга күтәреп сөйлиләр. Үткән ел аны партия сафына кабул иттеләр.

— Деталеңә йөрәк җылысын кушып эшкәртсәң, бер кайчан да контроль кире бормас,— дип әйтүе белән мең тапкыр хаклыдыр Зәмия. Шулай бара аның заводтагы тормышы. Ә менә йөрәге тыныч түгел.

Нишләп соң әле ул үзен кая куярга белмичә борчылып йөри? Кичә цехком председателе бүлмәсенә килеп кергән иде, уңайсызланып калды. Клуб директоры Нәсимә Садриевна да шунда. Цех начальнигы да, мастер да кергән.

— Менә кирәк кеше үзе килеп җитте,— дип, елмаеп сүз башлады мастер София Григорьевна,— без борчылып тора идек.

— Нигә борчылырга?

— Милли ансамбль җитәкчесез калды бит,— дип сүзгә кушылды клуб директоры,— сезне чакырырга килдем.

Ләкин Зәмия аларның бу карарын хупламады:

— Мин бүтән клубка йөрмим. Сүз бирдем. Җырламаска, биемәскә... Хезмәтем — станокта минем...

— Сәбәбе?

Сәбәбен сөйләп биреп буламы инде аның. Бүлмәдәгеләрдән барыбер кеше — Нәсимә Садриевна гына белә аны. Ул да сөйләп бирә алмый. Үзе гаепле бит. Кешегә аңлатып булмый андый хәлне. Ә сәбәпнең җәтмәсе юлда, Әтнә юлында үрелә башлаган иде.

...Шефлык күрсәткән район авылларында ике айга якын үзешчәннәр концерты күрсәтеп йөргәннән соң, юл уңае туры килеп, Зәмия бригада җитәкчесеннән: «Туган авылыма да сугылып бер җырлап китим», дип рөхсәт сорады. Каршы килмәделәр. Автобуска төялеп кайттылар. Яңгырга эләктеләр. Автобус батып та алгалады.

— Бәхетең юк синең, Зәмия,— дип әйтеп куйды бригада җитәкчесе,— бәхетсезгә җил каршы. Ә монда коеп яңгыры да...

Концерт шәп узды. Зәмияне сәгатькә якын сәхнәдән чыгармый җырлаттылар. Соңыннан рәхмәтләр укып, күңелле итеп озатып калдылар. Кайту юлына чыгып бераз тынычлана төшкәч, килгәндә әйтелгән сүз Зәмиянең келт итеп исенә төште.

— Шулай да мин үземне бәхетсез дип санамыйм, дуслар.

Үз уйларына чумып, автобус тәрәзәсеннән карап барган бригада җитәкчесе бу сүздән сискәнеп китте. Һәм алдын-артын уйлап тормастан әйтте дә салды.

— Исең киткән шундый бәхеткә! Гомерең буе кара хезмәт, ялгыз тормыш. Син бүтән бәхеткә кызык.

Шундый тантаналы минутлардан соң мондый сүзләр ишетермен дип уйламаган да иде Зәмия. Димәк, син юньле булсаң, ир белән торыр идең. Бәхетсезлегең үзеңнән димәкче буламы икән инде бу. Бары тик шунда гына микәнни соң бәхет. Аның бит

яратып эшли торган эше, кешеләрне куандыра торган җыры бар. Ул үзе өчен түгел, кешеләр өчен җырлый. Кешеләр бәхетне төрлечә аңлыйлар, күрәсең.

Бәхәс зурга китә башлаган иде, бригаданың башка членнары кушылып артыкка җибәрмәделәр, уен-көлкегә бордылар. Казанга кайтып җиткәнче беркем бер сүз дә сөйләшмәде.

Шуннан соң Зәмия клубка йөрүен, үзешчәннәр белән концертларда катнашуын ташлады. Авыр иде аңа. Җырсыз тора алмый иде ул. Болай ялгыз гына түгел, аңа кеше алдында җырларга кирәк иде. Тыңлаучыларның сине хуплавын сизгәндә генә җырчы бәхетле була ала. Үз-үзен тыңлау өчен генә булса да, әнә граммзапись мастерскоена барып, ул үзенең күп җырларын пластинкага яздырып кайтты. Эче пошса, тота да радиолага куя... Кем тыңлый соң аны? Карт әнкәсенә үз кызының җыры, әлбәттә, туты кош сайравыннан да артык тоела торгандыр. Ничек соң халык алдына чыгарга?

...Ә кичә, бәхетенә каршы, клуб директоры аның каршысына үзе килгән. Гафу үтенүеме бу аның? Әллә аны мәҗбүр генә иткәннәрме? Зәмия ансамбльнең тоткасы иде, ансыз булмый, ялгышны төзәтә белергә кирәк, цехына үзең бар, дип әйттеләрме икән? Ничек булса да булган, ул үзе килгән иде.

Зәмия ул вакыт риза булмаган иде.

Бүген аны тагын чакырдылар. Үз-үзен җиңеп, акылына буйсынып килде. Чөнки әллә ничә ел бергә үзешчәннәр түгәрәгендә йөргән аерылмас дуслары бар аның. Юбилей көннәренә зур программа әзерлибез, дип корган олы планнары бар. Ничек аларны җиргә салып таптыйсың! Аннары нигә соң әле ул үзенең хисләренә алай ирек бирде? Гел йөгәнләп кенә тота иде бит ул аларны. Клуб аның туган йорты кебек. Биредә ул 1956 елда беренче тапкыр «Башмагым» музыкаль комедиясендә төп рольдә уйнады — Сәрвәр булып җырлады. Аның «Арча кичләре», «Мәхәббәт», «Кил, кил гүзәлем» дигән җырларны башкарганда алган алкышларына теләсә нинди артист көнләшерлек. Шул чакта сәхнәдә туган хисләрне син бернинди бәягә дә, бер кайда да таба алмыйсың. «Танырсыңмы, әтием» көен башкарганда бу җырчының үз кызы Илсөярне күз алдына китереп җырлавын залдагыларның берсе дә аңламый, әлбәттә.

Әйе, җыр, җыр инде ул, җырлыйсың да бетә. Ә менә кыз белән ата арасындагы ятсыну бетми. Кыз әтисен танымый. «Әткәем кем?» — дип баланың йөрәге сызланмый торгандыр дисеңмени!

Бер көнне Илсөяр мәктәптән бик борчылып кайтып керде. Әбисе дә, әнисе дә сагаеп калдылар. Шым гына үз бүлмәсенә кереп киткән Илсөярне борчымадылар. Бераз вакыт үткәч кенә Зәмия аның янына керде. Кызының күзләре яшьләнгән иде. Илсөяр әнисе алдына башын салып озак уйланып утты.

— Әнием,— диде ул, ниһаять, башын күтәреп,— бүген сочинение язарга тиеш идек. Әти-әниләребез турында. Ә мин яза алмадым. Кем минем әтием? Нигә ул качып йөри? Кайсыгыз гаепле сезнең? Бер килүендә миңа ул сәгать алып бирермен дигән иде, нигә онытты ул вәгъдәсен? Нигә алдады? Әти кеше алай алдарга тиешмени?

Күңеле тулган иде баланың.

Шушы кичне Зәмия аңа барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Барысын да, гүкмичә-чәчмичә... арттырмыйча, киметмичә... ничек булган, шулай... Ничек ташлап китүен дә, тормыга эләгүен дә, квартира таба алмый интегеп йөрүләрен дә, хатын-кыз өчен авыр булса да ссуда алып шушы йортны салуын, әтисенең ярдәм итмәвен, Илсөяр өчен аннан алимент акчасы да алырга баш тартуын, килгәч кызыма бирәм дип акча чыгарса, кирәкми, үзеңнең ике кызың бар, аларга калсын дип кире кагуларын,— барысын-барысын да сөйләде.

Аналы-кызлы кочаклашып елаштылар алар бу кичне.

Иртәгесен Илсөяр комсомол билеты тотып кайтты.

Билетта Илсөяр әтисенең исеме дигән җирен буш калдырткан иде. Сабый түгел инде, үзе хәл иткән, дип бер сүз дә эндәшмәде Зәмия.

...Клубның караңгы почмагындагы ялгыз урындыкка утырып әнә шуларның бөтенесен дә күздән кичерде Зәмия, һәм, ниндидер авыр йөктән арынган шикелле, җиңеләеп урыныннан кузгалды, тиз-тиз атлап, үзешчәннәр репетиция ясый торган бүлмәгә юнәлде. Анда Зәмияне күтәреп алгандай каршы алдылар. Әйтерсең, ун ел күрми

торганнар. Беренче булып клуб директоры Нәсимә Садриевна кул суды. Озак та үтмәде, клуб залларының берсендә аның «Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем» дип җырлаган матур тавышы яңгырады.

* * *

Шәһәрдән Савинка поселогына болынлык аша салынган тар сукмактан җиңел генә атлап бер хатын кайтып бара. Гадәтенчә, ул һаман җырлый. Уң яктан шәһәр кварталлары бишәр катлы йортлары белән поселокның агач өйләренә һөҗүм итеп киләләр. Тиздән биредә Совет районына олы урам үтәр. Шул олы урамдагы биек йортларның берсендә аның да үз тәрәзәсе булыр. Өмет белән яшәсен кеше. Елак кешеләрне яратмый Зәмия. Хезмәт белән табылган олы бәхет бетми дә ул, таралмый да. Сүнми дә сүрелми дә... Бәхетең үз кулыңда дигән төшенчәне ирекле илдә яңа яктыязмышка ирешкән кеше генә чын мәгънәсе белән аңлый ала. Әлегә әнә аның үз капкасы бар, номер сугылган үз йорты, абзар-курасы, ишек алдын бүлеп утырткан бәләкәй генә җимеш бакчасы, анда өч алмагачы бар. Быел берсенең зур ботагын кар басып сындырган иде, торгызып бәйләп куйгач, чәчәк атты. Аның үзенә дә шулай аякка басарга кешеләр ярдәм итте бит.

...«Тынычлык» урамында йортлар күп түгел. 15—20 бармы икән? Ә бәхетле кешеләре күбрәк. Үз бәхетеннән үзе качып йөрүчеләре дә бар. Унынчы йортның кечкенә капкасы төбенә ара-тирә кичләрен һаман да бер ир кеше туктап, нәрсәдер көтеп тора. Бәхетен эзләп йөрмиме икән ул биредә?..

# Беренче имтихан

Август азаклары иде. Җәйләүләргә, Ык буйларына күзгә моңсулык үзенең сары канатын җәя башлаган. Кырларда урак өсте кызуы кими төшкән, комбайннар тузан болыты эчендә соңгы кишәрлекләрне әйләнәләр. Урып-җыелган кырлар аша бормаланып яткан такыр юлдан безнең УАЗ тизлек белән ашыга. Төрле авылларны үтәбез. Һәр авыл башында зур такталарга язылган каршылау һәм хәерле юл теләп озату сүзләре чагылып кала. Без Минзәләдән шактый ерак бер авылга — Калмыякка барабыз. Райком секретаре Сабира ханым Хәкимова безне алдынгы хатын-кызлардан берсе, колхоз парткомы җитәкчесе белән таныштырырга вәгъдә итте.

«Без» дигәнем — киногруппа, Казан кинохроника студиясенең урып-җыю көннәрендә кыр батырларын төшерергә, дип махсус задание алып чыккан операторлары. Максатыбыз — әллә нинди сенсация эзләү түгел инде, шулай да, райком секретаре авыз тутырып мактап торгач, районда алдынгы колхозлардан да саналгач, без «Искра»га бармыйча булдыра алмадык. Күптән инде киножурналда хатын-кыз җитәкчеләрне, бигрәк тә колхоз җитәкчеләрен күрсәткәнебез юк иде.

Бер сәгатьтән без Калмыякта идек инде.

Колхоз идарәсеннән чыгып безнең янга килгән кызны, гәрчә ул райком секретаре белән үз итеп күрешсә дә, һич кенә дә шушы дүрт-биш авылны берләштергән зур колхозның партия комитеты секретаре Әнисә Сабирова булыр дип уйламаган идек.

Безне таныштырдылар.

Беренче сөйләшүдән үк ул кинога төшүдән баш тартты.

Үзе урынына башка колхозчыларны тәкъдим итте ул безгә. Без төшермәскә риза булдык, тик хуҗалыкны күрсәтүен үтендек. Бусы инде операторның хәйләсе иде.

Ике көн Калмыякта яшәвебез вакытында Әнисә турында менә нәрсәләр белдем мин.



...Техникумны тәмамлап кайткач, Әнисәне ни сәбәптәндер зоотехник итеп түгел, экономист итеп билгеләделәр. Бер дә күңеле тартмый иде аның кабинет эшенә. Ләкин бу турыда җитәкчеләр белән сүз кузгатырга ничектер җае чыкмый торды. Әнә шулай теләр-теләмәс кенә эшләп йөргән чакта Сарманнан, техникумда бергә укыган иптәшләреннән, хат килеп төште. «Безгә кил. Җиң сызганып тотынырлык эшләр күп», диганнәр алар. Мавыктыргыч чакыру Әнисәнең бөтен күңелен биләп алды. Буш вакыт табып, Сарманга барып ризалык та биреп кайтты. Партия райкомында эшләүче туган абыйсы Рәшит Солтанов аны моның өчен җиңелчә генә шелтәләп тә алды.

— Нигә шулай эшләдең?

— Намусым кушты.

— Үзебез үстергән кыз, дип горурланалар авылда.

Әнисә дәшмәде.

— Колхозчыларга ничек күренерсең?

— Бер тапкыр «юньсез» диярләр дә бетәр...

— Әллә анда синең ирең калдымы?

— Калса, ни әйтерсең?

— Ирең белән кайт. Сыйдырырлар.

Сарманга китүнең инде хәл ителгән булуын, бер атлаган адымыннан кызның кире кайтмаячагын аңлаган Рәшит абыйсы сүз көрәштерүнең, үгетләүнең мәгънәсез икәнлегенә тәмам төшенде. «Ярар, мин сине башка юл белән кармакка эләктерермен» дип, тиз генә район үзәгенә кайтып китте ул.

...Чыннан да нәрсә эшли соң әле ул Әнисә? Дөрес сукмакка бастымы, әллә ялгышамы? Нигә аның тузгыган күңелен аңламыйлар? Ул бит туган авылын — Калмыяны яратмаганнан ташлап китми. Ык буйларын, сабый чактан ук аунап үскән җимешле болыннарны, әрәмәлекләрне ничек итеп оныттырга, бүтән авылга алыштырырга мөмкин! Җиденче классны ул шушында әйбәт билгеләргә генә тәмамлады. Аңа укытучылары да, туганнары да зур өмет багладылар. Өметне шулай акларгамы? Кайда эшләсәң дә барыбер түгелме? Балалыктан чыгып үсмер чакның тормышка тәпләрәк карый башлаган бер вакытында күңел үзе дә сизмичә әллә кайларга омтыла, әллә нәрсәләр эшләргә дәрт итә.

...Җиде көн өенә кайтмаган иде ул чакта Әнисә. Ата-ананың төн йокылары качты.

— Үзеңне бетермә,— дип тынычландырырга тырышты Әхмәтгәрәй карчыгы Фатыйманы,— бала балага охшамый, өнә алты балаң, алтысы алты төрле. Югалмас, Әнисә югала торганнардан түгел. Бәлки абыйларына киткәндер.

Эзләмәделәр, шау-шу кубармадылар. Җиденче көнне Әнисә үзе кайтып керде. Гаепле булса да, елмаерга тырыша. Бер нәрсә дә булмагандай кыска гына аңлатып бирде: фермага эшләргә кердем. Сыерлар савам.

— Шушы кечкенә, нәзек бармакларың беләнме? — дип, ана еларга җитешеп кызгана башлаган иде, иренең кырыс карашын күреп туктап калды.

Әтисенең хуплавын сизеп торган Әнисә батырая төште һәм: «Эшлим булгач эшлим, өйрәнермен»,— дип сүзен бетерде. Билгеле, имчәк тарта-тарта куллары аруын, беләкләре сызлавын, савып бетердем, дип киткәч, Маһирә апасының яңадан килеп, шул ук сыердан гөжләтеп сөт агызуын, буе җитмәгәнлектән бәләкәй утыргыч алып килеп утыруын сөйләп тормады.

Шул көзне ул Минзәләгә барып авыл хуҗалыгы техникумында читтән торып уку өчен имтихан биреп кайтты. Үзе генә түгел, тугыз кеше иде алар авылдан. Әмма торабара бишкә калдылар, ә ахырга кадәр исә бары тик Әнисә генә чыдады. Уку — әнә

белән кое казу, диләр. Мәктәптә сине мәҗбүри укыталар, ә биредә үзеңә укырга кирәк. Бөтен ихтыяр көчеңне җыеп укырга... Вакыт дигән нәрсә бер дә туктап тормады, үтте дә китте. Ферма йортында эштән бушаган араларда иптәш кызлары Әнисә алып кайткан китапларны кычкырып укыйлар иде. Алар укый, ә Әнисә конспект төзеп утыра. Һәр минутның кадерен белергә, аны кирәкле эшкә файдаланырга өнә шул техникумда укыган елларда өйрәнде дә инде Әнисә. «Кызың кайда укый, кем булырга?» — дип сорасалар, Фатыйма апа горурланып: «Мал врачы булырга»,— дип җавап бирә иде. Ул вакытта әле ана белән ата кызларының маллар дәвалаучы гына түгел, кешеләр тәрбияләүче дә булачагын белмәгәннәрдер. Кая алар, Әнисә үзе дә язмышы аңа нинди авыр юл сайлаганын соңга таба гына абайлый башлады. Алты баланың берсе бораулау мастеры, нефтьче. Берсе Түбән Кама шәһәрендә төзүче-монтажчы. Кечесе урта мәктәп бетерә, берсе унны тәмамлап колхозда эшли. Әнисә алты ел сыер сауды, укыды, техникумны уңышлы тәмамлады. Терлекчелек эшенә тәмам гашыйк иде ул. Техникумда бергә укыган иптәшләре генә аның күңелен икеләндерделәр. Күңел гадәти булмаган сәяхәтләр, очрашулар, яңа урын, яңа кешеләр, ниһаять, киңрәк колач җәеп эшли торган мәйдан эзли иде.

Китәргә иде Әнисәнең бар теләге. Инде тәмам җыенган иде. Көтмәгәндә килеп чыккан бер хәл күңелен кирегә борды да куйды.

Колхозның зоотехнигы авырган иде. Әнисәгә аның урынына эшләп торырга куштылар. Күптән инде маллар арасына омтылган кыз моңа шунда ук риза булды. Маллар караучысыз калмасын, дип тырышып йөри торгач, ун көнләп вакыт үтте. Озакламый барырмын, дигән вәгъдәсен истә тоткан күрше район җитәкчеләре Әнисәне алырга дип машина да җибәргәннәр. Каян белгән, кем аркылы ишеткән диген, абыйсы Рәшит Солтанов белән райком секретаре Сабира Хәкимова да килеп җиткәннәр.

— Без сине партия учетыннан төшермибез,— диделәр Әнисәгә,— үз колхозыңда кирәк син.

Әнисә Сабирова мәсьәләсен җыелышка куйдылар. Җибәрмәделәр. Ә отчет-сайлау җыелышында аны колхоз коммунистлары бер тавыштан оешманың секретаре итеп сайладылар. Шул хәлләрдән соң коммунистларның ышанычына җиңелчә карап буламы соң! Партия дисциплинасы бар. Җаваплылык дигән зур бурыч бар коммунист өчен. Үз колхозың, үз кешеләрең. Алар сине үстергән. Эшеңне күрсәт. Көчең бар икән, төпкә җигел, камытның олысын ки. Җигелдеңме — тарт, диләр. Ә ничек тартырга соң? Кемнәр белән? Нәрсәдән башларга?

— Бусы инде мәсьәләнең икенче ягы,— диделәр райкомнан килгән вәкилләр,— партиядә шундый тәртип бар: белмисең икән — өйрәтәләр.

Төнлә дәүләт амбарларына озатылырга тиешле соңгы тонналарны төягән автомашиналарны, алдынгы шоферларны, ындыр эшчеләрен киножурналга төшереп алдык. Бу төнне колхозда ашлык сугу тәгәлләнде. Пландагы 14500 урынына 20 мең центнер озатылды. Колхоз председателе Ханигыйлем Хәсәенов та, партком секретаре Әнисә дә, барлык актив колхозчылар да биредә. Аларның йокысызлыктан кызарган күзләре прожектор яктысында тагын да кысыграк булып күренәләр. Тузан, машиналар гөрелтесе, төрле командалар, кисәтүләр... Машиналар, фара яктыларын уйната-уйната, урам буйлап олы юлга чыгалар.

Һәм кинәт бөтенесе дә тынып калды.

Иртәнгә кадәр ял. Авыл урамнары ындырдан таралучы колхозчыларның сөйләшкән, капка ачкан тавышлары белән бераз җанланып торды да тагын тынлыкка чумды. Без, киногруппа егетләре, идарә йорты белән янәшә салынган кунак өенә кайттык. Аның ишек алдына караган бер тәрәзәсеннән идарә йортындагы председатель бүлмәсенең якты тәрәзәсе күренеп тора. Тартып куелган пәрдә аша ике шәүлә күренә. Председатель белән секретарь... Аларга әле йокы юк. Кызык, нәрсә турында сөйләшәләр икән алар? Әнә председатель урыныннан торып идән буйлап әрле-бирле йөри, кызып-кызып нәрсәдер аңлата. Ә Әнисә утырган, ара-тирә сүз куша. Аның һәр сүзе председательне кабызып җибәргәндәй итә. Каты бәхәс бара, ахрысы.

...Бүлмәдә ут таңга кадәр сүнмәде.

Иртән түзмәдем.

— Төне буе нәрсә турында бәхәс алып бардыгыз, Ханигыйлем агэ? — дип сорадым.

— Әй, эш турысында инде,— диде председатель һәм машинасын кабызды,— кылчыклы балык ул... Шул вакыт янибызга Әнисә килеп туктады:

— Икмәк турында бәхәсләштек,— диде бусы да, туры җавап бирмичә.

Димәк, ярамый. Һәр хуҗалыкның үзләре генә белә торган, читләргә сөйләргә ярамаган эчке эшләре, үзләренә генә хас серләре була. Нигә артыгын төпченергә... Башкасын белмәсәм дә, председатель авызыннан әйтелгән «кылчыклы балык» дигән сүзнең асылын тора-бара төшендем мин. Әнисәнең үз авызыннан әйтелгән булган икән ул.

Куйбышев исемендәге колхозга председательләрне, партком секретарьларын, белгечләрне семинарга җыйганнар. Колхозның уңай якларын тәҗрибә төсендә күрсәтеп йөргәннәр. Райком секретаре Хөсәенов, Әнисә янына килеп: «Я, кызым, хәзер син үзеңә кунакка чакыр инде», дип тәкъдим иткән.

— Рәхим итсеннәр.

— Уха пешереп сыйларсыңмы?

— Безнең Ыкның балыгы кылчыклырак шул.

— Ишеттегезме? Димәк, килеп йөрмәгез дию инде моның.

Семинарга килүчеләр шаркылдап көлеп җибәргәннәр.

Каршылаганнар, әлбәттә. Күрсәткәннәр, сыйлаганнар да... Һәммәсе тәртипле узган. Андагы сөйләшүләр инде онытылып бетте дигәндә райком секретаре бер көнне «Искра» колхозына үзе килеп төшкән. Әнисәне җиңел машинасына утырткан да туптуры борчак чабучылар янына алып киткән. Барсалар, күзләре дүрт булган Әнисәнең. Чапкычларны борчактан алмый киткәннәр. Өстәмә җибәрелгән кешеләр вакытыннан элек өйләренә таралганнар.

— Менә мин сиңа кылчыклы балык булып кадалам инде,— дип райком секретаре Әнисәне мондый тәртипсезлек өчен бик каты шелтәләгән дә, машинасына утыртып, яңадан авылга алып кайтып киткән.

Авылга кайтып җиткәнче Әнисә дә, секретарь да дәшмәгән.

Ошый бу усал кыз райком секретарена. «Шундыйларны күбрәк тәрбияләргә кирәк»,— ди ул һәр вакыт.— Тик игътибардан читтә генә кала күрмәсен. Кыз бала — кош бала, канатланыр да куяр. Канатларын үз авыл туфрагына бәйләргә кирәк».

Әй әлекте дә соң бу көнне бригадирларга. Әйтсә әйтә белә инде Әнисә. Үзеңә үтәрлек итеп әйтә. Аның бу гадәтен хәзер бөтен колхозчылар белә. Тәртипсезлек, оешмаганлык күрсәтсәң, Әнисә күзеннән, аның туры сүзеннән котылырмын димә. Шешә белән дус булып эшкә аяк чалучыларга бигрәк тә каты бәрелә Әнисә. Дәүләт Шәрипов, Алексей Волков белән булган сөйләшүне коммунистлар әле дә хәтерлиләр. Кеше кешегә охшамый. Берсенә каты бәрелсәң, икенчесенә җылы сүз кирәк. Әнә менә тезелеш бригадиры Хәниф Харрасов белән бөтенләй башкача булды Әнисә. Хәнифне ул, урамдамы, әллә инде магазин төбендәме исерек килеш очратты. Бер сүз әйтмәде, карап кына узды. Айныгач аңа «Әнисә күрде» дип әйткәннәр. Шунысы җиткән иде. Өч көн буе ул Әнисәнең күзенә күренергә оялып йөрде, идарә йорты тирәсеннән читләтебрәк узды, дежурный-мазар килсә «менә чакырыргадыр» дип тиргә бата торган иде. Юк, чакырмады аны Әнисә. Борчылуы Хәнифне партком секретаре каршына үзе китерде.

— Чакырып, каты итеп сүксәң, мин тинтәккә җиңелрәк булыр иде,— дип сүз башлады ул.

— Ә нигә чакырырга? Менә үзең килдең.

— Ачулан, бик каты ачулан мине, Әнисә сеңелкәш...

— Минем ачуым бетәр ул... Шулай йөреп халык ачуына тап булма...

Бригадир өчен шулай сөйләшү җиткән иде. Кош караучы Миңнур Мөхәммәтсәлихова иса партия җәзасы кулланырга туры килде. Колхозның 50 килограммнан артык балы югалган. Ә коммунист Миңнур аны белгән һәм әйтмәгән. Бюрода карап җыелышка куйдылар һәм, бөтен игын үлчәп, партия сафында торырга яраклы түгел, дип карар чыгардылар. Бер тавыштан...

Партия оешмасының карарын райкомда расладылар.

...Кай вакыт Әнисә уйга кала: сыер сәвучы булып эшләде. Ике кулына бер хезмәт иде. Зоотехник булгач та бары тик үз тармагы өчен генә җавап бирә иде. Ә хәзер... сиксәнгә якын коммунистны берләштергән зур оешма. Бригадаларда үзләренең оешмалары, 60 ка якын комсомолны берләштергән яшьләр оешмасы, соңгы елларда колхозда профсоюз оешмасы да төзелде. Һәммәсенә җитәкчелек итәргә, хуҗалыкны алга җибәрү өчен һәр тармактан зур тырышлык таләп итәргә кирәк. Бер секретарьның гына көче җитәрлек түгел моңа. Аңа бюро членнары зур ярдәм итә. Алар үзләренә беркетелгән эшне җиренә җиткереп үтиләр. Өч урында марксизм-ленинизм нигезләрен өйрәнү буенча партия укулары алып барыла. «Намус», «Терлекче», «Яшь көч» исемле стена газеталары чыгарыла, «Прожектор», «Чаян» дигән сатирик тәрәзәләрдә тәртипсезлекләр, ялкаулар һәм эчкечеләр көйдергеч тәнкыйть уты астына алыналар. Колхозның иген уңышы елдан-ел күтәрелә бара.

«Сүз бирдеңме — үтә». Ә ул сүз бирде. Райком бюросында секретарь итеп расланганда, аннан: «Каушап калмассыңмы?» — дип сорагач: «Акларга тырышырмын»,— дип җавап кайтарган иде.

— Тырышырга гына түгел, эшләргә кирәк,— дип төзәтте аны бюро членнарыннан берсе.

Дересе дә шулай ич. Тырыштым — барып чыкмады, дип соңыннан акланырлык булмасын. Биргән сүзне үтәргә кирәк. Шулай булмаганда, синең коммунистлык бурычыңны аңлавың буш сүз генә булып кала.

* * *

Ык буйларында кара бөрлегән пешкән чак иде. Колхозда экономист булып эшләүче дусты Гөлсем Котдусова белән алар икәүләп бөрлегән ашарга төштеләр. Печәннәрә җыеп алынган иркен болын һавасы, борылып-борылып аккан Ык суы, бармак башыдай эре булып пешкән кара бөрлегәннәр кыз вакытның серле хыялларын тагын да тирәнәйтеп, киңәйтеп җибәрделәр. Әнисә бераз тын гына барды да бөтен тавышы белән «Туган авылым» көенә җырлап җибәрде.

— Шуннан башка бүтән җыр белмисеңме әллә? — дип куйды иптәш кызы.

— Эх, баяныңны алып килмәгәнсең, шәп концерт ясар идек без синең белән икәүләп.

— Сыерлар алдындамы?

Икесе дә тыела алмыйча көлеп җибәрделәр. Таллыклар арасыннан бер көтү сыерчыклар бу тавыштан дәррәү күтәрелделәр дә, дуга ясап баш очында бер әйләнгәннән соң, көньякка таба турылап еракка очып киттеләр.

— Бүген син нигә шундый әле?

— Имтихан җитә, дускаем.

— Нинди имтихан?

— Отчет-сайлау җыелышы була. Сентябрьдә. Доклад яза башлаганчы, бер җилкенеп аласым килде. Бер ел секретарь булып эшләдем. Ә нәрсә эшләдем, үзем дә белмим.

— Ә син ничек булган, шулай сөйлә.

— Әйтергә җиңел...

...Нәрсә турында сөйләр соң ул коммунистларга? Ничек итеп авылны ташлап китәргә йөрүе турындамы? Ничек итеп беренче бюро утырышын, партия җыелышын үткәрүе турындамы? Әллә җәйләүгә килеп иптәш кызларының гөжләтеп сөт сауганлагы кыяфәтләренә карап сокланулары? Әллә кешеләргә, коммунистларга, коллективка карата беренче тапкыр үзендә ничек ышаныч тууын сөйләрме? Бөтенесе дә хәтерендә аның.

Әле секретарь итеп сайлап куюларына берничә генә көн иде. Терлекчеләр арасында конкурс үткәрү вакыты килеп җиткән. Районнан комиссия көтәләр. «Искра»-лылар әзер түгел. Нишләргә? Киңәшкә коммунистларны җыйды ул. Хәлне бәйнә-бәйнә аңлатып бирде. Һәрберсенә шушы ике-өч көн эчендә нинди конкрет эш белән шөгыльләнергә икәнлеген күрсәтте.

Ярышта «Искра» колхозы фермалары конкурста уңай яктан телгә алынды. Әйе, аерым коммунистларның активлыгы турында, уңай тәҗрибә турында күбрәк сөйләргә кирәк докладта. Аларның кечкенә генә матур сыйфатларын күрә белергә, кимчелекләрен үзләре аңларлык итеп әйтеп бирә белергә кирәк. Теге вакытта колхоз председателе белән нигә таңга хәдәр бәхәс барган дисеңʼ? Аның, җитәкченең, ялгыш адым ясамавы өчен. Югыйсә, булмаганны булды диеп ялгыш отчет та бирүең мөмкин. Менә ни өчен әйтә алмаган икән Әнисә ул турыда чит кешеләргә.

Юк, Әнисә, син секретарь буларак, үзең турында сөйләмә, синең хакта башкалар сөйләсен. Китапханәдә укылмаган китаплар калмавы турында да, сеңелләреңнең сиңа китап ташый-ташый арып беттек инде, дип зарлануларын да, югары партия мәктәбенә укырга керү өчен беренче тапкыр зур комиссия алдында имтихан бирүең турында да башкалар сөйләсен. «Канәгатьләнерлек эшләде», дип бәя куйсыннар әчен, ай-һай, күпне башкарырга кирәк. «Юбилейга буш кул белән килмәбез»,— дип әйтә икән, колхоз парткомы секретаре Әнисә Сабированың моның өчен нигезе бар, димәк.

* * *

Эш беткәч ул безгә, группа членнарына, колхозның төрле тармакларын иркенләп күрсәтеп йөрде. Уннарча гектарга сузылган алма бакчаларына алып килде. Бу бакчаны алар мәктәптә укыган вакытта утыртканнар. Пионерлар килеп булышып, су сибешеп йөргәннәр. Димәк, монда Әнисәнең дә үз агачы бар.

Аннан соң без умарталыкка, аның әтисе янына бардык. Әхмәтгәрәй абзый безне көрәзле бал белән сыйлады, чәй янында Сталинград янында барган сугыш истәлекләре белән уртаклашты, хәлне белергә сирәк килә, дип кызыннан зарланды. Кинооператорлар тик йөрмәделәр, әлбәттә. Үз кирәкләрен эшли бирделәр. Кайда ничек төшергәннәрен Әнисә күп очракта сизми дә калды. Киткәндә, уңыш бәйрәменә кунакка чакырып калды ул безне.

Соңгы тапкыр без Әнисә белән Татарстан колхозчыларының Казанда булып үткән чираттагы конференциясендә очраштык. Ул делегат булып килгән иде.

Аны яңадан партком секретаре итеп сайлаганнар.

Хәзер инде ул Югары партия мәктәбенең икенче курсы өчен имтиханнар тапшыра. Тормышта беренче имтиханны уңышлы үткән азыл кызы боларын да әйбәт бирер, әлбәттә.



## ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫНА

**Гали Халит**

# КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

*Һ. Такташның соңгы чор иҗатында гуманизм һәм герой проблемасы*

1.

Революция кешесенең батырлыгын һәм әчке матурлыгын сурәтләү акрынлап 20 нче еллардагы татар совет әдәбиятының магистраль юнәлешенә әверелде. Беришe язучылар иҗтимагый-тарихи вакыйгалар ташкынында революция герое күрсәткән батырлыкка, ә икенчеләре ул геройның яңа әхлагы һәм интим-шәхси мөнәсәбәтләре формалашуга игътибар итсә дә,— аларның һәммәсенә әдәби герой концепциясен яңача аңларга омтылыш уртак иде. Алар нигезеннән үзгәргән авыр тарихи шартларда совет кешесендә үсә барган югары гражданлык һәм әхлак сыйфатларын күрергә теләделәр. Монда барыннан да әһәмиятлерәге — күчеш чорындагы яшь кеше проблемасы иде.

Яңалык өчен көрәш гражданнар сугышы кырларыннан идея, психология һәм көнкүреш сферасына күчте. Безнең җәмгыятьтә яңаның үрентеләре көннән-көн югарырак күтәрелә һәм үзләренең тамырларын ныграк җибәрә баралар, алар инде безнең кешеләрнең яңа иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләренә тагын да калкурак булып ачылырга мөмкинлек тудыралар иде.

20 нче елларда татар язучыларының игътибарын нык биләп алган бер зур мәсьәләгә — иҗтимагый-революцион бурыч белән шәхси теләкләрнең берлеге мәсьәләсенә дә әнә шул югарыда сөйләнгәннәр яктылыгында якын килергә кирәк. Әдәбиятка ул читтән килеп кермәде яки язучылар аны үзләре уйлап чыгармады, ә революция тәкъдим иткән, тормыш үзе күтәргән идея-эстетик проблема иде ул.

20 нче елларның азагына табан Такташ иҗатында да, аның дөньяга карашындагы гуманистик идеалларның үсеше һәм катлаулануы буларак, иҗтимагый һәм шәхси башлангычларның берлеге мәсьәләсе аеруча кискен төс алды. Социализм идеалы белән рухланып, совет халкы тагын да яңа җиңүләргә барган бер заманда шагыйрь иҗатында мондый хәлнең булуы бик табигый иде. Тормышка һәм кешегә мәхәббәте, ышанычы турында Такташ аеруча югары тон белән, басым ясап җырларга теләвен белдерде.

Ах, син, илем,
Ничек үләрсең соң,
Сагынып кешеләр синдә булганда,
Ничек үлим,
Берләр меңнәр өчен —
Меңнәр берләр өчен торганда![1] —

дип тәмамлаган иде ул «Болай... гади җыр гына» дигән шигырен (1928). Һәм бу строфаны, шул елларда шагыйрьне бик биләгән уй-тойгыларының шигъри сыйдырылышлы бер мисалы итеп, аның күп кенә әсәрләренә эпиграф рәвешендә китерергә мөмкин булыр иде.

Билгеле булганча, үзенең күп кенә замандашлары шикелле, Такташ әдәбиятка гомумгуманизм байрагы астында килеп, кеше мәхәббәте, аның иреге, бәхете һәм матурлыгы кебек мәңгелек идеалларга табынуын җырлады. Иске дөньяның ерткычлыгына, кешелексезлегенә каршы куелган бу гуманизм, әлбәттә, бик абстракт һәм чикле иде әле. Беренче вакытларда шагыйрь идеалының шулай булуы аның иҗатында традицион-шартлы сурәтләрнең өстенлек алып торуына да җайлы җирлек булды. Бернникадәр вакыттан соң инде мәңгелек идеаллар икенче мәгънә, икенче яңгыраш ала бардылар, ягъни революцион-сыйнфый эчтәлек белән сугарыла башладылар. Ниһаять, язучы фәкать социалистик җәмгыятьтә генә гуманистик идеал конкрет һәм реаль мәгънә алуын аңлауга иреште.

Социалистик революция нәтиҗәсендә сыйнфый көрәш идеясе белән баетылган гуманизм татар әдәбиятында чәчәк атты. Такташ гуманизмы да шул рухта формалашты. Әмма моңардан әле аның идея-эстетик эчтәлегендә шагыйрь кичергән иҗади эзләнүләргә хас сыйфатлар һәм билгеләр булмады дигән нәтиҗә ясалмаска тиеш.

Һичшиксез, Такташның соңгы дәвер иҗатындагы гуманизм татар әдәбиятының идея-эстетик эчтәлеген, философик колачын күпкә баетты һәм киңәйтте. Ләкин безнең тәнкыйть Такташның, нигездә, шигырьләре белән генә эш итеп, башка жанрлардагы әре генә әсәрләрен читтә калдыру аркасында, аның иҗатындагы иҗтимагый һәм шәхси башлангычлар мөнәсәбәтен, гуманистик идеянең формалашуын бөтен фактик тулылыгы белән ачып җиткергәне юк әле. Шул яктан килгәндә, Такташның, мәсәлән, драмалары да өйрәнелә торган проблемага зур гына ачыклык һәм тулылык кертүгә булышалар дип уйлыйбыз.

20 нче еллар азагында шагыйрь берничә драма язган иде. Шулардан беренчесе итеп «Күмелгән кораллар»ны (1927) алырга мөмкин.

Авылда революция бара. Кешеләрнең иҗтимагый, шәхси һәм хәтта нәсел мөнәсәбәтләрен астын-өскә әйләндереп, сыйнфый көрәш көчәя. Берәүләр — революцияне ясаучылар һәм яклаучылар, ә икенчеләре — аның дошманнары. Җамали крестьянның малае Мансур — актив коммунист булып, авылдагы революцион көчләргә җитәкчелек итсә, Җамали туганының малае Солтан исә — советка дошман элементларның атаманы. Бай баласы буларак, Солтан искене кайтарырга тели һәм, атасы саклаган тәртипләрне җимерүгә катнашкан өчен, Мансурны гафу итә алмый. Мансурның кече энесе Рөстәм, революцияне җырларга ниятләп, хыялланып йөргән бу яшь егет, Солтан кулыннан һәлак була.

Үзенең кем икәнен аңлый башлаган һәм күңеле көрәш романтикасы белән тулы Рөстәм драманың үзәгендә торган гуманистик идеяне шигъри сынландыручы яңа кеше образы итеп Солтаннарның антигуманизмына, кешелексезлегенә каршы куелган шикелле. Революцион-сыйнфый көрәш азатлык сөйгән кешенең, чергән искелекне җимереп, аның урынына матур, яңаны төзү өчен биргән фидакарьлегеннән башка була алмый. Шуңа күрә дә ул хәтта интим-шәхси теләкләрдән ваз кичүне таләп итә икән — моны да кире кагу мөмкин түгел. Мансурга гашыйк булган Сәгыйдә мөгаллимәнең революция өчен үз вөҗданына җинаять эшләвен — Солтан белән шәхси мөнәсәбәткә кереп, аннан балага узуын да хурлык дип карарга ярамый. «Юк, без икебез ике сыйныфның баласы... Бел, минем йөрәгем астында синең балаң кала. Ләкин ул гомергә синең исемеңне йөртмәс. Мин үзем теләп, сине үлем җепләренә бәйләдем»[1], — ди Сәгыйдә

[1] Һ. Такташ. Әсәрләр. I том. Казан. 1931 ел. 277 бит.

Солтанга һәм, туачак баласының атасы булуга карамастан, аны революцион хөкемгә тапшырырга булыша.

Әйе, болар һәммәсе бергә яңа гуманизмның җир өстендә кешелеклелек тантанасын урнаштыру өчен барган канлы көрәш эчендә тууы хакында сөйли. Мансурның Сәгыйдәгә төбәлгән сүзләрен тик шул мәгънәдә генә аңларга мөмкин: «Сәгыйдә! Теләсәң, мин — синең иң якын иптәшең, әгәр мине ярату хисләрең югалмаган булса, балаңның атасы да булырмын».

Шулай итеп, «революция өчен кардәшлек юк» дигән принципка соңгы тамчы канына кадәр табынган герой бу очракта бөтенләй икенче яктан ачылып киткән кебек: аның һәммәсен җиңә һәм һәммәсен үзенә гашыйк иттерә торган кешелеге күркәм булып алга баса.

Күренә ки, Такташ драмасында да революция башыннан ук татар әдәбиятын биләгән билгеле тема һәм романтик образлар, коллизия һәм мотивлар урын алалар. Мәсәлән, Мансур образында Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр»ендәге Батырхан сызыклары төсмерләнә һәм драманың төп гуманистик концепциясе дә 20 нче еллардагы татар әдәбияты өчен типик. Монда да ул шулай ук иҗтимагый идеалның шәхси теләкләрдән өстенлеген берьяклы социологик итеп аңлаудан азат түгел әле. Әмма шул «үтелгәнне кабатлау» эчендә Такташча аңланган һәм җырланган гуманистик идеал утыра: ана белән баланың үзара бәйләнеше мәңгелек һәм өзелмәслек булган кебек, революция, кешелеклелек һәм мәхәббәт тә бер-берсеннән аерылгысыз. Такташ гуманизмындагы философик башлангычның шигъри гүзәллеге дә әнә шунда.

Әйткәнебезчә, интим-семья мөнәсәбәтләренең иҗтимагый бурыч белән бәйләнеше безнең тормышның тыныч шартларында аеруча катлаулы һәм нечкә яклары белән өскә чыга башлады. Монда инде яңа кешенең әхлак философиясен төзү һәм яңадан корудагы кыенлыклар тагын да кискенрәк һәм авыртучанрак булып тоела иде. Такташның «Югалган матурлык»[1] дип аталган икенче драмасындагы персонажлар нәкъ шундый кыенлыклар белән очрашалар да инде. «Мин ул әсәрне курыкмый яздым. Аңа булган тәнкыйтьне дә шулай бодро, куркусыз каршы алам»[2],— дигән шагыйрь үзенең 1929 ел, 16 январь хатында, чөнки бу драмада авторның әйтергә теләгәне бик гади һәм ачык: совет семьясы таза булырга һәм бер-берсен яратып, аңлап тормыш корган кешеләрнең иҗтимагый һәм шәхси интересларын гармонияле, акыллы итеп гәүдәләндергән беренче коллектив булырга тиеш. Бу ноктадан килгәндә, драма геройлары ике төркемгә аерыла. Аларның беренчесе, төрле сәбәпләр аркасында искелек белән мөнәсәбәтләрен өзмәгәнлектән, үзләренең шәхси тормышларын һәм интим мөнәсәбәтләрен яңача коруга җиңел карыйлар. Икенче төркем вәкилләренә хас сыйфатлар бигрәк тә Газиз һәм Галия образларында сурәтләнеп, алар беренче төркемгә хас йола-гадәтләрдән һәм теләкләрдән күп югары торалар. Бу ике төркем геройларның капма-каршылыгы, контрастлары драматик конфликт итеп алынмаган. Автор аларны беркайда да тенденциоз рәвештә бәрелештерми, хәтта шартлы киртәләр белән аерып та куймый, ә бу каршылык, конфликт аларның әхлак дөньясында һәм тормыш философиясендә тирән булып яшеренеп ята. Автор тормыш чуарлыгын ак-карага җиңел итеп кенә аерып, тезеп бармый. Искелек белән яңалык янәшә генә яшәмиләр, ә буталалар да, аралашалар да. Тормыш җиңел түгел әле. Күп кенә кешеләр хәтта ярым ач хәлдә яшиләр. Ятим балалар да, үзләренең нәсел-нәсәпләрен белмәгән ата-аналар да тулып ята. Әмма әнә шундый хаос, буталчыклык һәм күңелсезлек дәвам итүгә карамастан, таза башлангыч өскә калка бара. Ул мещаннарча туң һәм мәгънәсез яшәүгә каршы булган идеалга табан юл салырга омтыла. Яңалык романтикасы да шунда инде. Үзләре тирәсендәге күп кенә замандашларына үрнәк булырлык итеп, тиң мәхәббәт һәм бер-берсен аңлау җирлегендә тормыш корган Газиз белән Галиянең ашкынулары әнә шундый. Алар — тормышның якты идеалларына һәм матур иҗади максатларына табынган яшь кешеләр. Матурлык турындагы дәртле хыял алар тормышының башлангычын яктыртып тора һәм киләчәгенә дә ышаныч бирә: «Теләсәң, син минем кояшым булырсың да, мин синең планетаң булырмын, син минем күкрәгемне җылытып, аннан

---

[1] Драма беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 12 санында басылды. Монда өзекләр шул чыганактан алына.
[2] Х. Госман. Егерменче елларда татар поэзиясе. 305 бит.

матур яз, чиксез иҗат тормышы уятырсың»,— ди Газиз Галиягә. Шулай итеп, зур тормышның якты кыйбласы табылган шикелле. Газиз һәм Галия үзләренең тормышларына сөенәләр. Галия партиягә кабул ителә, ә Газиз бик уңышлы гына итеп, үзенең производстводагы һәм фәнни эшләрен үти. Түземсезлек белән беренче баланы көтәләр, аңарда киләчәкне һәм бәхетне сынландырган яңа буын идеалын күрергә телиләр:

«Ул туачак яңа кеше безнең канибызны гасырларның күкрәгенә салып барыр. Ул еллар очында туачак Иркле нәселләргә безнең тавыш белән сөйләр...» ди Газиз, һәм Галия дә:

«Ул безнең тавыш белән сөйләр... Мин аның йөрәк тибү тавышын ишетәм инде...» ди.

Әмма бу романтик, канатлы ашкынулар һич тә алдан күру мөмкин булмаган тормыш кыенлыкларына бәрелеп җимереләләр: «Әллә нәрсә... бүгенге гаилә төзелергә өлгерми — җимерелә бара»,— ди Газиз үзенең яшьтәшләре турында, һәм озакламый алар үзләре дә шундый ук фаҗигале факт алдында калалар. Геройларның тормышка һәм анда үз рольләренә булган каршылыклы карашлары өскә бәреп чыга һәм бәрелешә:

«Галия. Мин арыдым. Утырыйк. Соң ни эшлим мин? Миңа быел университет бетерергә кирәк. Син үзең дә моңа карыша алмыйсың. Партия тапшырган эшләрне дә эшләп булмый бит. Болай да мин, партсобраниеләргә йөрүдән артык, партия эшенә катнаша алмыйм. Инде учреждениедә дә эшләүгә килгәч, аны ташларга миңа ярамый. Матди якны бөтен авырлыгы белән синең өстеңә ташлау җинаять булыр иде. Матди ягыбыз болай да начар. Сиңа болай да авыр. Кәң буе заводта эшлисең. Аннан партия эшендә. Төнге сәгать 4 кә кадәр өйдә проектлар өстендә утырасың... Әгәр мин эшне ташласам, сиңа тагын да авыр булыр. Аннан соң син эшләп тә, мин эшләми, синең көч белән тапкан акчага көн итә башласак... Юк, мин аны эшли алмыйм, Газиз!..»

Менә нәрсәдә икән хикмәт: җәмәгать эшчесе булыргамы, әллә фәкать хатын гынамы? Шул сорауга җавап эзләгәндә инде Галия белән Газизнең барлык романтик корылмалары сүтелә башлый. «Ике зур теләккә омтылган йөрәкләр гаилә төзи алмыйлар»,— дигән нәтиҗә ясый Газиз, шуның белән үз тормышларында килеп чыккан бәхетсезлекне акларга теләгәндәй була. Беренче баланы тапканнан соң, Галия аны тәрбияләргә һәм хәтта имезергә дә вакыт таба алмый. Бала үлә, ә ана үзенең иҗтимагый бурычына, эшенә фанатикларча бирелүдән һич тә баш тартмый. Шуның өчен ул икенче, тагын да авыррак җинаять эшли: аборт ясата һәм үзенең һәлакәтен якынайта. Галия һаман да боларны иҗтимагый максат өчен эшлим дип юана һәм аклана: «Мин үземнең псәнлегемне югалттым, мин үземнең яшьлегемне югалттым. (Буылып юталли.) ...Мин Сөтен матурлыгымны югалттым. Әйт, әйт, мин кешелек дөньясы алдында беренче ана булырга тиешле идемме, әллә җәмәгать эшчесеме? Син әйт миңа».

Галиянең язмышы әнә шулай фаҗигале булып бетә. Драмада аның соравына, әлбәттә, җавап юк. Ни өчен Такташ үз геройларының язмышын кискен драматизм белән хәл итә? Ул үз геройларының тормышында нинди дә икенче юлны тапмаганмы яки табарга теләмәгәнмени? Нәкъ киресенчә. Такташ, белә торып, аларның унай идеалларын, гуманистик ашкынуларын романтиклаштырып, реаль мөмкинлек белән аеруча кискен бәрелешкә керткән. Ләкин бу бәрелешнең мәгънәсе иҗтимагый түгел, ә фәкать психологик кына. Шул рәвешчә, турыдан-туры заман темасына, тормышына бәйле проблеманы традицион-романтик ачкыч белән ачарга теләү барып чыкмады, чөнки ул ачкычның, күтәренке әдәби эффекттан башка, һичбер «сихерле», «магик» сыйфаты юк иде инде. Һәм моннан шулай ук нинди дә политик хата эзләү дә урынсыз булыр иде. Ә чынлыкта исә «Югалган матурлык», традицион-психологик коллизияләргә бай романтик драма буларак, югары гуманистик, оптимистик максатны куйган һәм, иске әхлак-көнкүреш философиясен ташлап, ә яңасын кыю рәвештә тудырып, замандашларына башкача яшәргә кирәклек турында сөйләгән әсәр бит. Газиз белән Галия образларында Такташ яңа кешеләрнең никадәр рухи һәм иҗтимагый матурлыкка сусауларын күрсәтергә теләде. Аларның фаҗигале язмышларында ясалмалык һәм шартлылык авторның мондый изге нияте әһәмиятле, актуаль булуын һич тә юкка чыгара алмый әле. Ә вульгар тәнкыйть исә «Югалган матурлык»ның эстетик каршылыклары эчендә гәүдәләнгән сәламәт идеяне күрмәде.

Татар әдәбият фәне, Такташның фәкать поэзиясеннән генә чыгып, аның бигрәк т соңгы чор иҗатында социалистик реализмнын «такыр юлыннан» туп-туры, беркая д читкә чыкмый гына үсеп баруын күрергә күнекте. Хәлбуки, мәсьәлә байтак катлаулы иде. Шагыйрьнең тик шул өч драмасын («Күмелгән кораллар», «Югалган матурлык» «Камил») күз алдында тотсак кына да, әле 20 нче елларның азагында да аның иҗаты киеренкелек белән, тирәнтен эзләнүләр белән барганлыгын сизәрбез. Ул әсәр ләрдә яңа кешенең рухи дөньясына вакыты белән кыю ясалган, әмма урыны белә бик үк уңышлы булып бетмәгән разведка бар иде.

## 2

Шигъри гадилек һәм матурлыкны эзләү юлы такыр гына булмады. Ул бер үрдә икенчесенә күтәрелү генә дә түгел иде. Реалистик эзләнүләрнең тирән эзләрен калдырган «нәни шаярулар»дан соң, Такташ поэзиясендә социалистик төзелеш күтәр барган һәм әле бик үк билгеле, ачык булмаган тема-мотивларны үзләштерүгә табан житди борылыш башланды. Бигрәк тә 1929 ел тирәсендә шагыйрь иҗатында «көн кадагына» бәрә торган социаль-политик акцент белән сөйләү көчәеп китте. Аның шигъри стиленә дә публицистик «тыйнаклык» тоны килеп керүен дә шуның белән генә аңлатырга мөмкин. Бу үз нәүбәтендә газета прозаизмына хас гадиләштерү һәм утилитаризм кебек кимчелекләрдән дә азат булмады. Ә мондый кимчелекләр исә борылыш чорындагы татар поэзиясенә гомумән хас иде.

20—30 еллар аралыгында Такташның кискен рәвештә заманның яңа зур темаларына, аларны тагын да колачлырак сурәтләрдә чагылдыра башлауга борылуын, әһәмиятле факт буларак, искә алу белән бергә, шагыйрьнең элеккерәк чор иҗатында расланган кайбер поэтик тенденцияләре тоныкланыбрак киткәнлеген дә әйтергә кирәк. Бу очракта без Такташ иҗатында, мәсәлән, көчле генә тамыр җибәрә барган лирик психологизмның арткарак чигенүенә ишарә итәбез.

Такташ стиленең үсешен, үзгәрешен күзәтеп, Х. Госман 20 нче елларның икенче яртысында шагыйрь иҗатында, мәсәлән, халык җыр моңы көчәеп китүенә, әмма берничә вакыттан соң бу моңның сүнүенә игътибар итеп, шигъри сөйләмендә ирония элементларының көчәя төшүен, интонациясенә кырыслык төсмере йөгерүен искәртә[1].

Табигый, язучы иҗатында яңа һәм тагын да көчлерәк шигъри элементның үсүе электә тулы гына күренгән башка элементларны, сыйфатларны арткарак этәрергә, хәтта кысрыклап та чыгарырга мөмкин. Такташ стиле формалашу процессында да мондый хәлләр, әлбәттә, булды. Әмма шул ук вакытта моңа охшаш күренешләр ул еллар поэзиясендә, бердән, лирик тонусның гомумән сүлпәнәюе белән дә, икенчедән, зур иҗтимагый-фәлсәфи гомумиләштерүгә омтылышның көчәюе белән дә бәйләнгән иде. Шулай ук вульгар социологизмның әдәбиятта лирикага һәм психологизмга каршы көрәш алып барганлыгын да онытмаска кирәк. Бу көрәш поэзиядә кешенең эчке дөньясына игътибарны, әлбәттә, какшата, йомшарта иде. Тора-бара РАПП-ТАПП концепцияләрен бик нык яклаган тәнкыйтьчеләрдән Г. Галиенең инде 1927 елда ук формалаштырылган кайбер тезисларын бу уңай белән искә алырга туры килә: «Без, пролетариат әдәбиятының төп нигезе эпостан, ягъни гади генә иттереп әйткәндә, үзеннән башкалар турында язудан тора, дибез. Ләкин безнең шигырь язучылар «әбәзәтелне» үзләрен кыстырырга, үз шигырьләренең төп каһарманнары итеп үзләрен куярга — ясалма лирикага бирелергә ярататар. Алар күбесенчә үз эшләре, үз тойгылары, үз карашлары турында «җырлыйлар»... Сез бармак белән санарлык кына, ә матурлык, шигърият, көчле тойгылар — миллионнар арасына сибелгән нәрсәләр алар»[2]. Әлбәттә, бу фикерләр арасында бертөрле дә поэзиягә хилаф һәм мәкерле ниятләр, максатлар юк. Ләкин эпос белән лириканы кара-каршы кую тенденциясе дөрес ноктадан чыкмый иде. Лирика шәхеснең субъектив омтылышларын ачык белдерә торган форма булганлыктан, бу еллар тәнкыйтендә һәм әдәбиятында аны революциягә чит индивидуализм күренеше итеп, вульгарлаштырып аңлау күзгә ташланып торды. Шул ук ноктадан килеп, классик поэзиядәге лирика да халыкка дошман сыйныфларның настроениесен

---

[1] Х. Госман. Егерменче елларда татар поэзиясе. 335 бит.
[2] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1927 ел. 14 август саны.

чагылдырды дип хөкем ителде. Шулай итеп, жанр төшенчәсе идеологик төшенчә белән алыштырылды.

Шушындый карашларга нисбәтән, объектив лириканы һәм эпосны яклау дип, субъектив лирикага һөҗүм итү аеруча 20—30 еллар арасында бик тупас төс алды һәм гомумән безнең поэзиядәге психологик, интим лириканы кыерсытуга әйләнде. Күпчелек шагыйрьләрнең моның белән исәпләшми иҗат итүләре мөмкин түгел иде.

Шәхеснең коллектив белән, кешенең һәм шул исәптән әдипнең халык белән бердәмлеген, аерылмаслыгын бик туры, яссы итеп аңлау — безнең әдәбияттагы психологизмның һәм лириканың үсешен тоткарлаган сәбәпләрдән берсе иде. Ул язучының, шагыйрьнең үзен шәхес итеп аңлавына тоткарлык булып торды. Такташ иҗаты да, үзенең психологик һәм лирик сыйфатын саклау, үстерү һәм ачу өчен, әнә шул югарыда искә алынган кыенлык һәм каршылыкларны кичерми кала алмады. Моны күрмәү — шагыйрьне зур әдәби хәрәкәт тышында калдыру булыр иде.

Такташны өйрәнүчеләр арасында шагыйрьнең соңгы елларында күренгән иҗади кимчелек һәм кыенлыкларын читләтү күзгә ташлана. Бу, бәлки, язучының социалистик реализмга үсешен өзлексез, бөтен итеп, гармоник итеп күрсәтү максатыннан эшләнәдер. Тышкы яктан моны яхшы ният дип карарга да мөмкин. Ләкин аның эчтәлеге, кызганычка каршы, бөтенләй үк объектив һәм фәнни нәтиҗә бирми шул. Такташның ташлама һәм шомартуларга мохтаҗ талант түгеллеген исбатлап торасы юк. Монда сүз, әлбәттә, ясалма «объективлык» һәм «фәннилек» өчен генә шагыйрьнең индидер «гөнаһларын» күпертү турында түгел, ә аның тормышчан дөреслекне һәм шигъри матурлыкны эзләү юлында очраган иҗади үсеш кыенлыклары турында бара.

Билгеле булганча, диалектик материализмны совет әдәбиятының иҗат методы дип игълан итү һәм аны турыдан-туры критик реализмга яки романтизмга каршы куюу аерым язучыларның гомумән иҗат методы һәм хосусан әдәби осталыгы дөрес формалашуга бик тә комачаулады. Социалистик чынбарлык белән тыгыз бәйле совет әдәбияты дөрес юлдан үсә баруына карамастан, вульгар социологизм берише язучыларның иҗат мөмкинлекләрен күпмедер күләмдә богаулады. Такташ шулай ук вульгар социологизм басымыннан читтә кала алмады. Үзенең эстетик концепцияләренә һәм ышанычларына каршы буларак, ул 1930 елда «Тыңла, ТАПП!» дигән мәкаләсендә болай язган иде: «Без үзебезнең уночьеллык көрәшебездә иске буржуаз милли әдәбиятның мөндәриҗәсен дә, формасын да җимерү эшендә чиксез зур эшләр эшләдек. Без үзебезнең интернациональ мөндәриҗәле, пролетариатның сыйнфый теләкләре белән сугарылган, матурлык ягыннан татар милли буржуа әдәбияты белән тиңдәшмәслек югары пролетариат әдәби стиле тудыруда зур адымнар атладык»[1].

Мондый фикерләрдә, әлбәттә, Такташча булган оригиналь бернәрсә дә юк. Болар бары да — ТАПП лидерларының «фәнни-критик» арсеналыннан алынган билгеле штамплар гына. Алар шагыйрьнең үз иҗат практикасына һәм эстетик карашларына һич туры килмиләр. Әмма шулай да «үтә суллык» кайвакытларда, барлык актуаль булган һәм көн бурычына җавап бирә торган нәрсә әдәби матурлыкка ия һәм сәнгатьчә аклана, дигән карашны яклауга китерә иде. Такташ поэзиясенә үтеп кергән газета прозаизмын да әнә шуның белән генә акларга мөмкин. Гомумән 20 нче еллар азагында көндәлек, «актуаль шигырьләр» татар поэзиясен бик нык чүпләп, шул чүп астында ук алар үзләре дә күмелеп калдылар.

Ләкин без моның белән Такташ поэзиясендә тиешле шигъри янгыраш алган «актуаль темаларга» багышлы публицистик шигырьләрнең әһәмиятенә һич тә күз йомарга теләмибез. Әйтик, аның «Иптәшләр», «Син дошманым минем», «Тун трагедиясе» һ. б. шундый әсәрләре, һичшиксез, публицистик поэзиянең уңышлы үрнәкләре булып торалар.

Такташ, художник буларак, сәнгатькә һәм аның роленә вакытлы, үтеп китүчән, көндәлекле утилитар карашлардан югары тора алуы белән көчле иде. Яңа чынбарлык һәм аны төзүче кеше белән якыннан таныша бару шагыйрьдә матурлык, аның асылы һәм әһәмияте турында тирән уйланулар уятты. 1930 елгы очеркларының берсендә ул шулай яза:

---

[1] Бу мәкалә «Атака» журналының 1930 елгы 2 санында басылган. Монда алынды: һ. Такташ. Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр. 243 бит.

«— Соң нәрсә ул матурлык? Шул хакта башка җыелган фикерләр чуалалар.

— Һәрбер файдалы нәрсә матур.

Әйе.

Һәрбер маңгай тире, йөрәк каны, мең еллар буенча көраш нәтиҗәсендә туган һәрбер файдалы нәрсә матур! Мин үземне кин урманнар, яшел басулар аркылы ыргылып алга өстерәгән поездның матурлыгы турында уйларга тырышам. Соң ни өчен хәзергә кадәр кешелек тудырган даһи җырчылары шушы бөек хезмәт тудырган матурлыклар турында җырламаганнар? Ни өчен матурлыкны хатын-кыз күзеннән, табигый яратылыштан гына эзләгәннәр алар?.. Экономика матурлыкка булган карашны үзгәртә бара. Кичәге матурлар үлде. Иртән аның яңасы туар». («Сагынылган җирләрдә».)

Әлбәттә, бу өзектәге фикерләрнең һәммәсен дә дөрес һәм төгәл дип булмый. Бигрәк тә «һәрбер файдалы нәрсә матур» яки кичәге матурлыкның үлүе кебек карашларны тулысы белән кабул итүе кыен. Әмма шагыйрь иң әһәмиятлесен дөрес билгели: матурлык кеше хезмәте белән тудырылган, ягъни иҗат ителгән нәрсәдә, шуңа күрә ул үлми, ә өзлексез үсә һәм дәвам итә. Әнә шундый Горькийча концепция Такташның чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтендә тагын да тирәнәеп һәм шагыйрьнең гуманистик идеалын баетып, тамыр җибәреп үсә башлады.

Яңа тормыш материалын сәнгатьчә сурәтләү объекты итеп үзләштерү һәм аңлау белән генә чикләнмичә, Такташ, барыннан да элек, аның шигъри матурлыгын күрсәтергә, иҗтимагый-фәлсәфи мәгънәсен ачарга теләде. Бу яктан социалистик җәмгыятьтәге кеше проблемасы аның иҗатында аеруча әһәмияткә ия булып тора. Әйтергә мөмкин ки, монда инде герой проблемасы турыдан-туры социалистик җәмгыять һәм кеше язмышы ноктасыннан куелды. Бу, һичшиксез, шагыйрь иҗатында ачылып киткән яңа нокта, яңа аспект иде.

1928 елда Такташ «Үтеп барышлый» дигән шигырен яза. Халыкка мәхәббәт һәм аның зур язмышы турында уйланулар, классик әдәбият традицияләре белән аваздашлыкка кереп, беренче тапкыр күңел тирәнлегеннән чыккан көчле борчылу булып яңгырадылар. Бу әсәрнең беренче һәм икенче вариантлары арасында күпме генә аерма булмасын, аларның икесендә дә халык турындагы уйлар шагыйрьнең эчке дөньясын тулаем биләп алуы хакында сөйли иделәр. Монда «шагыйрь һәм халык» темасы Такташ иҗатында элек күренмәгән бөтен ачыклыгы һәм тирәнлеге белән күз алдына бастырылды. Халыкның тарихтагы ролен аңлауда, аңа үзенең мөнәсәбәтен билгеләүдә шагыйрьнең җитди позициягә басып һәм җитлеккән тавыш белән сөйли башлавы иде бу.

Хезмәт иясенең, гади кешенең язмышы гомумән түгел, ә конкрет тарихи җирлектә Такташның игътибарын үзенә җәлеп итә барды. Моның матур бер үрнәге — «Мокамай» (1929) шигыре. Киеренке драматизм белән сугарылган бу әсәр тулы мәгънәсендә кеше язмышы темасына багышланган. Монда кеше язмышының революция һәм социализм язмышы белән бәйләнешен аңлау үзенең гаҗәп оригиналь поэтик чагылышын тапты, аның сәнгатьчә матурлыгы һәм нечкәлеге тагын да калку, күркәм һәм җанлы булып алга басты.

Шагыйрь иҗатында Мокамай образы да кинәттән генә тумыйча, байтак вакытлар дәвамында формалаша килгән булса кирәк. Үзенең тормышчан прототибы белән тыгыз бәйләнгән бу герой Такташның берничә әсәрендә теге яки бу төстә сәнгатьчә гәүдәләнешен тапкан. Аны беренче мәртәбә, мәсәлән, «Күмелгән кораллар»да очратырга мөмкин. Монда Мокамай дезертирлар арасында — күпчелеге үзенең аңы җитлекмәгәнлек һәм революция дошманнарының коткысы аркасында халыктан аерылган кешеләр янында күренә. Ләкин язучы аны бу мөхиттән аерылыбрак торган бер герой итеп күрсәтергә тели. Мокамай сыйнфый-гуманистик сыйфатлардан мәхрүм түгел. Шуңа күрә дә ул Габдулла мөгаллим шикелле аңлы кешеләр йогынтысында контрреволюцион «дусларыннан» читләшергә омтыла, халыкка явызлык эшләүчеләр белән бергә булуыннан ризасызлыгын күрсәтә, ярлы крестьяннарны таларга барудан баш тарта һәм хәтта үз тирәсендәгеләргә кыю сүзләр әйтүдән дә курыкмый.

Инде шигырьдәге Мокамай образын тудырганда, Такташ аның соңгырак еллардагы фаҗигале язмышына игътибар иткән. Монда Мокамайның гуманистик кыяфәтен характерлаган төп фикер «Күмелгән кораллар»дагы Габдулла сүзләре белән

бик аваздаш шикелле: «Мин мондагы кешеләрдән берәүгә ышансам — ул да син. Син — усал тиле, ләкин син гакыллы һәм яхшы йөрәкле»,— ди ул Мокамайга.

«Мокамай» шигыренең дә буеннан-буена «син яхшы идең, синең яхшы иде күңелең» дигән фикер лейтмотив булып бара. Монда шагыйрьнең балачак дусы — гади авыл егетенең трагик образы күз алдына бастырылган. Ул иске дөнья корбанын символлаштыра, ә ул дөньяда тормыш төбенә ташланган кеше ялгызлыкта газапланырга яки һәлак булырга тиеш. Мокамай да нәкъ шундый язмышка дучар: ул тормышта дөрес юлны таба алмыйча түбәнгә тәгәри һәм үзен-үзе һәлак итә. Бу фаҗигале язмыш нигезендә «тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен» белмәү ята дип аңлата шагыйрь. Шуңа күрә Мокамай язмышы — ул иске кеше язмышы. Менә шул факт язучының кеше язмышы һәм аның коллективтагы роле турында житди уйлануылары өчен чыганак булып тора.

Син белмәдең:
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр,
Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен,
Күмәк тормыш җирдә төзиләр...

Мокамай язмышы безнең илдә барган менә шундый зур тарихи процесс яктылыгында, халык язмышы белән контрастта күрсәтелгән.

Икенче яктан лирик геройның оптимистик образы калка. Ул җәмгыятьтә үзенең урынын тапкан һәм анда үз роленең тарихи мәгънәсен аңлаган кеше язмышын сынландыра.

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым.
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син меналмадең...
Калдың, югалдың...—

дип белдерә ул лирик герой. Аның алдында инде тормыш горизонтлары киң булып ачылган. Аңарда шәхеснең яңа җәмгыять белән, күп миллионлы массаларның көрәше, эше һәм изге теләкләре белән бәйләнеш «серләрен» аңлаган шагыйрь язмышын да күрергә кирәк. Шигырьнең бер лирик лейтмотивы булган традицион ак каен образы да бөтенләй яңа поэтик көусәсе белән күз алдына килә. Ике геройның әкияттәге кебек сагынып сөйләргә калган матур дуслыгын һәм яшьлеген генә түгел, ә алга, якты бәхетле тормышка ашкынучы кеше идеалларын да сынландыра ул.

Шулай итеп, илебездә коллективлашуның кызган бервакытында язылган «Мокамай» шигыре гаҗәп отышлы поэтик формада һәм философик тирәнлек белән, әмма бик тә аңлаешлы һәм гади итеп, социалистик гуманизм идеясен раслады. Бу гуманизмның асылы, кеше һәм җәмгыять бәхетле булсын өчен, миллионлаган шәхесләрне җиңелмәслек зур көчкә әйләндерү, аларны берләштерү максатында ята иде.

3

Билгеле булганча, 20—30 еллар аралыгы халык тормышында һәм аңында искиткеч тирән революцион борылыш белән характерланды. Социалистик төзелешнең тизләтелгән темпы һәм илнең сыйныфсыз җәмгыятькә баруы безнең чынбарлыкның уңдырышлы яңа катламнарын кузгатып, кешеләрне яңадан тәрбияләүнең иҗтимагый-әхлакый мәгънәсен тагын да баетты һәм кискенләштерде.

Үткәннең зарарлы идея һәм гадәтләре белән көрәштә кешенең иҗади активлыгы һич булмаганча үсеп китте. Әдәбиятта менә шундый чынбарлыкны тулы итеп чагылдыру өчен, аны турыдан-туры хис итәргә, кеше рухының тирәнлегенә керергә, ә тирәнлектә барган зур төзелеш-үзгәрешләрнең тавышын гына ишетеп, читтән карап, риторик шатлык белдереп кенә тормаска кирәк иде.

Үзен тормыштан артта калуда һәм пассивлыкта гаепләүчеләргә җавап итеп, әмма үкенеп түгел, ә иҗади мөмкинлекләренә ышанып, Такташ болай дип чыккан иде:

Ә мин, җырлый алмый бүгенгене,
Шулай ярты юлда ардыммы,
Зур елларның бөек борылышында
Ыргытылып читтә калдыммы?..
А, юк!
Бу тик болай,
Бу тик әле
Алга бару өчен тукталу,
Күтәренке тавыш алган чакта,
Бераз гына туктап тын алу...
(«Җавап». 1929.)

«Алга бару өчен», барыннан да элек, халыкның зур тормышы эченә керергә һәм, ул тормыш шигъри көндәлдә иң әһәмиятле сәнгать ихтыяҗына әверелсен өчен, аны якыннан аңларга, бөтен йөрәк белән хис итәргә кирәк иде. Үзенең төп иҗади максатын шагыйрь әнә шундый рухта аңлады да инде.

Менә шул максатка ирешү юлында лирик герой проблемасы да аның алдына икенче яклары белән килеп басты. Һәм бу проблеманы аңлауда да, аны сәнгать ноктасыннан яңача хәл итүдә дә Такташ кыюлык күрсәтүдән читләшмәде.

Кайбер шагыйрьләр иҗатында күренгән артык тар, интим тойгыларга һәм хәсрәт мотивларына һөҗүм иткәндә, ул еллардагы тәнкыйть гомумән лириканы, лиризмны кире кагу юлына басып, хәтта ниндидер «коллектив лирикасы» турында да сөйләгән иде: «Шагыйрьләр үзләренең психикаларыннан, үзләренең йөрәк ялкыннарыннан аерылып, җәмгыятьнең аерым вәкилләрен эчке хисләре белән гәүдәләндереп, тормышларын күрсәтә алмыйлар. Хәзерге шигырьләрдә без күмәк психология, күмәк тормыш күрә алганыбыз юк»[1].

Ул вакытларда әле яшь булган бер тәнкыйтьче тарафыннан язылган бу юллар заманында бик таралган догмаларны яхшы ук шәрәләндереп күрсәтү белән гыйбрәтле: димәк, шәхси лиризм һәм коллектив лиризм — икесе ике нәрсә икән. Шуңа күрә шагыйрь үз психикасын түгел, ә коллектив психикасын җырларга тиеш. Әлбәттә, мондый караш астында поэзияне зур тормыш белән бәйләргә өндәү кебек изге ният ятса да, ахыр чиктә ул шагыйрь шәхсенең әдәби ролен тарайтуга һәм инкарь итүгә китереп чыгара иде. Ә чынлыкта исә, шагыйрь белән бәйле лирик геройны артка этәреп, аны пролеткультчылар яклаган «коллектив геройга» әйләндерү түгел, ә бу ике герой арасында тирән уртаклык тудыру, лирик геройның тормышка, тарихка, халыкка һәм кешегә карашын киңәйтү мәсьәләсе көн тәртибендә тора иде. Такташны лириканың һәм лирик геройның ролен менә шул юнәлештә хәл итү кирәклек бик тә борчыды. Һәм әйтергә кирәк: аның шагыйрьлек таланты, шәхси ихтыяры вульгар догмаларның басымына мөмкин кадәр буйсынмаска, бирешмәскә омтылды.

Тормыш фактларының, кеше кыланышларының һәм уй-кичерешләренең тышкы ялтыравыкларына, ыгы-зыгысына исе китеп, шулардан «иҗат илһамы» тапкан әдипләрдән Такташ ерак торды. Чынбарлыкны үз шәхси дөньясы аша үткәреп аңлаудан һәм хис итүдән башка язучының яңа заманга лаеклы әсәр тудыруы һич мөмкин түгеллеген ул яхшы төшенә иде. 20 нче еллар азагында һәм 30 нче еллар башында ул да, башка язучылар белән бергәләп, ил буенча сәяхәт итә, эре промышленность районнарына, шул исәптән Донбасс шахталарына һәм күмәкләшүче авылларга барып чыга. Болар һәммәсе шагыйрьнең дөньяга карашын һәм тормыш багажын баетты, әлбәттә. Ләкин ул бервакытта да үтеп барышлый күрелгән нәрсә генә сайланган теманы дөрес, тулы чагылдыручы әдәби әсәр язу өчен җитә дип уйламады. Ул, барыннан да элек, яңару атмосферасының үз һавасын суларга, заман рухын сизәргә һәм тавышын якыннан ишетергә омтылды. Тик шулай булганда гына идея эчтәлеге бай һәм сәнгатьчә көче зур әдәби әсәр тудыру мөмкин икәнлеген онытмады.

[1] «Безнең юл» журналы, 1919 ел. 2 сан. Курсив безнеке.— Г. Х.

1929—1931 елларда шагыйрь күп кенә мәкалә һәм очерклар язып, сәяхәт итеп йөргәндә туган уй-тойгыларын һәм әдәбият алдына социалистик яңалык куйган бурычтеләкләр турындагы фикер-карашларын чагылдырды. Бу яктан «Бүгенге матурлык һәм аны жырлаучылар турында», «Тынла, ТАПП![1], «Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында» («Ижат хатлары») кебек мәкаләләре бик тә кызыклы. Боларда ТАППча берьяклы концепцияләрнең шаукымы сизелсә дә, безнең әдәбиятның социалистик төзелешкә нык якынаюы, борылышы кирәк һәм бу котылгысыз дигән фикер бик ачык үткәрелә, әмма бу борылыш, Такташ аңлавынча, декларатив түгел, ә чын мәгънәсендә зур чынбарлыкның көндәлегенә үтеп керү һәм шул ук вакытта реализмның төп эстетик принципларыннан һич тә чигенмәү рәвешендә генә булырга тиеш. Әнә шул позициядән торып, Такташ татар поэзиясенең югары идея-эстетик яңгырашын арзанлы агитка һәм жансыз риторика белән төссезләндерергә теләүчеләрне рәхимсез рәвештә тәнкыйть итте. «Бездә кайбер иптәшләр бар,— дип язды шагыйрь «Ижат хатлары»нда,— аларның шигырьләренең исемнәре дә «кызыл» була, шигырьләренең эчтәлегендә дә бик күп ясалма пафослы сүзләр була. Ләкин ул «пафослы» сүзләр билгеле бер фикерне, идеяне жанландыруга хезмәт итмәүләре сәбәпле, буш, жансыз, нәфрәтләндерерлек дәрәжәдә эшсез — «безработный» сүзләр генә булып калалар».

Сәнгатькә каршы булган шалтыравык «поэзияне» кире кагып һәм хөкем итеп, Такташ чынбарлыкны әдәби үзләштерү һәм чагылдыруның бик ачык принципларын, критерийларен алга куйды: «Соң безнең бүгенге көрәшебезгә кирәкле әсәрләр тудыру өчен нәрсәләр кирәк? — дип сорый да ул гади һәм төгәл итеп җавап бирә:— Әдәби әсәрне, шигырьне яшәтүче «җаны», конкрет бер төп идеясе булу кирәк! Язучы язарга утырганда, аның башында массага әйтергә теләгән фикере булсын!» («Ижат хатлары».)

Эчтәлек һәм форма мөнәсәбәтенә кагылып, Такташ поэзиядәге новаторлык турында да бик мәгънәле, гыйбрәтле фикерләр белән чыга. Аныңча, шигъри идея белән бергә һәм аның тик аерылмас өлеше булып туганда гына, шигъри форманың яңалыгы тормышка сәләтле һәм хәзерге укучыга аңлаешлы булырга мөмкин. Мондый фикерләрнең күпчелеге тулысы белән шагыйрьнең үз иҗат практикасыннан килә иде.

Язучының турыдан-туры үз иҗат индивидуальлегеннән башка сәнгатьчә новаторлык (яңалык) булырга мөмкинме соң? Такташның «Иҗат хатлары» язылган чакларда мондый сорау күп кенә татар язучыларын борчый иде.

Сәнгать әсәренең объективлыгы һәм язучының субъективлыгы турындагы мәсьәлә 20 нче еллар дәвамында әледән-әле игътибар үзәгендә калып, ана җавап бирү тирәсендә бик күп төрле һәм үтә каршылыклы фикерләр мәйданга килә торды. Әйтик, пролеткульт теоретикларының сәнгатьтәге шәхси башлангычка каршы чыгулары, Леф тәнкыйтьчеләренең художник тавышын «предмет тавышы» белән алмаштыру турында сөйләүләре, ә вульгар социологизмның сәнгатьтәге объективлык белән художник индивидуальлеген аермыйча, соңгысын юкка чыгарырга теләве — болар һәммәсе ахыр чиктә художникның, язучының чынбарлыкка мөнәсәбәтенә ялгыш юнәлеш бирәләр, ориентациясен бозалар иде.

Язучының индивидуаль стилен һәм тормыш материалын үзенчә аңлавын инкарь итү кебек, ул вакытларда киң таралган тенденцияләргә каршы барып, Такташ һәрбер әдипнең дөньяга үзенчә художестволы-эстетик караш ноктасы булырга тиешлеген яклады: «Һәрбер язучының теге я бу идеяне формалаштыруда аның субъектив аерымлыклары шиксез зур бер роль уйный,— ди ул.— Аның психологик аерымлыклары теге я бу идеяне формалаштыруда бик күп үзенчәлекләрен катнаштыра. Һәм язучының үзенә характерлы иҗат буяулары, конкрет бер идеяне җанландырырга кирәк булган материалларны сайлый һәм аларны урнаштыра белүе нәкъ үзенчә булуы мөмкин. Бу һәр язучының специфик моментларына бәйләнгән». («Ижат хатлары»).

Әгәр дә без ул елларда раппчылар рус совет поэзиясен «демьянлаштыру»[2], ә аларга ияреп, таппчылар татар поэзиясен «крыймовлаштыру»[3] кирәклеккә өндәү белән нык кына шөгыльләнүләрен искә алсак, Такташның ни өчен художник индиви-

---

[1] Бу мәкалә шагыйрьнең кайбер җыентыкларында «Донбасска баргач» дигән исем белән басылган.— Г. Х.

[2] Демьян Бедныйча язу.

[3] Мансур Крыймовча язу.

дуальлеген аеруча тырышлык белән яклавын аңлау кыен булмас. Үзенең бөтен рухы белән аның бу хактагы фикере Маяковскийның канатлы булып киткән түбәндәге сүзләрен искә төшерә:

«Чынында исә миңа бер генә нәрсә кирәк: яхшы һәм төрле шагыйрьләр күп булсын». («Пролетар шагыйрьләргә хат», 1927.) Бу да шулай ук шигъри индивидуальлекне төссезләндерүгә, юкка чыгаруга каршы полемик тон белән әйтелгән иде.

«Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында сөйләгәндә, Такташ куелган мәсьәләгә, әдәбиятта «диалектик материализм методы» дип, теңкәгә тигән яңгыравык сүзләр белән түгел, ә аның эстетик мәгънәсен аңларга, ачарга ярдәм иткән эшлекле максат белән җавап бирергә омтылды. Совет язучысы үзенең партияле бурычын — халыкка хезмәт итүдә һәм максаты ачык сәнгать тудыруда күрергә тиешлегенә шагыйрь тагын бер мәртәбә басым ясап, «Иҗат хатлары»ның азагында, бөтен сөйләгәннәрен йомгаклагандай итеп, болай ди: «Пролетариат шагыйренең «фәлсәфи» булуы аның кечкенә генә бер фикерне дә кеше аңламаслык итеп язуда түгел, бәлки пролетариатның зур идеяләрен, аларның зурлыкларына зарар итми, киң массага аңларлык итеп, гади рәвештә, җанлы, матур бер форма белән бирә һәм массаның йөрәгенә сеңдерә белүдә. Бездә моңа начар бер күз белән «упрощенчество» итеп караучылар бар. Бу бик ялгыш караш. «Упрощенчество» ул шул фикернең зурлыкларына зарар китерер дәрәҗәдә шаблонлы язуда. Зур бер фикерне аның зурлыгын югалтмый, җиңел рәвештә әйтә алу — бу шагыйрьнең талантлы булуын, әйтергә теләгән фикерен этрафлы рәвештә белүен һәм ялангач формага түгел, бүгенге теләкләргә хезмәт итәргә теләвен күрсәтә».

Совет поэзиясендәге халыкчанлык һәм партиялелек мәгънәсен Такташ шулай аңлый иде. Бу төшенчәләрне ул үзләренең эстетик эчтәлек һәм шигъри чагылышлары белән бер-берсеннән һич тә аерылмас булырга тиеш дип карады. Чөнки чынлыкта да ул шулай иде. Бу эстетик концепциясен шагыйрь үзенең соңгы әсәрләреннән берсендә — «Киләчәккә хатлар»да (1930—31) аеруча тулы итеп тормышка ашырды.

## 4

1931 елда «Үзем турында» («О себе») дигән русча бер мәкаләсендә[1] Такташ «Киләчәккә хатлар»ның төп максатын болай аңлаткан иде: «Аларда мин киләчәк буыннарга безнең яңа тормыш өчен, яңа кеше өчен алып барган героик көрәшебезне тасвирларга тырышам»[2].

Заманның әһәмиятле тема һәм проблемаларын эченә алырга тиешле зур шигъри цикл итеп уйланылган бу «Хатлар», кызганычка каршы, авторның иртә үлеме аркасында, тәмамланмый калдылар. Әмма басылган өч кисәге бу әсәрнең идея-художество байлыгын, монументаль максатын тулы итеп күз алдына китерергә, һичшиксез, нигез була ала. «Киләчәккә хатлар» совет поэзиясендә барган зур процессның — тормышны эпик-философик аңлап сурәтләү тенденциясенең татар поэзиясендәге беренче күренекле үрнәге булды дияргә мөмкин. «Хатлар»ның үзәгендә чорның катлаулы, каршылыклы социаль һәм мораль табигатен сурәтләү аша кешеләр, сыйныфлар һәм буыннар язмышы турында уйланулар тора. Хәзерге заман философиясен аның тарихи перспективасы белән шигырь телендә күрсәтү — әсәрнең эчке пафосы менә шул.

Безнең гомер бөек планетаның
Шау-шулы бер чорына очрады,
Планетада бүген зур дау бара,
Ыгы-зыгы
Килеп тора бөтен почмагы,—

ди шагыйрь, әсәрнең лирик герое һәм хикәяләүче буларак алга басып.

Беренче карашка Такташ әдәбиятта күптән билгеле эпистоляр форманы сайлаган шикелле. Әмма шул традицион формага салынган фәлсәфи-шигъри эчтәлек «Хатлар»ны безнең заман турында киләчәк буыннар белән зур сөйләшү мәгънәсендәге лиро-

[1] «Красная Татария» газетасы. 1931 ел. 24 май саны.
[2] Һ. Такташ. Пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр. 248 бит.

эпик әсәр иткән. Поэма тулысынча киләчәк заман кешеләренә шигъри хат (послание) булып эверелгән, ягъни гадәттәге хат формасыннан бик күпкә киңәйгән, димәк, аның традицион функциясе бик нык үзгәртелгән, яңартылган һәм баетылган. Безнеңчә, Такташ әсәре заман турындагы шигъри һәйкәл буларак, Маяковскийның «Бөтен тавыш белән» дигән атаклы ораториясенә бик аваздаш. Бу ике әсәр арасында эчтәлек һәм шигъри башкарылыш ягыннан никадәр генә аерымлык һәм үзенчәлек булмасын, замандаш ике шагыйрьнең, үзләре һәм чор турында бөтен житдилек һәм жаваплылык белән сөйләп, киләчәккә горур мөрәжәгать итүләре — аларның уртак шигъри табышы булды дияргә мөмкин. Маяковскийның искә алынган бу соңгы әсәрендә субъективлык белән объективлыкның, лирика белән тарихилыкның тыгыз бәйләнеше күзгә бәрелеп торды. Такташның «Киләчәккә хатлар»ы да шундый бәйләнешне гәүдәләндерде.

«Киләчәккә хатлар»ның лирик герое — шулай ук трибун шагыйрь. Ул да үзе һәм чоры турында башын югары күтәреп, киң сулыш белән яшәүче оптимист-гражданин булып сөйли. Өч хат дәвамында да лирик герой, чор турында хөкем йөртүченең биек трибунасына басып һәм аның аша килер буыннарга кулын сузып, һәрвакыт безнең буынның тыйнак, гади бер вәкиле булып һәм үзенең ерактагы адресаты белән чын күңелдән сөйләшүче булып кала. Лирик геройның бу сыйфаты шагыйрьнең А. М. Горький белән очрашуы шикелле жанлы бер фактны сурәтләвендә гаҗәп отышлы итеп ачылган. Такташның лирик герое нәкъ Горькийча акыллы һәм күркәм гадилеккә табынуын белдерә: заман һәм кеше турындагы дөреслекне ачык һәм гади итеп әйтергә — менә шундый аның шигъри девизы.

Безнең фикеребезчә, «Киләчәккә хатлар»ның бөтен ритмикасы, интонациясе, композициясе һәм, ахыр килеп, стиле беренче нәүбәттә лирик геройның характеры белән билгеләнергә тиеш. Бу характерда коммунистик яңалыкның туктаусыз җинүен раслаган реализм да, югары романтик аһәң дә ачык сизелә. Публицистик-лирик пафосның күтәрелеп китүе дә, хикәяләү тонының басынкы агылышын үзенә буйсындырган шигъри киеренкелек тә фәкать лирик герой ихтыярының колачы белән генә үлчәнергә мөмкин. Такташ лирик геройның чынбарлыкны социаль-тарихи аңлау колачы никадәр киң һәм тирән булса, аның лирик һәм эпик башлангычларны үзара яраштыру, гармонияләштерү мөмкинлекләре дә чикләнмәгән.

Соңгырак чорда Маяковский иҗатында да лирик геройны «читләштерү» тенденциясе көчәеп киткән иде. Моңа охшашлыкны Такташта да күрергә мөмкин. Бу факт шагыйрьнең чынбарлыкны лирик чагылдыруы киң колач ала баруы турында сөйли иде. Маяковский поэзиясендәге шикелле үк, Такташта да лирик монолог белән бергә геройның «хикәяләве» кебек алымга урын бирелде. «Киләчәккә хатлар» — шуның конкрет үрнәге.

«Киләчәккә хатлар»ның төп идея-философик максаты, әйткәнебезчә, бик ачык һәм мөһим: бу, барыннан да элек, көчеш чорына, ягъни сыйныфларны бетерү һәм сыйныфсыз җәмгыятьнең нигезен салу чорына, хас булган иҗтимагый-сыйнфый һәм мораль-этик каршылыкларның искиткеч катлаулылыгын күрсәтүдән гыйбарәт. Кешене һәм җирне яңарту өчен, «кеше — кешегә бүре» дигән мораль кодексы җәмгыятьнең барлык әшәке йола-гадәтләрен җиңәргә тиешле социалистик гуманизм өчен көрәш бара. «Кеше — кешегә дус булсын» өчен бара ул көрәш. Бу юлда совет җәмгыяте үз тарихында иң кыен дәверләреннән берсен кичерә. Изүче сыйныфларны ил эчендә тәмам бетереп һәм яңадан тәрбия итеп алга барганда, без һәр адым саен аларның төрле битлек кигән һәм төрле кыяфәт алган калдыклары белән очрашабыз.

Иске белән яңаның бәрелеше һәм каршылыгы безнең чынбарлыкның төрле сфераларында, почмакларында бара. Ул ачык сыйнфый көрәш белән генә чикләнми, ә хәтта шәхеснең психологик дөньясында да бик яшерен төскә кереп чагылырга мөмкин:

Бездә сыйнфый көрәш хәзер фронтлардан
Бөтен почмакларга күчәнә;
Һәр ганлә ике каршылыкның
Берләшүен ала эченә...

Шуның бер конкрет мисалы итеп, «Икенче хат»та Мохтар карт образы сурәтләнгән. «Ул авылда тырышып колхоз төзегән, оештырган ярлы-ялчыны». Ләкин аның аңында, психологиясендә һәм семья тормышында искелек йолалары теге яки бу төстә

һаман да үзләренең каршылыкларын күрсәтәләр әле. «Мохтар бабай аңында — каршылыклар көрәше,— дип яза шагыйрь «Үзем турында» мәкаләсендә.— Бер яктан, ул колхозның өстенлекләрен, акылы белән уйлап, бик яхшы белә, икенче яктан, хосусый милекчелек гадәтләреннән аерыла алмый».

Әйтергә мөмкин ки, Мохтар образы 30 нчы еллар башындагы татар әдәбиятында үзенең тормышчан каршылыклары һәм кыйланышлары белән күрсәтелгән беренче оригиналь реалистик типлардан булды. Аңа охшаган яки аны дәвам иттергән типларның барлыкка килү факты үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Мохтар образын тудырыр алдыннан Такташ, әлбәттә, чынбарлыкның җанлы фактларын нечкәләп күзәткән, өйрәнгән. Искелек белән үзләренең мөнәсәбәтләрен тиз генә өзәргә һәм киләчәккә бару юлына кыю басарга батырчылык итмәгән замандашларына тапкыр трагикомик сыйфатларны шагыйрь тулырак һәм төгәлрәк итеп тотарга омтылуын аның иҗат лабораториясеннән ачык күреп була. Мохтар образына бәйләнештә язучының, мәсәлән, «Таң» (1931) дигән бер очеркын искә төшерү урынлы булыр шикелле.

Мохтар, әлбәттә, «Таң»да сурәтләнгән крестьян түгел. Ләкин аның язмышында да шундый ук көлке һәм кызганыч хәл төсмерләнә. Мохтар образы инде тулы әдәби тип итеп эшләнгән. Аның эволюциясе, үсеше, үзгәреше безнең күз алдыннан үтә. Аның характеры, психологиясе һәм аңы иске белән яңаның кискен бәрелеше аша формалаша. Шуңа күрә Мохтар искелек белән үзенең бәйләнешен аңлый башлаган образ буларак кына түгел, ә аңардан тәмам котылу өчен, коллектив белән үз язмышын тыгыз итеп бәйләү юлына баскан тип буларак та гыйбрәтле. Мохтар язмышында шагыйрьнең «Мокамай» шигырендә үзәк итеп куелган идеясе конкрет реалистик чагылыш алды:

> Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
> Чыгу юлын бергә эзлиләр;
> Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен,
> Кұмәк тормыш җирдә төзиләр...

20 нче еллар татар поэзиясендә яңа геройны үзенең каршылыклы, киеренке табигате белән Такташ шикелле тирән кичереп сурәтләгән икенче шагыйрь булмады. Алай гына да түгел, хәтта бөтен бу чор татар әдәбиятында аның герое үзенең уникальлеге белән аерылып торды. Шартлы-романтик дөньядан килерәк, гыйсъянчы герой, билгеле булганча, үзенең кырыс трагик кыяфәте белән, бөтен искелеккә каршы баш күтәргән, килешмәс, горур ялгызак булып алга баскан иде. «Пасха чаңнары»на (1923) кадәр ул шул позасында калды әле. Бу шигырь гыйсъянчының трагик акцентсыз һәм корбан булу настроениеләреннән азат, оптимистик тонда сөйли һәм хәрәкәт итә башлавын белдерә кебек. Ул инде, хәзерге заманга йөз белән борылган хәлдә, яңа шартларда шул ук иске дошманына һөҗүмен дәвам иттерә. Нәкъ үз аяк астында яңа туфракның барлыгын сизә башлау белән, Такташ героена хас трагик сыйфат та юкка чыга бара. Космик төшенчәләреннән акрынлап читләшә барып, бу герой көндәлек тормышка якын килә, аның настроениеләрендә элекке романтик контраст-антитезалар кими башлый. Кичерешләрендә ярым тоннар һәм характерында психологик нюанслар көчәеп китә. Шәхеснең иҗтимагый идеал белән гармониясенә, аерылмаслыгына дәртле омтылыш шагыйрь эстетик идеалын тулысынча билэп ала. Бу хәл инде үз нәүбәтендә геройның тормыштагы яңа, уңай башлангычны раслап, эчке каршылыклардан азат булырга теләвен тагын да активлаштыра... Гомуми сызыкларда күз алдына китергәндә, Такташ героеның юлы шулайрак булыр иде.

«Киләчәккә хатлар», һичшиксез, Такташның 20—30 еллар аралыгында җитлеккән яңа герой концепциясен тулы итеп чагылдырды. Шагыйрь үз поэзиясенә эпик герой өчен киң юл ачып, коллектив, халык, җәмгыять һәм тарих каршында үз бурычын җитди аңлаган шәхес үсешенең тулылыгын күрсәтүне максат итте. «Өченче хат»та мин социалистик хезмәтнең кеше психологиясен ничек үзгәртүен сурәтлим»,— диде ул. Анда «Синең бабаң» дип аталган образ — совет эшче сыйныфының бер вәкиле трибунага чыга. Мохтар белән чагыштырганда, ул герой бик үк конкрет бирелмәгән, әмма аның гомуми портретында зур мәгънә бар. Коммунистик буынның бер бабасы буларак, бу эшче шулай ук үз чорына хас каршылыклардан азат түгел әле. Ләкин

без аңарда инде каршылыкларның башка төрен очратабыз. Аңлы һәм алдынгы хезмәт кешесе булганлыктан, ул үз заводының план үтәүдәге артталыгын авыр кичерә, үз коллективының киң халык хәрәкәтендә тиешле урын ала алмавына пошына һәм шуның өчен үзен дә җаваплы саный:

Ул бүгенге бөек төзелешкә
Айнык бер күз белән каравын,
Заводында барган прорыв өчен
Үзен мәсьүл итеп санавын
Ул әйтергә залга теләде...

Шулай итеп, совет кешесенең зур тормыш, халык һәм җәмгыять белән бердәмлеге турындагы фикер Такташ эстетик концепциясенең үзәге булып ныгыды һәм аның реалистик таланты ачылуга көчле этәргеч бирде. Яңа геройда формалаша барган шәхси һәм иҗтимагый бердәмлек психологиясенә аеруча игътибар итеп, шагыйрь үз замандашларының күңел дусы, юлдашы һәм укытучысы булырлык лирик герой образын тудыруга иреште. Шушы ук процесста аның поэзиясендә объектив лирик башлангыч киң булып ачылып китте. Бу инде конкрет тормыш, халык, заман һәм тарих белән тирәннән бәйләнгән уй-тойгыларның язучы иҗат интересларында өстенлек итүе дигән сүз. Бу хакта Такташның матбугатка чыкмый калган кульязмаларында мондый фикерләр теркәлгән: «Шагыйрь бүгенгенең бөек фикерләрен иң югары ноктаЛарына кадәр үзләштерергә, укучыларның кушуларын, газета мәкаләләренең кычкыруларын көтми, социаль заказны тормыштан үзе ала белергә, бүгенгенең киләкләрен алдан күрә һәм вакытында җырлап барырга тиешле...

Ул миллионнарча кешеләрнең йөрәк тибүләрен тыңларга, аларның күзләре аркылы йөрәкләренең иң тирән җирләренә карый белергә,— таркау, эшләнмәгән, үзләре дә ачык аңламаган теләкләрен, хисләрен җыярга, ул теләкләрнең орлыкларын үзендә урнаштырып, йөрәк каны белән тәрбияләп үстерергә, аларны үсеп беткән бер рәвешкә кертеп, миллионнарның үзләренә кайтарырга тиеш...»[1]

Чыннан да, җитлеккән Такташ шигъри героеның объектив-лирик мәгънәсе бу очракта аеруча төгәллек белән формалаштырылган. Реалистик типиклаштыруның иҗтимагый һәм психологик табигатен тирән итеп аңлавы шагыйрьнең лирик героен да шартлы-романтик богаулардан коткарды. Әлбәттә, бу берьюлы гына эшләнмәде. Такташ герое заман көндәлеге һәм вакыйгалары белән нык элемтәгә кергән саен, аның тормышчан, реалистик сыйфатлары да өскә калка барды. Шул җирлектә инде лирик һәм эпик башлангычларның үзара тыгыз бәйләнеше дә барлыкка килде, тагын да ачыкланды.

20 нче еллар азагында Такташ игътибарын бигрәк тә иҗат психологиясе, халык уй-тойгыларын шигырьгә әверелдерү эстетикасы җәлеп итә. Поэзиядәге яңа матурлыкның табигате, шул матурлыкны беренче булып күрергә һәм ачарга тиешле художникның роле турында уйлана шагыйрь. Монда беренче итеп объектив һәм субъектив каршылыкларны кичереп үсүче замандаш геройны сурәтләү мәсьәләсенә игътибар арта. Мондый герой, катлаулы идея-мораль кыяфәте һәм драматик язмышы белән, беренче чиратта конкрет тормыш тирәлегендә, мохитында, үзенең кыланыш-хәрәкәтләре аша күрсәтелергә тиеш[2]. Нәкъ шуның белән бәйләнештә «Такташны барыннан да элек кешенең рухи хәле, психологиясе күбрәк кызыксындыра башлады»[3].

Тарихилык (историзм) белән лириканың тыгыз керешүе, кушылуы — совет поэзиясенең социалистик реализмга үсешен характерлаган бер сыйфат булды. Безнең фикеребезчә, шушында ук инде 20 нче еллар азагына табан Такташ иҗатында сизелерлек урын алган лирик эпосның да үзенчәлеге ята иде. Поэзияне заман сулышы белән сугарырга, аны чынбарлыкка йөз белән куярга, «нәфис дәреслек нигезендә кешенең бөтен эчке каршылыклары белән җанлы психологик типлар тудырырга[4]» омтылыш —

[1] М. Мамин. Һади Такташ поэзиясе. 83 бит.
[2] Бу мәсьәләләр Х. Госманның «Егерменче елларда татар поэзиясе» дигән хезмәтендә байтак тулы яктыртылган.— Г. Х.
[3] Шунда ук, 335 бит.
[4] Һ. Такташ. Зәкуан мулла шәҗәрәсе. «Кызыл Татарстан» газетасы. 1929 ел. 84 сан.

чорның реалистик эпосын замандаш психологиясе һәм лирик герой дөньясы белән органик кушу ихтыяҗын да көчәйтә барды. Такташ әдәби осталыгының мөмкинлекләре шул ноктага юнәлтелделәр. Шуңа күрә шагыйрь эпик геройны гына түгел, ә лирик геройны да тарихның җанлы фонында, чор көндәлеге атмосферасында гәүдәләндерүгә аерата игътибар итү турында фикер йөртте.

Совет әдәби хәрәкәтенең төп үзәненә кергән Такташ поэзиясе хәзер инде тагын да югарырак һәм реаль иҗтимагый яңгыраш алган уңай, раслаучы идеалның тулылыгы, көр тавышлы булуы белән аерылып тора иде. Бу момент, әйтергә мөмкин ки, яңа тарихи үрләргә күтәрелеп барган татар совет әдәбиятының торышын билгеләде. Күпләгән язучылар иҗатында реализмның кырыс ноткалары тагын да ачыграк яңгырый башлады,— һәм алар милли әдәбияттан искергән темаларны, эстетик бизәкләрне кысрыклап чыгару, тормышның яңа материалын һәм шуңа тапкыр әдәби чараларны үзләштерү исәбенә көчәя бардылар. Шулай ук яңа тема һәм сурәтләү чараларына әдәбиятның текә борылган вакытында публицистик риториканың да, схематизм күренешләренең дә кабаттан җанланып китүе табигый. Үткән заман темалары белән мавыгуны артык хупламыйча, Такташ әдәбиятның үсеше һәм камилләшүе өчен төп җирлек хәзерге заман тормышы белән тыгыз бәйләнеш икәнлеген алгарак куеп сөйләде.

Партиялелек идеясе һәм халык белән бердәмлек тойгысы шагыйрьнең бүгенге тормышта булып торганны аңлау сәләтен киң итеп ачып һәм яктыртып җибәрде. Шуның белән бергә сәнгатьтәге матурлыкның да, шагыйрь үзе әйткәнчә, «нәфис дөреслекнең» дә мәгънәсе — социалистик чынбарлыкны илһамланып җырлаудан һәм шуңа каршы торганны нәфрәтләнеп хөкем итүдән гыйбарәт икәнлеге аның эстетик карашларында тулысынча конкретлашты. Шул позициядән ул коммунистик киләчәкнең бөек панорамасын күрде:

Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә,
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә...

20 нче елларның икенче яртысында гомумән татар поэзиясенең һәм аеруча Такташ иҗатының тарихи-фәлсәфи эчтәлеге баюы «шигъри алдан күрү» мотивларының көчәюе белән бергә барды. Гыйсъянчылык дәверендә үк инде Такташ һәм аның замандашлары игътибарын, җирдәге тарихи үзгәрешләргә нисбәтән, Галәмдәге бинниһая күренешләр җәлеп иткән иде. Ләкин монда конкрет җир чынлыгына һәм тарихи процесска бәйләнештә алдан күрү тойгысы бик абстракт, зәгыйфь иде әле. 20 нче еллар азагына табан Такташның шигъри хыялы, заман чынлыгыннан «үсеп чыгып» һәм бүгенгенең киләчәк белән бәйләнешен чагылдырып, чорны «узып» китә башлады. Аның бигрәк тә «Гасырлар һәм минутлар» поэмасында зур урын тоткан революцион-тарихи перспектива романтикасы соңгы еллардагы поэзиясендә тормышчан киң колач һәм конкретлык алды. Менә шунда инде шагыйрь тарихи оптимизмы да идеалның тормыш белән бәйләнешен раслаучы яңа сыйфатын күркәм итеп ачып җибәрде. Шуңа күрә дә табигый ки, Такташның 20 нче еллар азагындагы поэзиясендә коммунистик киләчәк романтикасы аеруча ышаныч һәм горурлык белән яңгырады. «Пролетариат язучысы,— диде ул,— әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңелмәслек бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә безнең бүгенге идеалларыбыз җиңүләренең иртәсе белән мәңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган көрәшләргә чакыра белергә тиешле»[1].

Шул рәвешчә, Һади Такташ иҗаты, бик катлаулы үсеш кичереп, татар совет әдәбиятының олы юлына чыкты. Социалистик чынбарлыкның иң әһәмиятле темаларына юнәлеш ала барып, шагыйрь милли классик шигъри традицияләр һәм үз чорының алдынгы рус поэзиясе казанышлары белән тыгыз бәйләнештә новаторлыкның гүзәл

---

[1] Күрсәтелгән җыентык, 241 бит.

үрнәкләрен калдырды. Татар совет поэзиясенең халыкчан гадилеген тагын да югарырак баскычка күтәргән һәм яна заман таләпләренә җавап биргән үз шигъри стилен тудырды. Бу стильнең нясе — безнең тормышка һәм совет кешесенә һәрвакыт кайнар һәм тирән ышаныч белән караучы лирик герой. Ул да социалистик җәмгыять һәм аны төзүчеләр белән бергә туктаусыз үсә килде. Шуңа күрә аның рухи һәм поэтик биографиясе бай да, катлаулы да. Такташ лирик герое — өзлексез эзләнүчән, тынгысыз һәм таләпчән шәхес. Аның эчке дөньясы уй-тойгыларының гаҗәп төрле, күп кырлы һәм хәрәкәтчел булуы белән аерылып тора. Әмма алар ачык, гади һәм туры. Такташ поэзиясе белән замандаш арасында тирән теләктәшлек бар. Мондый сыйфат исә шагыйрь идея-эстетик интересларының, чынбарлыкны сәнгатьчә аңлавының киң колачлыгы турында сөйли,— болар һәммәсе бергә Такташның художниклык таланты көчле һәм үзенчәлекле икәнлеген күрсәтә иде.

Татар поэзиясенең Тукайдан алып Җәлилгә кадәр булган тарихын бер ноктагарак җыеп карасак, гомумирак мондый бер нәтиҗә ясарга мөмкин: Габдулла Тукай безнең поэзияне халыкчанлык принципларында ныгытып, аны милли җирлегенә утыртты; һади Такташ исә татар поэзиясен тарихның зур революцион үсеше белән бәйләү юнәлешендә үстереп алып китте, ә Муса Җәлил инде аны явызлыкка буйсынмас совет кешесенең батырлык рухы белән үтәдән-үтә сугарды. Әлбәттә, мәсьәләнең болай куелышы схематик та, шартлы да кебектер. Әмма ул өч шагыйребез иҗатларында өстенлек алган һәм татар поэзиясенең язмышына хәлиткеч йогынты ясаган иң характерлы сыйфатлар итеп югарыда күрсәтелгәннәрне алу дөреслектән ерак булмас дип уйлыйбыз. Һичшиксез, алар иҗаты аша халыкчанлык, батырлык, гражданлык һәм гуманизм идеяләре безнең поэзиягә үзләренең какшамас тамырларын тирән итеп җибәрделәр һәм реализмның ныклы нигезен салдылар. Алардан башка татар поэзиясенең шундый югары сыйфатларын тулысынча күз алдына китерү мөмкин булмас иде. Ләкин моннардан әле һич тә Тукай, Такташ һәм Җәлил мирасларында гына татар поэзиясенең тулы байлыгы чагылды, ә алардан башкаларның роле кечкенә диган нәтиҗә чыкмаска тиеш. Әмма бу өч талантның,— татар поэзиясен олы юлга алып чыгуга хезмәт иткән башка шагыйрьләр эшчәнлеге белән һәм киң мәгънәсендә алдынгы әдәби традицияләр белән аерылмаслык булып берекан хәлдә,— безнең әдәбият тарихында югалмаслык эз калдырулары бәхәссез инде.

Һади Такташ, шобһәсез, безнең поэзиянең үткәне белән бүгенгесен һәм киләчәген өзелмәслек итеп бәйләгән талантларның иң күренеклеләреннән берсе булып калачак. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, аның «тавышы ерак еллар күкрәгендә янгырый алыр» һәм аның кешелекле җылы хисләрен, киләчәккә өмет белән тулы теләк-уйларын алып барыр.

Без беләбез сезнең киләчәкне,
Без беләбез сезнең киләсен,
Без беләбез соңгы күрәшләрнең
Безгә җиңү алып бирәсен! —

ди ул горур тавыш.

**Тәлгат Галиуллин**

# АЗАТЛЫК ҺӘМ ГУМАНИЗМ ПОЭЗИЯСЕ

Республикам минем, Татарстан,
Син тугансың — безгә сан булган.
Туфрагыңа Ленин кулы белән
Мәңге яшәү көче салынган.

*С. Хәким.*

**Татар совет поэзиясен Бөек Октябрь революциясе һәм яңа, социалистик чынбарлык тудырды. Табигатькә яңару, матурлык һәм ямь алып килгән яз шикелле, революция халык массаларында моңарчы күрелмәгән иҗат дәрте, мәдәнияткә, гүзәллеккә омтылыш уятты, алар күңелендәге шигърият чишмәләрен ачып-актарып җибәрде. Октябрь революциясенең югары идеал һәм омтылышларын үзенә сеңдереп, татар шигърияте азат халыкның ашкынулы хис-тойгыларын җырларга кереште.**

**Беренче адымнарыннан ук татар совет поэзиясе үз киләчәген ил язмышы белән бәйләде. Революция һәм гражданнар сугышы чоры да, илне индустрияләштерү һәм колхозлашу еллары да, фашизм коллыгына каршы көрәш дәвере һәм сугыштан соңгы чынбарлык та татар шигърияте үсешендә тирән эз калдырды, аның идея-эстетик принципларын камилләштерде, аны яңа үрләргә, кешелек сәнгатенең югары казанышы булган социалистик реализмга алып килде. Юлында нинди генә авырлыклар һәм киртәләр, текә таулар һәм чоңгыллар очрамасын, татар поэзиясе үзенең гуманистик позицияләреннән һәм азатлык идеалларыннан артка чигенмәде.**

**Вакыт иң гадел судья, диләр. Ярты гасыр вакыт эчендә татар поэзиясе узган тарихи юлны күздән кичергәндә, моңа аеруча нык ышанасың. Кайчандыр популяр булып, каш өстендә йөртелгән аерым әсәрләр, вакыт сынавын үтә алмыйча, тарих чүплегенә төшеп калганнар. Олы шигъри ачышлар, рухы белән киләчәккә ашкынган әсәрләр исә, киресенчә, еллар узган саен зуррак һәм масштаблырак була барганнар. Шул нисбәтән күңелне яңа татар поэзиясенең нигезе салынган гражданнар сугышы чоры һәм егерменче еллар поэзиясе халык хыялларына турылыгы, тарихи оптимизмы, күтәренке пафосы белән аеруча нык үзенә тарта.**

**Ялкынлы еллар поэзиясен, иҗат юлларын элегрәк башлап җибәргән М. Гафури, Г. Камаллар белән бергә, Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Б. Рәхмәт, Ш. Фидан һәм Йосфый кебек тормышның төрле катламнарыннан күтәрелеп азатлык дулкынында шигърияткә килгән яшь каләмнәр тудыра. Табигый талантлары, тормыш тәҗрибәләре һәм иҗади йөзләре төрле-төрле булган бу шагыйрьләрне уртак омтылыш, уртак хис якынлаштыра. Алар капитал дөньясының астын-өскә китергән иҗтимагый**

борылышның әһәмиятен, колачын, татар халкы тормышына алып килгән яңалыгын һәм революциянең гуманистик, иҗади рухын халыкка житкерү теләге белән яшиләр.

Революциянең үз сәнгатен, үз поэзиясен тудыру, бигрәк тә аның үзенә хас иҗат методы булдыру, формасын һәм стилен табу җиңел булмый. Дәвернең үзенә тиң яңа әдәбият нинди булырга тиеш? Яңа матурлыкның сәнгатьчә сынын ничек табарга? Ике дөнья арасында барган дәһшәтле көрәшне, канлы сугыш кырларында туган яңа геройны сурәтләгәндә, үткәннән килгән традицияләргә таянырга ярыймы? Тормыш шундый характердагы сорауларны бер-бер артлы тезеп кенә тора. Ә җавапны бирү дә алдан әзерләп куймаган.

Яңа чорга бәрабәр иҗат методын һәм яңа кешегә тиң әдәби геройны эзләү төрле юнәлештә бара. Социалистик реализм искелеккә каршы авыр идея-эстетик көрәш аша, модернизм, пролеткульт, раппчылык, ялган романтизм шаукымнарын җиңә-җиңә үзенә юл сала. Кыю иҗади ачышлар яңадан чигенүләр, авыр югалтулар белән чиратлаша.

Форма, стиль өлкәсендә яңалык эзләү, кирәгеннән артык «тырышлык» вакыты белән формализмга да китереп чыгаргалый. Г. Кутуй, К. Нәҗми кебек яшь шагыйрьләр рус декадентларының форма өлкәсендәге экспериментларын кабатлыйлар, футуризм, имажинизм кебек шәкли агымнар белән саташып йөриләр. Ләкин әлек-әлектән халык тормышы белән бәйләнеше нык булган татар поэзиясендә модернистик шаукымнар тирән тамыр җибәрә алмыйлар.

Әдәби мираска мөнәсәбәтләрендә яшь шагыйрьләр бер чиктән икенчесенә сугылалар. Берәүләре, традиция колына әверелеп, үткәндәге ачышларны кабатлау, яңа эчтәлекне иске форма ярдәмендә генә сурәтләү юлына кереп китсә, икенчеләре, пролеткульт, РАПП теоретикларының догмаларын кабатлап, мираска арка белән борылалар, яңа әдәбиятны буш урында тудыру хыялы белән шашынып йөриләр. Иҗат юлларын революциягә чаклы башлап җибәргән реалист шагыйрьләр исә Тукай васыятьләренә, фольклор традицияләренә турылыклы булып калалар. Бу яктан Г. Камал һәм М. Гафури поэзиясе аерылып тора. Реалистик башлангыч, оптимистик рух аларның канында, хисендә яши. Шуңа да М. Гафури иҗаты яшь талантларны үзенә тартып, рухландырып тора, мираска яңача караш формалашуга булыша, киләчәктәге кыю ачышлар өчен җирлек була.

Социалистик чынбарлык поэзиянең һәм эчтәлеген, һәм образлар системасын тамырдан үзгәртеп кора. Әлектән таныш әдәби типларны яңа кеше, чорның югары идеалына, изге максатына ахыргача бирелгән кызыл көрәшче алыштыра. Соңрак аның янына алдынгы эшче, игенче, хезмәт интеллигенциясе вәкиле килеп өстәлә. Тышкы һәм эчке дошманнарга каршы көрәш дәвамында ул яңа геройның психологиясе, холкы, фикерләү рәвеше үзгәрә[1]. Ләкин революцион чынбарлык тудырган шәхеснең рухи дөньясына үтеп керү, аның характерында борнап, чәчәк атып килгән яңа сыйфатларны, холкын-фигылен чагылдыру җиңел булмый. Шагыйрьләр иң әлек халык массасының җыелма, символик образын, Кызыл Армия сурәтен тудыралар. Поэзия халык образын гәүдәләндерүдән аның бер индивидын, аерым шәхесне, гомумидән конкретны сурәтләүгә күчә бара. И. Иосфыйның «Кызыл иптәшләргә», Ш. Фидаиның «Кызылармеецка», М. Гафуриның «Татар егетенә» кебек шигырьләрендә халыкның бер вәкиле — тарих ташкынының уртасына килеп кергән кызыл сугышчыны аңларга омтылыш ачык төсмерләнә. Хәзерге поэзия югарылыгыннан чыгып хөкем йөрткәндә, бу әсәрләрдә риторик сорау-эндәшләрнең, декларатив лозунгларның күплеге, анализның бөтенләй диярлек булмавы күзгә ташлана. Геройның үзенә генә хас сөйләме дә, индивидуаль йөзе дә юк сыман. Ләкин ул герой матур һәм батыр булуы, идеал-омтылышларының бөтенлеге белән укучыны дулкынландыра. Революция шагыйрьләренең әсәрләреннән көрәш дәрте, сугыш ялкыны бәрелеп тора, дары һәм кан исе килә.

Тагын шунысы бар: бу еллардагы поэзия әсәрләренең күпчелеге романтизм методына хас алымнар ярдәмендә язылган. Ни өчен бу иҗат методы авыр көрәш елларында алгы нәүбәткә чыккан соң? Чөнки романтизм сәнгатенең шартлы алымнары, куе төсләре һәм лиризмы дәһшәтле елларның рухына, ачы драматизмына, героик характерына аваздаш була. Икенче яктан, татар поэзиясендә, халык иҗатында романтик башлангыч, тормышны идеал аша сурәтләү әлек-әлектән зур урын тоткан. Ләкин

[1] Г. Халит. Яңа герой ничек туды. «Казан утлары» журналы. 1965 ел. 7 сан

революция романтизмның һәм эчтәлегенә, һәм формасына зур яңалык та алып килә. Шуларның берсен генә атап үтик. Мәгълүм булганча, революциягә кадәр иҗат ителгән романтик әсәрләрнең нигезендә алдынгы карашлы художникның алга, киләчәккә омтылган идеалы белән чынбарлык, сыйнфый җәмгыять арасындагы конфликт ята иде. Хәзер исә бу киртә алып ташлана. Шагыйрьнең илһамы героик тормышны, һәр төрле милли һәм социаль изүләрдән азат шәхесне, киләчәкне җырлауга юнәлә. Яңа эчтәлек, яңа эстетик тәҗрибә форманы да, шигъри сурәтләү алымнарын да үзгәртүгә китерә.

Гражданнар сугышы чоры һәм егерменче еллар башындагы революцион романтизмның көче дә, күләгәле яклары да Фәтхи Бурнаш иҗатында аеруча ачык төсмерләнә. Сизгер табигатьле шагыйрь чорның уңай героен бик тиз күреп ала һәм бөтен дәртен, яшьлеген кызыл көрәшче образын җырлауга багышлый. Ф. Бурнашның гражданнар сугышы чоры поэзиясен канатлы романтикадан башка күз алдына китерүе кыен. Романтизм аның өчен «үсеш һәм яшьлек чире» генә булып калмый, ә бәлки дөньяга карашының, талантының аерылмас бер сыйфаты да була.

Кызыл көрәшче образының революциягә бирелгәнлеген, дошманга чиксез нәфрәт хисен укучыга тулырак җиткерү нияте белән, Ф. Бурнаш романтизмның сыналган алымнарын эшкә җигә: вакыйганы һәм геройны калкытыбрак, чынбарлыктан өскәрәк күтәреп куя, куе эмоциональ төсләргә, лирик чигенешләргә, символикага киң таяна.

Дөрес, Ф. Бурнашның шигырь-поэмалары схематизмнан, шартлылык һәм прозаизмнан да азат түгелләр. Кызыл көрәшченең үзенә генә хас индивидуаль йөзе, фикерләү рәвеше, характеры еш кына ачылмый кала. Рухи дөньяның, эчке үсешнең, кичереш динамикасының бөтенләй диярлек бирелмәве Ф. Бурнаш героен рус әдәбиятында киң таралган «тимер яңаклы», «күн курткалы», киң җилкәле, олы гәүдәле норматив кызыл сугышчы образына якынайта. «Ф. Бурнашның һәм башка күпләрнең «типовой» сюжетка корылган поэмаларындагы кыз һәм егет образлары да бер-берсеннән аерым булган индивидуаль эчке сыйфатларга ия түгелләр»,— дип, Г. Халит бик дөрес яза[1].

Ләкин шагыйрьнең, революция эпосын, яңа чор дастанын тудырырга омтылып, кызыл сугышчыны героик-патетик югарылыкка күтәреп сурәтләве һәм чор романтикасына тирән үтеп керүе эзсез югалмады. Татар поэзиясенә романтик шагыйрь алып кергән иркен композицияле, сыйдырышлы, «миниатюр» поэма бүгенге яшь шагыйрьләр иҗатында тернәкләнеп, үсеп китте. Мәсәлән, И. Юзеевнең «Язылмаган поэма»сы шул традициядән үсеп чыккан уңышлы әсәрләрнең берсе.

Татар шагыйрьләре революциягә төрле әзерлек белән киләләр. Бөек борылышны һәркем үзенчә аңлый, яңа чынбарлыкның олылыгын, тарихи максатын үзенчә җырлый. Әдәбият белемендә «гыйсъянчылык» дип аталган юнәлеш вәкилләре, мәсәлән, беренче планга шәхес азатлыгы проблемасын куялар[2]. Ф. Бурнашның кызыл укчысы нигездә халык интереслары белән генә яшәсә, гыйсъянчы лирик-романтик «мин» аерым кеше бәйсезлеге өчен сугышка күтәрелә. Берсендә коллективизм рухы, икенчесендә индивидуалистик омтылыш үзәктә тора. Ләкин бу аерма алар арасындагы билгеле бер уртаклыкны да инкарь итми. Икесендә дә кабатланмас характеры, җаны, тойгысы булган кеше образы юк диярлек.

Гыйсъянчылыкның төп идеалы — вату, җимерү, үч алу, кан агызу. Гыйсъянчы шагыйрьләрнең романтик герое искелеккә, аллага, дингә һәм билгесез иҗтимагый явызлыкка каршы чыга, күккә, җиргә кизәнә, дөньяның астын-өскә китерү хыялы белән яна. Гыйсъянчылыкның бу омтылышы шул чор өчен характерлы һәм нигездә уңай күренеш иде. Ләкин материалистик карашның, политик платформаның ярым-йорты булуы аларны бер яклылыкка, схематизмга алып килә. Гыйсъянчы герой инкыйлабның яңаны төзүгә юнәлтелгән иҗади омтылышын бөтенләй диярлек күрми, игътибарны тезгенсез җимерүгә, стихияле көчләргә баглый. Үз шәхесе белән кирәгеннән артык мавыккан, халык массасыннан өстә торган бу гипертрофик геройның гуманизмы тормыштан ерак һәм абстракт яңгырый. Халык массасының тарихи ролен дөрес бәяләмәү аерым шәхесне идеаллаштырып сурәтләүгә, ихтыярның җәмгыять үсешендә тоткан ролен күпертеп күрсәтүгә алып килүе мөмкин иде. Вакыты белән ул шулай булды да.

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1965 ел. 7 сан. 101 бит.
[2] Татар совет әдәбияты тарихы. Казан. 1960 ел. 76—78 битләр.

Биредә сүз гыйсъянчылыкны тоташ каршылыклардан торган һәм шагыйрь шәхесен күккә чөюдән башканы белмәгән юнәлеш итеп калдыру турында бармый, билгеле. Х. Госман, Г. Халит, Р. Бикмөхәммәтов, Х. Хәйри һ. б. галимнәрнең хезмәтләрендә романтизмның бу катлаулы күренеше дөрес бәяләнде. Гыйсъянчылыкның төп бер сыйфаты — дини фанатизмга, аллаларга, фәрештәләргә һәм һәр төрле «ары яктан» килгән авторитетларга каршы көрәш, аларны тәхеттән бәреп төшерү — шул чор өчен гаять демократик, прогрессив роль уйнаган.

Дини символика, хыялый сюжет һ. Такташның башлангыч чор иҗатында бигрәк тә зур урын тота. Бу хәлнең мәгълүм сәбәбе дә бар. Шагыйрь революцияне шатлык белән каршыласа да, реаль матурлыкны, чорның яңалыгын тиз генә аңлый алмый. Вак буржуаз иллюзияләр, аерым шәхес батырлыгын идеаллаштыру аны катлаулы һәм чуар романтик форма белән мавыгуга алып килә.

Такташның романтик герое авыр эзләнүләр, сөрлегүләр аша революция алып килгән тормышка атлый. Бер урында ул юлында очраган каршылыкларны тар-мар китереп барган мәгърур кеше буларак ачылса, башка әсәрләрендә көчле характеры белән әле генә сокландырган герой кулын салындыра, пессимизмга бирелә, «мин адаштым, таба алмыйм юл» дип, сыкрана-әрни башлый...

Шигъри эпосның яңа сәхифәсен хезмәт темасы һәм эшче образы ачып җибәрә. Социалистик төзелешнең беренче адымнары белән рухлану, хезмәттә чын матурлык һәм югары әхлак чыганагы күрү, сыйнфый изү богауларын алып ташлаган азат шәхеснең иҗади эшенә соклану татар шагыйрьләре өчен бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы һәм илһам чишмәсе була. Хезмәт темасына кискен борылыш Татарстан җөмһүрияте төзелгән 1920 елдан башлана. Мәсәлән, шул елда К. Әмири, Ә. Сәгыйди һәм Ш. Фидаиләр бер үк темага һәм бер үк исем белән («Эшчегә») аталган яңа шигырьләрен язып чыгалар. Ш. Фидаи эшчене кызыл йолдызны сүндерү хыялы белән саташкан баронга, кара шайтанга — капиталга каршы көрәшкә чакырса, Ә. Сәгыйди исә дикъкатьне революциянең иҗади ягына юнәлтә, эшче белән игенче арасындагы якынлыкның, союзның зарурлыгын күрсәтүне максат итә:

Тот сөялле кул белән
Чүкечне, сук, сыксын тимер!
Шул тимерне сындырып,
Ачлыкларын барысын җимер!
Синнән игенче илендә
Шәп сукаларны көтә,
Шәп сабанарны көтә
Һәм чалгы-уракларны көтә.

Шул ук чорда Ф. Бурнашның «Татар пролетариатына», Н. Исәнбәтнең «Коммуна тимерлегендә» шигырьләре укучыга барып ирешә. Дөрес, яңа сыйныф кешесенең характерында туып килгән үзгәрешләрне, психологик нюансларны тотып алу, аның эчке дөньясына үтеп керү ансат булмый. Шул ук декларативлык, схематизм аяк чала. Ләкин эшче темасына игътибар салу поэзия үсешендә уңай роль уйный. Соңрак бу теманы тарихи планда өйрәнгән һәм татар эшчесенең революцион аңы үсешен киңрәк сурәтләгән әсәрләр дә языла башлый. Беренче юнәлешнең үзәгендә М. Гафуриның «Эшче» поэмасы торса, икенчесен әдәбиятка Х. Туфан алып килә.

Х. Туфан, «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Бибиевлар» шикелле хәзергәчә үз кыйммәтләрен югалтмаган эпик әсәрләре белән, татар поэзиясен яңа тәҗрибә, яңа географик мөхит белән баета. Борылыш елларының тенденциоз рухы, революцион дәрте аңкып торган бу әсәрләр шагыйрьнең яшьлек хисләре, тормышның чокыр-чакырлы юллары өстеннән аягын каната-каната атлаган беренче адымнары турында, Уралның мәһабәт, кырыс табигате, эшчеләр коллективы, аның азатлык өчен көрәш юллары турында сөйлиләр. Шагыйрь өермәле, кайнар тойгыларын, үзе әйтмешли, машинаны куып узган дәртле уйларын революцион көрәш романтикасын, азатлык идеалын җырлауга юнәлтә:

Әй сез, бунтлар, җил-туфанлы көннәр,
Өермәләр, утлар, вулканнар!

Яраттым мин сезне
Малай чакта,
Әллә романтикка,
Әллә йөрәк иләс булганга?..

Х. Туфан татар әшчеләре арасында революцион аңның үсешен, ике идеологиянең маңгайга-маңгай бәрелешен конкрет, кабатланмас образлар аша күрсәтә. Менә ордыбәрде Хабул, «соңгы мамонт кебек кызык» алаканат Минап, үзенчә фикерли торган Чапый, большевик Данил образлары... Һәркайсының үзенә генә хас язмышы, тормыш юлы, холкы-гадәте, хәтта тел үзенчәлеге бар.

Егерменче еллар уртасында Һ. Такташ иҗатында яңа матурлыкка таба кискен борылыш күренә. Шагыйрь, һәр төрле иллюзияләр, күк романтикасы һәм абстракт бунтарьлык белән арасын өзеп, дикъкатен социалистик яңарышка һәм чорның унай героена юнәлтә. Халык иҗатының, татар поэзиясенең иң камил традицияләренә, замандаш рус шагыйрьләре В. Маяковский, Э. Багрицкий ачышларына таянып, ул романтизм белән реализмның яңа синтезы аша социалистик реализм методына килә, шигъриятне югары идеяле, тирән хисле, сәнгатьчә нәфис әсәрләр белән баета һәм үз стилен, үз шигъри мәктәбен тудырып калдыра.

Такташның гыйсъянчы герое, характерын, рухын үзгәртеп, чынбарлыкка, иҗтимагый тирәлеккә мөнәсәбәтен, тормыш фәлсәфәсен һәм эчке дөньясын торган саен тирәнрәк ача бара. Бу үсеш 1924 елда иҗат ителгән «Давылдан соң», «Гасырлар һәм минутлар», «Еллар таңында», «Сыркыды авылы» шикелле шигырь-поэмаларда аеруча ачык төсмерләнә. Шагыйрь яңа җәмгыятьтә яшәячәк кешенең асыл сыйфатларын, характер үзенчәлекләрен, дөньяга карашын үзендә чагылдырган герой турында күп уйлана. Уйлану-эзләнүләр аны Ленин образына алып килә. «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы шул юлда шагыйрьнең иң зур ачышы иде.

Поэманың эмоциональ нигезендә Ленинның үлеме, дөньяның барлык намуслы кешеләрен тетрәткән авыр кайгы, хәсрәт тойгысы ята. Ләкин Такташ бу конкрет вакыйганы һәм ул хәрәкәткә китергән хисне тасвирлау белән генә чикләнми. Шагыйрь, хәтер канатында үткәнгә кайтып, эре шигъри сызыклар аша, Ленинны тудырган тарихи чорның төп үзенчәлекләрен ачып бирә дә, бүгенге җир шарына киң караш ташлый, бөек даһиен югалткан халык кайгысын, Ленин идеяләренең тантанасын сурәтли.

«Гасырлар һәм минутлар» поэмасында Такташның тылсымлы таланты үзенең яңа сыйфатлары белән ачыла. Шагыйрь романтизм сәнгатенең революцион чынбарлык алып килгән үзенчәлекләренә киң таяна. Романтизм аңа тормышны колачлырак итеп сурәтләргә, акыл кодрәтенә, кеше көченә дан җырларга, поэмага экспрессив тасвир алымнарын, кус төсләрне алып керергә мөмкинлек бирә. Такташның башлангыч әсәрләренә хас романтик экзотика, «серлелек» пәрдәсе алып ташлана, таныш булмаган ерак галәмне, аллалар, фәрештәләр дөньясын реаль җир шары, билгесез идеаллар өчен шашынып йөргән абстракт «Җир уллары»н халык баласы — Ленин алыштыра. Шагыйрь романтизмны публицистик хөкем ачышлары белән синтезлый. Бу — поэманың төп бер үзенчәлеге, Такташның зур эстетик ачышы.

«Гасырлар һәм минутлар» поэмасы Такташның замандашларына гына түгел, гомумән киләчәк буын шагыйрьләр иҗатына да тирән тәэсир ясаган әсәр булды. Татар шагыйрьләре Ленин образына, ул яшәгән чорга кат-кат әйләнеп кайттылар, Такташ сызган буразнаны дәвам иттерделәр, тирәнәйттеләр, киңәйттеләр. Шул җөмләдән С. Хәким иҗатына күз салыйк. Шигъри интонациясе һәм стиле белән Такташтан аерылып торса да, үзгәрәк юл белән атласа да, фикерләвенең киңлеге, тарихи чорга тирән үтеп керә белүе, революцион рухы, тенденциоз пафосы, романтик тасвир чараларына иркен таянуы белән, һәм күзгә күренми торган меңләгән җанлы җепләр белән С. Хәким шигырь-поэмалары да «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы традицияләренә килеп тоташа.

С. Хәкимне күп еллардан бирле бер мәсьәлә борчый. Безнең халык язмышында, аерым шәхесләр тормышында Ленин нинди роль уйнаган? Ленин һәм тарих, Ленин һәм халык проблемасының аерылгысыз бер кисәге булган бу тема «Ленин фәрманы белән», «Язгыз, җир уллары», «Күңелем Ленин белән сөйләшә» кебек әсәрләрдә шигъри тирәнлек һәм осталык белән гәүдәләндерелә. С. Хәким, тормышта, чынбарлык-

та булган вакыйга-хәлләрне алып, аларны хыял һәм талант көче белән тулыландырып, бастып, хәзерге чорның актуаль мәсьәләләрен күтәргән киң фәлсәфи уйлануларга килә. Тарихи теманы шагыйрь йөрәге, хисе аша уткәрә. Лирик интонация «Күңелем Ленин белән сөйләшә» шигырендә кичерешнең үзәгендә ята. Бу әсәр Такташ поэмасында сизелеп уткән «Ленин һәм мин» темасының яңача үстерелүе булып кабул ителә. Шагыйрь лирик җылылык, оптимистик рух, конкрет детальләр аша киң гомумиләштерүгә килә:

Без узарга тиеш, әй, юллар бар,  
Зур эшләргә чакырып ил дәшә.  
Юлга шулай чыгар алларыннан  
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Шул рәвешле, Такташ чәчкән орлыклар шифалы җиргә төшә, аннан яңа, гүзәл үрентеләр үсеп чыга...

Егерменче елларның икенче яртысын тулысы белән Такташ чоры дип йөртергә була. Аның һәр әсәре һәм проблемасы, һәм формасы белән ачыш санала, поэзиягә зур яңалык алып килә. «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай», «Алсу», «Киләчәккә хатлар»... Бу әсәрләрендә шагыйрь бер урында кырыс реализмга, икенче очракта тормыш романтикасының чагылышы булган канатлы романтизмга өстенлек биреп, кеше рухында, тормышта барган яңарыш процессын, табигый матурлыкны дәртләнеп сурәтли, киләчәккә киң караш ташлый. Ул шәхеснең интеллектына, хис-кичереш дөньясына яңа сукмаклар сала, татар теленең сурәтлелек көчен арттыра, эчке җегәренә үтеп керә. Такташ үз чорының социаль-этик һәм сәяси проблемаларына багышланган югары сәнгатьчә әсәрләр бирү белән илнең үсеш перспективасын күзалларга омтыла. Совет поэзиясенең гүзәл эпосы, шагыйрьнең иҗат васыяте булган «Киләчәккә хатлар» әсәрен шул омтылышның гүзәл бер үрнәге дип бәяләргә мөмкин.

1940 елда М. Җәлил Такташ поэзиясенә мондый бәя биргән иде: «Һ. Такташ поэзиясе үлемсез. Аның югары художестволы формада бирелгән, тирән эчтәлек белән сугарылган шигырьләре хәзерге көндә дә актуальлекләрен югалтмыйлар, алар күп миллионлы совет яшьләрен коммунистик рухта тәрбиялиләр. Һади Такташ иҗаты — безнең чордагы татар совет поэзиясенең иң югары ноктасы»[1].

Еллар узган саен Такташ поэзиясенең көче, яңачалыгы тирәнрәк ачыла бара. Хәзерге татар поэзиясендә аның традицияләрен читләтеп үткән шагыйрьне күрсәтүе кыен. Такташ шигъриятенең шифалы тәэсире И. Юзеев, Р. Әхмәтҗанов, Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллиннар иҗатында үзен аеруча ачык сиздерә. Шагыйрьнең чылтырап аккан чишмә суы шикелле саф, кешелекле юморы Ш. Галиев иҗатында күренә.

*  
* *

Иске тормыш килеп билен бөксен  
Чор тудырган яңа кешегә.

*М. Җәлил.*

30 еллар татар поэзиясе... Тарихка илне индустрияләштерү, авылны коллективлаштыру чоры буларак кереп калган уньеллыкта укучы күңеленә уелып куелырлык дистәләгән эпик поэмалар, кеше йөрәгенә, аның рухи дөньясына яңа сукмаклар салган йөзләгән лирик шигырьләр иҗат ителә. Халыклашкан җыр аерым жанр буларак формалаша, баллада ныклап аякка баса.

Җәмгыятьнең социаль структурасы үзгәрү, сыйнфый аерымлыкларны кимәтә барып, яңа тормышка ныклап аяк басу, авыл белән шәһәр, акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы аерымлыкны бетерү юлында ясалган җитди адымнар поэзиягә яңа коллизияләр, яңа сюжет-конфликтлар алып килә. Иң әһәмиятлесе шул: 20 еллар поэзиясе революция һәм гражданнар сугышы белән яшәсә, хәзер тормыш шигъри музаны

---

[1] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. 3 том. Казан. 1956 ел. 323—324 бит.

заман темасына, социалистик төзелешләр темасына юнәлтүне таләп итә. Кылычын чүкечкә, мылтыгын сукага яисә штурвалга алыштырган әдәбият герое үзенең тышкы кыяфәтен үзгәртү белән генә чикләнми, аның фикер сөрешендә, әхлагында, психикасында яңа сыйфатлар бөреләнә. Тормыш һәм чынбарлык турында яңа концепция урнаша, яңа тәҗрибә туа. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, халык аңының бер чагылышы булган поэзия дә, шагыйрь үзе дә зур үзгәреш кичерә. Әйтик, егерменче еллар башында язучыларны сыйнфый төркемнәргә, группаларга бүлеп йөртү модада иде. Хәзер исә моның зарурлыгы калмый. Бер үк авторның авыл темасына да һәм шәһәр темасына да караган әсәрләр язуы гадәти төс ала. Авылның ямьле табигате кочагында туып үскән Ф. Кәрим, мәсәлән, социалистик төзелеш темплары белән илһамланып, эшчеләр тормышына багышланган «Җиденче мич» поэмасын яза. Шагыйрь искелек белән көрәштә яңаның чыныгуын, хезмәткә кешелек тарихы белмәгән яңа мөнәсәбәт урнашуын, әгәр шулай әйтергә яраса, теманың эченә кереп, эпик киңлек һәм сәнгатьчә тирәнлек белән сурәтли. Берничә елдан соң Ф. Кәрим авыл темасын, колхозлашу хәрәкәтен үзәккә алган «Тавышлы таң» әсәрен иҗат итә. Аннары «Аникин» поэмасы басылып чыга. Соңгы әсәрендә инде шагыйрь киң сулыш, күтәренке рух белән халыклар арасындагы дуслык, интернационализм, туган илгә мәхәббәт идеяләрен сурәтли. Шулар өстенә Ф. Кәрим шәхеснең эчке дөньясын тасвирлаган гүзәл лирик шигырьләрен әледән-әле биреп бара. Кыскасы, совет шагыйренең иҗат диапазоны, шигъри горизонты киңәя, эрудициясе һәм культура дәрәҗәсе үсә.

Утызынчы елларда тормыш белән бәйләнешнең яңа формалары туа. Мәсәлән, бер төркем татар әдипләре, эшчеләр тормышы белән тирәнрәк танышу нияте белән, Донбасска юл тота. М. Гафури, Сибкомбайнстрой төзелешенең беренче ташын салу тантанасына катнашып, шуннан яңа очерклар, лирик шигырьләр алып кайта. Ш. Маннур илнең төрле заводларында бетончы, прокатчы булып эшли. Бу гамәли тәҗрибә татар поэзиясен «Колчеданлы таулар өстендә», «Чуен ташкыннар», «Бетончылар җыры» шикелле эпик әсәрләр белән баета.

Тормыш белән бәйләнешнең бу төренә мисалларны күпләп китереп булыр иде. Дөрес, «көн кадагына сугу», «фактлар теориясен» идеаллаштыру схематик, бер яклы, декларатив һәм производство темасына багышланган гади очеркка якын торган әсәрләрне дә дөньяга күп алып килә. Ләкин чор таләбен тоеп, социалистик төзелешләр пафосы белән дәртләнеп, яңаның чәчәк атуы өчен янып-көеп яшәү гомумән алганда мактауга лаеклы күренеш иде.

Язучыларның беренче съезды сүз осталарын партия һәм марксистик идеология тирәсенә берләштерү эшен тәгәлли. Татар әдәбияты Горький иҗатын, аның өйрәтмәләрен юл күрсәтүче якты йолдыз итеп ала. Бөек әдипнең социалистик реализм, типиклык, уңай герой, әдәби техника турындагы өйрәтмәләре, мирасны, халыкның сөйләм телен җиң сызганып өйрәнергә чакырган ялкынлы мәкаләләре татар шагыйрьләренең эзләнүләренә дә киң колач бирә. Мираска уңай мөнәсәбәт урнаша. Тукай традицияләре, халык иҗаты җәүһәрләре поэзиягә яңадан кайтарыла. Юлны бирелә дә М. Җәлил, Ф. Кәрим, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур шикелле яңага сизгер каләм осталары ерып бара. М. Җәлилнең бу өлкәдәге эшчәнлеге бигрәк тә игътибарга лаек. Шагыйрь «Совет фольклорын җыйнарга чынлап керешергә» исемле мәкаләсендә, әдәби дилетантизмга һәм ясалмалыкка каршы чыгып, халык әдәбиятын күбрәк халыкның үзеннән, бетмәс-төкәнмәс байлыкларны берничә чыганактан чумырып алырга чакыра.

М. Җәлил утызынчы елларда язылган әсәрләрендә халыкчан тирәнлеккә һәм осталыкка өйрәнүнең гүзәл үрнәкләрен биреп калдыра. «Алтынчәч» драматик поэмасында ул фольклорның иң борынгы катламнарын, тарихи мифологияне «терелтеп» җибәрә. Халыкның ирекле мәхәббәт турындагы мәңгелек хыялы тормышка ашуны сурәтләгән «Хат ташучы» поэмасын халык лирикасының нәфис һәм салават күпередәй төрле төсле нәкышле өлгеләре белән чигеп бара. Бу поэманы еш кына «Мәхәббәт турында гүзәл җыр» дип атыйлар, аны Мәҗнүн, Фәрһадлар гыйшкы турындагы классик әсәрләр белән чагыштыралар. Дөрес фикерне кабатлап тормастан, әсәрнең икенче бер сыйфатына басым ясыйсы һәм шуңа нисбәтән өйрәнелә торган чор поэзиясенең мөһим бер үзенчәлегенә тукталып үтәсе килә.

Совет әдәбиятының башка чорларындагы кебек үк утызынчы елларда да кешене социалистик рухта тәрбияләү, аның аңыннан искелек калдыкларын, «тумыш тапларын»

кысрыклап чыгару бурычы куела. Революция һәм гражданнар сугышы чорында кешене, беренче чиратта, тарихи атмосфера, тирәлек, азатлык өчен көрәш тәрбияләде. Утызынчы елларда исә яңа кешенең дөньяга карашын, иҗтимагый характерын аңлы һәм максатлы рәвештә, фәнни нигездә үзгәртү принцибы алга чыга. Шигърият үзенең телескобын шәхеснең рухи дөньясына, яңа яшәеш өчен барган дауны сурәтләүгә юнәлтә. Фольклорга һәм прогрессив әдәби традицияләргә мөрәҗәгать итүнең төбендә дә шул ук идеологик максат — тормышка якынаю, замандашның характерын, психологиясен тирәнрәк аңлау теләге ята иде. Кешенең йөрәк серләре, мәхәббәте һәм нәфрәте, сөенече һәм көенече турында уйланулар формасында язылган лирик һәм фәлсәфи парчалар күбәя. Пейзаж, мәхәббәт лирикасы тиешле урынны ала.

Билгеле, чор алып килгән үзгәреш-яңарышларга ул чакта тиешенчә исем бирү, аларның асылына төшенү процессы хәзер без уйлаганнан күп мәртәбә кыенрак бара. Үсеш авырлыгын Ф. Бурнаш, М. Җәлил, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй шикелле шагыйрьләр дә кичерәләр. Ф. Бурнаш, мәсәлән, егерменче еллар поэзиясенә хас купшылыктан, декларативлыктан арына алмыйча интегә, уңай һәм тискәре, искергән һәм яңа традицияләр арасындагы чикне сиземләмичә, инерция буенча язуын дәвам итә.

Җаны-тәне белән социализм төзү эшенә бирелгән һәм һәр мизгелдә үзгәреп-яңарып торган кешенең уй-тойгы дөньясын аңлау, рухи кичерешләре симфониясен бөтен тулылыгы һәм күркәмлеге белән сәнгатьчә чагылдыру М. Җәлилгә дә җиңел генә бирелми. Аның «Сәрвәр», «Җиһан» поэмаларында шәхес белән коллектив, яңа әхлак белән искедән күчкән гореф-гадәтләр арасындагы катлаулы иҗтимагый коллизия, әйтергә кирәк, беркатлырак чишелә. Яңа әхлак, яңа җәмгыятькә лаеклы җанлы кешеләрне югары әдәби осталык белән күрсәтүгә М. Җәлил «Хат ташучы» поэмасында ирешә.



* * *

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

*Ф. Кәрим.*

Бөек Ватан сугышы бөтен совет әдәбияты, шул исәптән татар шигърияте өчен дә җитди имтихан булды. Вәхшилеккә, кыргыйлыкка һәм урта гасыр караңгылыгына каршы гуманизм һәм патриотизм байрагын югары күтәреп көрәшкә чыккан совет әдәбияты, халык тормышы, ил язмышы белән бәйләнешен тагын да ныгыта төшеп, авыр сынауны намус белән үтте, җиңү көненә яңа идея-эстетик уңышлар белән килде. Сугыш чорында халык батырлыгына тиң йөзләрчә үлмәс әсәрләр язылды. Бу дәвер әдәбияты, художник омтылышлары белән халык идеаллары арасындагы бердәмлекнең югары үрнәге буларак, гасырларга үтәр, дастан-җырларга күчәр.

1941—45 еллар поэзиясен гадәти әдәби төшенчәләргә сыйдыру кыен. Кырыслыгы һәм дәһшәте буенча кешелек тарихында тиңдәше булмаган Ватан сугышы тормыш белән сәнгать, шәхес белән җәмгыять арасындагы шартлы киртәләрне алып ташлады. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, А. Алиш, Х. Мөҗәй, С. Хәким, М. Садри, Н. Арсланов, Г. Хуҗиев, Ш. Мөдәррис, З. Нури һәм биредә исемнәре аталмаган башка шагыйрьләр бер кулларына каләм, икенчесенә мылтык тотып ут һәм дәһшәт эченә ташландылар. Халык өстенә ябырылган афәт шагыйрьләрнең нәфрәт хисен кузгатты, аларның талантын яңа яктан ачты. Сәнгатьнең сизгер һәм җитез жанры булган поэзия яңадан әдәбиятның иң алгы сызыгына чыкты. Шигърият халык батырлыгының көзгесенә, елъязмасына әверелде. Ә. Исхакның «Канга кан», К. Нәҗминең «Фашизмга үлем», Ә. Ерикәйнең «Сугышка, иптәшләр», М. Садриның «Атлан, егет, акбүз атыңа» шикелле чакыру рухында язылган шигырьләренә сугыш чоры поэтик эпосының беренче битләрен ачып җибәрергә насыйп булды.

Фашизмга каршы көрәш елларында совет әхлагының, гуманизмның көче, тантанасы

бөтен тулылыгы белән ачылды. Барлык әдипләрне, совет сугышчыларын борчыган бу идеяне Ф. Кәрим «Мин — гуманист» шигырендә түбәндәгечә әйтә:

Фашистларны кем күбрәк кырса,
Ул үзенең туган илендә
Чын гуманист булып мактала,
Даны җырга күчеп кабатлана
Ирек сөйгән халык телендә.

Халыкның героизмын, җиңүгә ышанычын җырлау, Октябрь казанышларын саклап калуга чакыру шикелле гражданлык мотивлары, шагыйрьләрнең интим хисләре белән кушылып, поэзиянен яңа төрен — батырлык һәм йөрәк лирикасын тудырдылар. «Мәхәббәтем минем атакага бара»,— дип язды шагыйрь Ф. Кәрим. Баш очында палач балтасы асылынып торганда да, М. Җәлил сөйгәненә мөрәҗәгать итеп болай диде:

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгырем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.

Илдән киттем ил һәм синең өчен
Автоматым асып аркама,
Илемне һәм сине алыштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Бу шигырендә М. Җәлил йөрәк түрендә туган иң нечкә интим кичерешләрнең, патриотизм, югары гражданлык мотивларының яңа синтезына ирешә.

Сугыш еллары татар поэзиясенең иң илһамлы һәм үзәк темасы — ирекле һәм бәйсез туган ил, туган җир темасы булды. Ул шигърияткә хәтфә болыннары, иркен сулары, иксез-чиксез киңлекләре, чиккән яулык һәм өч почмаклы хатлары, сөйгәнен озелеп көткән чибәр кызлары белән килеп керде, үзенә бер җылы, лирик атмосфера тудырды, җиңүгә рухландырып торды. М. Җәлилнең «Яулык», «Юллар», Ф. Кәримнең «Бизәкле ал яулык», Ә. Исхакның «Татарстан уллары», С. Хәкимнең «Куллар» шикелле әсәрләрен генә искә төшерик. Алардан кешелеклелек рухы һәм туган илгә иксез-чиксез мәхәббәт хисе аңкып тора. Бу олы мәхәббәт исә халыкның иң якын һәм изге байлыгын аяк астына салып таптау хыялы белән котырынган фашизм чиренә нәфрәт уята, шәхеснең героик тойгыларына канат бирә.

Героик чынбарлык барча поэтик жанрларны да аякка бастырды. Мәсәлән, канлы сугыш елларында татар шагыйрьләре 20 дән артык поэма язалар. Аларның һәр кайсының үзенә хас интонациясе, юнәлеше бар. Ф. Кәримнең «Гөлсем», «Пионерка Гөлчәчәк», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы» шикелле лирик-романтик поэмалары фидакарьчә камиллекләре һәм кеше рухына тирән үтеп керүләре белән аерылып торалар. Ә. Фәйзинең Ленинград блокадасы геройларына багышланган «Туу сулышы» әсәре аналитик башлангычы, оптимистик рухы һәм фәлсәфи уйлануылары белән кадерле. Н. Арслановның «Рус кызы» поэмасы кеше нәфрәтенең көче һәм рухи үлемсезлекнең сере турында уйландыра. Ш. Мөдәррис язган «Тупчы Ваһап» дастаны сугыш чоры романтизмының гүзәл бер үрнәге булды. Совет патриотизмын дәртләндереп җырлауга багышланган бу поэмалар белән шигъриятнең теләсә кайсы дәвере горурлана ала.

Сугыш елларында кешенең матурлыгын һәм батырлыгын, идеалларының югарылыгын һәм омтылышларының сафлыгын калкурак итеп күрсәтергә мөмкинлек биргән героик баллада кебек романтик жанрның татар поэзиясе тарихында күрелмәгән югарылыкка күтәрелүе дә табигый. М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә», «Кызыл ромашкалар», Ф. Кәримнең «Идел», «Тимер һәм тимерче» балладалары совет кешесенең батырлыгын һәм горурлыгын романтик биеклеккә күтәреп җырладылар. Бу әсәрләрдә татар поэзиясенең демократик традицияләре, яңа тәҗрибә белән баетылган халык символлары, мотивлары, мифик бизәкләре яңача яңгырады. Поэзия, милли ачышларга таянып, халыкчан тамырларын ныгытты, офыгын киңәйтте һәм интернациональ киңлекләргә чыкты.

* * *

Бишьеллыкның бөек гигантлары
Һаман үсә,
Һаман күккә таба үрелә,
Башларыннан инде сез яшәгән
Коммунизм кыры күренә...

*Һ. Такташ.*

Соңгы ун-унбиш ел эчендә илебез тормышында зур иҗтимагый һәм экономик үзгәрешләр булды. Партиянең XX съезды хуҗалыкның бөтен тармаклары үсешенә яңа юнәлеш бирде, халык белән партия, аерым шәхес белән җәмгыять арасындагы ленинчыл демократик мөнәсәбәтләрне гамәлгә кайтарды. Кешелекнең иң гүзәл хыялы — коммунизм җәмгыяте хәзер реаль чынбарлыкка әверелә. Кеше рухы, кеше хисләре яңача үсеп дә үсеп генә!

Татар поэзиясенең дә офыгы, таралыш сферасы киңәйде. Иң мөһиме шул: шигырьнең халык тормышында, ил язмышында тоткан роле елдан-ел үсә бара. Поэзия чынбарлыкның катлаулы проблемаларын, кешенең алга, якты йолдыз кебек балкып, үзенә чакырып торган коммунизм идеалларына ашкынуын, Җир шарын борчыган иҗтимагый-политик конфликтларны, әхлак-этика мәсьәләләрен, үсешебезне тоткарлый торган күләгәле якларын кыюрак сурәтли башлады.

Поэзиягә хас гомуми күтәренкелек рухы жанрлар үсешендә дә ачык күренә. Бер мисал китерик. Сугыштан соңгы елларда, мәгълүм булганча, шигъри повестьлар күп язылды. Әдәбият һәм шигъри культура үсешенең яңа этабында тезмә белән язылган романнар иҗат итү мөмкинлеге туды. С. Батталның «Чирмешән буйларында», Ә. Давыдовның «Йокысыз төннән соң» кебек романнарыннан өзекләр дөнья күрде, татар поэзиясендә яңа жанр формалашты. Аларның үзәгендә татар кешесенең үткәнен, башка милләтләр белән бергә олы тарихи вакыйгаларга таба хәрәкәтен күрсәтү максаты ята. Аерым җитешсезлекләре булуга карамастан, халыкның иҗтимагый аңы үсә баруын тулы канлы образлар аша хикәяләгән бу әсәрләр татар поэзиясен күпмегәдер баетты, тулыландырды.

Чынбарлыкка яңа эстетик мөнәсәбәт баллада һәм поэма жанрлары үсешендә дә эз калдырды. Юмор белән сатира да күзгә күренерлек уңышларга ирешә бара. Тормышның күләгәле якларын ачыктан-ачык халык хөкеменә чыгарырга мөмкинлек биргән бу жанрның юлы киңәйде, иҗтимагый тормышта тоткан урыны үсте. Газета-журналлар һәм нәшрият көлке әсәрләренә урынны кызганмый башладылар. Сатирик поэзиянең үсешенә Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ә. Исхак, Ш. Мөдәррис, Ә. Давыдов, З. Нури шикелле шагыйрьләр һәр кайсы үзенчә яңалык алып килде. Бу сәнгатьтә яңа буын шагыйрьләр арасында З. Мансур, Г. Афзал, Ш. Галиев исемнәре аерылып тора. Тукай, Такташ, Җәлил традицияләрен дәвам итеп, халык иҗаты, халык теле җәүһәрләренә таянып, алар татар көлү сәнгатен яңа образлар, яңа интонацияләр, иҗат алымнары белән үзләренчә баеттылар.

Лирик поэзия өлкәсендә кызыклы үзгәрешләр күп. Чынбарлыкны шигъри сизмәүнең бу төп жанры кеше рухының олылыгын, катлаулы кичерешләр гаммасын, шатлыкны һәм кайгыны, сөенечне һәм көенечне самими һәм сәнгатьчә камил итеп сурәтләгән әсәрләре белән укучының мәхәббәтен һәм ихтирамын казанды. Г. Тукайның халык җырлары турындагы сүзләре хәзерге лирикага карата ифрат төгәл булыр иде. Лирик поэзия чын мәгънәсендә «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушан көзгесе» була бара. Шигърият шәхес киләчәге өчен тирән борчылган, бөтен кешелеккә шатлык һәм бәхет өләшү идеалы белән янып-көеп йөргән гуманист кеше образын тудырды. Бу урында С. Хәкимнең «Усал диләр мине...», «Әтнә урамында», «Бер горурлык хисе», «Юат син шуларны», «Озын чылбыр, бик күп бәжралар» шикелле әсәрләрен генә искә төшерик. Кешенең рухи үсеше социалистик идеалның гамәлгә ашуына, материаль җирлекнең ныгуына бәйле, ди шагыйрь.

Еллар мине усал иттеләр...
Бер көйләнсә тормыш, булса нык,

Әле шуны сизә башладым —
Кими бара икән усаллык.

Кеше өчен янып йөрү, аның язмышын йөрәк хисе аша үткәрү, киләчәккә тирән ышаныч Х. Туфан лирикасының да төп үзәге диеп була. Ул үзенең бер чыгышында «шагыйрь әсәрләрендә үз йөрәген, үз хисләрен ачып бирә белмәсә, кешенең рухи дөньясына да үтеп керә алмый» дигән иде. Бу — шагыйрь белән укучы арасындагы һәр төрле шартлылыкларны алып ташларга, читләшүне, бер-береңә ышанмаучылыкны бетерергә чакыру иде. «Каян алдың?», «Син дә көттеңме?», «Нишләтик сине, йөрәк?», «Кая шулай ашыгасың, йөрәк?» шикелле төрле чорда язылган, әмма хәзер бигрәк тә урынлы яңгыраган шигырьләрендә Туфан үз йөрәгенең кардиограммасын укучы кулына ышанып тапшыра кебек. Шул ук традицияне хәзерге яшьләрнең күбесе үстерә, дәвам итә.

Катлаулы һәм киеренке бу чорда аерым кеше язмышы ил, Җир шары язмышы белән тыгыз бәрекккән. Илнең киләчәге һәм бүгенге иминлеге аерым шәхесләр кулында. Шәхес бәхете — ил язмышында. Галәмдә барган һәр вакыйга өчен җаваплылык сизү поэзиянең рухи һәм тематик чикләрен киңәйтте, оптимистик яңгырашын көчәйтеп җибәрде. Бу фикерне соңгы елларда бик күп шигырь китапларына тупланган дистәләрчә әсәрләр раслый алыр иде.

Заман темасы — хәзерге поэзиянең җаны, бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы. Бу үзәк тема, көннән-көн матурлана, камил сыйфатларга байый килгән чордашыбызны сурәтләү темасы өлкән шагыйрьләр иҗатына да, яшьләргә дә сүнмәс-сүрелмәс дәрт бөркеп тора, аларның иҗади активлык рухын ныгыта.

Шигърият ул тере организм шикелле. Аның бер дәверен икенчесеннән аерып алуы кыен. Әһәмиятле ачышлар, укучыны уйландырган, дулкынландырган әсәрләр, уңай традиция буларак, алдагы чорга үтәләр, яңа йолалар тудыралар. Шуның өстенә төрле буын язучыларының игътибарын үзенә тартып торган, хисендә яшәгән һәм кайта-кайта эшкәртелердәй темалар була. Халык йөрәгенә агулы ук булып кадалган һәм XX гасырның иң зур фаҗигасе булган Бөек Ватан сугышы темасы, мәсәлән, шундыйлардан. Аңа сугыш газапларын үз җилкәләрендә күтәргән безнең бик күп солдат-шагыйрьләребез белән бергә сугыштан соңгы яшьрәк буын шагыйрьләре дә еш мөрәҗәгать итәләр.

Әдәби тәнкыйть соңгы еллар татар поэзиясендә гомуми фәлсәфи уйлану рухының, күләмлерәк һәм колачлырак итеп язарга омтылуның көчәюе турында еш һәм бик урынлы яза. Шул ук Х. Туфанның «Сәлам сиңа, тормыш», «Ә җир барыбер әйләнә», «Матур бу дөнья», «Син үзең бирдең» шигырьләре бу юнәлешнең ачык мисалы була алалар. Андый әсәрләрдә тормышны һәм кешене диалектик каршылыклары аша аңларга омтылу нәтиҗәсе булган аналитик фикерләү дә, масштаблылык та бар. Кыскасы, поэзия фәлсәфи-интеллектуаль киңлекләргә чыга.

Укучының эстетик зәвыгы үскән саен шагыйрьгә дә таләпләр арта бара.

Кызганычка каршы, безнең беришә шагыйрьләргә һәм әсәрләргә «әчке матурлык», әхлакый биеклек, югары культура һәм интеллектуальлек җитенкерәми әле. Башка халыклар поэзиясендә күптән мәгълүм хакыйкатьләрне зур ачыш итеп тәкъдим итү, бер үк темалар тирәсендә әйләнү үсешне, әлбәттә, тоткарлый. Безнең поэзия үрнәкләре ил, дөнья киңлекләренә дә сирәк чыга кебек. Ләкин поэзия үсешенә һәр вакытта да халык идеалы белән яшәгән, олы гражданлык хисе белән янган шагыйрьләр юнәлеш бирә килде һәм бирәчәк. Әдәбиятка яңа аяк баскан яшьләр иҗаты да шигъриятнең шундый киләчәгенә ышаныч уята. Бу яктан безнең хәзерге поэзия талантларга бай егерменче елларны хәтерләтә. Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Р. Харисов, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, М. Әгъләмов һәм Зөлфәтләр иҗатында заманга хас яңачалык, проблематиканы, лирик геройны сәнгатьчә тасвирлау принципларын баетырга, тулыландырырга омтылыш тенденциясе ачык төсмерләнә. Яшь шагыйрьләр Тукайның киң һәм тирән мирасына, Такташның кыю эзләнүләренә, Җәлилнең гражданлык лирикасына, Ф. Кәрим романтикасына, бөтен совет поэзиясенең экспериментларына таянып, үз тавышларын, үз моңнарын эзлиләр. Чынбарлык матурлыгы белән әдәби традицияләр арасындагы рухи якынлыкны, уртаклыкны эзләү, уйлану яшь каләм осталарының әдәби зәвыклары формалашу процессын тизләтә.

**Вахит Хаков,**
филология фәннәре кандидаты

# ӘДӘБИ ТЕЛ ХӘЗИНӘСЕНЕҢ КЫЙММӘТЛЕ ИСТӘЛЕГЕ

*XIII гасырда төзелгән бер сүзлек турында*

**Сөйләү теле кебек үк, төрки халыкларның язма телләре формалашу да бик борынгы заманнарга барып тоташа. Безнең эраның V йөзенә караган язма хатирәләренең табылуы әнә шул хакта сөйли[1]. Хәзер ул истәлекләрне өйрәнүгә бездә дә зур игътибар бирелә башлады. Бу аңлашыла да. Чөнки гомум төрки мирасны, гомум төрки тел чыганакларын җентекләп өйрәнгәндә генә татар әдәби теле һәм әдәбияты формалашу мәсьәләләрен фәнни нигездә хәл итәргә мөмкин.**

**Борынгы татар теле үзенчәлекләрен чагылдырган язма истәлекләр арасында төрле сүзлекләр аеруча әһәмиятле.**

**Биредә шул кадәресен дә әйтеп үтү урынлы булыр: сүзлекләрнең төзелүен борын-борыннан тормыш үзе таләп иткән. Сәүдәнең, экономик мөнәсәбәтләрнең үсүе төрле территорияләрдә яшәгән халыкларның бер-берсе белән аралашуына китергән. Бу аралашу исә халыклар арасында аерым телләрне өйрәнү һәм белү зарурлыгын да көн тәртибенә куйган. Борынгы сүзлекләрнең күбесе әнә шундый практик ихтыяҗлардан чыгып төзелгән. Шуңа күрә төрле глоссарийлар, тарихи сүзлекләр халыкның җанлы сөйләм телен чагылдыру ягыннан кыйммәтле истәлекләр булып саналалар.**

**Без бу мәкаләдә укучыларны XIII йөздә төзелгән шундый бер сүзлек белән таныштырып узмакчы булабыз. Ул «Төркичә-гарәпчә сүзлек» дип атала. Авторы билгесез. Хәзерге исәп буенча 1245 елның 28 гыйнварында төзелеп беткән. Моны кульязма азырындагы сүзләрдән күрергә була. Анда: «Бу әсәр шогбан аеның 27 нче көнендә якшәмбе көн 623 елда тәмам булды. Күчереп язучы Хәлил бине Мөхәммәд бине Йосыф эл-Кунави» дип язылган.**

**Аны беренче мәртәбә Голландия галиме М. Т. Хоутсма Лейденда саклангак кульязмасы нигезендә 1894 елда бастырып чыгара[2]. Шулай ук поляк профессоры А. Зай-**

---

[1] Төрки язмалар арасындагы беренче истәлек «Хуастуанифт» дип йөртелә. Уйгур шрифтында язылган бу истәлекнең аерым өлешләрен немец һәм инглиз телләрендә А. Лекок, рус телендә академик В. В. Радлов, С. Е. Малов, Л. В. Дмитриева бастырып чыгара.

[2] M. T. Houtsma. Ein türkisch-arabisches Glossar. Nach der Leidener Handschrift. Herausgegeben und erläutert von M. Th. Houtsma. Leiden.— E. I. Brill. 1894. Немец телендә.

Хәзерге көндә аның берничә данәсе генә сакланып калган. Биредә Ленинград китапханәсендәге нөсхәсе файдаланылды.

ончковский, филология фәннәре докторы Э. Нәҗип, казакъ теле белгече А. Курышжанов, төрек галиме А. Инан хезмәтләрендә дә бу сүзлек турында кайбер фикерләр очрый.

Сүзлек борынгы кыпчак кабиләләре телен чагылдыра. Шуңа күрә ул татар теле тарихы өчен әһәмиятле материал булып тора. Билгеле булганча, Идел буе татарлары һәм аларның теле формалашу шушы территориядә яшәгән борынгы җирле төрки кабиләләр белән тыгыз бәйләнгән. Һәм борынгы кабилә телләренең йогынтысы нәтиҗәсендә Идел буе төрки әдәби теле гасырлар буе байый һәм камиллашә килгән. Шул процесста билгеле бер кабилә диалекты хәлиткеч рольне үтәгән. Татар теле формалашуда мондый алшартларның берсе итеп кыпчак теле санала. Моны борынгы язма хатирәләр белән расларга мөмкин. Тикшерелә торган сүзлек тә шундый документларның берсе.

XIII йөздә кыпчакларның бер өлеше Идел буеннан Мисырга күчеп китә. Бу процесс, монголлар һөҗүменә кадәр үк башланып, Алтын Урда дәүләте төзелгәч тагы да көчәя төшә. Мисыр белән Алтын Урда арасында дипломатик мөнәсәбәтләрнең урнашуы гарәп һәм кыпчакларның үзара аралашуында зур роль уйный. Шулай ук Алтын Урда ханы Бәркәнең ислам динен кабул итүе бу ике дәүләтне бер-берсе белән тагы да якынайта[1]. Вакытлар үтү белән кыпчаклар Мисырда дәүләт-идарә эшләренә дә катнаша башлыйлар һәм армиядә җитәкче постларга күтәреләләр. Хәтта хөкүмәт белән җитәкчелек итүче династияләр барлыкка килә. Әмин әл-Холи күрсәтүенчә, 1250—51 еллардан башлап, Мисырда власть кыпчаклар кулына күчә. Солтан Бәйбарс, Калаун чыгышлары ягыннан кыпчак булалар[2].

Мисырга күчкән кыпчаклар (икенче төрле аларны мәмлүкләр дип йөртәләр) берничә гасырлар буе җирле халыкка культура ягыннан зур йогынты ясыйлар. Дәүләт күләмендә төрки тел өстенлек ала, шул телдә бай әдәбият туа. Гарәп укымышлылары һәм шагыйрьләре төрки телне (кыпчак телен) өйрәнгәннәр, ул телнең матурлыгын күргәннәр, әсәрләрен дә төрки телдә язганнар[3].

Без сүз алып бара торган сүзлек гарәпләр белән кыпчаклар арасында тел алмашуда беренче ярдәмлек булып хезмәт иткән. Һәм ул үзе дә Мисырда менә шул кыпчаклар идарәсе башлану алдыннан — 1245 елда төзелгән. Андагы сүзләр һәм тел үзенчәлекләре соңыннан Сараиның «Гөлстан»ында, шул чорда язылган башка әсәрләрнең нигезендә ята. Алтын Урдада һәм Мисырда әдәби телне һәм төрки әдәбиятны формалаштыруга кайсы күп, кайсы аз дәрәҗәдә хәзерге татарларның, Кырым татарларының, башкортларның, үзбәкләрнең, казакъларның, төркмәннәрнең һәм әзербәйҗаннарның борынгы бабалары катнашкан[4].

Инде турыдан-туры сүзлекнең эчтәлегенә кагылышлы мәсьәләләргә күчеп, Хоутсма чыгарган әлеге басмага күз салыйк. 7 битлек кереш сүздән соң китапның төп бүлекләре башлана. Беренче бүлектә (8—42 битләр) кыпчак теленең грамматик үзенчәлекләре турында языла. Икенче бүлектә сүзләр һәм аларга аңлатмалар бирелә (43—110 битләр). Һәр сүз башта гарәп шрифтында языла, аннан соң шул сүзнең транскрипциясе һәм немец теленә тәрҗемәсе бирелә. Аерым сүзләрне чагыштыру өчен Хоутсма «Коман мәҗмуга»сына да мөрәҗәгать итә. Лейден кульъязмасының тексты, ягъни сүзлек үзе М. Хоутсма китабының соңгы өлешендә бирелгән. Безнең өчен нәкъ шушы соңгы өлеше әһәмиятле дә.

Андагы гарәпчә һәм төркичә сүзләрне, ул сүзләрнең мәгънә төсмерләрен җентекләп тикшереп чыкканнан соң, М. Хоутсманың аңлатмаларында берникадәр төгәлсез-

---

[1] С. Закиров. Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом. Рус телендә. «Наука» нәшрияты. Мәскәү. 1966 ел. 4 бит.

[2] Амин эл-Холи. Связи между Нилом и Волгой. Гарәп теленнән тәрҗемә. 1962 ел. 10 бит; С. Закиров. Күрсәтелгән хезмәт, 35 бит; Л. А. Семенова. Салах ад-дин и мамлюки в Египте. Рус телендә. «Наука» нәшрияты. 1966 ел. 51 бит.

[3] Амин эл-Холи. Күрсәтелгән хезмәт, 31 бит.

[4] Э. Н. Наджип. Кыпчакско-огузский литературный язык... Москва. 1965 ел. 39 бит.

лекләр булуы күренә. Кайбер сүзләрнең мәгънәсен ялгыш аңлату яки лексик берәмлекләрнең барлык омонимик һәм полисемик вариантларын бирел җиткермәү кебек җитешсезлекләр очрый. Боларга казакъ теле белгече А. Курышжанов та игътибар итә [1]. Хәзерге тюркология фәне күзлегеннән чыгып карaганда, Хоутсма китабында транскрипциянең дә бөтенләй үк камил булмавын әйтергә кирәк.

Сүзлектәге тел үзенчәлекләрен, аерым сүзләрнең бирелешен, грамматик формаларны чагыштырып карау андагы сүзләрнең хәзерге татар теленә бик якын булуын күрсәтә. Бигрәк тә шул чордагы халык теле элементларын эченә алуы ягыннан бу ядкарь игътибарны җәлеп итә. Андагы күп сүзләр хәзерге әдәби телдә һәм диалектларда да сакланган. Әлбәттә, чорга хас тел аерымлыкларын (борынгылык күренешләрен, гомум төрки тел өчен характерлы билгеләрне, язма тел элементларын һ. б.) һич тә инкарь итәргә ярамый. Шунысы әһәмиятле, төркичә-гарәпчә сүзлек телнең лексик хәзинәсен чагылдыру белән генә чикләнми, бәлки гомумпланда борынгы телне күз алдына китерергә дә ярдәм итә, сүзләрнең үзгәрүләре, сөйләм нормалары, телдәге аерым грамматик формалар, кушымчалар турында да мәгълүматлар бирә.

Сүзләрнең кулланылулары ягыннан чыгып, төзүче үз хезмәтен дүрт өлешкә бүлә. Анда төрки исемнәргә, фигыльләргә, фигыльләрнең төрләнешенә, кушымчаларга багышланган бүлекләр аерылып чыга. Күләм ягыннан төп урынны сүзлек өлеше тәшкил итә. Әйтелеш һәм мәгънә ягыннан кайбер лексик берәмлекләрдәге үзгәрешләрне искә алмаганда, андагы сүзләр нигездә хәзерге татар телендә дә актив кулланылышта йөриләр.

Сүзлек тематик яктан тагын күп кенә бүлекләргә бүленә (Хоутсмада — 26, ә кулъязмада — 41). Аерым бүлекләргә кергән сүзләрнең барысы да бүлек исемнәренә туры килеп бетмиләр. Бүленешләрдә мәгънә ягыннан бөтенләй башка семантик төркемгә караган сүзләр дә очрый. Бүлекләрдә китерелгән сүзләрнең кайберләрен карап чыгыйк:

Күк җисемнәрен һәм шуңа бәйләнешле предметларны белдергән исемнәр: күк, ай, йолдыз, болыт, туман, йагмур, кар, боз, суык, йәшен, йылдырым, күкрәмәк [2].

Җир өстендәге предметлар: ком, таш, кыя, йар, йул, йорт, ишик, ачкыч, кииш, учак.

Су һәм аның белән бәйләнешле сүзләр: су, йырмак, булак (елга), күл, тирән, сай, ташкын су, акар су, балык, сөлек, караб, йилкән.

Агачлар, үсемлекләр, җимеш куаклары, яшелчә: агач, төб (төп), ботак, чыбык, йабрак (яфрак), чәчәк, алма, йөзем, куз (чикләвек), усак, тал, кайын, орман, кабак, карбоз, торма, кишер, суган — йува, сарымсак, гөләп, саз, бостан, тигәнәк.

Җир эше, чәчү белән бәйләнешле сүзләр: игин (иген), игинче, сабан, урак, тырмавыч, көрәк, арба, салам, орлык, богдай, борчак, тары, мәрҗәмак (ясмык).

Хәрби лексика: кылыч, кын, сөңге, калкан, йарук (латы), кебә, ашык (шлем), йәйә, кереш (тетива), ук, чукмар, ийәр, йөгән, тезген, нукта, камчы, кемелдерек (ядрә), чалыш-санчыш (сугыш).

Кошлар һәм алар белән бәйләнешле сүзләр: кара кош, лачын, шонкар, торна, каз, үрдәк, күгәрчен, чыпчык, карга, йабалак, сыгырчык, карлыгач, томшык, йомыртка, ойа, тозак.

Хайван исемнәре икегә бүлеп бирелә: ерткычлар һәм кулга ияләштерелмәгән башка хайваннар (аслан, каплан, сыртлан, төлке, бүре, барс, куйан, су-

---

[1] А. Курышжанов. К истории и критике «Тюркско-арабского словаря XIII века». Исследования по истории казахского языка. Рус телендә. Алма-Ата. 1965 ел. 9—24 битләр.

[2] Сүзләр транскрипциясез, нигездә хәзерге язылышта бирeләләр.

сар, тиен]; йорт хайваннары [эт, ат, айгыр, тай, колын, үкүз, бузагу (бозау], сыгыр, тана, куй, тәкә, кәҗә, тонгуз, чучка]. Аерым сыйфатлау сүзләренә дә мөрәҗәгать ителә. Мәсәлән, атларга карата буз, тимер буз, туры, кара, чобар, сары, кола йагыз (каракөрән], чал (ак], ала кебек сүзләр кулланыла. Төсне белдерүче сыйфатларда (ак, кара, кызыл, сары, күк-зәңгәр, йәшел] дәрәҗә билгеләре ачык төсмерләнә: кап-кара, кып-кызыл, сап-сары, йәм-йәшел, күз-күк (зәп-зәңгәр мәгънәсендә].

Һәр бүлек шул чорга иҗтимагый тормышның киң сферасына караган сүзләрне эченә ала. Бу сүзләр аша халыкның тормыш һәм яшәү шартларын, һөнәрен, җәмгыятьтәге иҗтимагый-экономик һәм культура мөнәсәбәтләрен сизенергә мөмкин. Кайбер бүлекләрдә халык арасында киң таралган ашамлык исемнәре (аш, шүрба, ит, куырма, итмәк, бал, айран, сөт, йүремчек, корт], тормыш-көнкүрешкә караган әйберләрнең исемнәре (мәсәлән, түшәк, йурган, кап, себерге, казан, кашык, илэк, уклагу (уклау], ут, кол, чакмак (чакма], чыраг (йактырткыч], бишек, сакыз, кабтан (кафтан], күнләк (күлмәк], чүбрәк, киндер, мамык, эчлек, буз һ. б.) бирелә. Сүзләрнең синонимик вариантлары да очрый: кушак, бил багы; башмак, эзлек (ягъни эз калдыручы]; тамак, бугаз һ. б.

Кеше организмы белән бәйләнешле сүзләр үзләре бер төркемне тәшкил итәләр. Мәсәлән: буй, түбә, сач, толым, буйын (муен], азуг (азу теш], култык, кул, терсәк, беләк, бармаклар (олы бармак, сук бармак, урта бармак, атсыз бармак, чичләк бармак], карыш, карын, балгыр, тубык, табан, ут, кан, тамыр, сеңер, сүңәк (сөяк], тир, гәүдә һ. б.

Сүзлектә бер бүлек саннарга багышланган. Кайбер фонетик үзгәрешләрне искә алмаганда санау тәртибе һәм саннарның бирелеше борынгы телдә дә хәзергечә үк булган.

Төп сүзләргә (алтын, көмеш, кургашын, корыч, ут, уймак, бычкы, үтүрге, беләү, кубыз һ. б.) аффикслар ялгау юлы белән профессия һәм һөнәрчелек исемнәре ясалган. Анда чы-че кушымчаларының гаять актив кулланылышта икәнлеге күренә. Мисаллар: битикче (язучы], утачы (дәвалаучы, табиб], йунгучы (балтачы, плотник], итмәкче (икмәк салучы], итче, сатчы (сатучы], йөкерче (йөгерүче], тукурчы (тукучы], икинче (игенче], кимәче (көймәче], буйачы (буяучы], сүнгече, йырлайчы (җырчы], кубызчы, йабчы (төзүче], илче, йүкүнче (наместник], текче (тегүче] һ. б.

Бер бүлек борынгы кеше исемнәренә карый: Байбарс, Котлыбарс, Колбарс, Айбарс, Алтыбарс, Ил бәге, Айтугды, Көнтугды, Айтимер, Коштимер, Биктимер, Котлыба, Айба, Кучбә, Айбик, Котлыбик, Актай, Тимерхан, Тимерташ, Алтынташ, Бикташ һ. б. Мондый кушма формадагы исемнәрдә төрле мәгънә төсмерләре чагыла: Котлы + ба — бәхетле бәк, Ай + ба // Ай + бик — ай төсле бәк, Куч + бә — көчле бәк, Котлы + бик — бәхетле бәк, Котлы + барс — бәхетле барс (пантер], Бик + таш — таш кебек бәк һ. б. ш.

Туганлык һәм кардәшлек мөнәсәбәтләрен белдерә торган сүзләр аерым бүлеккә кертелгәннәр. Мәсәлән: ата, ана, карендәш (ир туган], кыз карендәш, өйедәш (хатын], угыл, кыз, килен, кийәү (кияү], уги углан һ. б. Шулай ук ир, карт, йекет, кече углан (бала], агуз углан (имчәк баласы], иркән (буйдак], кунак, бәлеш, йат, йулдаш, тоткын, кол, кырнак (асрау кыз) кебек сүзләр дә шулар рәтендә карала.

Халык арасында киң таралган авыруларның атамалары һәм кешенең физиологик хәле дә сүзлектә урын алган. Мәсәлән: җан тартмак, котырмак, чобан (фурункуль], тилелек, үзйөрмәк (эч китү], иснәмәк, йанчыкмак (хәл китү], йөтермәк (йөткерү], эссетмә (лихорадка] һ. б.

Капма-каршы мәгънәләрне белдерүче сүзләр (антонимнар] бу язма истәлектә бер рынга туплап бирелгәннәр. Мисаллар: йакшы — чиркин (начар], йакын — йырак, йумарт — чукмар, алып (батыр] — алыг (куркак], тере — үле, игиз — йалгыз, бай — йуксыл, барлы — йуклы, атлы — йайау (җәяү], исрүк — айык, үст — аст, бүтүн — сынык, чын — йалган, татлы — ачы, суык — эссе, тулы — буш һ. б.

Сүзләр кушымчалар ярдәмендә дә бер-берсенә каршы куелганнар: сакаллы — сакалсыз, йасы — йасысыз, өсле — өссез, көчле — көчсез, күзле — күзсез, котлы — котсыз (бәхетле — бәхетсез].

Бер үк сүзләрнең төрле мәгънә төсмерләрен күзәтергә мөмкин. Тел гыйлемендә полисемик сүзләр дип йөртелгән мондый лексик берәмлекләрдә төп (номинатив]

мәгънә саклана. Ләкин, контекстагы кулланылышларына карап, аларда төрле мәгънә төсмерләре барлыкка килә.

Мәсәлән:

йир — җир (планета).
йир — урын.
йир — җирнең бер кисәге (участок).
борчак — чәчү культурасы.
борчак — күктән ява торган боз.
арка — кеше организмының бер өлеше.
арка — ярдәм.

Төрки телләрдә һәрберсе мөстәкыйль мәгънәгә ия булган аваздаш сүзләр — омонимнар да зур урын тоталар. Борынгы төрки тел традициясе рәвешендә дәвам итеп килә торган мондый сүзләрне күзәтү дә бик кызыклы. Менә аларның кайберләре:

корт — бүре.
корт — корт (бөҗәк).
ай — елның календарь бүленеше.
ай — күк җисеме.
курган — араи.
курган — ныгытма (крепость).
курган — кабер өстендәге чардуган.
ут — үлән (утау, утлау сүзләрендә саклана).
ут — янгын, яктылык мәгънәсендә.
йаш — күз яше.
йаш — яшь (аңа биш яшь).
йаш — өлгермәгән җимеш, яшелчә.
он — сан.
он — пешерү өчен әзерләнгән продукт.

Хәзерге телдә бу сүзләрнең кайберләре борынгы телдәге кебек үк омонимик мөнәсәбәттә тормыйлар: алар телнең эволюцион үсешендә мәгънә үзгәрешләренә тартылганнар яки, телдән бөтенләйгә төшеп, архаик формага әйләнгәннәр.

Лексик-семантик, тарихи-этимологик аспекттан чыгып карaганда, сүзлектә аерым сүзләргә хас үзенчәлекләрне очратырга була. Мәсәлән, тәңре, изге сүзләрен алыйк. Аларны ислам дине белән генә бәйләнешле итеп карау дөрес түгел. Чөнки алар төрки халыкларда ислам таралганчы ук мәҗүсилек чорыннан бирле кулланылалар. Татар телендәге зәңгәр, тәңре, күк сүзләре өчесе дә бер мәгънәгә барып тоташалар һәм тарихи планда синоним сүзләр булып каралалар. Зәңгәр төсне белдерә торган мәгънә аларның нигезендә ята. Зәңгәр, тәңре сүзләре аваз төзелеше ягыннан гына үзгәртелгәннәр. Тәңре сүзендә зәңгәр сүзендәге кебек үк төс мәгънәсе чагылган, соңыннан ул күктәге алла дигән төшенчәне белдерә башлаган. Кайбер төрки телләрдә зәңгәр сүзе урынында күк сүзенең йөрүе дә шуның белән бәйләнешле.

Изге сүзе борынгы телдә ийге формасында яхшы мәгънәсен биргән. Татар телендәге игелек сүзе шуңа ишарә итә. Беренчел мәгънә (яхшы) аерым төрки телләрдә хәзер дә сакланган. Ә татар телендә й һәм з авазларының күчеше нәтиҗәсендә бу сүзнең мәгънәсе дә үзгәргән. Мәгълүм булганча, тел үсеше процессында авазлар күчеше мәгънә үзгәрүдә зур роль уйный. Мәсәлән, үгсез (ятим), өйдәш (хатын), өйле (ягъни өйләнгән) сүзләрендәге үг — өй тамырлары — бер үк формалар. Мондый мисаллар һәм шуңа охшашлы башка үзенчәлекләр югарыдагы фикерне ачык раслыйлар.

Сүзлектә хәзерге татар әдәби телендә очрамый торган төрки сүзләр дә шактый. Сагым (мираж), кирән су (эчә торган су), кырбага (бака), йабылдырык (яфрак), үрбәкә (торма), сазган (дракон), кулан (билбау), сү (гаскәр), бусу (засада), тарару (үлчәү), базаркан (сәүдәгәр), агын (басып керү), әүдән (сәләтле, зирәк), төкмә (хәйләкәр), чиркин (яман), күсә (сирәк сакал), әкше (әче) кебек сүзләр шундыйлардан. Мондый сүзләр төрки телләргә хас аерым урынчылыклар белән бәйләнештә дә каралалар.

Төркичә-гарәпчә сүзлектә, кыпчак теле үзенчәлекләреннән тыш, угыз тармагына караган төркмән теле элементларына да урын бирелә. Күп очракларда алар кыпчак теле сүзләренә адекват рәвешендә кулланылалар. Мәсәлән:

| төркмән теле | кыпчак теле |
|---|---|
| гөбек | киндек |
| додак | ирен |
| егин | иң (җилкә) |
| күнес (гүнеш) | кояш |
| толу (долы) | борчак (бозлы яңгыр) |
| банбук | мамык |
| сөвүт | тал |
| корт | бүре |
| таушан | куян |
| сиңек | чебен |

Сүзлектә гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләр аз. Мәсәлән: сарай (йорт), караван сарай (караван йорты), дивар, шәһәр, анар (гранат), хөрмәт, баг (бакча), дәстәрҗә (борын яулыгы), кәгат (кәгазь), хуҗа, зыян, хамри (ак мәгънәсендә), базарган (сәүдәгәр)... Алар арасында фарсы теленнән кергәннәре күбрәк. Фарсы сүзләренең кайберләре кыпчак сүзләре белән параллель бирелгәннәр. Мәсәлән: алу//көкен (кара җимеш), банир//йүремчәк (сыр), жулаһ//токурчы (тукучы), дост//ынак (дус), каһал//армаву (ялкау), килим//чекмен (кием), калы//кәр (ковер).

Аерым сүзләрнең фонетик төзелешендә традицион, язма һәм башка төрки тел үзенчәлекләре күзәтелә. Сүзләрнең уртасында һәм ахырында W авазы урынына Г ның (йаглык, багыр, агыр, таг, йәйәг, аг, азуг теш), интервокаль позициядә г урынында к ның (үкез, сакыз, сикез, тукыз) кулланылуы, кайбер сүзләрнең уртасында й урынына г ның (сыгыр, түгмә), сүз ахырында саңгырау аваз урынына яңгырауның (колаг) булуы һәм башка үзенчәлекләр шулар рәтендә каралалар.

Сүзлектә сүз төркемнәренең төрләнешенә һәм фигыль формаларына шактый урын бирелгән. Боерык фигыльнең берлек санда гыл-гел, кыл-кел кушымчалары белән ясалган формалары очрый: укыгыл, белгел, суйгыл, эчкел, йандыргыл, ачкыл, кайткыл,ултыргыл, йиткел, башлагыл, баткыл, баглагыл, аглагыл (ела), утлагыл, тарагыл, санагыл. Күплек санда бу фигыльләр күп очракларда — кыз-кез кушымчаларын кабул иткәннәр (языңыз — язмаңыз). Хәзерге тел белән чагыштырып караганда, фигыльләрнең төрләнешендә артык зур үзгәрешләр күренми. Мисал өчен, үткән заман хикәя фигыльнең төрләнеш үрнәген китерик:

| | |
|---|---|
| йаздым | йаздыг |
| йаздың | йаздыңыз |
| йазды | йазды |

Ыр — ер — р кушымчалары ялганып, процессны белдергән сүзләр борынгы телдә хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсен белдергәннәр.

Мәсәлән: Йосыф дисә күзләреннән канлар агар,
Фиркать уты хәсрәт илә бәгърен ягар,
Висаль умар, өмид датар, кире бакар, —
Кавышмактан һич өмид кәсмәз имди.
(«Йосыф вә Зөләйха».)

Бу күренеш сүзлектә дә чагылыш таба. Чагыштыру өчен берничә мисал:

| Борынгы тел | Хәзерге тел |
|---|---|
| язармын | язам |
| язарсың | язасың |
| язар | яза |
| ат агнар | ат ауный |
| [illegible] чүкәр | дөя чүгә |

Күренә ки, татар телендә бу формаларда хәзерге заман төшенчәсе сакланмаган. Бары тик мондый семантик-грамматик үзенчәлекләрнең традиция рәвешендә хәзерге телдә стилистик максатларда кулланылу очраклары гына бар. Мәсәлән: «Актер йортында ул сәнгать турында иптәшләрчә сөйләшеп утыру өчен һәркайчан вакыт т а б а р. Әңгәмәдәшен игътибар белән т ы ң л а р, интересларының киң колачлы булуын күрсәтүче берничә үткен сүз ә й т е п к у я р». («Соц. Татарстан» газетасы.)

«...дугасыз җигелгән әйбәт атка у т ы р ы р, башын күккә күтәреп, дөньяга борын тишекләре белән карап б а р ы р. Бер адым җәяү а т л а м а с.» (Г. Әпсәләмов.)

Сүзлектә я з г а й формасының киләчәк замандагы эшне яки хәлне белдерүе турында әйтелә. Башка тарихи язма истәлекләрдә дә моның ачык чагылышын күрергә мөмкин. XVI йөздә язылган «Төхфәи мәрдан» әсәреннән бер мисал:

Сән яхшылык кыл, яхшылыкта бар мәзә,
Кем яманлык кылса,— ул т а п к а й җәза.
Кем егылганда кулын тот бер моңлының —
Ул тәкый т о т к а й кулың бер көн синең...
Изгелек хакын б е л г ә й л ә р,—
Илкедин килгәнчә изге к ы л г а й л а р.

Сүзлектә сүзләр бәйләнешенә караган үрнәкләр белән дә танышырга була. Мәсәлән: сәңа әйтермен, сезгә әйтермен, аңа әйтермен, анларга әйтермен, безгә әйтерсез, алгыл моны, китергел моны һ. б. Җанлы сөйләмдә инверсион тәртип киң урын ала: эчкел бу суны. Йигел бу итмәкне (хәзерге телдә: аша бу икмәкне) һ. б.

XIII йөздәге тел үзенчәлекләрен чагылдырган тәрҗемә-гарәпчә сүзлектә моннан тыш күп кенә характерлы якларга тукталырга мөмкин булыр иде. Хәзергә кадәр хәл ителеп җитмәгән проблемаларны, кайбер томанлы мәсьәләләрне ачыклауда сүзлек әһәмиятле роль уйный. Ниһаять, татар теленең нинди кабилә телләре җирлегендә үсеп килүен раслау өчен бу язма хатирә кыйммәтле чыганаклардан санала. Шуңа күрә киләчәктә аны җентекле рәвештә өйрәнү татар телендәге аерым нормаларның тарихи-эволюцион үсешен объектив күзалларга ярдәм итәчәк.

# ҖЫР ӨЙРӘТТЕ МИНЕ ХӨР ЯШӘРГӘ

Утызынчы еллар татар җыр сәнгатенең чын мәгънәсендә чәчәк ату чоры булды. Бу, әлбәттә, иҗтимагый күтәрелеш, халык тормышының яңадан-яңа сыйфатлар белән баюы һәм шул рухи күтәренкелек шартларында иҗат дәрте белән янып яшәүче яшь композиторлар төркеменең барлыкка килүе белән бәйле күренеш иде. Моңа, һичшиксез, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе ачылу да ярдәм итте.

1929 елдан алып Бөек Ватан сугышына кадәр композиторлар тарафыннан 180 ләп җыр иҗат ителгән. Шуларның 96 сы Муса Җәлил һәм Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган (һәрберсенә 48 әр җыр туры килә). Димәк, бу чордагы җыр сәнгатенең, җыр поэзиясенең уңышлары һәм кимчелекләре турында сөйләгәндә сүзне күбрәк шушы ике шагыйрь иҗаты тирәсендә алып бару кулайрак булыр төсле. Чөнки шул заманның йөзен билгеләүче популяр һәм характерлы җырларның яртысыннан күбрәге алар өлешенә туры килә.

Муса Җәлилнең 1919—20 елларда язылган шигырьләре арасында гражданнар сугышы темасын чагылдырган «Төрле җырлар», үрдәк бәбкәләре саклаучы балалар авызыннан әйтелә торган «Тилгән» исемле такмаклар очрый. Ә 1929 еллардан башлап исә шагыйрь махсус рәвештә җыр текстлары язарга тотына.

Билгеле булганча, М. Җәлил бу елларда Мәскәүдә чыга торган «Октябрь баласы» журналының редакторы булып эшли. Журналның музыка бүлегенә исә Латыйф Хәмиди җитәкчелек итә. Муса Җәлил сүзләренә башлап музыка язучы кеше дә шушы яшь композитор була. 1929—32 елларда, аларның иҗади дуслыгы нәтиҗәсе буларак, ун җыр язылып, шуларның тугызы «Октябрь баласы» һәм «Ударниклар» журналларында басылып та чыга.

Җырларның күбесе октябрят һәм пионер яшендәге балаларга багышланган. Бу табигый күренеш, чөнки, беренчедән, Муса Җәлил иҗатының башлангыч чорында балалар әдәбияты өлкәсендә активрак эшләде, икенчедән, журналның кечкенәләр өчен чыгарылуы да биредә хәлиткеч рольне уйнаган булса кирәк. «Октябрь баласы»нда басылган җырлы уеннардан «Күрсәт әле!», «Куян» әнә шул хакта сөйлиләр.

Бу җырлы уеннар халык авыз иҗатына нигезләнеп язылулары белән аеруча кызыклы. Мәсәлән, «Күрсәт әле!» уенында түгәрәк ясап әйләнүче балалар уртада торучыдан: «Күрсәт әле, Камали, ничек утын яралар?» яки «Күрсәт әле, Кәримә, ничек чаңгы шуалар?» дип сорыйлар. Түгәрәк эчендә торучы, җырлаучыларга җавап итеп, утын яру, чаңгы шуу хәрәкәтләре ясап күрсәтә. Ә «Куян» исемле җырлы уенда балаларның берсе «куян» булып башкалардан кача. Балалар: «Куян, куян, син кайда?» дип, җыр белән эзлиләр. «Куян» качкан урыныннан «мин яшел болында» яки «мин ерак далада», «мин куе урманда» дип җавап кайтара. Аны беренче табучы бала үзе «куян» була һәм уен яңадан башлана. «Ленин турында» (1932), «Октябрь җырлары» (1929), «Көз җитте» (1929) җырлары да кечкенәләргә адресланган.

Латыйф Хәмиди белән Муса Җәлилнең иң яхшы җырлары яшьләргә, комсомолларга багышланган. Шундыйлардан «Юнгштурм» (1930), «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы» (1930), «Уңыш бәйрәмендә», «Беренче вальс», (1930), «Күңелле яшьләр» (1932) һәм «Кызыл очкын җыры», утыз ел элек язылуларына да карамастан, бүген дә яшьлек дәрте бөркеп торулары, күтәренке рухлы булулары белән җанга рәхәт биреп, күңелдә җылы хис кузгатып яңгырыйлар. Яшәү шатлыгын чагылдырулары, оптимистик рухта булулары белән алар утызынчы елларда туган иң яхшы совет җырлары рәтендә торалар.

Татар опера студиясенә килүгә Муса Җәлил композиторлар белән яңа иҗади элементларга керә һәм җыр поэзиясе жанрында тагын да активрак эшли башлый. Аның иҗатына Мансур Мозаффаров, Заһит Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов кебек композиторлар ешрак мөрәҗәгать итә башлый. Яшь композиторлардан Хөснул Вәлиуллин һәм Исмай Шәмсетдинов та беренче җырларын Муса Җәлил сүзләренә язалар. Бу елларда шагыйрьнең 28 яңа әсәре музыкага салына, элегрәк басылып чыккан тагын өч шигыренә көй языла. Хөснул Вәлиуллинның «Комсомолларга» (1937), Мансур Мозаффаровның «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы» (1937), Фәрит Яруллинның «Колхоз кызына» (1936) җырлары музыкага салынган текстларга кабат мөрәҗәгать итү төсендә иҗат ителгәннәр.

Яңа җыр текстының тууы төрле очракта төрлечә була. Кайбер шигырьләрен Муса Җәлил композиторларга үзе тәкъдим итсә, икенчеләрен композиторлар үз теләкләре яки студия заказы белән язганнар. Мәсәлән, 1937 елда Татар опера студиясе, композиторлар һәм җыр текстлары язучы шагыйрьләрнең иҗатын тагын да җанландыра

төшүне күздә тотып, берничә иҗади заказ ясый. Октябрь революциясенең 20 еллыгы уңае белән үткәрелгән конкурска Муса Җәлил тугыз текст тәкъдим итә. Аларның дүртесе инде музыкага салынган була, ә калган бишесенә — «Сагыну» (З. Хәбибуллин), «Ватан җыры» (М. Мозаффаров), «Карашларың», «Батыр егет турында» (З. Бичурин), «Сталин турында җыр» (М. Латыйпов) — музыка беренче тапкыр языла.

Муса Җәлил хезмәте белән балалардан ераклашкач та кечкенә гражданнар тәрбияләү мәсьәләләре белән кызыксынуын ташламый. 1934 елда ул «Совет балалар әдәбиятына иң нык игътибар» дигән мәкаләсендә балалар әдәбияты, балалар өчен җырлар язу мәсьәләләре татар совет язучыларының беренче съездында махсус тикшерелергә тиеш дип чыга. Муса Җәлил балалар өчен язылган җырларны очраклы күренеш дип карамаска, киләчәктә композиторларны кечкенәләр өчен җырлар гына түгел, бәлки системалы рәвештә җыентыклар, цикллар иҗат итәргә чакыра.

Җәүдәт Фәйзи «Беренче альбом» дигән мәкаләсендә Муса Җәлилнең 1935 елның язында гади, җиңел, шул ук вакытта зурлар өчен дә кызыклы балалар җырлары иҗат итү идеясе белән янып йөрүен сөйли. Шагыйрь шул вакытта Җәүдәт Фәйзигә «Пионерка Мәмләкәт турында җыр» һәм «Чаңгы шуганда» исемле ике шигырь алып килә. Ләкин аларга язылган көйләр композиторның үзенә дә, шагыйрьгә дә ошап бетми. Шуңа күрә эш тукталып кала. 1936 елның язында алар бергәләп иҗат итүләрен тагын яңартып җибәрәләр һәм алты җырдан торган «Беренче альбом» төзелә.

Альбомга урнаштырылган сүз башында Муса Җәлил болай дип яза: «Бу җырлар барысы да безнең икебезнең дә тема һәм аны ничек итеп бирү өстендә, сүз белән музыканы органик бәйләү өстендә өзлексез бергә эшләвебезнең җимеше булып тудылар. Без сүздә дә, музыкада да мөмкин кадәр гадилек, халыкчанлык, җиңеллек һәм аһәңлелекне сакларга тырыштык».

«Беренче альбом» мәктәпкәчә яшьтәге балаларга адресланган була. Аңа хайваннар һәм кошлар турындагы җырлардан «Күке», «Әтәч», «Карак песи» кертелә. Шагыйрьнең фикере буенча, «Чишмә», «Шмидт бабай» җырлары балаларда хезмәткә мәхәббәт, илнең мактаулы кешеләренә хөрмәт уятырга, ә «Беренче дәрес» җыры исә аларны укуга дәртләндерергә тиеш була. Шунысын әйтергә кирәк, «Беренче альбом»дагы җырлар безнең көннәрдә дә киң таралганнар һәм укучылар тарафыннан яратып тыңланалар. Бигрәк тә «Чишмә» һәм «Карак песи». Муса Җәлил сүзләренә «Сәгать», «Маэмай» (Җ. Фәйзи), «Маэмай» (Ф. Яруллин), «Чишмә», «Парашютсыз курчак» (М. Мозаффаров) кебек тагын берничә җыр язылган.

1941 елда Мансур Мозаффаров элек Фәрит Яруллин тарафыннан файдаланылган «Яз җыры» текстына яңа музыка яза. Соңрак, сугышның беренче көннәрендә, Муса Җәлил сүзләренә Фәрит Яруллин тарафыннан «Соңгы көрәшкә», Нәҗип Җиһанов тарафыннан «Ватан өчен» исемле җырлары иҗат ителә. Болардан соң «Хат ташучы» радиопостановкасына Мансур Мозаффаров язган «Хат ташучы җыры» дөньяга чыга да, шагыйрьнең исеме музыка сәнгатеннән озак вакытка югала.

Утызынчы елларда татар җыр сәнгатенең барлыкка килүе һәм үсүендә Муса Җәлилнең роле һичшиксез зур. 1929—41 елларда шагыйрь тарафыннан илледән артык махсус җыр текстлары язылган. Шуларның кырык икесе кырык алты вокаль әсәргә поэтик чыганак булып хезмәт иткән[1].

Әлбәттә, җырларның һәммәсе дә бер үк кыйммәткә ия түгел. Алар арасында абстракт, нинди вакытка караганы билгесез булганнары (мәсәлән, «Моряклар» җыры Челюскинчылар тәэсирендә язылган, ләкин тексттан аны белеп булмый), альбом шигырьләре («Карашларың»), яки поэтик яктан өлгереп җитмәгәннәре дә («Сәгать») очрый. Тик Муса Җәлилнең күп кенә җыр текстлары сәнгать әсәрләре буларак кыйммәтле һәм алар мөстәкыйль яшәргә дә хаклы. Күбесенең безнең көннәрдә дә яшәве әнә шуны раслый.

Шунысын истә тотарга кирәк, бу чорда җыр жанрының тематикасын киңәйтүгә дә Муса Җәлил шактый тырышлык куя. «Туган ил», «Ватан җыры», «Ленин турында», «Сталин турында», «Кырларга, суларга», «Беренче вальс», «Конституция турында җыр», «Колхоз кызына», «Күк юрга», «Батыр егет турында», «Кызыл очкыч җыры», «Соңгы көрәшкә» кебек җырларның исемнәрен генә атап чыгу да Муса Җәлилнең, шагыйрь һәм гражданин буларак, җыр сәнгатенә җитди карағанлыгы турында сөйли.

Шагыйрьнең лирик шигырьләре дә игътибарны беренче чиратта тематик төрлелекләре белән җәлеп итәләр. Бу җырлар кеше рухының бөеклеген, хисләрнең катлаулы төсмерләрен оста чагылдырулары, мәхәббәтнең көчен үзенчәлекле һәм кабатланмас шигъри бизәкләр аша әйтеп бирә алулары белән аерылып торалар. Муса Җәлилнең җыр сөючеләргә бүген дә яхшы таныш булган «Яз җыры», «Яшьлек җыры», «Кызыма», «Бишек җыры», «Ана җыры», «Сөю җыры», «Карашларың», «Сагыну», «Җиләк җыйганда» кебек җырларын әнә шул күзлектән чыгып бәялисе килә.

Утызынчы елларда композиторлар, җыр текстының сәнгатьчә эшләнеш ягыннан камиллектән бигрәк, аның музыкага җиңел һәм уңайлы салынуын гына таләп иткәннәр дип әйтү, әлбәттә, бик үк дөрес булып бетмәс. Чөнки тематик һәм жанр төрлелегенә омтылу үзе үк җыр текстына кайбер аерым таләпләр куйган.

Бу чорда татар музыка сәнгатендә беренче тапкыр марш ритмындагы әсәрләр языла. Аларның күбесе, әлбәттә, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан йомшак, байтак маршларда авторлар татар халкының пунктир

[1] Утызынчы елларда язылган җыр текстларының кайберләре музыкага соңрак салынган. Мәсәлән, «Чишмә җыры». Ә кайберләре исә («Санитар җырлары», «Комсомол бригадасы җыры», «Язгы яңгыр», «Туган ил», «Безнең җыр», «Кытай пионеры турында», «Конституция турында җыр») көйгә салынмаганнар.

ритмлы музыкасының формаль якларын гына алганнар, нәтиҗәдә бу әсәрләр «каләм сынау» дәрәҗәсеннән күтәрелә алмаганнар [1]. Шундый кимчелекләре булуга да карамастан, яшь композиторлар тарафыннан язылган бу маршларда чорның колоритын, яшьлеккә хас ашкынуны күрмичә булмый [2].

Марш жанрын үзләштерә барып, утызынчы елларның урталарында татар композиторлары популяр патриотик җырлар иҗат итү дәрәҗәсенә күтәреләләр. Шундый җырлардан аеруча Җәүдәт Җәйзинең «Шауласын, гөрләсен безнең җыр» (Әхмәт Ерикәй сүзләре) һәм Мансур Мозаффаровның «Туган ил» (Әхмәт Ерикәй сүзләре) әсәрләрен күрсәтеп үтәргә кирәк.

Шунысы характерлы, үзенең бу җырына кадәр Мансур Мозаффаров Муса Җәлил сүзләренә «Ватан җыры»н иҗат итте һәм анда халык арасында киң таралган рус революцион җырларының кырыс колоритын һәм көчле яңгырашын бирергә омтылды. Бу әсәр зур уңыш казанмаса да, аның өстендә эшләү композиторга яңа темага мөрәҗәгать итү, аны сәнгатьчә ачу юнәлешендә тәҗрибә тупларга ярдәм итте.

Совет кешеләренең бәхетле яңа тормышына дан җырлаучы әсәрләр күбрәк марш яки такмак жанрында язылсалар да, композиторлар үз-үзләрен кабатларга, жанр үзенчәлекләре кысасында гына чикләнеп калырга теләмиләр. Мәсәлән, Заһит Хәбибуллинның «Без — яшь көчләр» (Әхмәт Ерикәй сүзләре) җыры — яшьлек дәрте ташып торган марш булса, Латыйф Хәмидинең «Уңыш бәйрәмендә» әсәре (Муса Җәлил сүзләре) — яшәү шатлыгы, яктылык бөркеп торучы вальс, Мансур Мозаффаровның Мөхәммәт Садри сүзләренә язган «Сайра, сандугач»ы — бию элементлары белән тыгыз үрелгән хәрәкәтчән, күңелле җыр, ә Заһит Хәбибуллинның «Чишмә янында»сы (Әхмәт Ерикәй сүзләре) — лирик җыр.

Шулай итеп, утызынчы елларда, җырларның тематикасы киңәю белән бергә, аларның жанр төрлелеге дә арта. Әгәр дә Ватан, яшьләр, хезмәт турындагы җырлар башлыча марш жанрында язылсалар; бәхетле тормыш, колхоз тормышы, шулай ук шат яшьлек турындагы җырларның байтагы халыкның салмаграк темптагы лирик җырлары рухында иҗат ителгәннәр. Мондый төрлелеккә ирешүдә Муса Җәлилнең бай поэзиясе уңайлы җирлек булган.

Яңа темаларга, яңа образларга мөрәҗәгать итү татар җырының традицион чараларын яңартуны таләп итә. Татар композиторларының музыкаль теленә яңа көнкүрешне эмоциональ образлар аша гәүдәләндергән яңа интонацияләр һәм ритмнар килеп керә. Текстның сәнгатьчә эшләнеше никадәр югары булса, аның музыкага тәэсире дә шулкадәр көчлерәк була.

Текст белән музыканың сәнгатьчә тиешле югарылыкта торулары, үзара тыгыз бәйләнеше Заһит Хәбибуллинның «Сагыну», Мансур Мозаффаровның «Җиләк җыйганда» әсәрләрен татар җыр классикасы дәрәҗәсенә күтәрделәр. Композиторларның һәр икесе дә Муса Җәлил сүзләрендәге эмоциональ төсмергә, хиссиятка тиң музыкаль яңгыраш таба алганнар. Җырларның икесендә дә халыкка хас моң бар, бу аларны чын мәгънәсендә халыкчан иткән. Сүз уңаеннан шунысын да әйтергә кирәк, «Сагыну» һәм «Җиләк җыйганда» күптән инде халык җыры булып китте.

Утызынчы елларда татар композиторларының эзләнүләре шул чорның динамикасын чагылдыруга, заманның рухын бирергә омтылу белән бәйләнгән. Мондый җырларга уңышлы мисалларны Латыйф Хәмидинең Муса Җәлил сүзләренә язган әсәрләре арасыннан күпләп табарга мөмкин. «Күңелле яшьләр», «Юнгштурм», «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы», «Беренче вальс» һәм башка җырларда композитор Муса Җәлил шигырьләрендәге «яшь йөрәкләр ялкынын» уңышлы чаралар белән бирә.

Мәсәлән, композитор «Күңелле яшьләр»дә үсә баручы мажор тавышларга таяса, «Беренче вальс» татар җырында вальс ритмын куллануның беренче үрнәге булып тора [1]. Беренче карашка гади генә күренгән бу җырда эчке энергия, сыгылмалылык көчле. Андагы хәрәкәт стихиясендә актив төстә үсә алу мөмкинлеге яшеренгән. Композиторның музыкаль теле ул чор өчен кыю һәм яңа. Аның җырларында ярдәмче бизәү чаралары булган кереш тоннар еш очрый. Ул еллардагы татар музыкасының гомуми хәлен исәпкә алсак, бу зур яңалык. Музыкада еш кына йөгерек пассажлар ишетелеп кала, аның болай динамик һәм дулкын-дулкын булып яңгыравына фортепьянода башкарылу өчен язылуы да ярдәм иткән.

Шулай итеп, Муса Җәлил поэзиясе утызынчы еллардагы җыр сәнгатендә, тематик төрлелек белән бергә, музыкаль теленең баюына да ярдәм иткән.

Утызынчы елларда шагыйрьнең җыр сәнгатенең үсешенә керткән өлеше зур. Балалар өчен чыгарылган журналларның редакторы, Татар опера студиясендә әдәби бүлек мөдире буларак, Муса Җәлил җырларның тематикасын киңәйтү юнәлешендә зур тырышлык күрсәтте. Заман темасына күтәренке лирик җырлар иҗат итте. Балалар җыры сәнгатен тудыручыларның берсе булды. Муса Җәлил, шулай итеп, татар җыр сәнгатенең тууы һәм үсүенә зур өлеш кертте.

**Йолдыз ИСӘНБӘТ.**

---

[1] Моңа кадәр Г. Хайбулкин, Ф. Яруллин, С. Сәйдәшевның инструменталь маршлары гына билгеле була.

[2] Калган маршлардан бу чорда С. Сәйдәшевның «Шлем» пьесасына язылган «Кызылармеецлар җыры» (1929) һәм «Совет яшьләре җыры» (1932) сәнгатьчә югарылыклары белән аерылып тора.

[1] Музыка кораллары өчен язылган иң беренче татар вальсларыннан С. Сәйдәшевның 1918—1920 елларда фортепьяно өчен язган «Татар вальсы» санала.

Гөлшат Зәйнашева

# КӘКҮК



Әйдәгез күңелебез белән ямьле Агыйдел буйларына, Актаныш якларына юнәлик. Бер матур җәйге иртә. Күктә алтын шар сыман мәһабәт кояш балкый. Һава саф, әкрен генә йомшак җил искәләп куя. Күк йөзе чип-чиста, зәп-зәңгәр. Җырларда макталган, борылып-борылып аккан гүзәл Агыйдел. Агыйдел дулкыннарының серле шавын тыңлап, ямь-яшел тугайлар җәйри. Мең төрле хуш исле чәчәкләргә күмелгән яшел тугайларга кушылып иген кырлары сузылган. Иген кырлары бу якларда, диңгез кебек, очсыз-кырыйсыз. Офыклар бу якларда еракка-еракка китеп югала.

Арыш кыры. Куе булып тишелгән игеннәр буйнга утырып килә. Арыш кыры өстендә тургай сайрый, якындагы әрәмәлектә кәкүк кычкыра. Арыш арасыннан сузылган тар гына юл буйлап өстенә ак ситсыга вак кына чәчәк төшкән җиңел, гади күлмәк, аягына шундый ук гади чүәкләр кигән җитез адымлы, кечкенә, ыспай гәүдәле яшь ханым бара. Ул үзе кебек үк гади, ләкин курчаклар кебек матур, чиста итеп киендергән, берсе ун-унбер, икенчесе дүрт-биш яшьләрдәге ике кыз җитәкләгән. Ап-ак яулыгы астыннан чыгып, ханымның маңгаена кап-кара чәчләре сибелгән, йөзе, кояшта янып, кара кучкыл төскә кергән, җиңел-җиңел атлап, әле бер, әле икенче кызына борылып карый-карый нәрсәдер күңелле итеп сөйли, елмая. Елмаеп-көлгәндә аның ап-ак төшләре күренеп китә...

Бу — җырчы Әлфия Афзалова. Ул туган яклары Актанышка ялга кайткан, үзенең Гүзәл һәм Зөлфия исемле кызларын җитәкләп җиләккә бара. Кырым, Кавказ курортларына да барганы бар аның, әмма ләкин еш кына ул җәйге ялында туган якларына кайта, туган ягының иген кырларында йөри, туган туфрак һавасын сулый, туган як болыннарының хуш исле чәчәкләрен җыя, сайрар кошларының моңнарын тыңлый, Агыйдел суында коена, кызларын җитәкләп әрәмәләргә, урманнарга җиләккә бара, якташлары, бергә уйнап үскән дуслары белән очраша, аларның хезмәтләрен, үстергән игеннәрен күреп куана. Республикабызда мул уңыш үстереп макталган актанышлыларның яңа матур тормышын күреп кайту, минем күңелемә көч, җырларыма яңа дәрт өсти, ди Әлфия Афзалова.

Җыр дөньясына ул моннан 18—19 еллар элек килеп керде, әлеге Агыйдел буйларыннан, ямь-яшел тугайлардан, иген кырларыннан күңеленә халкыбызның саф моңнарын төяп, әнә шул аклы ситсы күлмәге кебек җанга, йөрәккә якын, үз булып килеп керде ул. Хәзер инде Әлфия Афзалова Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең танылган җырчысы, Татарстанның атказанган артисткасы.

...Әлфия Афзалова 1933 елда Башкортстанның Калтасы районы Яңа Кабан авылында туа. Актанышта үсә. Балачагы аның ятимлектә үтә. Әлфиягә нибары дүрт яшь булганда әнисе үлеп китә. Әлфия әнисе Миңнеямал апаның бик мөлаем, ягымлы



йөзен, үзәк өзгеч моңлы тавыш белән әкрен генә көйләп йөргәннәрен бик аз гына хәтерли.

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы әтисе Афзал аганың да гомерен бик иртә өзә. Әнисенең авыз эченнән генә моңаеп көйләүләре, әтисенең чабата ясаганда җырлаулары, матур чигеш кебек, Әлфиянең нәни күңеленә мәңгегә уелып кала.

Сугыш еллары. Ятимә кызлар тормыш бусагасы каршында япа-ялгыз торып калалар. Ләкин ятимәләрне үз куеннарына алып җылытучы, аларга тормыш бусагасыннан атлап китәргә ярдәм итүче күркәм күңелле кешеләр табыла. Әнисенең бертуган апасы Закирә апа килеп, ятимә кызларны Актанышка алып китә. Закирә апа (Әлфия аны Җыракай дип йөртә, ягъни ерак әнкәй дигән сүз) кулыннан килгәнчә тырыша, кызларга тернәкләнеп китәргә, аякка басарга ярдәм итә. Шулай да кечкенә Әлфиягә, үзенең кечкенә сеңелесе белән бергә, балалар йортында да яшәргә туры килә. Кызлар үсәләр, мәктәптә укыйлар. Әлфия үзенең үткенлеге, эшкә уңганлыгы, шаян, шук, җырга-биюгә оста булуы белән аерылып тора. Икенче, өченче класста укыган чагында ук ул матур итеп татар һәм башкорт халык көйләрен җырлый башлый.

Укытучы апалары Нәфисә Акмалова, Гөлсәйдә Фәттаховалар Әлфия күңелендә онытылмаслык җылы истәлек калдырганнар. Нәфисә апасы җыр ярата торган укытучы булган. Әлфия мәктәптәге беренче җыр дәресен әле дә хәтерли. Әлфиянең җырлавын класс тын алмый тыңлаган. Күрше классларда дәрес бирүче укытучылар да йөгереп кергәннәр. «Үзе бәләкәй генә, кара әле нинди көчле тавыш белән моңлы итеп җырлый бу бала!» — дип, хәйран калганнар. Әлфиянең иң беренче җырлаган җыры «Карлыгач» пьесасыннан Карлыгач исемле кыз җыры була. Аннары укытучы апасы аңа Җәүдәт Фәйзинең Муса Җәлил сүзләренә язылган «Карак песи» исемле җырын өйрәтә. Мәктәп концертларында гына түгел, Әлфия бала чагыннан ук Актаныш клубы сәхнәсендә җырлый башлый, бер генә концерт та, бер генә олимпиада да, агитбригаданың бер генә чыгышы да аның катнашыннан башка үтми. Халкыбызның борынгы озын көйләрен дә, кыска, шаян көйләрне дә, совет чорында туган күңелле җырларны да башкара ул.

1945 елда күренекле язучы Риза Ишморат Бөек Ватан сугышы кырларыннан кайта һәм туган ягы Актанышка ялга юнәлә. Актанышта ул яшүсмер кыз Әлфиянең матур җырлавын тыңлап соклана:

— Талантыңны югалта күрмә, сеңелем, Казанга килергә, җырчы булырга тырыш. Мин, Казанга кайткач, синең турыда тиешле кешеләр белән сөйләшермен, килсәң, урнашырга ярдәм итәрмен,— ди.

Риза абый чынлап та сүзендә тора, Әлфия турында филармония җитәкчеләре белән сөйләшеп куя.

1950 елда Актаныш районында үткәрелгән үзешчәннәр смотрында Әлфия Афзалова җыр буенча беренчелекне ала һәм бөтен гомерен, тормышын, сәләтен җырга, сәхнәгә багышларга дигән карарга килә.

Ә Актанышның шул еллардагы район комсомол комитеты секретаре Марселиза Гаҗетдинова Казанга, комсомолның Татарстан өлкә комитетына барып, Әлфияне Зөләйха Әхмәтова җитәкчелегендәге җыр һәм бию ансамбленә чакыруларын үтенеп кайта. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясеннән килгән артистлар да

Әлфияне күреп алалар һәм аңа Казанга килергә, укырга, өйрәнергә, җырчы булырга киңәш бирәләр.

Ниһаять, 1951 елда Әлфия Афзалова Казанга килә, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә солистка булып эшкә керә. Ансамбльнең танылган җитәкчесе Зөләйхә ханым Әхмәтова Әлфияне хорда, ансамбльдә җырларга өйрәтә. Аерата игътибар белән Зөләйха ханым Әлфиядән беренче музыкаль күнегүләр, сольфеджиолар җырлата, аны музыка грамотасы белән таныштыра. Тавышының чиста, йомшак тембрлы, халыкчан моң белән сугарылган булуы, ишетү, тыңлау сәләтенең, хәтеренең яхшылыгы, тәс-бит, килеш-килбәтенең мөлаемлыгы белән Әлфия Афзалова тиз арада ансамбльнең төп көченә әйләнеп китә. Хорда бергәләп җырлау белән бергә, ул башлап җырлый һәм концертларда ялгыз җырлаучы буларак та чыгышлар ясый башлый.

Әлфия зур музыка дөньясына беренче адымнарын шушы ансамбльдә атлый... Беренче адымнар... Зур сәхнәдә беренче адымнарны атлау җиңел булмый: каушата да, куркыта да, дулкынландыра да. Хорда коллектив белән бергәләп җырлау бер нәрсә, ә менә зур концерт залларында ялгыз гына җырлап кара! Сине йөзләгән тамашачылар күзләп, тыңлап утыра. Син аларга нинди яңалык, нинди матурлык, нинди эстетик ләззәт бүләк итә алырсың? Шуларны уйлап, күңеле белән эзләнгәндә, аңа үзе яраткан җырчыларының матур, моңлы тавышы ишетелеп киткәндәй була.

Әлфиянең кечкенә вакытыннан ук яратып тыңлап үскән җырчылары кемнәр соң? Иң әүвәл һәм барыннан да бигрәк, Гөлсем Сөләйманованың иркен сулыш белән, күкрәк түреннән кайнап чыккан көчле тавыш белән борынгы көйләрне җырлагандагы моң агышына хәйран калып үсә ул. Халык көйләренең бөтен нечкәлекләрен тоеп, нәкъ халык хыялындагыча, чын мәгънәсендә милли колорит белән җырлаган Гөлсем Сөләйманова кебек җырлый алсаң иде дип хыяллана Әлфия. Сумкасын тотып мәктәптән кайтып килгәндә дә, көянтә-чиләкләрен чыңлатып чишмәгә суга барганда да, инеш буенда кер чайкаганда да, иптәш кызлары белән кырга, колхоз эшенә булышырга барганда да ул җырлап-көйләп йөреп, Гөлсем апа моңнарын кабатларга тырышып, көйдәге матур, нәфис бормаларны аныңча алырга омтылып үсә. Шулай ук танылган җырчылар Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйроваларның халык көйләрен матур итеп җырлауларын үзенә үрнәк итеп куя. Әмма ләкин үзеннән өлкән буын җырчылар — Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйроваларны кабатлап кына музыка һәм сәнгать дөньясына яңа сүз, яңа моң белән килеп булмый. Үз сүзең, үз йөзең, үз моңың белән килергә кирәк.

Дөрес, аның тавышы Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйровалар тавышыннан үзенә бер аһәң белән аерылып тора. Аның тавышы берәүне дә кабатламый торган, күңелгә ятышлы, табигый йомшак тембрлы. Музыка теориясе теле белән әйткәндә, Әлфия Афзалованың тавышы меццо-сопранога тартым, шул ук вакытта альтка да тартымрак, халык теле белән әйткәндә, артык калын да, артык нечкә дә түгел. Аның тавыш диапазоны киң, иркен, ул түбән тавышларны да, югары тавышларны да бернинди көчәнүсез иркен ала. Шулай да Әлфия Афзаловага үз иҗат йөзен табарга кирәк була. Һәм ул эзләнә. Баштарак аның иҗаты эстрада җырчысы, эстрада артисткасы буларак ачыла башлый. Ул шул юнәлештә үз өстендә эшләргә керешә. Халык көйләрен җырлау белән беррәттән, композиторлар әсәрләрен, тугандаш халыкларыбыз җырларын өйрәнә башлый. Табигый таланты, табигый тавышы өстенә Әлфиягә үзлегеннән укырга, өйрәнергә, тырышырга кирәк була. Дөрес, аңа махсус музыка уку йортларына кереп укырга туры килми. Нота грамотасын үзлегеннән өйрәнү, гомуми белемен күтәрү аңа бик кыенга килә, шулай да Әлфия югалып калмый, укый, өйрәнә. Үзенә чын мәгънәсендә иҗат итәргә, үсәргә, профессиональ артистка булып җитәргә ярдәм иткән кешеләрне Әлфия зур хөрмәт белән йөрәгендә саклый. Татарстанның атказанган артисткасы Разия Тимерханова, Татар дәүләт филармониясенең элекке директоры Михаил Федорович Боголюбов, элекке художество җитәкчесе, хәзерге лекторий җитәкчесе Рәйсә Кәримовна Волковалар Әлфиягә зур сәхнәгә күтәрелергә чын күңелдән ярдәм иткәннәр. Рәйсә Волкова зур тырышлык, сабырлык белән Әлфиягә музыка грамотасы өйрәтә, аңа махсус дәресләр бирә, аның тавышын формалаштыру өстендә эшли. Ә тавыш өстендә эшләү ул — бик җаваплы хезмәт.

Әлфия Афзалованың тавышында, бигрәк тә беренче елларда, ниндидер вак кына

калтырау, дерелдәү сизелеп куйгалый торган була, ләкин еллар үтү белән Әлфия, зур тырышлык куеп, бу кимчелекне бетерә, аның тавышы ныгыганнан ныгый бара.

Солтан Габәшинең «Кәкүк» исемле җыры (Ә. Ерикәй сүзләре) Әлфиягә сәнгатькә үз сүзе, үз йөзе, үз моңы белән килергә башлангыч юл ача. Әлфия Афзаловага кадәр күренекле җырчы Гөлсем Сөләйманова зур осталык белән башкарып, халыкка таныткан бу атаклы әсәр Әлфия башкаруында яңа яңгыраш, ниндидер дулкынландыргыч, омтылышлы яңгыраш ала. Гөлсем Сөләйманова башкарган «Кәкүк» җыры үзенчә күркәм булса, Әлфия Афзалова башкарган «Кәкүк» үзенчә бер матурлык белән яңгырый. Әлфия Афзалова Гөлсем апа эзеннән килә, аның традициясен дәвам итә, һәм шул ук вакытта Гөлсем апаны коры кабатлаучы булып кына түгел, аның иҗатына яңа заман аһәңнәрен өсти, аның моңнарына үз моңнары аша килә. Нәтиҗәдә «Кәкүк» җыры эчке бер шатлык, олы мәхәббәткә өндәүче, тирән кичерешле әсәр булып яңгырый һәм Әлфияне зур иҗат юлына юнәлтә.

Сәхнә хезмәтенең беренче адымнарыннан башлап, Гөлсем Сөләйманова шикелле үк, Әлфия Афзалова да халык көйләрен һәм халык көе планында язылган композитор әсәрләрен җырлый. Музыка белгечләре бу җырчылар турында һәм мондый җырларны башкару осталыгы турында бәлки әле киләчәктә махсус мәкаләләр язарлар, чөнки халык көйләрен, гасырлардан-гасырларга күчеп сакланып килгән халык хәзинәләрен бөтен байлыгы белән күңел түреннән тибрәтеп җырлаучыларыбыз — безнең өчен кадерле кешеләр.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай әйткәнчә, «халык җырлары халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер». Халык көен чын мәгънәсендә халыкчан итеп башкару өчен җырчының эчке, рухи кичерешләргә бай булуы, шул халык арасында кайнап яшәве кирәк. Халык көен чын мәгънәсендә халыкчан итеп башкару өчен тагын халыкның бөтен тормышын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, фольклорын, ниһаять, исәпсез-хисапсыз җырларын, көйләрен, халыкның тарихи үткәнен яхшы белергә, һәм аның киләчәгенең матур булуына ышанырга кирәк. Әлфия Афзалова боларның берсеннән дә мәхрүм түгел. Ул халыкның үз эчендә кайнап үскән. Аның күңеле, уйлары, яшәве — бөтен дөньясы чын, халыкча. Менә шуңа күрә дә, халкыбызның борынгы озын көйләрен башкарганда да, бүген туган көйләрен җырлаганда да, Габдулла Тукаебыз әйтмешли, «чын безнеңчә матур, милли көй» итеп җырлый ул. Әлфия халык көйләренең бөтен нечкә бизәкләрен саклап, көйдәге бөтен бормаларны җиренә җиткереп җырлый һәм моңлы җырлыйм дип, кирәкле-кирәксез бормаландырулар белән чуарламыйча, һәр көйне үзенә генә хас, үзе таләп иткән бормалар белән генә баетып башкара. Әлфия башкаруында радио аша яңгыраган «Казан сөлгесе», «Зөлхиҗҗә», «Болын», «Дустыма», «Гөлҗамал», «Яшь наратлар» һәм башка бик күп көйләрне игътибар белән тыңлаганыгыз бар микән?!. Әлфиянең бу көйләрдәге бормалары, мелизмнары бик сак һәм урынлы, ифрат нечкә үлчәү белән үлчәнгән, үз җаенда гына, ап-ак атласка сизелер-сизелмәс ап-ак ефәк җеп белән чигелгән бизәк кебек, кыйммәтле бәрхет калфакка тезелгән вак кына энҗе сыман. Әлфия көйдәге һәр борманы эчке сиземләү белән тоеп куллана. Гомумән аңарда эчке сиземләү сәләте көчле. Моңлы итеп җырлау эчке сиземләү, тою сәләтенә бәйле булса кирәк дип уйлыйм мин.

Моң дигәннән, музыка турында сүз барганда «моң» сүзе бик еш әйтелә. Бу хакта Гомәр ага Бәширов («Казан утлары». 1969 ел. 3 сан), Гариф Ахунов («Социалистик Татарстан» газетасы. 1969 ел. 9 апрель саны) кызыклы фикерләр әйттеләр. Ул фикерләр белән килешеп, шуны гына әйтәсем килә: һәр халыкның үз моңы бар, безгә, татарларга, үз халкыбыз моңы, татар һәм башкорт моңнары якын, шулай ук без башка милләтләр музыкасында да моң ишетеп дулкынланабыз. Молдаван халык көйләрен, һинд җырларын җырлаганда, мин, мәсәлән, әллә нинди серле моңнар ишетәм. Моң ул — халык хисенең, халык уйларының бик нечкә, бик матур үзенчәлеген билгели торган тирән мәгънәле сүз. Бигрәк тә татар һәм башкорт музыкасын бәяләгәндә, еш кулланабыз без бу сүзне. Безнең халкыбыз «моң» сүзе белән нечкә гүзәллекне, милли гүзәллекне билгели, үлчи. «Моң» сүзен кайбер башка телләргә тәрҗемә итеп тә булмый. Моңны көйдәге ниндидер бормаларга, мелизмнарга гына кайтарып калдырырга ярамый. Моң ул көйнең бормалар, мелизмнар белән бергә яңгыраган җаны, тәне, рухы, сулышы — бөтен барлыгы. Җырчы-башкаручы эчке

рухы белән тоеп башкарганда гына ул тыңлаучы күңеленә җитә. Чын мәгънәсендә моңлы җырлау өчен, әле алда әйткәнчә, күңелең халык күңеле, уйларың халык уе белән бердәм булу кирәктер. Миңа калса, моң ул халыкка, илгә булган зур мәхәббәт хисләре белән бәйле булып туадыр кебек. Моң бит ул музыкада гына түгел, халкыбызның гомумән бөтен сәнгатенә, бөтен культурасына хас үзенчәлеге. Музыкада ул ачыграк, тиранрәк чагыла гына. Күренекле шагыйрьләребезнең шигырьләрендә моң юкмыни? Моң ул, минемчә, сәнгатьнең халыкчан булуыннан, тамырлары белән халык иҗатына барып тоташуыннан туа.

Кайберәүләр, ни өчендер, моңда кайгы-хәсрәт чагылышы гына табалар. Янәсе, моңлы җырлаучы ул кайгы-хәсрәт, сагыш кына уята. Моң ул, кайгы чагылдырамы, шатлык чагылдырамы, иң беренче чиратта, халык күңел кылларын чиртү, һәм ул кайгы-хәсрәткә генә өндәү түгел, ә бәлки шатлык хисләрен, өмет чагылдырганда да ниндидер бер нечкә агым булып үрелеп яңгырый. Әлфия Афзалованың хәзерге заманда туган берәр шатлыклы халык көен җырлагандагы моңына игътибар итик. Мәсәлән, Совет власте шартларында чыккан «Комсомолка Нәфисә» дигән көйне җырлавын тыңлыйк. Моңсыз җырламый бит ул аны. Әлфия башкаруында «Комсомолка Нәфисә» шулай яңгырый ки, хезмәт шатлыгы да, мәхәббәт куанычы да, бүгенге тормыш белән горурлану да, хатын-кызларыбыз характерына хас тыйнаклык, пакьлек, сафлык та яңгырый бу көйдә. Һәм җырның шулай яңгыравы, халык күңеленә җитәрлек көчкә ия булуы — барсы бергә шул моңлы булуыдыр инде ул.

Бөтен буяулары, бөтен нечкәлекләре, бөтен барлыгы белән безгә моң, халык моңы кадерле, үз булырга тиеш. Чөнки моңлы башкару сәнгате аша без тарихи үткәнебезне күрә алабыз, халык авыз иҗатын, фольклорны өйрәнә алабыз, гомумән культура байлыкларыбызны саклый алабыз. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты, халкыбызның күренекле композиторы Җәүдәт Фәйзи үзенең «Музыка кичәләре» дигән кызыклы һәм тирән эчтәлекле китабында Әлфия Афзалова кебек халыкчан итеп җырлаучылар турында болай дип яза: «Шуны да әйтергә кирәк, халык җырларын, халыкның милли көйләрен бөтен нечкәлекләре белән оста һәм матур итеп башкару — ул үзе бер сәнгать. Аларны башкаручы артистлар халкыбызның җәүһәрләрен көнкүрешебездә яшәтәләр, халык иҗатына мәхәббәтебезне арттыралар. Һәр милләтнең халык иҗаты булган эзкә, мәрҗәннәрен оста башкаручы җырчы, уенчылары булган кебек, татар халкының да урман-болын, чишмә-елга, басу-кырларының моңын сайрый торган үз тургайлары бар. Алар: Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Фәридә Кудашева, Зифа Басыйрова, Әлфия Афзалова һәм Илһам Шакировлар. Болар халык тарафыннан аеруча сөелгән җырчылар».

Хәзер Әлфия Афзалованың репертуары көннән-көн киңәя бара. Ул халык көйләрен дә, композиторларыбыз әсәрләрен дә бер үк осталык белән башкара. Әмма ләкин иң беренче чиратта ул халык көйләрен оста җырлавы белән танылды, халык көйләре аша тыңлаучыларның күңел түренә үтеп керде. Иҗат колачы көннән-көн киңәя баруы инде аны бүген эстрада сәнгатенең төп көчләренең берсенә әверелдерде. 1953 елдан алып ул ансамбльдән эстрада бригадалары составына күчте. Әлфия берничә ел Татарстанның атказанган артисты, танылган гармунчы Гани Вәлиев җитәкләгән эстрада бригадасында, аннары Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров белән бер бригадада — яшьләр бригадасында солистка булып эшләде. Әйтергә кирәк, халкыбызның иң талантлы, иң үзенчәлекле җырчысы Илһам Шакиров белән бер бригадада эшләп, Әлфия чын мәгънәсендә чыныгу узды, үз йөзен, үз сукмагын табу юлында бер баскыч үтте. Сүз чыкканда әйтеп китик, Илһам Шакиров Әлфиягә үзендә булган музыкаль югары белем белән бик уңай йогынты ясады. Ниһаять, Әлфия Афзалова Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия эстрада артистлары конкурсында җиңүгә ирешеп, конкурс лауреаты дигән мактаулы исем һәм диплом алды. 1962 елларда инде ул үзенә аерым эстрада бригадасы төзеп, зур программалар белән концертлар бирә башлады.

Әлфия Афзалова сәхнә иҗатында үз юлына җиңел генә, тиз генә килеп чыкмады. Өлкән һәм үзенең замандаш җырчыларыннан үзгә буларак, үз йөзе, үз моңы аңа үз бригадасында куйган тырыш хезмәтләре аша килде. Әлфия Афзалова Татар дәүләт филармониясендә беренче булып кыю рәвештә инструменталь ансамбльгә кушы-

лып җырлый башлады. Баянга кушылып җырлап та ул халык күзендә инде күренеп килә иде, ләкин Әлфия бүгенгә көннең сулышыннан, заман ритмыннан, рус һәм Европа музыкасы яңгырашыннан калышмаска теләде. Һәм менә Әлфия Афзалова үз бригадасы каршында кечкенә генә инструменталь ансамбль төзергә тәвәккәлләде. Башта бу ансамбль составы гади генә трио иде: баян, саксофон, гитара. Бер-ике елдан контрабас һәм бәрмә уен кораллары, барабан өстәлде. Шулай итеп, квартет, квинтет хасил булды, Әлфия шул ансамбльгә кушылып җырлый башлый. Һәр яңалык үз юлында киртәләргә очрамый калмый, Әлфиянең бу концертларына да баштарак шикләнеп караучылар булды. Имеш, татар тыңлаучысының колагы тальян гармун, баянга кушылып җырлауга күнеккән, кушылып сәхнәдә җырлаганда саксофон тавышы, контрабас дыңгырдавы, барабан дөбердәве артистка тавышын күммәсме? Халыкчан планда башкаручы Әлфия ниндидер стиль артыннан куып халыктан читләшмәсме, ераклашмасмы? Эстрада музыкасында халыкчанлыкны саклап буламы? Төрле уен коралларының яңгыравын яратмыйча, бигрәк тә авыл агайлары, авыл җиңгиләре клубтан чыгып китмәсме? Ә баксаң, безнең агайлар, җиңгиләр, ә яшьләрне әйтәсе дә юк инде, эстрада музыкасын аңлый икән, хәтта ярата икән. Эстрада музыкасы гына түгел, симфоник музыканы да, опера музыкасын да радио аша күп еллар ишеткән тамашачы бит ул. Әлфиянең инструменталь ансамбльгә кушылып җырлаган беренче концертлары ук уңыш белән бара башлады. Чөнки Әлфия халыкчанлыгын югалтмады, халыкчан планда башкару осталыгыннан тайпылмады. Һәм музыканың һәр төрен, шул исәптән эстрада музыкасын да, халыкчан итеп иҗат итәргә, башкарырга мөмкин. Әлфия Афзалованың кечкенә генә бу ансамбле — үзенә күрә нәни генә оркестр ул. Әле авылларыбыз клубларының күбесенә чын оркестрларның аяк баса алганы юк, менә шул чын оркестрларга, симфоник музыка кебек зур музыкаларга бару юлында мондый кечкенә ансамбльләр авылларга сукмак салучылар инде. Контрабас кебек күпчелек авыллар өчен ят уен коралларын беренче тапкыр тамашачыларга якыннан күрсәтү бу өлкәдә чирәм күтәрү кебек әһәмиятле хезмәт ул.

Шундый бер хәлне хәтерлим. 1965 ел иде булса кирәк, Әлфия Афзалова бригадасы республикабыз авылларына концерт бирергә чыгарга җыена. Дөнья күрү, сәфәр йөрү, халык арасында кайнау нияте белән мин дә Әлфияләргә ияреп авылларга чыгып киттем. Авылдан-авылга йөрибез. Менә бер вакыт Мөслимнән ерак түгел бер авылга килеп төштек. Машинадан музыка инструментларын бушаткан чакта, иңендә көянтә-чиләге белән судан кайтучы бер апа килеп туктады да контрабаска карап хәйран калды.

— Бу нинди кешедән дә биек олы скрипкә? — ди.

— Контрабас була бу, апакай,— дип, контрабасчы артист Йосыф Вәлитов олы скрипканың кылына бер-ике чиертеп алды. Апаның иңбашыннан көянтәсе төшеп китә язды.

— Әстәгъфирулла, тавышы трактор кебек гөрелди, бигрәк котсыз нәстәкәй икән,— дип куйды ул.

Колхоз клубы мөдире яшь кенә кыз бик үткен, чая булып чыкты:

— Апа, бу олы скрипкалы егет белән әнә теге труба кычкыртучыны, барабан кагучыны фатирга сезгә кертәм, туйганчы бер тыңларсың. Артистлар килә калса, әбизәтелне үземә кертерсең дип әйткән идең. Алар әле концерт башланганчы сезнең өйдә репетиция ясарлар,— диде.

Апа труба кычкырту белән барабан кагу дигәннең нинди хикмәт икәнен белә иде инде, әлбәттә. Алары бу олы скрипкадан да котсызрак дыңгырдаячак.

— Юк, юк, сеңелкәем, бу егетләрне әнә үзегезгә алып кайт, безгә әнә Әлфия Афзалова керсен, яки әнә әргән уйнаучысын алып китәм,— диде.

— Әлфия Афзалованы фатирга суырып алгандай алалар, ул инде фәлән апаларга керә. Синең өлешеңә тигән көмешең шушылар инде,— дип, мөдир кыз инструментлары янында көлемсерәп басып торган әлеге артистларга күрсәтте.

Апа теләр-теләмәс кенә, «артистлар килә калса, әбизәтелне үземә кертерсең» дигән вәгъдәсен бозмас өчен генә булса кирәк, «дыңгырдавык» артистларны үзләренә ияртеп алып китте. Ә кич белән концерттан соң сәхнә артына кереп артистларга рәхмәт әйтүче тамашачылар арасында әлеге апаның да алсу атлас күлмәге җилфәрди иде...



*Әлфия Афзалова үзенең инструменталь ансамбле белән. Л. Черкасов кларнет, З. Гыйбадуллин баян, Г. Евстегнеев барабан, Г. Клязов гитара, П. Вәлитов контрабас белән.*

Концерт бетеп өенә кайткач, бу апа дыңгырдаучы артистларны хәзинәсендә нинди тәмле ризык бар, барсын тезеп куеп сыйлаган. Ахырдан саксофончы һәм барабанчы рус егетләрә татар апасының каймаклы катыгын, кортлы маен, җиләк кагы салган хуш исле такта чәен, мамык кебек күпереп пешкән ап-ак күмәчен әллә ничә көн буе сөйләп йөрделәр. Гади татар авылы сәхнәсендә Әлфия Афзалованың эстрада ансамбле әнә шулай үз булып китте, җыр-музыка сөючеләр аны соклану катыш гаҗәпсенү белән яратып каршы алдылар. Соңгы елларда инде машинага төрле-төрле музыка кораллары төяп, авылларга концерт бригадалары килеп төшү бер кемне дә гаҗәпсендерми торган гадәти вакыйгага әйләнде.

Инструменталь ансамбльгә кушылып җырлау җиңел түгел. Җырның тирән эчтәлеген ачарга, аны сәнгатьчә матур итеп башкарырга кирәк. Тыңлаучы аңласын да, яратсын да, күңеленә эстетик ләззәт алып онытылып тыңласын да. Моның өчен ансамбльгә кушылып гадәти җырлау гына җитми. Ансамбль белән бер бөтен булып яңгырауга ирешергә кирәк. Ансамбль артистлары белән вокалист бер бөтен булып суларга, яшәргә тиеш һәм Әлфия Афзалова моңа ирешә алды. Инструменталь ансамбльгә кушылып җырлау Әлфия Афзалованың сәхнә эшчәнлеген, һичшиксез, баетып җибәрде. Аның концертлары уңышында инструменталь ансамбль солистларының да зур өлеше бар. Нәтиҗәдә күп тавышлы музыка туа, җыр сөючеләр күп тавышлы музыка тыңлыйлар. Җырлар инструменталь ансамбльгә кушылып башкарганда яңа яңгыраш алалар. Шул ук атаклы «Кәкүк» җыры инструменталь ансамбльгә кушылып башкарганда инде бөтенләй яңа аһәңнәр белән баеый. Кәкүк булып инде җырчы гына сайрап калмый, кларнет сайрый, һәм аны башка инструментлар кабатлый. Шулай итеп, халкыбызның кәкүге Гөлсем Сөләйманова сайравы белән янәшә яңа яшь кәкүк Әлфия Афзалова сайравы яңача яңгырый һәм бу сайрау көннән-көнгә, елданелга көчәя бара. Без бүген горурланып әйтә алабыз: безнең Әлфиябез Татарстанның моңлы кәкүге ул!

Әлфия Афзалованың үз йөзен, үз юлын табудагы алымнарының тагын берсенә игътибар итик. Ике кулын күкрәгенә кушырып хәрәкәтсез сын кебек җырлау Әлфиягә ят күренеш. Сәхнәдә ул тормыштагы кебек яшәп җырлый, җырның эчтәлеге, характеры таләп иткән чакта ул спай, килешле, элегант хәрәкәтләр, омтылышлар ясый.

Аның һәр хәрәкәте килешле, табигый, гадәти. Тавышында да, сәхнәдә үзен тотышында да ясалмалык, кыланчыклык юк. «Советская эстрада һәм цирк» журналының 1967 елгы 8 санында Н. Смирнова Әлфия Афзалова турында мондый сүзләр язды:

«Актриса бик үзенчәлекле. Аның җырлавында күп нәрсә үзенә җәлеп итә. Сәхнәдә үзен зәвыклы тоту, нәфислек, табигый кыланышлар, аның җиңел җырлавында гына түгел, грациоз хәрәкәтләрендә, йөрешләрендә, әһәмияткә ия күз карашларында да чагыла».

Тырыш хезмәт Әлфия Афзалованы олы сәнгатькә алып килде — 1963 елда аңа хөкүмәтебез Татарстанның атказанган артисткасы дигән мактаулы исем бирде.

Җырчының үз йөзен, үз юлын табуында аның репертуары зур роль уйный. Никадәр яхшы җырласаң да, бүтәннәр башкарган әсәрләрне кабатлап җырлап кына сәнгатьтә үз урыныңны таба алмавың ихтимал. Әлфия Афзалова башкалар моңарчы җырлаган халык көйләрен үз үзенчәлекләре белән баетып, кабатлап җырлау өстенә, үзенә генә хас репертуар булдыру өстендә дә тырышып эшли, композиторларыбыз әсәрләрен өйрәнә, үзенә махсус җырлар яздырта. Аның репертуарында Салих Сәйдәшев, Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов, Шакир Мәҗитов, Сара Садыйкова, Ренат Еникеев, Бәхти Гайсин, Фәтхерахман Әхмәдиев, Зиннур Гыйбадуллин җырлары бар. Күп кенә җырларны ул эстрадада беренче башлап башкара, һәм озак еллар җырлый, күп кенә җырга бәхетле озын гомер, матур язмыш бүләк итә. «Бохара-Урал» (А. Ключарев музыкасы, З. Туфайлова сүзләре), «Яшьлегемнең кайнар хисләре» (Ш. Мәҗитов музыкасы, Г. Сәгыйдуллин сүзләре), «Кайтам инде» (С. Садыйкова музыкасы, И. Юзеев сүзләре), «Яратам дисең син» (А. Монасыйпов музыкасы, Ә. Давыдов сүзләре), «Сәяхәтче җыры» (З. Гыйбадуллин музыкасы), «Туган авылым» (Т. Шәрипов музыкасы, Г. Рамазанов сүзләре) кебек күп кенә җырларны иң башлап диярлек Әлфия Афзалова җырлады, Әлфия Афзалова популярлаштырды. Шулай үз репертуарын булдырырга омтылуы аның иҗатта үз йөзен табарга омтылышы, тырышлыгы булды.

Җырны репертуарыңа алып иң беренче булып җырлау җаваплы һәм авыр эш. Ничек кабул итәрләр? Композитор һәм шагыйрь әйтергә теләгән фикерне тыңлаучыга җиткереп булырмы? Кыюлык, тәвәккәллек сорый бу хезмәт. Әлфиядә кыюлык, тәвәккәллек җитәрлек. Кайвакыт ул, үз репертуарын баету, төрләндерү өчен, композитор белән шагыйрьгә үзе яңа тема әйтә, үзе яңа җыр тууга булыша. Татарстанның халык артисты, күренекле композитор Александр Сергеевич Ключарев белән миңа мөрәҗәгать итеп, бер вакыт Әлфия Афзалова болай диде:

— Бер җыр языгыз әле. Минем минем тормышым, минем язмышыма багышлангандайрак җыр булсын ул. Гади генә бер кызның безнең илдә ничек кеше булуын аңлатсын.

Александр Сергеевич рухланып, дәртләнеп китте:

— Сүз кирәк, көе инде минем күңелемдә тибрәнә,— диде.

Әлфия язмышы минем язмышым кебек үк. Ярым ятимлектә үткән балачак. Ил, Ватанның җылы кочагы булмаса, без кем булыр идек?.. Ватанның гади кызлары без, шул Ватан безгә тормыш бирде, җыр бүләк итте. Нәтиҗәдә:

**Ватанымның гади бер кызы мин,**
**Туып үстем Идел буенда,**
**Чәчәк җыйдым зәңгәр болыннарда,**
**Җыр өйрәндем сабан туенда,—**

дип, Әлфиянең үз сүзләре белән үк башланып киткән бер җыр деньяга килде.

Тагын «Сәяхәтче җыры»н искә төшерик. Әлфия Афзалова белән бик еш очрашып яшибез, һәр яңалыкны уртаклашабыз, шатлык бергә, кайгы уртак, иҗат куанычларын бергә куанабыз, иҗат борчуларын бергә борчылабыз. Көннәрдән бер көнне Әлфия Афзалова арып-талып ерак гастрольдән кайтып төште. Артистның гомере тәгәрмәч өстендә үтә, дип белеп әйтәләр. Районнан районга, авылдан авылга машинага утырып кына бармый артист. Кышкы салкыннарда өстенә калын толыплар, аягына киез итекләр киеп чанага, юлсыз бураннарда тракторга утырып та йөри ул. Көзге явымнарда саз ерып, җәйге чelләдә тузанга батып, юл газабы — гүр газабы кичеп сәфәрдә йөри ул. Самолет белән ерак Себергә, Урта Азиягә дә, Балтик буена да оча алар, поезд

белән Мәскәү, Ленинградка да, Свердловскига да, Оренбург, Мурманскига да китә алар. Кайларга барып чыкмый да, кайда гына илләрдә, кайда гына юлларда йөрми артист халкы... Шулай зур сәфәрләрдә йөреп арып, талып, сагынып кайтуның үз моңы бар. Айлар буена балаларын күрмичә, семьясыннан аерылып, ерак гастрольләрдә йөргән артистканың өенә ничек сагынып кайтуын, кечкенә кызы Зөлфиянең әнисе кайткач, кочаклап сикереп күргәч, минем күземә яшьләр килгәне бар. Өенә кайтып кергәч, Әлфия әле бер, әле икенче кызын кочаклап үбә-үбә куана. Яше 70 тән узган булуына карамастан, һаман армый-талмый балаларны карап тәрбияләүче Закирә апа белән сагынышып беткән булалар алар.

— Менә безнең кебек сәяхәттә күп йөрүчеләр турында берәр җыр язсаң иде,— дип куйды Әлфия гастрольдән кайткан көннәрдә очрашкач. Ул аны-моны уйламыйча шаярып кына әйткәндәй әйтте. Әмма мин күңелемә салып куйдым һәм чынлап туган җирдән ерак китеп сәфәр йөрүчеләргә багышлап җыр язарга уйлап йөри башладым. Зиннур Гыйбадуллинның Әлфия Афзалова бригадасы составында баянчы булып эшләгән чагы иде. Ул да, Әлфия кебек, гастрольдән кайтып керми, юлда йөргәндәге кичерешләре, юлның әшкынулы ритмы, аның күңелендә инде көй булып туган. Бер көнне ул миңа шушы «Сәяхәтче җыры»ның көен баянда уйнап күрсәтте. Көй ошады, көйдә ниндидер ашкыну, хәрәкәт бар. Нинди сүз язарга икән дип уйлана торгач, күңелдә «Сәяхәтче җыры»ның беренче куплеты формалаша башлады:

> Таныш түгел юллар буйлап,
> Мин озак йөрдем.
> Туган ягым күренерме дип,
> Тауларга мендем.

Бу җырны иң беренче тыңлаучы да Әлфия булды. Тыңлады да: «Була бу! Нәкъ мин теләгәнчә була бу!» — дип җырлап карады. Ләкин җырның калган куплетлары бик озак язылды. Бер елга якын эзләп, уйлап йөрдем, әллә ничә вариант туды. Әлфия:

— Бусына тел әйләнми! Бусы авыр аңлашыла! Бусы көйгә туры килми,— дип, әллә ничә вариантны кире какты.

(Сүз уңаенда әйтеп китик, Әлфия җыр текстларына бик игътибарлы. Җырның сүзләре аңлашылмасырак, җөмлә уңайсызрак төзелгән булса, яки җыр куплетлары арасында үзара эчке бәйләнеш булмаса, хәзер сизеп ала ул. «Әбау! Тел әйләнми!..» генә ди дә бәяне бирел куя. Сүзгә игътибарлы булуы аның җыр текстындагы һәр сүзне аңлаешлы, табигый итеп, ачык дикция белән җырлавында да күренә.)

Күп эзләнә торгач, «Сәяхәтче җыры»ның соңгы бер вариантына тукталдык. Җырлар менә шулай авторлар өчен дә, башкаручы артист өчен дә озак эзләүләр нәтиҗәсе буларак кына туа.

Әлфиянең репертуары төрләнәнеп, баеп тора, аның өчен махсус җырлар языла. Татарстанның атказанган артисткасы композитор Сара Садыйкова белән шагыйрь Мостафа Ногман «Актаныш таңнары» дигән заманча матур аһәңле җырларын махсус Әлфия Афзалова тавышына язды лар.

> Актаныш таңнары,
> Ул минем йөрәк серемне аңлармы?..—

дигән кушымтасын аерата яратып, үзенә бер мәхәббәт белән җырлый Әлфия. Чөнки бу җырда аның туган ягына үзе белдерәсе килгән олы мәхәббәт хисләре салынган.

...Әлфия Афзалова, татар эстрада сәнгатендә беренчеләрдән булып, тугандаш халык һәм чит ил җырларын җырлый башлады. Бу эш тә җырчыга җиңел генә бирелмәде. Моның өчен табигый талант кына җитми иде. Әлфия Афзалова Мәскәүгә, чит ил җырларын башкару остасы Ирма Яунзем янына барып, уннан артык телдә (һиндчә, гарәпчә, казакъча, әзербайҗанча, үзбәкчә һ. б. телләрдә) яңа җырлар өйрәнде.

Һинд халык җыры «Айлы төн», үзбәк халык җыры «Гөлнара», казакъ композиторы Е. Брусиловскийның «Кил безнең авылга» дигән җырларын оста башкарып, Әлфия Афзалова җыр сөючеләрнең күңеленә үтеп керде.

Һинд халкының «Айлы төн»ендә никадәр нәфислек бар. Һинд җырчылары кебек, тел очында гына йомшак итеп җырлап, Әлфия тыңлаучыларны ышандыра алды. Аның

башкаруында «Айлы төн» безнең үз жырыбыз кебек аңлаешлы, җанга якын. Бу өлкәдәге хезмәте Әлфия Афзалованың сәхнә иҗатының аерым бер матур сәхифәсе. Җырга чын күңеле белән гашыйк булып башкарган кеше генә җырны тыңлаучы күңеленә җиткезә аладыр. Әлфия үзе башкарган җырларга чын күңелдән гашыйк була ул. Әлфиянең шушы һинд җырын яратып, аңа гашыйк булып, шашып йөргән минутларын онытуы кыен.

1960 елның кышкы салкын бер киче иде. Яңакларын алсулатып, ашкынып, очынып Әлфия килеп керде. Кышкы буранда кош тоткан мыни?! Кош түгел, җыр тоткан — кулында һинд җырының нотасы һәм сүзләре. Мәскәүдән Ирма Яунзем янынннан укып кайткан көннәре. Көен откан, һиндчә сүзләрен ятлаган, килеп тә керде, җырлый да башлады — һиндстан кино картиналарындагы атаклы артистка Наргизмени?! Ләкин күңеле тыныч түгел икән — татарчага тәрҗемә ит диеп миңа ялвара башлады. Авыз ачарга да бирми:

— Тәрҗемә ит! Зинһар, тәрҗемә ит!..

Ирма Яунземнан һинд җырының русчага тәрҗемәсен алып кайткан икән. Русча текстын укыгач, күнә башладым.

— Ярар, мәйтәм, берәр атнадан булыр бәлки...

Әлфиянең башкорт кызларыныкыдай кысынкырак кара күзләре түгәрәкләнде:

— Ничек инде бер атнадан?... Иртәгә авылларга гастрольгә чыгып китәм, иртәгә үк җырлый да башлыйм! Тыңлаучы минем авызыма карап сүзләрен аңламыйча утырсынмы? Һиндчә дә, татарча да җырлыйм!..— ди бу. Өзми дә, куймый да.— Хәзер үк тәрҗемә ит! — ди.

Кулга кәгазь-каләм алып утырабыз. Ул һиндчә җырлый, мин русча текстка карап татарча сүзләр эзлим. Ярты төнгә кадәр утырдык, бер юл да тәрҗемә итеп булмый. Әлфия, җырлап карый да:

— Көйгә килми,— ди.

Дүрт-биш сәгать эзләп, җырлап карый-карый утыра торгач, беренче куплет табылды:

**Җәйге төн, айлы төн,**
**Йоклый гөлләр,**
**Кошлар тынып калган.**
**Ә мин керфек какмыйм,**
**Өзелеп көтәм һаман...**

Төне буе утырып, таң алдыннан гына тәрҗемә итеп бетердек. Әлфия ул төнне өенә кайтмады, бездә йоклады. Таң ата башлаганда да ул әле урынында йоклый алмый ята иде.

— Йокла инде, таң ата бит! — дигәч:

— Матур бит! — ди.

— Нәрсә матур? Таң атуымы? — дим.

— Таң ату да матур, һинд җыры да матур, ничек йокламага кирәк,— диде Әлфия, хискә бирелеп.

Чит ил җырларын оста башкаруы өчен, Тынычлыкны яклаучыларның совет комитеты Әлфия Афзалованы Почет грамотасы белән бүләкләде.

Үзе дә Агыйдел буйларында туып-үскәнлектәндер, Әлфия Афзалова башкорт халык көйләрен, Башкортстан композиторларының әсәрләрен бик яратып җырлый. Башкорт җырчылары матур итеп башкарган «Почтальон», «Тенәкәй», «Элмәлек», «Туган авылым», «Кил, иркәм», «Нигә генә икән», «Раушаниям» кебек җырлар Әлфия Афзалова башкаруында матур яңгыраш таптылар. Әлфия Афзалова концертларын башкорт дуслар көтеп алалар. Әлфияне үз артисткалары саныйлар, матбугатта аңа җылы, матур мактау сүзләре язалар. «Совет Башкортстаны» газетасының 1963 елгы 23 ноябрь санында М. Мәгасумов мәкаләсендә мондый юллар бар:

«Әлфия Афзалова җырлый. Йөзләгән тамашачының ихтирамлы карашы аңа төбәлгән. Җырчы җырлый. Аның йөрәгеннән ургылган төрле халыкларның төрле вакытларда, төрле телләрдә иҗат иткән җырлары залга сибелә. Зал җырчының һәрбер җырын, тирән моңын, һәрбер өнен йотлыгып тыңлый. Тыңлый гына дип әйтеп булмый, юк. Уттай кызу эш өстендә кырдан кайтып, чишмәдән чайпылдырып алган төре-

көмештәй саф суны бер тында эчеп җибәргән шикелле, җырны да сусыны басылганчы эчә сыман...»

Башкортстанда, бигрәк тә туган авылы Яңа Кабанда булган концертлары Әлфия Афзалованың күңелендә матур истәлекләр, хатирәләр калдыра. Туган авылы кешеләре көтүче Афзал кызының Совет власте шартларында чәчәк аткан талантына сокланалар, аның белән горурланалар, аны авылдашлары «Кама» колхозының почетлы колхозчысы итеп алалар.

Башкортстанга еш гастрольгә барган кебек, Әлфия Афзалова башка тугандаш республикаларга да гастрольгә еш бара. Илебездә Әлфия Афзалова аяк басмаган республика, өлкә аздыр. Кайда татар — анда безнең артистлар бит, ә татар халкы бөтен ил буйлап таралган. Шунсы күңелле, халык кайда гына урнашып калып яшәмәсен, үз телен, үз музыкасын онытмый, аны ярата, хөрмәт итә, аңа омтылып яши. Тәгәрмәч өстендә гомере узган артистларга шул гына кирәк тә, халык мәхәббәтен тою алар өчен иң зур бәхет, илнең кайсы гына ягына барып чыксалар да, артистлар — көтеп алынган кунак.

Озын көйләр, җитди җырлар башкару белән бергә, Әлфия Афзалова шаян җырларны да яратып җырлый. Шаян, шук, күтәренке күңелле җырларны башкарганда ул эчке бер елмаю, эчке бер шуклык белән шаярып җырлый. Йөзендә, килеш-килбәтендә мөлаемлык саклаган хәлдә, ул ниндидер бер шаяру хисенә бирелә һәм үзе белән бергә тыңлаучыны да елмайта. Башкорт халкының «Элмәлек» дигән шаян җырын тыңлаганда безнең күз алдыбызга өстенә иске тун, аягына ак чабата, ак оек кына кигән һәм ярлы булуына карамастан, шат күңелле, кайгы-хәсрәт алдында баш ими торган горур, шаян, шук кеше образы килеп баса. Өстенә заманча тегелгән капрон күлмәк, аягына иң соңгы модадагы туфлялар кигән артистка үзенең җыры белән үткән заманның ак чабата, ак оеклы кешесен, җитмәсә сызылып киткән кара мыеклы егет кешесен безнең күз алдыбызга китереп бастыра. Образ тудыру җырчының художник була алуы ул. Әлфия Афзаловада имитацияләү сәләте көчле, халык теле белән әйткәндә, кеше булу, кешене копировать итү сәләте көчле. Җырлаганда образ тудыра алуы аның шуннан килә дә булса кирәк. Аның үз табигатенең шуклыгы да имитацияләү һәм импровизацияләү сәләте көчле булудандыр. Син борылган арада ул синең тавышыңны, көлүеңне, сөйләшүеңне копировать итеп куярга да күп сорамый. Кайвакыт ул үзеннән күп өлкән кешеләрне, калын тавышлы кешене, хәтта ир кешене копировать итә, тыңлап-тыңлап, карап-карап торасың да күз алдыңа әлеге кеше килеп баса, Әлфия, гипнозлаган кебек, сине шул кеше булып сөйләшеп яки җырлап ышандырып куя, ирексездән елмаясың.

Бу үткенлеге, шуклыгы өчен аңа кайвакыт үпкә, шелтә сүзләре дә эләгә, гаеп табарга теләүчеләр, мондый шуклыклары өчен аңа кырынрак күз белән дә караштыралар. Ә чынында эчкерсез, ачык күңелле, җайлы холыклы, тыйнак, мактану, эреләнүне белми торган гади кеше ул. Гади, хәтта кирәгеннән артык гади булып киткән чаклары да бар аның. Әмма инде репетиция вакытларында, концерт барганда аның әлеге гадилеге, самимилеге җитдилек белән үрелә.

Үз иҗат йөзен, үз юлын табудагы күп еллык тырышлык, хезмәт, армый-талмый үз өстеңдә эшләү, тынгысыз эзләнүләр дәвам итә. Әлфия Афзалова һаман репертуарын киңәйтә, тулыландыра бара, аның гомере һаман тәгәрмәч өстендә уза, ул һаман сәхнә түрендә, халкыбыз моңнарыннан килгән традицияләрне заманча үстереп җырлавын дәвам итә. Үзешчән сәхнәдән зур профессиональ сәхнәгә күтәрелгән Әлфиянең бөтен иҗатын күздән кичереп уйлансаң, шундый нәтиҗәгә киләсең: туган илгә, туган халкыбызга чын күңелдән бирелеп хезмәт иткән Әлфия — мәхәббәт һәм дуслык җырчысы ул. Үз җырларында ул кеше йөрәгенең иң нечкә кичерешләрен — мәхәббәт һәм дуслык хисләрен җырлый. Аның җырлары Ватанга бирелгәнлек, халыклар дуслыгы, тынычлык турында зур һәм җитди сөйләшү булып яңгырыйлар.

Икмәккә, кара алтынга бай булган, җырлап, шаулап-гөрләп үскән Татарстанның матур, зур сәнгате бар, шул сәнгатьне иҗат итүче ялкынлы кешеләре күп, ул сәнгать кешеләре арасында үз иҗат өлеше белән безнең Әлфия Афзаловабыз бар, Әлфиянең Агыйдел дулкыннары шавын, чишмәләр чылтыравын, ямь-яшел игеннәр тибрәлүен, хезмәт кешеләренең шат көлүен, тургай сайрауларын, кәккүк моңнарын хәтерләткән җырлары бар!..

**Фәләх Насыйров**

# БАРЫСЫ ДА ХӘТЕРДӘ



Эх, бу гомер дигәнең, бигрәк тә кыска инде! Кеше гомеренең ничек узып киткәнен сизми дә кала. Уйласаң, исләрең китәрлек...

Җаны-тәне белән эшкә бирелгәнгәме, Лотфулла ага Миңнуллинның башына бүгенге көнгә кадәр әле андый уйларның килгәне юк иде. Ә менә хәзер, коллектив белән аерылу, саубуллашу минутлары килеп җиткәч, үз-үзенә: «Бу гомер дигәнең кайчан гына узып китте соң! — дип куйды.— Әле кайчан гына бирегә эшкә килгән идем, баксаң, 35 ел вакыт үткән дә киткән...»

Аның каршында ничәмә еллар буе бергә эшләгән, авырлыкларын да, шатлыкларын да бергә кичергән хезмәттәшләре, дуслары утыра. Тантаналы да бу кичә, бер үк вакытта, әллә ничек, моңсу да...

Менә, трибунага партиянең Идел буе райкомы секретаре Борис Петрович Гордеев чыгып басты. Ул ашыкмыйча гына:

— Хөрмәтле Лотфулла Миңнуллович! — дип башлады сүзен. — КПССның Идел буе район комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының район Советы Башкарма Комитеты исеменнән Сезне 65 яшегез тулу көне белән чын күңелдән котлыйм!

Бүгенге истәлекле көндә, энергетика промышленносте системасында күп еллар буе тырыш хезмәтегез өчен тирән рәхмәтебезне белдерәбез.

Сез, партиянең турылыклы улы, беренче бишьеллыкның тәүге төзелешләреннән саналган — беренче җылылык электр үзәген салуга 1931 елда гади эшче булып килеп, директор урынбасарына кадәр үстегез. Үзегезне яхшы оештыручы, игътибарлы һәм сәләтле җитәкче итеп күрсәттегез. Без Сезнең белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Сез, Лотфулла Миңнуллович, үзегезгә тапшырылган эшкә зур җаваплылык хисе сизеп, безнең районның җәмәгать һәм политик тормышында да ару-талуны белмичә катнаштыгыз. Сезнең хезмәтегез башкаларга үрнәк булып тора.

Шундый ук җылы сүзләр әйтү, изге теләкләр белдерү өчен трибунага бер-бер артлы кешеләр күтәрелә. Алар күп. Казан электр-җылылык челтәрләреннән, ТЭЦ-2 дән, «Татэнергоремонт» һәм башка коллективлардан килгәннәр алар.

Әйе, 35 ел үзе бер гомер. Ләкин эш аның озынлыгында түгел. Хикмәт менә шул тормышның ничек узган булуында. Кеше гомеренең бәясе аның озынлыгына карап түгел, бәлки җәмгыять һәм халык файдасына керткән хезмәтенә карап йөри. Ә ул, Лотфулла ага, үзенең тормыш юлында күңел юатып искә алырдай хезмәтләр, нурын күрердәй якты маяклар калдырдымы! Ул ничек яшәде!

Бүген, үзен ялга озатуга җыйналган менә шушы тантаналы кичәдә, гомерендә

беренче талкыр аның күңелендә әнә шундый сораулар туды. Бу сораулар йөрәгенә бик тирән сеңгән хатирәләрне яңартты.

...Үз-үзен белә башлаганнан бирле, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләүне дә, батрак булып кулакларга бил бөгүне дә, 1921 елгы ачлыкта әтисенең үлү кайгысын да, берсеннән-берсе вак энесеңелләрен карау мәшәкатен дә — барысын-барысын да кичерде ул. Авылдагы хәерчелек һәм бөлгенлек, кече туганнарына ярдәм итү бурычы аны шәһәргә алып килде. 1924 елда ул үзенең туган ягы — Кама тамагы районы Олы Кариле авылыннан китеп, эшчеләр армиясе сафына басканда аңа 23 яшь иде. Башта ул Уралда агач эшкәртү заводларында эшләде, аннан Донбасс шахталарында забойщик булды. Беренче бишьеллык төзелешләре башлангач, яңадан Уралга кайтып, Березняк химия комбинатының нигезләрен салышты. Ул чор өчен шактый авыр булган бетончы һөнәрен үзләштерде.



Бетончы!.. Яратты ул бу эшне, бик яратты. Үзең койган бетон фундамент өстендә зур корпусларның мәһабәт стеналары күтәрелә баруын күрүдән дә зуррак шатлык юктыр дөньяда.

Юк, Лотфулла ага бетончы гына да булмады. Березняк химия гигантында ул шактый күп катлаулы монтаж эшләрен дә башкарды. Биек корпусларга бетоннан коелган зур тәрәзә рамнары куюда тоткарлык килеп чыккач, ул түзмәде, үзенең бригадасын җыеп алды да:

— Бу эшне әллә үзебезнең өскә алабызмы! — дип, иптәшләренә мөрәҗәгать итте.

Бетончылар аңгәмәсен тыңлап торган башка төзүчеләр:

— Чокырга измә салу түгел ул. Биек стеналар өстенә басып, бетон рамнар сөйрәргә кирәк,— дип көлделәр.

Бер яктан алар хаклы иде. Бу бит 1927 ел. Ул чакта күтәрү краннарын күргән кеше дә юк. Бөтен эш кул белән башкарыла. Өч-дүрт центнерлы авыр балкаларны җилкәләргә салып ташырга, биек стеналар өстенә баулар белән сөйрәп менгерергә кирәк. Боларны Лотфулла аңламый түгел, аңлый. Тик әнә шул тәрәзә рамнарын куярга кешеләр табылмау аркасында килеп чыккан тоткарлык белән күнеле килешә алмый. Йөрәктә ут янып, беләктә көч ташып торганда, ничек инде ул битараф булып калсын. Бригаданың башка членнары да:

— Алабыз! — дип торалар.

Берничә көн ул стеналарны, тәрәзә уемнарын карап, «рамнарны каян менгерсәләр, ничек итеп куйсалар уңайрак булыр!..» дип, күзәтеп йөрде. Ахырда «тәвәккәлләргә кирәк!» дигән карарга килде. Биеккә менеп эшләгәндә башы әйләнми торган берничә егетне сайлап алды да эшкә кереште.

Вакыт белән беркем дә хисаплашмады: көн бераз гына яктырдымы, биек стена өстенә менеп, арканнар белән авыр рамнарны сөйрәргә керештеләр. Эштән дә көн караңгылангач кына туктыйлар. Шулай итеп, атна-ун көн эчендә хәтсез генә тәрәзә рамнарын куйдылар. Хәзер инде:

— Чокырга измә салу түгел ул! — дип, бетончылардан көлүчеләр юк иде.

Бөтен коллективның менә шундый тырышлыгы белән беренче бишьеллык гигантларыннан саналган Березняк химия комбинаты көннән-көн үсә, күтәрелә барды. Менә шушында инде Лотфулла үз гомерендә беренче мәртәбә Мактау Грамотасы һәм акча белән бүләкләнү шатлыгын кичерде. Бу аны канатландырып җибәрде. Ул тагын да тырышыбрак эшли башлады. Әмма белем юклыгы үзен нык сиздерә иде: төзелеш эшләре елдан-ел катлаулана.

Бер көнне Миңнуллинны кадрлар бүлеге начальнигы чакырып алды:

— Сине Свердловскига, десятниклар курсына укырга җибәрергә булдык,— диде ул аңа.

Лотфулла эченнән шатланса да, ризалык бирергә ашыкмады.

— Яхшы. Уйлармын,— дип кабинеттан чыгып китте.

Бу мәсьәләдә аның үз планы бар иде. Кая гына барса да — Донбасскамы, Уралгамы — ул һәрвакыт «Кызыл Татарстан» газетасын алдырды һәм туган республикасындагы хәлләр белән танышып торды. Бигрәк тә рабфакка укырга керү турында язылган белдерүләрне кызыксынып күзәтә иде. Тик моңарчы бу адымны ясарга батырчылыгы җитми торды. Менә хәзер, аны десятниклар курсына укырга җибәрәбез дигәч, тотты да ул Казанга хат язды. Җавап озак көттермәде. «Сынауларны бирә алсаң, кайт»,— дип хәбәр иттеләр аңа. Ул шунда ук расчет алды һәм Казанга юл тотты.

Тырышкач, була икән. Сынауларны уңышлы гына бирде. 1930—31 уку елын да тәмамлады. Тәмамлавын тәмамлады, тик кесәсе бик нык саекты. Кече туганнарына да ярдәм итәсе бар, үзенә дә кирәк. Каникул вакытында бераз эшләп алыйм дип, җәен ул эшкә керде.

Ә эш эзләп йөрисе юк иде: әнә, Кабан күле буенда гына Казгрэс салынып ята.

— Бетончы мин,— дигәч, төзелеш начальнигы Гали Ганиев аны ике куллап каршы алды. Ярты ай да вакыт үтмәгәндер, үзен бригадир итеп куйдылар. Кул астында йөзгә якын кеше. Эшне өч сменада оештырырга кирәк. Лотфулланың исә мондый зур төзелешләрдә инде эшләгәне бар, тәҗрибәсе дә шактый. Эшне җайлап җибәргән арада, аның каникул вакыты узып та китте.

— Вакыт җитте. Китәм инде мин,— дип, ул төзелеш начальнигы янына керде һәм сәбәбен аңлатып бирде.

— Китмисең, Лотфулла, бездә каласың, эшлисең.

Миңнуллинның эченә пошаман төште. Аның укуын бер дә бүләсе килми — яше кечерәк булса бер хәер иде, инде утызга җиткән бит!

Ганиев аның кичерешләрен сизендеме:

— Әгәр, Лотфулла, сине кичке рабфакка күчерсәк, риза булырсыңмы! — дип, аның янына килде дә җилкәсенә кулын салды.

— Әйбәт булыр,— дип көлеп җибәрде бригадир.— Бик әйбәт булыр!

Шулай итеп, Миңнуллин көндезләрен Казгрэс төзеде, кичләрен рабфакта укыды. Киеренке хезмәт белән бергә китап-дәфтәрләр карап тагын бер ел узып китте. 1932 елда Лотфулла тормышында зур вакыйга булды: аны партия сафларына кабул иттеләр. Үзенең тормышын ул мәңгегә бөек Ленин төзегән партия белән бәйләде.

Яшь коммунист хезмәттә һәрвакыт үрнәк күрсәтергә тырышты. Ә Казанда Беренче җылылык электр үзәген салу бик кыен шартларда барды. Ул вакытта әле бер генә автомашина да юк иде. Төзелеш материалларын мәтәлеп китә торган ике көпчәкле агач арбалар белән ташыдылар. Бетон да тачкаларда күчерелде. Эш авыр, бик авыр иде. Шулай да аны төзергә, тизрәк сафка кертергә кирәк, Казан электр энергиясенә зур кытлык кичерә. Шәһәрдә бер генә электр станциясе — «Татарстанның өч еллыгы» исемендәге — станция генә эшли. Аның куәте нибары өч мең 500 киловатт кына. Ә шәһәр үсә, яңадан-яңа завод-фабрикаларның нигезләре салына. Бу хәл электр энергиясенә булган ихтыяҗны тагын да арттыра. Шуның өчен Казгрэс салу — удар төзелешләрдән саналды. Һич көтмәгәндә төзелештә авария булып, эш тоткарланып калды, язгы ташуда Кабан күлендәге су күтәрелде дә, аванкамераның стенасын ишеп, эченә су тулды. Аванкамера дигәнең кечкенә нәрсә түгел шул, тирәнлеге 20 метрга җитә, диаметры да шулкадәр үк. Аны казу өчен йөзләгән кешенең никадәр көче кергән, никадәр маңгай тире тамган. Никадәр куллар сөялләнгән. Хәзер менә шул чокырга тулган суны насослар белән суыртып, стеналарына ашыгыч рәвештә бетон салу бурычы тора иде.

Миңнуллин үз-үзенә урын таба алмыйча йөрде. Бу вакытта ул башка участокта эшли иде, шулай да түзмәде, аванкамераны барып карады да, күп уйлап тормастан, конторага юнәлде. Төзелеш начальнигы Ганиев кабинетына килеп керсә, анда да сүз шул турыда бара иде. Өстәл тирәсенә инженерлар, прораблар җыйналган. Барысы да:

— Ленинградтан белгечләр чакыртырга кирәк,— дигән фикергә тукталганнар.

Миңнуллин аларның сөйләшкәннәрен тыңлап-тыңлап утырды да сүзгә кушылды.

— Ленинградтан белгечләр килсә, әлбәттә, яхшы булачак. Тик алар кайчан килеп җитәрләр!..

— Атна-ун көннән дә артык узмас...— диде төзелеш начальнигы, бригадирга карап.

— Бу вакыт эчендә Кабан күлендәге су артып, аванкамераның стеналарын тәмам ишеп бетермәсме!.. Ул чагында...

Ул чагында нәрсә булачагы һәркемгә ачык иде. Миңнуллинның бу сүзләре төзелеш җитәкчеләрен уйга калдырды.

—Ә син, Лотфулла, нәрсә тәкъдим итәсең! Башка юл бармы соң! — диде Гали Ганиев паузадан соң.

— Минемчә, бар.

— Нинди!

— Стеналарына бетон салу.

— Аны кем башкара ала!..

— Минем бригада.

— Синең бригада!

Барысы да гаҗәпсенү һәм кызыксыну белән Лотфуллага карадылар.

— Березняк химия комбинатында шуңа охшаган стеналарны салганым бар иде. Әмма бу эшне бик кыска срокта, тиз башкарырга кирәк.

— Алайса, үз өстеңә аласың!

— Алам. Тик өстәмә көч бирерсез.

— Анысыннан эш калмас. Күпме кирәк, шулкадәр алырсың. Тик эшлә генә...

Миңнуллин үзенең комсомол-яшьләр бригадасы белән шул көнне үк эшкә кереште. Ул беренче сменага килгән иде. Шуннан икенчегә дә, өченчегә дә калды. Эш бик тыгыз. Барысын да карап, күзәтеп торырга, әле анда, әле монда булышып, ярдәмләшеп йөрергә кирәк. Төзелеш начальнигы Ганиевнең дә йокысы качкан. Ул да төнлә өч-дүрт мәртәбә килеп, бетончыларның хәлен белеп китте, Прораб та таң тишегеннән килеп җитте. Эш белән танышып чыкканнан соң, бригадир янына килеп:

— Син бик аргансың, Лотфулла Миңнуллович,— диде.— Төсләрең дә киткән. Кайтып бераз ял итеп кил. Синең урыныңда үзем калырмын.

Әйе, Лотфулла бик нык арыган иде. Бертуктаусыз өч смена эшләде бит. Хәзер инде куркыныч узды дияргә мөмкин. Стеналарның күп өлешенә бетон салынды. Суның бәреп керү куркынычы бетте.

Аванкамераның стеналарын коеп бетергәннән соң, дүрт-биш көн узгач, бригадирны төзелеш начальнигы Ганиев чакырып алды.

— Менә, Лотфулла,— диде ул таныш булмаган кешеләргә күрсәтеп: — Аванкамераның стеналарын коярга дип, Ленинградтан белгечләр килгән, без бергәләп барып карыйк инде. Алар ни әйтерләр!..

Бардылар. Читтән килгән белгечләр бетон стеналарны бик җентекләп, төрле яктан карап чыкканнан соң, бригадир янына килеп:

— Молодцы! Яхшы эшләгәнсез! — дип аның кулын кыстылар.

Соңга таба эштә берәр тоткарлык килеп чыкты исә, төзелеш начальнигы Гали Ганиев үзе, бригадир янына килеп, аның белән киңәшә башлады. Шулай, бервакыт Германиядән алынган турбиналарның фундаментын салу мәсьәләсе алга килеп басты.

— Немецның безгә ышанасы килми бит, Лотфулла. Моның өчен махсус белгечләр чакыртырга кушалар. Нишләрбез икән!..— дип, начальник тагын да мөрәҗәгать итте.

Турбиналарны махсус договор буенча, Германия заводының үз кешеләре килеп җыйды. Ә менә шуларның рамын бетонлаштырырга вакыт җиткәч, немецлар шикләнеп калганнар. Янәсе, «рус мужиклары» булдыра алмас.

— Һе,— диде Лотфулла, ачы елмаеп.— Башкаларны койганны, башкаларны эшләгәнне, аны гына ник коймаска!! Үзебез коябыз, Гали Ганиевич, үзем коям! — диде катгый рәвештә.

Миңнуллинның хәтерсенә бөтен коллектив көткән куанычлы көн аеруча тирән сеңеп калган. 1933 елның 18 гыйнварында ТЭЦның беренче турбинасы ток бирде. Бу көнне һичкайчан онытасы юк. Электр лампочкаларында балкыган яктылыкта, хәрәкәткә килгән йөзләрчә станокларда ул Ильич васыятьләренең тормышка ашуын күрде.

Мондый истәлекле вакыйгалар аның тормышында аз түгел. Казанның Ленин рай-

нына барса да, ул аны тыныч кына карап йөри алмый. Аның да нигезенә беренче ташны 1932 елны Лотфулла ага салды. Ул чакта анда бушлык, ачык кыр иде.

Хәзер Ленин районына барган саен Лотфулла ага хәйран калып кайта. Нинди зур агачлар үскән. Биек-биек йортлар, мәктәпләр, больницалар, культура йортлары, стадионнар, зур-зур заводлар үсеп чыккан.

Әйе, бүгенге гигантларның күбесенең нигезе менә шулай, беренче бишьеллыкларга барып тоташа. Беренче ТЭЦ төзелешендә генә дә Миңнуллин бригадасы 17 мең кубометр бетон салды. Бу күрсәткеч ул чор өчен чын мәгънәсендә рекорд иде. Бригаданың даны бөтен республикага таралды. Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы үзенең 1932 ел, 25 ноябрь Указы белән ул җитәкчелек иткән коллективны республиканың «Кызыл китабына» кертте. Ә Миңнуллинга — Социалистик төзелеш Герое дигән мактаулы исем бирелде. Бер елдан соң, Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы атаклы ташчылар бригадасын Татарстан хөкүмәтенең Мактау Грамотасы белән бүләкләде.

«Красная Татария» газетасының 1935 ел 5 июль санында игълан ителгән указын шатланып укыган көннәрен Лотфулла ага яхшы хәтерли. Анда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы карары белән «III Интернационал» исемендәге колхоз председателе Әхмәтҗановага һәм Казгрэс бетончысы Миңнуллинга Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Грамотасы бирелүе турында хәбәр ителгән иде.

Бу грамота Лотфулла агага аеруча кадерле. Аңа Михаил Иванович Калинин үзе кул куйган.

Тормыш юлына күз салганда, күңел сөенерлек якты истәлекләр шактый икән. 1932 елны Мәскәүдә Бөек Октябрь социалистик революциясенең 15 еллыгына багышланган тантаналы җыелышта катнашуы һәм шунда партия һәм хөкүмәт җитәкчеләрен күрү бәхете дә шундый ук кадерле истәлекләрнең берсе. Тагын бер елдан ул Михаил Иванович Калининны колхозчы ударниклар съездында — Казанда кабат очратты.

Әйе, «гомерем ничек узды икән!» дип борчылырлык урын юк Лотфулла агага.

...Ул, уйларыннан аерылып, башын күтәрде. Клуб тулы халык. Каршында хезмәттәшләре, дуслары утыра. Заманында аның бригадасында бетончы булып эшләгән кешеләр дә байтак. Әнә — Гадел Камалов, Һади Галимҗанов, Баһаутдин Җамалетдиновлар... Хәзер инде алар бетончы түгел, кайсы өлкән машинист, кайсы смена начальнигы, кайсы инженер. Лотфулла ага үзе дә әнә шул баскычларны узып, директор урынбасарына кадәр үсте. Бу вакыт эчендә ТЭЦ та бер урында тормады. Аның да куәте 20 меңнән 55 мең киловаттка кадәр артты. Якындагы елларда ул энергияне бүгенгегә караганда өч мәртәбә күбрәк бирәчәк. Ләкин шунысы берникадәр үкенечле. Лотфулла ага инде картайды, бу үзгәрешләргә инде ул үзе катнаша алмый. Эстафета хәзер аның улы Дилфрудларга күчте. Әшне хәзер алар башкара. Дилфруд, әтисе юлыннан китеп, энергетик булды. Димәк, Миңнуллиннар буыны һаман сафта — энергетика системасында.

Лотфулла ага Миңнуллинны ялга озатуга багышланган тантаналы кичә дәвам итә. Трибунага ул нигез салган беренче ТЭЦ вәкиле күтәрелде.

— Хөрмәтле Лотфулла ага! — диде ул, аңа карап.— Безнең якын дустыбыз һәм иптәшебез. Без сезгә киләчәктә дә узган тормыш юлыгызны бизәгән илһамның юлдаш булуын телибез. Зиһен һәм хәтерегез, киң колачлы хезмәтегез бездә эшләгән еллардагы кебек матур шытымнар бирсен!

Залда көчле алкышлар яңгырый. Бүгенге гигантларның нигезен салуга үзеннән зур өлеш кертКән хезмәт ветеранын котлыйлар, тәбриклиләр. Әйтерсең, аны ялга озатмыйлар, ә сафка кайтуын бәйрәм итәләр.

«Татарстан күпме производство алдынгылары һәм новаторларының данлы исемнәрен бирде. Аның героик эшләре елъязмасына тимерче И. Никулин, төзүче Л. Миңнуллин... исемнәре керде»,— диде КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев үзенең Бөек Октябрьның илле еллыгына багышланган тантаналы җыелыштагы речендә.

Әйе, хезмәт батырларын ил олылый да, зурлый да.

# НӘРИМАН НӘРИМАНОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ

1913 ел. Астраханьның демократик фикерле яшьләре, реакциянең каты басымына карамастан, татар-ногай халыклары арасында культура чаралары уздырырга тырышалар. Бу чараларны уздыруда аларга шәһәрнең революцион карашлы укымышлылары, интеллигенциясе ярдәм күрсәтә, җитәкчелек итә.

Культура чараларының җанланып китүенә ул елларда Астраханьда сәяси сөргендә яшәүче әзербәйҗанлы, зур революционер, галим, язучы Нәриман Нәримановның йогынтысы зур иде.

Нәриман ага, миллэтенә карамый, барча кешеләрнең дөньяга карашын үстерү өчен зур тырышлык күрсәтә иде. Татар-ногай массасына лекцияләр дә укый, сәхнәдән башкарыла торган культура чараларына да җитәкчелек итә, аларның эчтәлекләрен революцион мотивлар белән сугарып, халыкка җиңел үзләштерерлек итеп үткәрергә ярдәмләшә. Аның бу сыйфатлары турында мин шагыйрь Сәгыйть Рәмиев һәм укытучы, язучы Хөсни Кәримнән еш ишетә идем. Алар Нәриманов уздыра торган чараларның берсеннән дә калмый йөрипәр, аны: «Арслан йөрәкле кеше»,— дип атыйлар иде.

Бер бәйрәм уңае белән уздырылган әдәби кичәдә миңа аның белән якыннан күреп танышырга туры килде. Аның зур культура иясе, галим кеше икәнлеге бөтен торышыннан, мөгамәләсеннән күренеп тора иде. Ул үзен һәркем белән гади тота, бу әле балалыгы чыгып бетмәгән яшь кеше, дип карамый, зурларга күрсәткән илтифатны яшьләргә дә күрсәтә, аларның сүзләрен тыңлый, тиешле булган урыннарда хөтерләрен калдырмаслык сүзләр белән хаталарын төзәтә. Аның бу сирәк кешеләрдә генә була торган сыйфаты һәркемне үзенә тарта иде.

Әдәбият кичәсендә катнашырга мине Сәгыйть абый чакырды.

— Анда мин нәрсә эшләрмен соң! — дип сорагач, ул:

— Анда барыбызга да эш табылыр, кичә яшьләр көче белән уздырыла,— диде.

— Сәгыйть абый, мин бик барыр идем, тик минә әти дә, әни дә минем спектакльләрдә катнашып, кичәләргә барып йөрүемә каршылар бит. Әти бик кырыс кеше, «Йөрисе түгел, әнә сабагыңа йөрисең, шул җитәр»,— дип кисәтеп куйды инде,— дидем.

Сәгыйть абый минем бу сүзләрне кашын җыерып тыңлады да:

— Ярар, катнашырга теләгең булса, мин әткәңнән рөхсәтне үзем сорармын,— диде. Аннары минем сүзгә артык әһәмият бирмәгән кебек:

— Син шулай да Тукайның «Бәйрәм бүген» дигән шигырен өйрәнеп куй, насыйп булса, кичәдә шул шигырьне сөйләрсең,— дип өстәде.

Ул килеп сөйләшкәч, әти каршы килмәде.

Көне килеп җиткәч, «Җәмгыяте хәйрия» йортына бардым. Мин килгәндә, бер төркем ирләр, аяк өсте торып, шаркылдап көлә-көлә, укытучы Шәһит Гайфинең сөйләгәнен тыңлыйлар иде. Аннары белдем: ул сөйләгән маҗара Хөсни Кәримнең «Калмык сахрасында» дигән хикәясендә тасвирланган икән.

Шәһит абзый минем дә килүемне күреп: «Аман килдеңме, чырагым! Кил, уртада бул»,— дип, мине үзләре янына чакырды. Мин таныган кешеләрдән монда Шәһит Гайфи, Хөсни Кәрим, ул вакытларда Астрахань халкына һәвәскәр артист буларак танылган Зәйни Солтанов бар иде. Башкалары таныш түгел, хәзер дә исемнәре хәтеремдә сакланмаган. Араларында Сәгыйть абый гына күренми иде. Озак та үтмәде,

ишектән бик мәһабәт кыяфәтле бер кеше белән Сәгыйть абый да килеп керде. Җыелган халык аларны, бигрәк тә әлеге мәһабәт кыяфәтле кешене, зур илтифат, ихтирам белән каршы алдылар. Барысы белән дә исәнләшеп чыккач, Сәгыйть абый ул кешегә:

— Нәриман әфәнде, рәхим итегез,— дип өстәл янына утырырга урын тәкъдим итте һәм башкаларны да өстәл тирәсенә утырырга өндәде. Миннән башка, урта мәктәптә укучылардан, тагы ике кыз килгән иде. Без, өстәл тирәсендә утырган халыкның әңгәмәсе нәрсә турында барачагын белергә тырышып, сүзләре ишетелеп торырлык урынга урнаштык. Сүзләр ишетелә, аңыбыз җиткәнчә, аңлап та була. Тик Нәриман аганы аңлавы читенрәк. Ул татарча аз сөйли, аны да әзербайҗан акценты белән сөйли. Русча сүзләре ачык, салмак, аңларга җиңел. Сәгыйть абый, рәис вазифасын үтәүче буларак, башлап сөйләүне аңа тапшырды.

Нәриман ага яшьләрнең әдәбият кичәсе уздырырга уйлауларын, хосусан аны бәйрәм көннәренә туры китереп уздырачакларын бик урынлы һәм дөрес дип тапты. Уздыра торган кичәбездә аерым бер максатны алга куярга кирәклеген әйтте. «Минем фикеремчә, ул максат — яңалыкка, мәгърифәткә омтылу идеясе, искелеккә каршы көрәштән гыйбарәт булырга тиеш,— диде.— Бәйрәм көннәренә туры килгәндә, кичәгездә халыкның күп булуы бәхәссез. Шуның өчен кичәдә ишеттерергә уйлаган әдәби материаллар да алдыгызга куйган максатыгызга муафикъ булырга тиеш»,— дигән фикерләрен белдерде. Ул күп сөйләде, бик мәгънәле сөйләде. Мин хәтеремдә калганнарын гына язам.

Аны кичәнең планы белән таныштырдылар. Анда күрсәтелгән әдәби материалларны күзәтеп чыккач, ул кайсы белән килеште, кайсыларын, тәнкыйть күзе белән карап: «Боларын мин кертмәс идем,— диде.— Искелеккә каршы көрәш коралы булырлык әдәбиятны оста кулланырга кирәк. Татар шагыйре Тукайның быел үлгән елы, әле аның кайгысы халыкның йөрәгендә яна. Менә кичәгә аның шигырьләрен күбрәк кертергә кирәк. Ул халык тормышындагы, аңындагы чынбарлыкны тасвирлаган шагыйрь. Аның күп шигыре искелеккә, наданлыкка, бозыклыкка каршы юнәлдерелгән. Тукай — ул идея көрәшчесе, искелекнең тамырларын корыту өчен тормышның ямьсез якларын сурәтләүче. Бу ягы белән ул Гогольне хәтерләтә. Менә сез монда Сәгыйть әфәнденең «Таң вакыты»н кертмәгәнсез. Татар дөньясының искелек, наданлык эченнән чыга алмый ятуында, аңарга комачаулык иткән сәбәпләрне кем ача! Минемчә, иң элек, без моны Тукайда күрәбез. Сәгыйть Рәмиевнең «Таң вакыты» моңа өстәмә булып тора. Без уздыра торган чаралар халыкның миен искелектән, наданлыктан чистартырга ярдәм итсен! Яңа фикерләргә, иҗтимагый хәрәкәткә юл ачсын иде. Менә шулай, дуслар!»

Мин аның сүзләрен йотлыгып тыңлыйм. Хәтта соңрак аның белән очрашкан көннәрдә алган тәэсиремне, аның сүзләрен язып бара торган булып киттем. Аңлашылмаган урыннарын мине үзенең шәкерте итеп карый торган Хәсни Кәримнән сорый идем.

Шулай фикер алышудан соң, ул, кичәнең идея җитәкчесе булып, утырыш беткәнче безнең арада калды. Аның монда утыруы сәбәпледер дә, бәлки, кичә бик уңышлы үтте.

Кичәдә укырсың дип кушылган «Бәйрәм бүген» дигән шигырьне Сәгыйть абыйга укып караган идем, ул мине тыңлады да:

— Юк, юк, болай сөйләргә ярамый, бу гади сүз тезмәсе булып кына яңгырый. Шигырьне укыганда аваз төрләнешләренә игътибар итәргә кирәк,— дип, үзе укып күрсәтте.

— Мин бит, Сәгыйть абый, сезнең кебек сөйли алмыйм, миннән булмый,— дигән сүземә ул ачуланды:

— Булмый дигән сүзне уеңа да китермә,— диде.— Булмый дигән сүз — юк сүз.

Миңа карышырга урын калмады. Шул арада безнең янга Нәриман ага килеп тукталды. Ул, миңа ягымлы елмаю белән карап:

— Туташ, артка чигенергә ярамый! Без яши торган гасыр фәкать алга баруны гына таләп итә. Артка чигенү йомшаклыкны күрсәтә,— дигәч, мин бу әхлакка сыймаслык тискәреләнүемә оялып, икесеннән дә гафу үтендем. Өйгә кайтканда, мине озатып барган Хәсни Кәримгә бу авыр тойгым турында сөйләдем. Ул мине юатып:

— Аның өчен ул кадәр борчылма, тик яхшы сабак дип кенә кара, ул безнең арада зур галим, педагог кеше, тирәсендәге халыкка яхшы йогынты ясауны, тәрбияләүне үзенә бурыч итеп куйган кеше,— диде.

Кичәгә Астраханьда яшәүче әзербәйҗанлы культура һәвәскәрләре дә катнаштылар. Алар бер пәрдәлек комедия куйды. Пьесаның исеме хәтеремдә калмаган. Сюжеты бай белән хезмәтче арасында өзлексез бара торган конфликт турында иде. Комедия буларак оста язылган пьеса иде ул. Аны уйнау шартларын җиткереп сәхнәгә куюга Нәриман ага күп көч салды.

Нәриман ага турында сүз барганда, Сагыйть абыйның: «Ул зур галим, әдип, гади әдип кенә түгел, революционер әдип. Ул җәмәгатьчелек хәрәкәтенең мәгънәсен яхшы аңлап, аның эчтәлегенә зур әһәмият бирә. Халыкның аң-белемен мөмкин булган юллар белән үстерергә тырыша. Ул шул юл белән революцион эш алып бара»,— дип сөйләве хәтеремдә калган.

Икенче бер әдәбият кичәсен Астраханьның кышкы театрында уздырдылар. Халык күп килде. «Билет җитмәде»,— дигән хәбәр бик тиз таралды.

Кичәдә конферансье вазифасын Шәһит Гайфи башкарды. Ул сүзгә бик оста кеше, кайсы бер чыгышларга аңлатмалар биреп, халыкның игътибарын туплый иде.

Үзе дә Тукайның «Дөньяда торыйммы дип киңәшкән дустыма» дигән шигырен зур осталык белән сөйләде. Нәриман ага аны:

«Наш конферансье на высоте своего дела»,— дип алкышлап мактады. Ул һәркемнең күңелен күтәрә торган сүзләр белән рухландырып утырды. Ул әле бер кеше янына, әле икенчесе янына барып, аның әзерлеге турында, кәефе турында сорашты, каушабрак калганнарны:

— Бывает, все пройдет, все будет хорошо,— дип юатты.

Сәхнәгә чыгарга чиратымны көтеп торганда, ул минем янга килеп:

— Каушап калдыгызмы әллә! — дип сорады. Мин, башымны селкеп, хәзер елап җибәрергә әзерләнгән бала кебек: «Әзрәк бар»,— дидем.

— Сез бит, минем белүемчә, урта мәктәптә укыйсыз. Анда кичәләрдә катнашканда каушамыйсыздыр бит! — диде.

— Анда бит көндә күрә торган үз кешеләр.

— Монда да бит үз халкыбыз. Мәктәбегездә үзегезне ничек хис итсәгез, монда да шулай сизегез, бар да яхшы булыр!

Аның бу сүзләре, киңәшләре ярдәме белән мин үз чыгышымны җиңел башкардым.

Кичәнең күңелләрдә тирән тәэсир калдырган бүлеге — Сагыйть абыйның «Таң вакыты» әсәре булды. Ул бик борынгы карт рәвешендә ап-ак озын сакал таккан иде, шундый ук — ап-ак чәч, кашлар, ап-ак мыек. Үзе ак җөббәдән, башында ак каләпүш сыман нәмәрсә. Зур кайгы баскан рәвешле ишарәләр белән, ул чып-чын мәгънәсендә дин сөреме белән томаланган, яктылыктан йөзләрен чөергән кайбер татарлар өчен, аларның гамьсезлекләренә акылдан шашардай булып борчылуын белдерә. Сагыйть абый шигырьне бик зур пафос белән, гаҗәп оста сөйләде. Нәриман ага аны кочаклап:

— Афәрин! Сагыйть әфәнде,— дип тәбрикләде.

Нәриман ага бу шигырьнең композициясенә килешле декорация һәм бутафория эшләтте. Прожекторлар яктысы белән таң атуы, кояш чыгуы күрсәтелде.

Соңыннан, ул чыгышын хәтергә алып сөйләгәндә Сагыйть абый: «Мин алай булыр дип уйламаган идем, Нәриман ага ярдәм итте»,— дия иде.

Хөсни Кәрим җитәкчелегендәге хорның Тукайның «Милли моңнар»ын җырлавы зур уңыш белән узды. Ул үзе, оста җырчы буларак, көйләрне матур башкаруга әһәмият бирә иде. Хор ул үзе укыта торган шәкертләрдән төзелде. Без кызлар да кушылдык. Ул хорда җырлаучыларның тавышларын яраштырып килештерүгә зур көч куйды. Хөсусан, бу килештерү Тукайның «Милли моңнар»ында бик матур, тамашачылар сүзе белән әйткәндә, «йөрәкләрне тетрәткеч булып яңгырады».

Әдәбият кичәсе бик уңышлы узды. Тамашачылар урыннарыннан алкышлау белән генә канәгатьләнмәделәр, үз араларыннан сәхнәгә вәкилләр чыгарып та кичәне оештыручыларга рәхмәт әйттеләр...

ЗӘЙНӘП КӘРИМОВА

# ФАТИХ КӘРИМИ

*(Тууына 100 ел тулу уңае белән)*

Фатих Кәрими 1870 елның 30[18] мартында хәзерге Татарстан республикасының Әлмәт районы Миңлебай авылында заманының прогрессив карашлы кешесе Гыйльман Кәримов семьясында туган. Байлыгы зур булмаса да, Гыйльман ага балаларын укытырга нык әһәмият биргән. Чистай мәдрәсәсен тәмам итеп, мөдәррислек таныклыгы алган олы улы Фатихны мулла итәргә теләмичә, дүрт ел Истамбул университетының «мөлкия» мәктәбендә[1], аннары алты ай Мәскәүдәге бухгалтерия курсларында укыткан. Соңыннан Петербургка Ильяс мирза Бураганский типографиясенә җибәреп, китап басу һөнәренә өйрәткән.

1899 елда Фатих Кәрими, Оренбургның зур бае Шакир Рәмиевнең тәрҗемәчесе сыйфатында, Европа буйлап сәяхәт итә, Көнбатышның техникасы, гыйлем-мәгърифәте, тормышы белән таныша. Шулай итеп, Ф. Кәрими күп төрле телләр (русча, фарсыча, гарәпчә, французча, төрекчә, хәтта бераз латынча), химия, физика, математика, тарих, география, педагогика һ. б. фәннәрне белүче киң карашлы мәгърифәтче-галим булып җитешә. XX йөз башында бездә бу сыйфатларга ия булган кеше юк иде. Шундый белем байлыгы белән коралланып, ул Россиядә яшәүче татар һәм гомумән төрки телле халыкларга гыйлем-мәгърифәт орлыгы чәчүгә керешә. Мәсәлән, укытучылар әзерләү өчен Оренбург Каргалысында педагогия курслары оештыра[2], Оренбургның пычрак подвалында, атасы белән бергәләп, кечкенә бер типография ача һәм шунда әдәби, фәнни китаплар бастыра башлый.

Фатих Кәриминең иҗат эшчәнлеге күп кырлы һәм катлаулы. Ул — язучы, журналист, төрле фәннәр буенча дәреслекләр төзүче, педагог, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе.

Язучы Ф. Кәрими, көчле сүз художнигы булудан бигрәк, рационализм һәм критик реализм вәкиле сыйфатында таныла. Ул татар җәмгыятен басып торган наданлык һәм шуның учагы булган иске тип татар мәктәп-мәдрәсәләрен, аларның башында торучы кадимче ишан, мулла һәм байларны, шул мәктәп-мәдрәсәләрдә укып кешелек сыйфатын югалткан шәкерт һәм хәлфәләрен, суфи һәм казыйларын накъ булганынча, дөрес итеп укучы күз алдына бастыра.

1904 елда басылган «Европа сәяхәтнамәсе» исемле әсәре аркылы Ф. Кәрими Россиядә яшәүче төрки телле халыкларны Көнбатыш Европа тормышы белән таныштырды. Бу әсәрен Ф. Кәрими гади бер ил гизүче сыйфатында гына язмый, бәлки Европадагы тормыш-көнкүрешнең аерым детальләрен татарның шул замандагы тормышы, гореф-гадәте белән чагыштырып та бара.

Оренбургта 1906 елда Ф. Кәрими редакторлыгында «Вакыт» исемле газета, Р. Фәхретдинов редакторлыгында 1908 елда «Шура» исемле әдәби-гыйльми журнал чыга башлый.

1912 елның көзендә Ф. Кәрими «Вакыт» һәм «Шура» редакциясенең махсус хәбәрчесе булып Истамбулга китә һәм Балкан сугышы вакытында Төркия тормышы

---

[1] Мөлкия мәктәбе — Истамбул университетының дәүләт эшчеләре (чиновниклар) әзерли торган факультеты.

[2] Бу курслар 1889, 1890 һәм 1891 елларның җәй айларында эшли. Курска Россиянең төрле өлкәләрендә эшли яки эшләргә хәзерлекле яшьләр килә.

турында күп санлы очерк-хатлар яза. 1914 елда аның бу очерклары, 45 басма табак зурлыгында, аерым китап булып басылып чыктылар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан яхшы каршы алындылар. Г. Тукай бу хат-очерклар турында: «Әнә «Вакыт» мөхәррире Фатих әфәнде Төркиядәге вакыйга һәм хәлләрне гүя тере җанварлар тоткан кебек җанлы итеп кара диңгез аркылы йөздереп җибәргән диярлек фельетоннар яза. Аларны «Вакыт» идарәсендә пешереп, халык өстәленә җан азыгы итеп куялар»,— дип язды.



«Вакыт» һәм «Шура» үз чорының прогрессив кешеләре каршында зур авторитет белән файдаланды. «Вакыт»ның баш мәкаләләрендә,— дип язды Г. Тукай,— милләтне иң йөдәткән, иң аптыраткан мәсьәләләрендә тиешле юллар күрсәтелә». Галимҗан Ибраһимов 1913 елда Ф. Кәримигә язган хатында:

«Халык күп турыда сезнең ишарәгә дикъкать итәргә өйрәнгән. Идарәбез исеменнән (сүз «Аң» журналы идарәсе турында) Сездән шул сөальгә (милләт мәсьәләсе турында) бер-ике сүз, бер-ике җөмлә белән булса да җавап язуыгызны үтенәм. Әгәр дә озын язачак булсагыз, безгә аерым бәхет булачак»,— ди. Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин.

Ф. Кәрими «Вакыт» һәм «Шура» журналларында эшләү белән генә чикләнмәде. Ул поляк язучысы Ф. Пуцековичның төрле халыклар турындагы 40 брошюрасын тәрҗемә итеп, шуларның утызлабын бастырып чыгарды. Ләкин ул бу китапчыкларны механик тәрҗемә итү белән генә чикләнмәде, бәлки төрле халыкларның тормышын татар халкы тормышы белән чагыштыра да барды. Тарих, география буенча китаплар язды, укытты.

1917 елгы февраль революциясеннән соң Ф. Кәрими Вакытлы хөкүмәтнең политикасын нык тәнкыйть итте. Вакытлы хөкүмәт башлыгы Керенскийны империалистик буржуазиянең приказчигы» дип атады.

1917 елның сентябренә чаклы Ф. Кәрими З. Рәмиевкә хезмәт итә. Ләкин 20 сентябрьдә, Оренбург типографиясе эшчеләренең гомуми забастовкасы һәм Ф. Кәриминең эшчеләрне яклавы һәм аның бу чордагы политик позициясе уңае белән, аны үзе оештырган һәм 12 ел хезмәт иткән «Вакыт»тан китәргә мәҗбүр итәләр. 1 ноябрьдән Ф. Кәрими «Яңа вакыт» исемле икенче газетага күчә.

1918 елның язында, Оренбург Советлар кулында чакта, Ф. Кәрими «Яңа вакыт»ны чыгаруны дәвам итә. Ул шулай ук яшьләрнең әдәбият түгәрәгенә булыша, аларның җыентыкларына «Рәсем, шигырь, музыка» исемле озын мәкалә яза, җыентыкны «Яңа вакыт» типографиясендә бастыра. Шушы түгәрәкнең юлламасы белән 1922 елда Муса Җәлил Казанга килә.

1919 елның январенда Дутов Оренбургтан бөтенләй куылгач, Ф. Кәрими анда чыккан «Эшчеләр дөньясы», «Юл» һ. б. совет газеталарының редколлегия члены булып эшли, халык мәгариф институтында, башкортлар техникумында, казакълар өчен оештырылган курста укыта, балалар тәрбиясе турында «Иҗтимагый тәрбия» исемле китабын һәм 1925 елда Казанда Сайланма әсәрләрен бастыра. Аннан Мәскәүгә күчеп, Центриздатта эшли, көнчыгышны өйрәнү институтында төрек теле укыта. Мәскәүдә чакта да Ф. Кәрими яшь язучылар белән бәйләнешен өзми, аларга төрле киңәшләр бирә, укырга, белемнәрен күтәрергә өнди. Дәрдмәнднең 1929 елгы «Яңалиф» нәшриятында чыккан бер томлыгын төзүдә катнаша, аңа шагыйрьнең биографиясен язып кертә. Ф. Кәрими 1937 елның 27 сентябрендә 67 яшендә үлә.

Хәй ХИСМӘТУЛЛИН,
филология фәннәре кандидаты

# *УКУЧЫ СҮЗЕ*

Күренекле прозаигыбыз Фатих ага Хөснинең тагын бер яңа җимешеннән авыз иттек. «Казан утлары» журналында[1] аның «Гыйльменисa» повесте басылып чыкты. Әсәр, нигездә, Ф. Хөснигә хас җор телле, тормышның, бигрәк тә авыл тормышының, бөтен нечкәлекләрен белеп язылган. Повестьта гыйбрәтле вакыйга алынган. Бу шактый катлаулы, тормыш ситуацияләренә бай әсәр. Ф. Хөснинең «Гыйльменисa»сын укыганчы Рафаэль Мостафинның «Казан утлары»нда басылган «Үз көең булсын» дигән зур күләмле әдәби тәнкыйть мәкаләсен карап чыккан идем. Р. Мостафин анда Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» повестенда Әлбинә образын кимсетеп бирүен искәртеп киткән иде. Мин аның белән килешәм. Хәзер ул дөрес әйтә: «безнең заманда бу мәсьәләгә караш-мөнәсәбәт шактый үзгәрде төсле».

«Гыйльменисa»ны укыгач, миндә шундый фикер туды: яшәп килгән тормышка, кыргый йолаларга протест итеп алырдай мисаллар хәзер генә түгел, революциягә тикле дә булган икән бит. Шул авыр тормышның бөтен газапларын үз җилкәсендә татыган Гыйльмениса мисалында моны ачык күрергә мөмкин. Кияүгә чыгып бер-ике ай тору белән «характерлары туры килмәгәнлектән», тизрәк әти-әнисе өенә йөгереп кайтучы, әтисез баласын олы яшьтәге үз әнисенең муенына тагып, үзе «кыз»га әверелеп чабучы кайбер йөгәнсез яшьләргә зур сабак булырлык әсәр бу, минемчә.

Җыеп кына әйтсәк, әсәр бик әйбәт, бик гыйбрәтле, бихисап матур-матур детальләргә бай.

Сәмигулла ХӘЙРЕТДИНОВ,
КПССның Мамадыш райкомы
инструкторы.

---

[1] № 4, 1969 елда.

# ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

## Фатих Хөсни

# КАРА КОФЕ

хикәя

*Г. Халиткә*

### I



Мин — көньяк курортларының берсенә ялга китеп барышлый, ул — хезмәт командировкасы буенча Мәскәү юлында без бер купега туры килдек һәм, әллә ни көч сарыф итмичә генә, танышып киттек. Юлдашым урта яшьләрдән узган, хезмәт юлын гади авыл укытучысы булып башлаган, хәзер дә әллә кая сикермәгән, кечерәк бер фәнни-тикшеренү институтында урта кул сотрудник булып эшләүче, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «чалбар төбе шомартудан узмаган», ләкин тормышны шактый күргән, бәлки шул сәбәптәндер, җирдәге хәл-әхвәлләргә ничектер юмор аша карарга өйрәнгән бер кеше булып чыкты.

«Сез кайдан?», «Мин шуннан!» кебек гадәттәге танышып китү сүзләреннән соң ук, әңгәмәбез һич ясалмасыз башланып китте.

— Юлда чәй дә чәй инде... Өйдәге кебек җиренә җиткереп пешерелгән булмаса да, бугаз пешекләргә ярый,— дип ташладым мин, проводница китергән болганчык чәйгә теләр-теләмәс кенә иренемне тидереп.

— Бәлки, сезгә кара кофе заказать итәргә кирәк булгандыр,— диде юлдашым. Бу сүзләрнең әйтелешендә үк ниндидер эчке бер мыскыл яшерелгән иде, шуны мин үз адресыма алмагаем, дип уйлап булса кирәк, ул тизрәк аңлатып бирүне кирәк тапты.

— Дөнья булгач очрыйсың икән... Туры килдем мин үз гомеремдә кара кофе җене кагылган бер адәмгә. Просто ник туры килдем дигән көнгә төштем.

Юл озын, йокларга иртә, юлдашым сөйләргә, ә мин тыңларга ярата торган кеше булып чыктык, кыскасы, вагон бара келтер-келтер, бу китте башыннан узганны тезеп:

— ...Мин ул чагында йомырка кабыгыннан тишелеп кенә чыккан бер авыл укытучысы идем. Ахрысы, чыкканда ук бераз чирләшкәрәк булганмындыр, шулай да сөйкемсез үрдәк баласы булдым дип әйтмәс идем. Сөйкемсез үрдәк баласы булган булсам, Кырымга бесплатно путевка эләгер идеме соң. Ә бу «бесплатно» дигәнем соңыннан минем җилкәгә ике бәя булып төште. Ашыктырмагыз, хәзер шул турыда башлыйм сүзне:

...Шулай, менә хәзерге кебек барып ятканда, килеп керде минем купега ак якалы бер адәм. Аякта ялык та йолык лаклы ботинка. Чалбарның сырлары, ачуым килмәгәе, ипи кисәргә ярарлык. Җилетта сәгать чылбыры. Макинтош энәдән-җептән генә. Салгач, кая әләргә белмичә, бер мәл аптырабрак торды бу. Аннары шыгырдап торган хром чемоданын ачып, аннан элгеч чыгарды и, киереп-торып, минем баш очына китереп элмәсенме!

Мин инде, әлбәттә, сүз катты юк, бер почмакта сеңеп кенә утырмыш. Буш килгән путевкаң, и башланмас борын ук: «Бетәм! Бетәм!» дип кесәңдә җылап торган акчаң белән шундый мәһабәт адәмгә ничек сүз катмак кирәк? Хәер, ул үзе дә миңа сүз катып мәшәкатьләнмәде. Утырды. Ап-ак кульяулыгы чыгарып пеләшен сөртеп алды. Мыегын бөтерде. Аннары бер миңа, бер чемоданына күзен йөрткәләде. Бераз гарьләндем, әй. «Миннән шикләнә, ахры, бу» дигән уй күңелне тырнап үтте. Ну, мин дә сер бирде юк. Утырам, и вагон селкеткән шәпкә тегенең макинтошына ышкылам. Башласа, сүзне шуннан башласын, сдача кайтарырга миндә дә «ваклар» әзер.

Юк, аннан башламады. Менә сезнең кебек, проводница китергән чәйне яманлаудан башлады: янәсе, суынган, болганчык, бернинди ароматы юк, и шулай алга таба да алга таба...

Ул сукрана дип чәйне алыштырып китерүче булмады, бу чаклысы тәк и тәк аңлашыла торгандыр. Суык чәйне шупырдата бу, ә үзе кызганнан-кыза бара. Беләсезме, нәрсәне элеп алды аннары? Кара кофе дип элеп алып китте аннары. Ара-тирә үз сүзеннән үзе кодрәтләнеп, кулны ышкып куя. Ап-ак бармаклары «шырт-шырт» сына. Ул да түгел, иреннәрен чәпелдәтә. Янәсе, кофеның нинди генә сортлары юк. Кайсы илдән, нинди тарада, нинди этикеткалар белән килә. Ароматы саклансын өчен кофены ничек, нинди утта пешерергә кирәк. Аның, лично үзенең, кайсы сорт кофеларны авыз итеп караганы бар и нинди зат кешеләр табынында... Шулай китте, китте бу фани дөнья тәкәсе, минем әзерләп куйган «ваклар» гел торып калды. Кофе турында болай төчеләнеп сөйләгәне өчен генә кешенең авызына чәпәп булмый ич. Сөйләнә бирсен. Үзем тыңлаган атлы күренеп утырам, ә үзем тегенең макинтошына ышкыла бирәм.

Шулай да — адәм баласы хатадан хали түгел бит — кара кофе турындагы очсыз-кырыйсыз әкиятләре белән колак итемне бик ашый башлагач, мин — беркатлы хәлфә абый — ничектер телгә килгәнмен. Бер дә орып-бәреп түгел, бик тә киртәсенә кертеп, культурный итәргә тырышып әйткән идем кебек, югыйсә.

— Кырым ягына барабыз ич, кофедан без дә авыз итәрбез әле,— дигән идем. Бары тик шулай гына дигән идем, факыр, җитә калды бит абзыкаема. Тотынды бу миңа очып кунарга.

Юк, очып кунудан элек пиджагын салып элде. Әле пиджагына, әле миңа сүзсез генә бер мәл карап торды. Аннары пиджагын, элгән җиреннән алып, пөхтәләп кенә астагы ящикка, чемоданы өстенә таслап куйды. И шуннан соң, яңа көч туплап дигәндәй, мин ялгыз үрдәкне чукырга тотынды. Аның, кызып-кызып и мин аңламый торган заграничный сүзләр кыстыргалап, мин сакаллы сабыйны шәп кенә каезлавыннан соң, местком путевкасы белән курортка баручы без фәкыйрегез, иң

элек, кара кофе мәсьәләсендә гомумән бер нәрсә дә белми торган һәм, аннан килеп, Кырым турында, бигрәк тә хәзерге заман Кырымы турында, бөтенләй сай йөзүче шәкерт булдык та калдык.

Шәкерт булсам булдым, заграничный сүзләрне бик тә авыз чәпелдәтеп яудыручы бу укымышлы Ак яканы артык тилертү юлына басмадым. Ул кара кофе и аның сортлары, и аны пешерү, нинди чәшкәдән эчү ысуллары турында сөйләнә калды, мин йоклап киткәнмен.



## II

Мин, әлбәттә, иртә уяндым. Хатын сыер саварга торганда, кирәк булса да, булмаса да, сикереп аякка басарга өйрәнелгән. «Кара кофе» бик рәхәтләнеп йоклый иде әле. Игътибар иткәнем шул булды: яка, галстук, костюм, макинтош яклары бик шәптән булса да,— кеше күзе төшми торган җир бит — носкиена күзе җитмәгән моның. Ноские яхшы ук керләнгән и ул аны салып ятуны кирәк тә тапмаган. Ихтимал, одеал белән каплагач күренмәс дип уйлагандыр. Иртәнге тәмле йокысы вакытында одеалы ертылаш шуган, пычрак носкидагы аяклар аязда торып калган. Бигрәк тә шунысы истә: уң аягының баш бармагы, аеруча эрсезлек күрсәтеп, носкиен тишеп чыккан. «Мин монда! Хуҗам йоклаганда бераз якты дөнья күреп калыйм», дигәндәй, башын кәңкәйтеп миңа карап тора иде.

Мин йоклаган кеше өстенә карап торуны гомумән яратмыйм, бу очракта аның ул ирек сөюче аяк бармагына карап фәлсәфә корып торырга тамчы да дәртем кузгалмады. Ул торып киенгәнче дип коридорга чыгып киттем. Тәрәзәдән дөньяга — авылларга, кырларга, өсте кыеклап ябылган коеларга карап бардым: киң икән дә соң бу дөнья, малай! Ә түбәсе гел безнең авылдагы кебек. Зәңгәр күк тә, иген кырларын ударникларча кыздырып торучы якты кояш.

Шактый озак йөрдем, буфетка барып, тамакка кабып килдем. Инде торгандыр дип, купега барып керсәм, чынлап та торган, юынган. Алай гынамы соң! Ике күзем дүрт булды: агаем бәләкәй генә игәүләр белән тырнагын игәп утыра.

«Син, местком сөеклесе, сүзеңне үлчәп сөйләш, кеше әнә тырнак өчен дә тартмасы белән инструмент, тартмасы белән буяу йөртә. Имәндә икән чикләвек!» дидем мин, эчемнән генә үзем-үзем иртәнге сабакны биреп.

Ләкин, дөресен әйтим, үлчәп торырга да, үлчәмичә генә тондырырга да өлгермәдем, бу үзе тотынды. Минем белән сөйләшеп түгел, әлеге шул тырнаклары белән сөйләшкән кебек, җайлап кына тезә бу сүзләрне:

— До чего беркатлы халык китте хәзер,— ди бу, бармаклары белән эч серен бүлешеп,— имештер, Кырымга барасы да кара кофега муеннан чумасы. Хоть зат танымый торган кешегә әйт сүзне, хоть менә бу стенага әйт. Кырымда син, сәр, бигрәк тә хәзерге заман Кырымында, Кара диңгездә коенсаң коенырсың, но җиренә җиткереп пешерелгән, тиешле церемониясе белән бирелгән кара кофены таба алмассың.

Шулай да бөтенләй үк бетереп ташлавы булмаган икән, Симферопольгә җиткәч, поездан төшеп, вокзалга кергәч, бу мине кеше югырак бер почмакка тартып алып, яшертен серен чишкән кебек, әйтте миңа:

— Сез миңа ошадыгыз, егет. Нәрсәгез, кай ягыгыз белән ошаганыгызны точно әйтә алмыйм, но ошадыгыз,— әнә шулай эретә торган итеп башлады бу. Аннары, тавышын тагын да кыса төшеп, өстәде.— Менә шушы Симферополь шәһәрендә, аның да кеше таптамый торган аулак бер почмагында инде ул настоящий кара кофе. Һәм анда аны,

будь добр, китерәләр җиренә җиткереп. Әлбәттә, мондагы түгел, контрабанда юлы белән китерелгән мал. Барасы җиребездә пожар юк, багажларны камерага тапшырыйк та, әйдәгез, алып барыйм мин сезне шул аулак урынга.

Йа хода, тырнакны буяп йөрмәсәм дә, мин дә бит адәм баласы, кызыксынудан шырпыдай кабынып киттем.

Барганда извозчик белән, көймәле тарантаска утырып, байларча бардык. Ул чагында әле атлар почеттан төшмәгән иде, сугышка хәтле булган хәл бу. Олы урамнарны үттек, бер заман олысын-кечесен аерып булмый торган бер будкага килеп кердек. Бакча да бер катлы таш өйләр. Челтәрле рәшәткә дә алар буенда тар гына тротуарлар. Шул тар гына тротуарлардан, мин сиңайтим, түшле генә кыз-хатыннар үткәләпсүткәләп китә. Хәер, болары сүздән килеп чыккан сүз генә — мәсьәлә анда түгел.

Мәсьәлә шунда: бара торгач, килеп туктадык без әлеге ак йортларның берсенә. Вывескасы-фәләне юк, тавыш-тын шулай ук ишетелми. Төштек тарантастан, киттек кереп калиткадан. Өй эче, малай, болын кадәр дияр идем, болында бит аның кеше кулы белән тезеп куйган мондый зиннәтләре булмый. Аннары тагын болында мондый мимылдык, мондый текә сыйраклы, мондый көлеп торучы назлы-көяз чибәрләре дә сибелеп кенә тормый. Минем Ак яка хуҗа ханымның кулын үбеп кенә күреште. Ниндидер минем баш җитми торган сүзләр ымлаштылар.

Дөресен әйткәндә, болары сүздән килеп чыккан сүз генә — мәсьәлә анда түгел.

Мәсьәлә шунда: бер заман, җаным, челтәрдән-кружевадан күмелгән безнең хозяйка-кабартма көмеш подноска бәләкәй генә чәшкәләр утыртып китереп куйды безнең алга. Бу — шул, юл буе Ак яка мактап килгән әлеге кара кофе дигәннәре икән инде. Бик үк кабаланмыйм, кырын күзем белән генә Ак якага карыйм. Ул нишли, мин дә шулай эшләргә исәп. Теге кулын күкрәккә куеп һәм хозяйка-кабартмага мөлаем гына елмаеп башын иде. Аннары чәшкәне ике бармагы белән генә эләктереп, чәнчә бармагын яңа туган ай кебек өскә таба кәкрәйтеп, ирененең очы белән генә и бер дә шупырдатмыйча эчә башлады. Ат күзе чаклы гына шул бәләкәй чәшкәне, ачуым килмәгәе, әллә тагын ярты сәгать эчкәндер. Минеке, әлбәттә, алай чыкмады. Бармакны да айга охшатып булмады, авыз да тупас, иренгә тидерим генә дисәм, берьюлы йотканмын да җибәргәнмен.

Болары сүздән килеп чыккан сүз генә — мәсьәлә анда түгел. Мәсьәлә шунда: мактаулы кофе минем кече телгә дә йокмады, ә минем юлдашым шул бер чәшкә кара кофедан бөтенләй иләс-миләскә әйләнде. Күзләре калайланды, сүзләрен тотып кала алмас хәлгә килде, ике сүзнең берендә «пардон да пардон», хозяйка-кабартманың ак кулларын ялап кына тора. Бер араны алгы бүлмәгә чыгып, чак кына югалып торганнар иде, әллә шунда чынлап та тилертә торган берәр «контрабанда» кабып кергән инде...

Әкәмәт ягы тагын шунда: кузгалыр вакыт җиткәч, мин беркатлы, үзем эчкәнгә үзем түлим дип, кесәдән янчыкны гына чыгара башлаган идем, юлдашым-Ак яка, башын тәкәббер генә борып, миңа карап куйды. Шулай да, нихәтле генә беркатлы булсам да, бу караштан мин үземә кирәген, ягъни: «Миңа түләмәскә дә мөмкин икән!» дигән мәгънәне төшенеп алган идем инде.

Калганын юлдашым кайтырга чыккач өстәп төшендерде. «Дөнья күрмәгән шул син, авыл бәрәңгесе», дигән тәслерәк бер мәгънә төшендерде ул. Һәм телдән өстәп шуны әйтте.— Андый олы җирдә берьюлы икең дә янчык чыгару килешми, ваклык була,— диде.

## III

Моңарчы еракка чыгып йөргән кеше түгел, ул шау-шулы Ялта дигәннәренә барып төшкәч, мин бер мәл югалып ук калдым. Көннен иртәнге яртысы ярый да бара. Врачына-сестрасына йөреп, үлчәтеп, сула дигәч сулап, таблетка йотып, теге кабинетта билдән чишенеп, бусында анадан тума калып, ванна кереп, ваннасыннан чыккач, эшемне кырган кешедәй, ял бүлмәсендә йомшак диванга сузылып һәм шул сузылган җирдән сәгать-сәгать ярым «бүрәнә тарттырып» алулар белән обедны җиткерәсең. Эч пошарга, хатынны сагынырга вакыт калмый. Ә менә обедтан соңгысы яманның яманы: йокы туйган, корсак тулган, барыр җир юк, шул тирәдәге парк сукмакларын бер түгел, мең кат таптап үткәнсең, чибәррәк хатын-кыз сиңа карамый, чибәр түгеленә синең карыйсың килми, йөрисең шунда башына ис тигән кеше кебек. Ә тамак тук, өйдән чыгып киткәнгә байтак вакыт узган, сау тән, сау җан, дигәндәй, өйдә чакта хатын белән бергә баш куеп яткан ястык искә төшә. Аннары шундук хатын үзе күз алдына килеп баса, очып кайтып китәрдәй минутлар була, әкәмәт.

Атна-ун көн узгач булыр, шуннан да артык түгелдер, бер шулай шәһәр әйләнәсендә ялгыз-баш каңгырып йөри идем, иңенә чалгы күтәреп кайтып килүче бер гидайга тап булдым. Кырым, тау-таш арасы, чәчәкләр и яшь-җилкенчәкләр арасында разный анда кичке чыш-пышлар. И шунда, әкәмәт, чалгы күтәргән кеше. Дәррәү күңелем йомшап китте, авылга кайткан кебек булдым. Телем үк ачылды, бер дә белмәгән, күрмәгән кешегә: «Сезнең монда, тау-таш арасында, кайда соң болыныгыз? Чалгы белән селтәнерлек хет берәр уч төбегез бармы?» — дип сүз куштым. Авылын сагынган, чалгыны һәм хатынын сагынган адәм баласына икенче бер шундый ук адәм баласы белән танышып китү өчен күп кирәкми икән. Сөйләшеп, танышып киттек без моның белән. Җирле халык баласы булып чыкты бу, кашым-күзем ошагандырмы, әйтә алмыйм, шул бер очрашудан өенә кунакка апкитте мине. Болары сүз юктан чыккан сүз генә — мәсьәлә анда түгел.

Мәсьәлә шунда: нәкъ әнә теге вакытта, Симферопольдә, ат яллап барып, як-якка карангалап һәм, әлбәттә, авызны чылатырлык кына эләккән бәяле кара кофе кебек кара кофе белән сыйладылар болар мине. Мин шул, беркатлы авыл мөгаллиме, аны-моны уйлап тормастан:

— Сездә дә контрабандамы? — дип сорау бирүемне үзем дә сизмәгәнмен.

— Нишләп контрабанда булсын, үзебездә тулып ята,— дип җавап кайтарды хуҗа, чатлатып. Әллә минем сораугa хәтере калды, әллә мин-зур авыз хуш исле кара кофены чынаяк артыннан чынаяк коеп торганга, ничек кенә булмасын, җавапны бик чатлатып бирде хуҗа. Ә мин, үз чиратымда, мыекка шуны урадым: минем башны катырган Ак яканың сүзләре пүчтәк булып чыга бит бу килештән. Чын менә: кафеларда булсын, гади генә чәйханәләрдә яки колхозчы йортларында булсын, бер ияләшкәч, кара корсакка шактый күп чөмердем мин ул кара кофены.

Нилектән икәнен әйтә алмыйм, хикмәте-хода, тагын бер күрәсем килә башлады бит шул Ак яканы. Бәлки, юлда «Кара кофе! Кара кофе!» дип шапырынып, мин беркатлының башын әйләндергәне өчен үзеннән бер гөләсем килгәннәндер? Бәлки, Ялтаның кеше йөрми торган хәчтрүш бер чәйханәсенә алып кереп, үзен кара кофе белән күбенгәнче сыйларга теләгәнмендер? Ничек кенә булмасын, эчемдә кару саклый белмим, тагын бер күреп сөйләшәсем килә иде.

Тау белән тау гына очрашмый, диләрме әле, очраштык, әй. Ял итә торган Мисхорыннан туеп, көннәрдән бер көнне бу безнең Ялтага килеп чыккан. Набережныйда кеше арасында буталып йөргәндә, әллә кайдан

күреп, кочак җәеп каршыма килде. Кара кофе кыйссасын искә төшерергә өлгерми калдым, сүзне монда да ул башлады:

— Болай гына калдырмыйбыз бу очрашуны, коллега,— диде. Ни арада мин аның «коллегасы»на әйләнгәнмендер, ул турыда рәтләп уйларга бирмичә, бу шундук инициативаны үз кулына алды: мине такси остановкасына алып китте, иң элек мине утыртты, аннары үзе утырды.

— Башка бер җиргә дә түгел, «Тау башы»на,— диде, таксистка команда биреп. Мин болай үзем шат, ләкин, авызым колакта, дип үк әйтмәс идем. Ник дисәң, Ялтада унбиш көн торып, белгәнем-ишеткәнем түгел: нәрсә икән ул «Тау башы» дигәннәре?

«Тау башы» дигәннәре — шәһәрнең нәкъ кашына менгезеп, бик тә кыландырып салынган I нче разрядлы зур ресторан икән. Такси өчен Ак яка түләде, әйләнеп тора торган пыяла ишекләрдән башлап Ак яка керде, меню дигәннәрен иң элек Ак яка алды. Ап-ак алъяпкычлы, кыпкызыл иренле, нечкә билле һәм безнең эше, өйдән чыгып киткәненнән бирле, хатын-кыз заты күрмәгән кыргый бүреләрнең күзләрен яндырырлык итеп түш араларын күрсәтеп куйган сөйкемле официантканы, шулай ук, Ак яка чакырып китерде...

Шуннан соңгысы, ничектер, истә калмаган. Нәрсәләр ашаганыбызны белмим — ашалды. Нәрсәләр эчкәнебезне шулай ук белмим — байтак кына эчелгән дә булса кирәк. Истә калганы шул: төннең бер вакытында (шактый соң иде бугай инде), агаем, бу юлы аеруча энәдән-җептән генә киенеп килгән көләч чырайлы Ак яка агаем, гадәттәгечә авыз чите белән генә елмаеп, кешегә-карага һич ишеттермичә, колагыма иелеп әйтте:

— Мондый олы җирдә икең берьюлы янчык чыгару килешми, үзегез үк белергә тиеш,— диде. Мин иңке-миңкерәк торгач, өстәп тагын шунысын да әйтте:

— Тем более, теге вакытта мин чыгарган идем, исегездәдер.

Нишләмәк кирәк, бар булган байлыгымны чыгарып салырга туры килде шул. Иртәгесен: «Акчамны урлаттым, кайтырлык та калмады, ничек тә җыештырып җибәрә күр» дип, хатынга телеграмма суктым.

1969 ел

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

5 январьда партия өлкә комитетының конференц-залына язучылар, композиторлар, артистлар, художниклар һәм архитекторлар җыелды. Биредә республика иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумы ачылды. Докладчылар һәм чыгыш ясаучылар В. И. Ленинның 100 еллыгын, Татарстанның 50 еллыгын лаеклы каршылау, иҗат интеллигенциясе вәкилләренең иҗтимагый тормыштагы урыны, партия, халык алдындагы зур җаваплылыгы турында сөйләделәр. Советлар Татарстанының сәнгать осталары үзләренең олы бәйрәмнәрне иҗатта яңа уңышлар белән каршыларга җыенуларын, коммунизм җәмгыяте төзү эшенә тагын да активрак катнашырга омтылыш белән яшәүләрен күрсәттеләр.

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Ибраһим Гази әдәбияттагы партиялелек һәм халыкчанлык принципларына тукталды, милли һәм интернациональ үзенчәлекләр, аларның үзара бәйләнеше һәм бер-берсенә йогынтысы турында сөйләде. Докладчы татар совет әдәбиятының идея-эстетик үсеш дәрәҗәсенә, әдәбиятта Ленин темасын яктыртуга, Ленин идеяләренең тантана итүен ачыклауга зур игътибар бирде. «Татар совет әдәбияты,— диде ул,— илебездә барган мөһим вакыйгаларга һәрвакыт үзенең актив мөнәсәбәтен белдерә килде, татар әдәбияты һәрвакыт үзенең идея позицияләренең активлыгы белән аерылып торды. Татар язучылары Ленин васыятьләренә һәрвакыт турылыклы булдылар, партиялелекне һәм халыкчанлыкны үз иҗатларының нигезе итеп санадылар. Алар язган әсәрләрдә без авторның ачык позициясен күрәбез, язучы иҗатының төп юнәлешен, пафосын сизеп торабыз. Алар ил, халык язмышы белән яшиләр, хезмәт ияләрен дулкынландырган мәсьәләләр хакында язалар, халык кайгысын, аның шатлык-өметләрен уртаклашалар».

Революция сәнгатькә яңа сулыш өрде, аны коммунизмның югары идеаллары белән сугарды. Моны татар халкының музыка сәнгате үсешендә дә бик ачык күрергә мөмкин. «Композитор», «пианист», «оркестр» кебек сүзләр элек татар телендә гомумән юк иде. Республикабызның 50 еллык бәйрәменә татар совет музыка сәнгате зур уңышлар белән килә. Бездә музыка белеме бирүнең алга киткән бөтен бер системасы булдырылды. Татарстанда күп санлы музыка мәктәпләре, музыка училищелары һәм консерватория эшли. Безнең үз опера һәм балет театрыбыз бар. Милли опера һәм балет сәнгатенең тууы, музыкаль комедия жанрының үсеше шушы театр исеме белән бәйле. Татар халкы арасыннан гаять үзенчәлекле һәм талантлы композиторлар үсеп чыкты. Алар иҗат иткән җырлар һәм романслар, опера һәм балет әсәрләре, музыкаль симфонияләр киң илебезнең бөтен почмакларында яңгырый. Татарстан композиторлар союзы идарәсе председателе Нәҗип Җиһановның докладында сүз әнә шул мәсьәләләр хакында барды.

Татар халкының сынлы сәнгате дә чынчыннан бары тик Бөек Октябрь революциясеннән соң гына үсеп китә алды. Бүгенге Татарстан рәссамнары Россия Федерациясе художникларының зур отрядын тәшкил итә. Алар ясаган рәсемнәр күптән инде республика чикләрен үтеп чыкты. Безнең художниклар үзләренең бөтен талантларын бөек коммунизм төзү эшенә багышлыйлар. Соңгы елларда алар «Советлар Россиясе», «Зур Идел», «Тынычлык сагында» исемле күргәзмәләрдә, театр, кино һәм телевидение художникларының Бөтенсоюз күргәзмәсендә, Совет дәүләтенең һәм ВЛКСМның 50 еллыгына багышланган күргәзмәләрдә катнаштылар. Алар кулы белән эшләнгән сынлы сәнгать әсәрләре һәркайда югары бәя алды. Татарстан художниклар союзы председателе Харис Якупов пленумда катнашучыларны республикабыз рәссамнарының соңгы елларда иҗат иткән яңа әсәрләре белән таныштырды, совет художниклары алдында торган мактаулы һәм җаваплы бурычлар турында сөйләде.

Докладлардан соң фикер алышулар башланды. Фикер алышуларда ике дистәгә якын кеше катнашты. Алар докладчылар тарафыннан күтәрелгән мәсьәләләрне тагын да конкретлаштыра һәм тулыландыра төштеләр. Беренче булып шагыйрь Сибгат Хәким сүз алды. «Ленин исеме,— диде ул,— минем үз республикам каршындагы конкрет үзгәрешләр аша үтеп керде. Ленин тәгълиматы мине тормыш һәм әдәби күренешләрне бәяләүдә масштаблылыкка, кыюлыкка һәм принципиальлеккә өйрәтте. Минем халкымның күңелендә юлбашчыга карата олы хөрмәт хисләре яшәп килә. Ул хисләр үзләре үк җырга һәм поэмаларга, повесть һәм романнарга күчерүне сорап торалар».

Композитор Җәүдәт Фәйзи музыка сәнгатебез, аерым алганда, опера һәм балет әсәрләре турында сөйләде. Музыкаль сәхнә әсәрләре тудыруда һәм татар музыкасын пропагандалауда Муса Җәлил исе-

мендәге опера һәм балет театрының зур ролен билгеләп үтте, хәзер әнә шул бик кирәкле эшнең шактый йомшара төшүен әйтте.

— В. И. Ленинның 100 еллык бәйрәме,— диде Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Мөнирә Булатова,— безне репертуарны яхшырту буенча җитди эшләр башкарырга чакыра. Театрларга югары сыйфатлы пьесалар, Ленин идеяләренең тантанасын ачык һәм ышандырырлык итеп күрсәткән сәнгать әсәрләре кирәк. Безгә тормышны раслаучан оптимизм белән сугарылган, халкыбызның батырлыгына дан җырлаган әйбәт пьесалар кирәк.

Сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга барлык совет халкының, бөтен дөнья хезмәт ияләренең хөрмәте һәм мәхәббәте чиксез зур. Үзенең шул мәхәббәт хисен халык әдәби иҗатында гәүдәләндергән. Төрле илләрдә, төрле телләрдә иҗат ителгән шул байлыкның шактый өлеше белән татар укучылары хәзер үз ана телебездә таныша алалар. Татарстан китап нәшрияты бөек бәйрәмгә татарча ленинчананың 4 томын бастырып чыгарды. Бу эш киләчәктә дә дәвам итәчәк. «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури татарча ленинчананы тагын да тулыландыру белән бәйле мәсьәләләр хакында сөйләде.

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының директоры Рәшидә Җиһаншина пленумда катнашучыларны юбилей елында куелачак сәхнә әсәрләре һәм театрның иҗат планнары белән таныштырды.

Архитектор М. Х. Агишев Казанның архитектура йөзе, Татарстан архитекторлары һәм художниклар алдында торган мөһим бурычлар турында сөйләде.

Фикер алышуларда шулай ук Качалов исемендәге Рус драма театры артисты Е. Кузин, Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе М. Нигъмәтҗанов, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының баш дирижеры Ф. Мансуров, язучы Н. Дәүли, Татар дәүләт академия театры художнигы Ә. Тумашев, Казан дәүләт консерваториясе укытучысы Г. Ходжаев, тәнкыйтьче Р. Мостафин, Казан киностудиясе редакторы М. Хөснимәрданов, сәнгать белгече Л. Елькович иптәшләр катнашты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев пленумда зур речь белән чыкты. Пленумда катнашучылар барлык сәнгать кешеләрен тагын да активрак иҗат итәргә чакырган карар кабул иттеләр.

## ЛЕНИН ҺӘМ МАТБУГАТ

Январь урталарында КПСС өлкә комитетының политик мәгариф йортында республика журналистларының «Ленин һәм матбугат» дигән темага фәнни-теоретик семинары булып узды. Бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган ул семинарны КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге, Татарстан журналистлар союзы һәм Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы оештырган иде. Семинар эшендә, Татарстанда чыга торган газета-журналларның хезмәткәрләреннән тыш, Мари, Мордовия, Удмуртия, Чувашия һәм Башкортстан автономияле республикаларының, шулай ук Мәскәү һәм Ульяновск шәһәрләренең журналистлары да катнашты.

Теоретик семинарда катнашучылар В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының КПСС тарихы кафедрасы мөдире Р. И. Нәфиковның «В. И. Ленин тормышының һәм эшчәнлегенең Казан чоры», Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе С. Г. Батыевның «Ленинчыл милли политиканың тантанасы», КПСС Үзәк Комитеты янындагы Иҗтимагый фәннәр академиясе доценты М. С. Черепаховның «В. И. Ленин һәм публицистикада анализ мәсьәләләре», шул ук академия аспиранты Ф. И. Әгъзамовның «Ленин һәм милли матбугат», Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы мөдире Л. Г. Юдкевичның «Ленинның чагылыш теориясе яктылыгында журналистика», шул ук кафедра доценты Г. Кашшафның «Татар журналистикасы үсешендә Ленин идеяләренең роле» һәм СССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитетының фәнни-методик бүлеге мөдире В. Н. Ружниковның «Ленин һәм радио» исемле докладларын тыңладылар.

Семинар көннәрендә шулай ук хәзерге заман очеркы, аның үсеш тенденцияләре һәм актуаль мәсьәләләре хакында җитди сөйләшү булды. Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда «Наш современник» журналының баш редактор урынбасары В. Чалмаев, Мәскәү журналисты М. Шур, Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы укытучылары Г. Кашшаф һәм Л. Пивоварова, язучы Б. Камал, СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Ф. Мусин, Татарстан журналистлар союзы каршындагы очеркистлар секциясе җитәкчесе М. Әхмәтҗанов, журналист Б. Марихин һәм башкалар катнашты.

Соңыннан журналистлар республиканың җитәкче работниклары белән очраштылар. Алар алдында Татарстан АССРның Культура министры Б. М. Гыйзззәтуллин, Мәгариф министры М. И. Мәхмүтов, Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрының урынбасары М. С. Гуревич, Сәүдә министры И. А. Ташбулатов, Казан шәһәр советы башкарма комитеты председателе А. И. Бондаренко һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән журналистлар Казан шәһәренең В. И. Ленин исеме белән бәйле истәлекле урыннарында булдылар.

## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 70 ЯШЬ

Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Нәкый ага Исәнбәтне кемнәр генә белми икән! Аның берсеннән-берсе матур-рак җырларын, шигырь һәм поэмаларын укымаган, ул иҗат иткән үткен комедияләр, тирән дулкынландырырлык драмалар, җанны тетрәтерлек трагедияләр буенча куелган спектакльләрне карап сокланмаган кешеләр, ихтимал, сирәктер. Болардан тыш, ул әле күренекле тарихчы һәм этнограф, әдәби тел һәм әдәбият тарихы галиме, атаклы фольклорчы да. Татар халык мәкальләренең Нәкый Исәнбәт туплап чыгарган өч томлык китабы культурабыз үсешенә зур хәзинә булып керде. Менә шуңа күрә дә Нәкый ага Исәнбәтнең 70 еллык бәйрәме республикабызның авылларында, районнарында һәм шәһәрләрендә, шулай ук тугандаш республикаларда зур итеп, киң күләмдә билгеләп үтелде. Татарстанда чыга торган газета-журналларда һәм тугандаш халыклар матбугатында аның иҗаты турында язылган мәкаләләр басылды, радио һәм телевидение буенча күп санлы тапшырулар оештырылды, югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә, клубларда һәм китапханәләрдә, культура сарайларында, аның иҗатына багышлап, әдәби кичәләр, тантаналы җыелышлар уздырылды.

* * *

Казан шәһәре хезмәт ияләренең Нәкый Исәнбәткә 70 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында уздырылды. Анда республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол һәм иҗат оешмалары вәкилләре, эшчеләр һәм студентлар, шулай ук илебезнең төрле почмакларыннан килгән кунаклар катнашты.

Тантаналы кичәне, Нәкый Исәнбәтнең иҗаты турында кыскача кереш сүз сөйләп, язучы Мирсәй Әмир ачты. Язучы һәм тәнкыйтьче Гази Кашшаф әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турында доклад ясады. КПССның Татарстан өлкә комитеты, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Татарстан АССР министрлар Советы исеменнән юбилярны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев котлады. Котлау сүзләре белән шулай ук Башкорт дәүләт университеты проректоры Мидхәт Гайнуллин, танылган казакъ язучысы Тимергали Мортазин, Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Хәмзә премиясе лауреаты Назир Сафаров, әзербайҗан язучысы Айваз Айвазов, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Камалиев һәм башкалар чыкты. Юбиляр исеменә киң илебезнең бик күп почмакларыннан телеграммалар һәм котлау хатлары килгән иде.

Соңыннан Нәкый Исәнбәт әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, республикабызның сәнгать осталары көче белән концерт бирелде. Концертта юбилярның шигырьләре укылды, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

* * *

22 декабрьдә Түбән Кама шәһәренең «Нефтехимик» клубында Нәкый Исәнбәткә 70 яшь тулуга багышланган тантаналы юбилей кичәсе уздырылды. Анда әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад сөйләнде. Соңыннан зур концерт бирелде.

* * *

Декабрь ахырларында Әлмәт шәһәренең Техника йортында Нәкый Исәнбәткә 70 яшь тулуга багышланган кичә уздырылды.

* * *

Шундый ук кичә Пермь өлкәсенең Барда район Культура йортында да уздырылды. Район мәгариф бүлеге эшчесе Нәзһәт Зимасов әдипнең тормыш юлы һәм әсәрләре турында сөйләде. Кичәнең икенче бүлегендә «Тан» газетасы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәк членнары һәм үзешчәннәр көче белән концерт бирелде.

* * *

Нәкый Исәнбәт иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә 16 январьда Актерлар йортында да уздырылды. Кичәдә әдипнең шигырьләре укылды, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

* * *

Совет әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумы язучы Нәкый Исәнбәтне Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде.

## ҖӘҮДӘТ ФӘЙЗИГӘ — ОРДЕН

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумы композитор Җәүдәт Фәйзине Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде.

## ЯКТАШЫБЫЗ — ФӘН ДОКТОРЫ

Ленинград дәүләт университетының Шәрык факультеты укытучысы Габдрахман ага Таһирҗанов иран, төрки һәм гарәп филологиясе буенча язылган хезмәтләре белән фәндә үз сүзен әйткән галим.

Соңгы елларда Габдрахман ага IX—X гасырларда яшәгән бөек фарсы шагыйре Рудәки хакында тикшеренүләр алып барды. Фарсы, гарәп, рус, инглиз, француз, немец, үзбәк, таҗик һәм башка телләрдәге бик күп төрле һәм каршылыклы чыганакларны өйрәнү нәтиҗәсе буларак, аның «Рудаки. Жизнь и творчество. История изучения» дигән полемик рухлы, гаять үзенчәлекле һәм җитди хезмәте басылып чыкты.

11 декабрьдә Шәрык факультетының Гыйльми советында бу китапны диссертация итеп яклау булды. Фәнни оппонентларын-

нан И. С. Брагинский, Д. Кобидзе, И. П. Петрушевский кебек зур галимнәр һәм бүтән чыгыш ясаучылар хезмәткә зур бәя бирделәр, аның Рудәки турындагы бу тикшеренүенең бөек шагыйрьне өйрәнүдә дөнья әдәбият фәнендә яңа бер этап булуын билгеләп киттеләр.

Гыйльми совет якташыбыз Габдрахман Таһирович Таһирҗановка филология фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗә бирү турында бер тавыштан карар кабул итте.

### ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Баку шәһәр советы башкарма комитеты Нәриман районындагы Икенче Төньяк урамының исемен үзгәртү турында карар кабул итте. Аңа татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай исеме бирелде.

## ИСМӘГЫЙЛЬ РӘМИ

**Язучы һәм күренекле өлкән журналист Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев каты авырудан соң 28 декабрьда Казанда вафат булды.**

**И. Рәми 1895 елның беренче гыйнварында Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә туган.**

**Ул үзенең эшчәнлеген революциягә чаклы ук «Сәйяр» труппасында башлый. Октябрь социалистик революциясеннән соң, гражданнар сугышы елларында «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз», «Кызыл дөнья» исемле фронт газеталары редакцияләрендә актив эшләде, яшь Совет властен яклап, кызылармеецларны батырлыкларга рухландырып мәкаләләр, очерклар язды. Гражданнар сугышы тәмамлангач, Татарстан китап нәшриятында, «Яңалиф», «Чаян» журналлары редакцияләрендә, район газеталарында хезмәт итте.**

**Исмәгыйль Рәми күп кенә әдәби һәм публицистик әсәрләрнең авторы. Мәсәлән, безнең әдәбият һәм матбугат тарихын өйрәнү өчен зур әһәмияте булган «Вакытлы татар матбугаты. 1905—1925 еллар», «Татарча басма сүз. Истәлекләр» исемле китаплары, культура тарихыбызга багышланган күп санлы мәкаләләре, сатирик хикәя җыентыклары h. б. әсәрләре киң катлау укучыларга яхшы таныш.**

**Соңгы елларда И. Рәми, авыру булуына карамастан, татар әдәбияты һәм сәнгате тарихына бәйләнешле зур энциклопедик белешмәне тәмамлады.**

**И. Рәми татар әдәбиятын һәм басма сүз тарихын яхшы белүчеләрдән, классикларыбызның якын танышларыннан һәм дусларыннан берсе иде. Тирән белемле, хезмәт сөючән, тырыш, ачык йөзле язучы, талантлы журналист Исмәгыйль ага Рәми истәлеге безнең күңелләребездә мәңге сакланыр.**



ЗАҺИТ ХӘБИБУЛЛИН
музыкасы
НУРИ АРСЛАНОВ
сүзләре

# НӘСИМӘ

*Шаян җыр*

— Нәсимә,— дия, дия,
Теңкәңә тия, тия,
Язмыштан килгән чагым,
Утларда көйгән чагым,
Өзелеп сөйгән чагым...

Үзең сөймәсәң сөймә,
Минем сөюгә тимә,
Йөрәгем шулай тибә:
Нәсимә: «Сөймә»,— димә,
Нәсимә: «Сөймә»,— димә.

Бик моңсу миңа нигә?
Уйларымда син генә...
Әй син киләсең генә.
Нишлим, сөймәсәң сөймә,
Мин бик сөям, Нәсимә.

Эх... «Сөймим»,— димәсәнә,
Җаныма тимәсәнә...
Йөрәгем, көймәсәнә!
Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә,
Сөймәсәң сөймәсәнә.

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210